АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Татары Пермского края*

*Барда*

КАЗАНЬ · 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Пермь татарлары*

*Барда*

КАЗАН • 2017

УДК 39(470.41)+008(470.41)
ББК 70(2Р354)
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К.М. Миңнуллин** (рәис), **Д.Б. Рамазанова, М.Х. Вәлиев***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
***М.Р. Булатова***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Пермь татарлары. Барда.** – Казан, 2017. – 328 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унынчы китап).
ISBN 978-5-93091-209-8

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы бу китап Пермь крае, Барда районында яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, тарихи шәхесләргә багышланган язмалар урын алды. Шулай ук анда җирле халыкның авыз иҗаты, җыр-моңнары, осталарның кул эшләре, авыллар тарихы белән дә танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-209-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

# СҮЗ БАШЫ

Мәгълүм булганча, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарлар яшәгән төрле төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырып, халкыбызның миллимәдәни мирасын өйрәнү эшен дәвам итә. Әлеге чараның әһәмияте гаять зур: халкыбызның сөйләм телен, дөньяга карашын, рухи һәм матди мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын – барысын бергә туплап, бербөтен итеп өйрәнгәндә генә аның үткәнен тирәнрәк күзалларга, ерак гасырларга барып тоташкан тарихын, аерым төбәкләрдәге үзенчәлекләрен тагын да тулырак ачыкларга була.

Зур күләмле һәм төрле яклы өйрәнүләр халкыбызның тарихи ватанын күз алдына китерергә, музыка, сынлы сәнгать һәм башка өлкәләрдәге моңа кадәр читтәрәк калып килгән юнәлешләрне барларга мөмкинлек бирә. 2009 елдан оештырыла башлаган комплекслы экспедицияләр тарихында шактый бай тәҗрибә һәм күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирешелде. Шушы кыска гына вакыт аралыгында Институт, җирле төбәк җитәкчелеге белән берлектә, дистәдән артык китап чыгарып өлгерде. Иң әһәмиятлесе шул, басылып чыккан әлеге хезмәтләр фәндә дә, халык арасында да кызыксыну уятты һәм уңай бәяләнде.

Бу хезмәтләрдә Татарстанның Актаныш, Апас, Кукмара һ.б. районнарында, күрше Мари Эл, Удмуртия Республикаларында һәм Түбән Новгород, Оренбург,

Әстерхан, Омск һ.б. күп кенә өлкәләрдә яши торган татарлар турында бай мәгълүмат, тирән эчтәлекле тикшеренүләр урын алган.

Әнә шул эзлекле тикшеренүләрне дәвам итеп, 2013 елда Пермь краеның Барда төбәгенә дә (Сараш, Үдик, Әрәмә авыл, Түбән авыл, Бай авыл, I Әрҗән, II Әрҗән, Төнгүк, Күчтәнти, Танып, Каенавыл, Солтанай, Искер авылларына) комплекслы экспедиция оештырылды. Анда филология фәннәре докторы, профессор М.З. Зәкиев, филология фәннәре докторы, профессор М.И. Әхмәтҗанов, филология фәннәре докторы, профессор Д.Б. Рамазанова һәм филология фәннәре докторы Ф.С. Баязитова, филология фәннәре докторы Р.Ф. Исламов, шулай ук яшь галимнәребездән филология фәннәре кандидатлары И.И. Ямалтдинов, Р.М. Хөснетдинов һәм музыка белгече Э.М. Галимовалар катнашты.

Пермь татарлары–күпчелек галимнәребезнең фикеренчә, Казан татарларының этнографик төркеме. Аларның формалашуына төрки (татар, кыпчак, нугай һ.б.) һәм фин-угыр кабиләләре дә тәэсир иткәндер дип уйланыла. Әмма Пермь татарларының милли-мәдәни тормыш-көнкүрешенә Казан татарлары аеруча зур йогынты ясаган. Пермь сөйләше Д.Б. Рамазанова тарафыннан лингвистик география методы белән өйрәнелде, аның буенча микроатлас төзелде. Нәтиҗәдә, сөйләшнең диалекталь үзенчәлекләргә гаять бай икәне, әмма төп үзенчәлекләре буенча аның урта диалектка караган мөстәкыйль сөйләш булуы ачыкланды.

Барда төбәге мул сулы, риваятьләрдә сөйләнә, җырларда җырлана торган Тол елгасы һәм аның кушылдыклары буенда, бай табигать кочагында урнашкан. Әлеге төбәктә яшәүче милләттәшләребезнең ачык йөзле, киң күңелле, ярдәмчел, эшчән-уңган булулары, гыйльми сәяхәтчеләребезне моңлы, матур җырлары, уен-көлкегә бай иҗат әсәрләре белән бик теләп таныштырулары сокландырды.

Бу якларда тапкыр, зирәк фикерле, җор телле ир-егетләр, тәмле, йомшак сүзле әбиләр-апалар, уңган кызлар яши. Барда төбәгендә Бөек Ватан сугышы геройлары, хезмәт алдынгылары, язучылар, галимнәр, танылган композиторлар һәм җырчылар үсеп чыккан. Институтыбызның элеккеге хезмәткәре, фольклорчы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рәшит Ягъфәров, композитор, педагог Мәсгут Имашев кебек олпат шәхесләрне биргән бу төбәк.

Бардада үзләренең атаклы шәхесләрен зурлый беләләр, аларның исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан, бюстлар, истәлек такталары куела, мәктәпләрдә, мәдәният йортларында һәртөрле яд итү чаралары уздырыла. Менә шундый мәгърифәтле, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап, тагын да үстереп киләчәк буыннарга тапшыру теләге белән янып яши торган милләттәшләребез бар икәнен күрү, алар белән ныклап танышу-аралашу халкыбызның киләчәгенә өмет уята.

Әлеге китапта экспедициядә катнашкан белгечләрнең бай һәм кызыклы материаллары урын алды. Эпиграфик һәм археографик мирасны өйрәнү буенча танылган белгеч М.И. Әхмәтҗанов кабер ташларындагы язуларны укыды, Барда төбәге тарихы белән бәйле уникаль материаллар туплауга иреште.

Академик М.З. Зәкиев Барда төбәгендәге тел үзенчәлекләрен аларның ерак тарихы белән бәйләп күрсәтә, шушы территориядә һәм күрше республика яки өлкәләрдә алып барыла торган археологик казылмалар белән таныштыра.

Китапта Барда төбәгенең сөйләш үзенчәлекләренә багышланган күләмле мәкалә тәкъдим ителә. Аның авторы Д.Б. Рамазанова инде 50 елга якын Пермь крае татарларының сөйләшен өйрәнә. Шунысы характерлы, автор, халыкның теле аның тарихы белән турыдан-туры бәйләнгән, дигән карашны дәлилләп, Пермь татарларының тарихын да ныклап өйрәнә, Мәскәү, Уфа, Пермь архивларында күпсанлы документлар белән таныша, пермь сөйләшенең, шул исәптән Барда төбәгенең дә, тел үзенчәлекләрендә болгар чоры әдәби теле (мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» әсәре теле) белән уртак билгеләре булуын ачыклый. Татарстаннан читтә, башка халыклар чолганышында формалашуына карамастан, әлеге сөйләштә борынгы үзенчәлекләрнең тотрыклылыгын нигезли.

Ф.С. Баязитова күп еллар буе татар халкының рухи мәдәнияте, туй һәм көнкүреш йолаларын тикшерү белән шөгыльләнә, аның шушы юнәлештә дистәләрчә хезмәтләре дөнья күрде. Бу басмадагы мәкаләсе дә, гадәттәгечә, бай материал һәм кызыклы фактлары белән истә калыр.

Ф.Г. Гарипова – татарлар яшәгән төбәкләрнең топонимиясен һәм гидронимиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимә. Билгеле булганча, авыл, елга-су, урман-алан, тау-чокыр исемнәрендә, кыскасы, географик атамаларда халык тарихы, аның фикер галәме, иҗади

мөмкинлекләре чагыла. Кызганыч, аның үзенә бу китапны кулына алу бәхете генә насыйп булмады...

Р.Ф. Исламовның «Бардаларга бардык әле...» исемле язмасы экспедициянең тәфсилләп язылган көндәлеген хәтерләтә. Автор авыллар, аларның кызыклы кешеләре, мәчетләр, кабер ташлары, төрле басма һәм кулъязма китаплар турында сүз алып бара.

Музыка белгече Э.М. Галимова Пермь крае татарларының музыкасын өйрәнеп кандидатлык диссертациясе яклаган иде. Быелгы экспедициядә ул Барда төбәгенә хас музыкаль әсәрләр, уен коралларын тагын бер кат барлады һәм яңа язмалар да теркәде.

Барда төбәгенең сөяктән, агачтан чокып яки бүтән төрле әйберләр ясаучы осталары, татар түбәтәйләре һәм калфаклар чигүчеләре татар дөньясына күптән таныш инде. Өстәл җәймәләре, мендәр тышлары һ.б. чигү, челтәр бәйләү дә аларда электән үк киң таралган. Бу хәл киндер сугу терминологиясендә дә чагыла. Р. Хөснетдинов әлеге осталарның эшләре буенча күпсанлы фоторәсемнәр төшерде.

Экспедициядә катнашкан телче галимнәр, нәтиҗә ясап, барда сөйләше, һичшиксез, татар теленең урта диалектына караучы бер үзенчәлекле сөйләш, дигән фикерне үткәрәләр. Сәнгатьче, фольклорчы галимнәребез үз якларыннан бу фикерне раслыйлар.

Китап бай фактик материалга таянып язылган. Бу хәзинәне фәнни өйрәнү, милләттәшләребезнең рухи һәм матди иҗат җимешләрен басма сүз аша үзләренә кайтару – безнең изге бурычыбыз. Әлеге хезмәт татар тарихы, аның язма һәм рухи мирасы белән тирәннән кызыксынучылар өчен файдалы булыр, дип уйлыйбыз.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры*

# ТАШЛАРНЫҢ ДА ТАМЫРЫ БАР

*Марсель Әхмәтҗанов*

Пермь ягы татарларының мәдәни мирасын өйрәнү буенча Казан галимнәре шактый еллардан бирле эш алып баралар. Әлеге төбәккә оештырылган беренче археографик экспедиция 1963 елда Казан университеты студентлары катнашында Нил Юзиев җитәкчелегендә уздырыла. Бу экспедиция барышында йөзгә якын кулъязма китап табыла. Н.Г. Юзиев бу табышларны 1990 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы мирасханәгә тапшырды. Коллекциядә татар фольклоры һәм әдәбияты хәзинәләренә мөнәсәбәтле күп язмалар бар. Әлеге кулъязмаларга фәнни тасвирлама эшләнде һәм ул 2013 елда басылып чыкты (Кол. 39. № 4251–4152, 4254–4335)[1].

Пермь ягына икенче фәнни археографик экспедиция шулай ук Казан университеты студентлары катнашында Миркасыйм Госманов тарафыннан 1974 елны оештырылган иде. Көңгер, Урда, Уинск, Барда, Октябрь төбәкләрендә 500 ләп кулъязма китап тупланып, Казан университеты фәнни китапханәсенә кайтарып тапшырыла. Кызганычка каршы, бу китаплар әлегәчә тасвирланмаган. Миркасыйм ага аны үзе иң күп табышлар тупланган экспедиция дип бәяләде. «Каурый каләм эзеннән» исемле китабында М. Госманов Пермь якларында табылган борынгы язма истәлекләргә киң туктала[2].

---

[1] Ахметзянов М. Татарская археография описи рукописей, собранных во время археографических экспедиий (1972–2012 гг.). Казан, 2013. Часть третья. С. 104–139.

[2] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 40–41.

Диалектолог галимнәребездән Дария Рамазанова да бу якларда берничә мәртәбәләр булып, аларның тел үзенчәлекләрен тасвирлаган зур хезмәт язып бастырды[1].

Күчтәнти авылы егете Рәшит Ягъфәровның 1985 елда әлеге төбәктән кулъязмалар алып кайтып, Институт мирасханәсенә тапшырганы да онытылмый (Кол. 39. № 3500–3509, 3512–3514).

Безнең экспедиция исә комплексы булды, анда халык авыз иҗатын, музыкасын, сәнгатен, тел үзенчәлекләрен, археографиясен, эпиграфика культурасын өйрәнүче белгечләр катнашты. Экспедиция төркемендә, өлкән галимнәр белән бергә яшь галимнәрнең дә булуы күңелле күренеш иде.

Барда экспедициясен Институт дирекциясе һәм җирле җитәкчеләр яхшы итеп оештырды. Безгә консультант һәм халык белән очрашуларны тәэмин итүче итеп хөрмәтле Сәлим Назин билгеләнгән иде.

Ул Барданың күренекле кешеләре, атаклы урыннары белән танышырга мөмкинлек тудырды. Район хакимиятендә дә безнең белән очрашуга вакыт табып хөрмәт күрсәттеләр.

Минем өчен Барда татарларының туган телләренә кадерләп карауларын күрү үзе бер шатлык булды. Анда хәтта район администрациясенә эшкә килгән урыс милләтеннән булган хезмәткәрләр дә татарча сөйли, аңлаша алалар икән.

Бу як халкы үзләреннән чыккан атаклы кешеләргә дә хөрмәтен күрсәтә белә. Мәсәлән, алар Габдулла Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмировның (туган җире Бардада) авылдашлары булу белән горурланалар. Барда үзәгендәге мәйданда Тукайның затлы итеп эшләнгән бюсты урнаштырылган. Барда мәчетенең Зиннәтулла Әмиров нәселеннән килгән имамы Рафикъ хәзрәт Акманаев үзенең нәсел шәҗәрәсен язып, аны «Туган илем Кожамакты карьяседер...» исемле китабында Бардада бастырып та чыгарган[2]. Анда иң ерак баба итеп Бәгъдән мирза күрсәтелгән. Рафикъ хәзрәтнең шәҗәрәсе бүгенге Татарстанда яшәүче нәсел тармаклары белән дә туры киләләр. Хәзрәт безне Зиннәтулла бабасы йөргән болыннарга алып чыкты, аның йорт урынын да якынча хәтерлиләр икән.

---

[1] Рамазанова Д.Б. К истории формирования пермских татар. Казань, 1996. 239 с.

[2] Акманаев Р. Туган илем Кожамакты карьяседер... Барда, 2011. 67 б.

Барда төбәгендә Зиннәтулла баба кардәшләре – Әмировлар күп икән. Алардан бу якларда байтак кына имамнар да чыккан.

Рафикъ хәзрәт мәчете Барданың зур зираты янындагы бер тыныч почмакта, олы юлдан ерак булмаган җирдә урнашкан. Бик төзек, тирә-ягы да матур итеп әйләндереп алынган мәчет, яшькелт төскә буялган.

Барда ягының данлы егете, көрәшче һәм галим, журналист, фольклорчы Рәшит Ягъфәровның кабере дә Барда зиратында икән, без дә, аның кабере янына барып, мәрхүм рухына догаи сәламнәребезне җиткердек. Кызганыч, иртә китте ул якты дөньядан. Андый егетләр яшәсен дә яшәсен генә иде әле.

Экспедицион сәяхәтебезнең икенче көнендә без Сараш дигән авылга килдек. Бу авылда Бөек Ватан сугышында катнашып шәһит киткән Советлар Союзы герое Шәрифҗан Казанбаев туган икән. Авыл халкы аны онытмый. Геройга олы урамда бюст-һәйкәл куелган.

Безне Сарашның китапханәсендә каршы алдылар. Анда безнең белән очрашу өчен авылның тел осталары җыелды, чәйле өстәл янында матур гына аралашып утырдык. Мине, әлбәттә, ташбилгеләр культурасы кызыксындырды. Бу авылда бик зур, урман булып шаулап утыра торган ике зират бар. Аларның беренчесе авыл эчендә калган, икенчесе авылдан берничә йөз адым читтәрәк. Зиратларның читләре тотып алынган, эченә фәкать капка аша гына керергә мөмкин.

Барда төбәгендә күпчелек зиратларда моннан йөз еллар элек үк танылган кабер өсте корылмасы 12–15 см диаметрлы бүрәнәләрдән ясалган агач буралардан гыйбарәт. Аларның уртача озынлыгы – 240 см, киңлеге – 140–150 см, биеклеге – 110–120 см. Бура өстенә матчасыман бер бүрәнә дә салынган. Бүрәнәләр кабыкларыннан тазартылган, аскы баганалар таш өстенә утыртылган. Кабер өсте буралары янында ташбилгеләр юк. Кайбер зиратларда алар зәңгәр яки яшел төсләргә буяп куелган, стенасына мәрхүмнең исем-фамилиясе язылган librнакталар да беркетелгән. Буралар кору культурасы инде XX гасырның икенче яртысында ук сирәк күренеш була, Барда зиратларында да аларның яхшырак сакланганнары артык күп түгел.

Бураларга алмаш булып 1950 еллардан соң күренә башлаган агач рәшәткә чардуганнар килә. Рәшәткә чардуганнарның үрнәкләре әле соңгы елларда да, сирәк булса да, күренәләр, алар зәңгәр,

яшел төсләргә буялганнар. XX гасырның икенче яртысындагы рәшәткә чардуганнар күпчелек очракта буялмаганнар.

1970–80 елларда солдат каберләре өстенә куела торган металл арматурадан ясалган тумбалар модасы кыска вакытлы була.

XX йөзнең соңгы ун елларыннан татар зиратларындагы металл арматуралардан эшләгән чардуганнарның үрнәкләре Татарстан, Пермь, Рязань, Курган, Чиләбе һ.б. төбәкләрдә дә очрыйлар.

Асылда андый чардуганнарның күбесенең, эчке ягына кереп, кабер өстен чистартып йөрү бик кыен, чөнки аларның күбесендә капкалар эшләнмәгән. Соңгы елларда кайбер зиратлардагы арматура чардуганнарга кечкенә капкалар да ясап куя башлаганнар (мәсәлән, Татарстанның, Чүпрәле районы, Мөчәли авылы зиратында һ.б. җирләрдә). Бу яхшы күренеш.

Бу уңайдан тагын бер фикер яши: татар зиратларында күп гасырлар буе (XVIII йөзгә кадәр диярлек) чардуганнар бик корылмаган. Кабер араларында йөрү җиңел булган. Бүген каберләрне бик тыгыз казыйлар, алар арасыннан йөрү дә кыен. Бу очракта хәлне беркадәр җиңеләйтү өчен каберләрнең баш очындагы ташбилгегә өстәп якякларына кирпечтән стеналар өеп, чәчәклек ясап куярга булла. Алар арасында тиешле киңлектә сукмаклар да калдырылса, ул каберләрне саклау өчен дә, төзәтү өчен дә уңайлы булыр.

Тагын бер тәкъдим: зират ташбилгеләренә мәрхүмнәрнең фотосурәтләрен кую безнең бабаларның борынгы традицияләренә каршы килә. Зиратларда ташбилгеләрдәге фотопортретлар анда килгән кешеләргә тискәре тәэсир ясый, аларның кәефен кыра.

Без Сараш авылы зиратларында һәм Барда төбәгендәге тагын 13 авылның 18 зиратында булып, ахирәт йортларын карадык, аларны саклап, чистартып, матур итеп тоту буенча үзебезнең тәкъдимнәребезне җиткерәбез, бәлкем аларны зират караучылар да истә тотып уйланырлар әле дигән фикердә калабыз.

2013 елның 4–10 июль көннәрендә мин Пермь краеның Барда төбәгендәге өйрәнгән Барда, Сараш, Үдик, Әрәмә, Искер, Каенавыл, Бакча, Байавыл (Куземьярово), I Әрҗән, II Әрҗән, Төнгүк, Күчтәнти, Танып, Солтанай дигән татар авылларында булып, күп кенә мәгълүматлар алдым. Әлеге авыллар зиратларындагы ташбилгеләр саны түбәндәгечә:

| Зиратлар | Ташбилгеләр саны |
|---|---|
| Барда зираты | 18 |
| Сарашның беренче зираты | 23 |
| Сарашның икенче зираты | 18 |
| Үдикнең беренче зираты | 7 |
| Үдикнең икенче зираты | 4 |
| Әрмәнең беренче зираты | 2 |
| Әрмәнең икенче зираты | 1 |
| Искер зираты | 12 |
| Байавылның беренче зираты | 8 |
| Байавылның икенче зираты | 1 |
| Каенавыл зираты | + |
| Төнгүк зираты | + |
| I Әрҗән зираты | + |
| II Әрҗән зираты | + |
| Күчәнти зираты | + |
| Таныпның беренче зираты | 5 |
| Таныпның икенче зираты | 1 |
| Солтанай зираты | 4 |

## Шәҗәрәләр һәм кулъязмалар

Төбәкнең узган гасырларда ук тарихи шәҗәрәләре булган, аларда татар халкының Алтын Урда һәм Казан ханлыклары дәверләрендәге тарихларына бәйле мәгълүматлар бар. Мин аларны «Татар шәҗәрәләре» китабының беренче томында махсус бүлектә туплап биргән идем. Бу баруда инде Барда төбәгендәге татар җәмгыятендә шәҗәрә традициясенең сакланышын ачыклау максатын күз алдында тотылды. Максатыма ирештем, дип әйтергә була. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның Зиннәтулла бабасы Барда ягыннан булуы турында әйтеп үткән идем инде. Ул хакта заманында һәвәскәр тарихчы Әмир Фатыйхов белән дә фикерләшкән идек. Барда җирлегендә Зиннәтулла бабайның бүгенге көннәргә җиткерелгән язма шәҗәрәсе белән очрашырга туры килде. Аны Рафикъ хәзрәт

Акманаев төзегән һәм аерым китап рәвешендә бастырып та чыгарган. Рафикъ хәзрәт бу китабын култамгасы белән бүләк итте. Ул зат баба нәселе буенча күп мәгълүмат туплаган.

Каенавылда борынгы морзалар нәселеннән булган Сакаевлар яшәгәнен белдек, аларның иң өлкән вәкилләреннән Рәшидә ханым Сакаева белән очраштык. Рәшидә ханым үз нәселләренең шәҗәрәсен төзегән. Аның күчермәсен дә алдык. Рәшидә ханым тагын туганнары Мөхсиневләр һәм Искәндәровларның да шәҗәрәләрен төзегән.

II Әрҗән авылы клубында да зур итеп эшләнгән Шәфикъ Рангулов нәселе шәҗәрәсенең бизәкле, төсле итеп ясалган текстын күрдем. Бик борынгыга китмәсә дә, ул да Барда якларында шәҗәрә традициясе саклануның матур үрнәге булып тора.

Барда төбәгендәге экспедициядә минем төп тикшерү объектым ташбилгеләр булганлыктан, кулъязмалар эзләү буенча күп йөри алмадым, ләкин, шулай да, 20 ләп язма истәлек таптым. Алар да фәнни яктан тасвирланыр, дип уйлыйм.

Экспедиция барышында Бакча авылыннан имам Назиф Балтаев, кулъязмалар эзләп йөргәнне ишетеп, мин Каенавыл зиратында йөргәндә, гарәп язуындагы бер кочак китап күтәреп килгән иде, рәхмәт яусын аңа бу эше өчен. Шул хәзинә арасыннан өч кулъязма китап аеруча кызыклы булып чыкты. Барда төбәгендә мираска карата шундый сакчыл затлар яшәве күңелне сөендерде.

## Ташбилгеләр

### Сарашның беренче зираты

№ 1. Агач рәшәткәдән ясалган, соры төскә буялган чардуган. Үлчәмнәре: 154×214 см, биеклеге – 135 см. Ул Батыров Гарифулла (1933–2004) кабере өстенә куелган. Чардуган рәшәткәсенә 16×22 см зурлыктагы корыч пластинкага, уеп, кириллицада мәрхүм турындагы мәгълүмат язылган.

№ 2. Металл арматурадан ясалган чардуган. Үлчәмнәре – 104x210 см, биеклеге – 114 см. Зәңгәр төскә буялган. Мәрмәр ватыгыннан ясалган эпиграфик ташбилге. Аның тимпанында гарәп хәрефләре белән иман кәлимәсе язылган, аның өстендәрәк, уеп, ярымай силуэты эшләнгән. Ташбилгегә хәзерге язмада «Казанба-

ев Данил Рафаил улы. 1969–30.II.2006» дип уеп язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре 7×35×70 см. Йөзлегенә мәрхүмнең фоторәсеме куелган.

№ 3. Металл арматурадан гади генә итеп ясалган чардуган. Үлчәмнәре – 145×212 см, биеклеге – 122 см. Карасу төскә буялган.

Чардуган дүрт почмагыннан металл трубадан ясалган дүрт баганага таянып тора. Багана башларына, металлдан кисеп, ярымай силуэтлары урнаштырылган. Кабер өстенә тәбәнәк кенә итеп (ике кирпеч калынлыгында) турыпочмаклы кысалар рәвешендә чәчәклек эшләнгән. Мәрхүмнең башы турысына кара мәрмәрдән ясалган турыпочмаклы ташбилге утыртылган. Ташбилге йөзлекнең өске өлешендә сул почмакка – ярымай, уң почмакка биш почмаклы йолдыз силуэты эшләнгән. Астарак овал формадагы түгәрәк эченә мәрхүмнең портреты куелган. Овалның биеклеге 16–17 см зурлыкта. Портреттан бераз «Рангулов Муллаҗан Миннибай улы (23.02.1921–16.12.2012) Участник битвы под Курском» диеп язылган. Ташбилге бер катлы басма өстенә ныгытылган.

№ 4. Зәңгәр төстәге чардуган, арматурадан эшләнгән. Чардуган эчендә мәрмәр ватыгыннан эшләнгән, мәчет сурәте төшерелгән ташбилге. Язмалары кыйпылып төшкән.

№ 5. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның эчендә металл пластинкалардан эшләнгән байраксыман эпитафик һәйкәл, ул ике катлы басмада тора.

Чардуганның тышкы ягында мәрхүмнең баш очында мәрмәр валчыгыннан эшләнгән ташбилге, күк төстә. Ташбилге йөзлегенең кырларындагы сызык кысалар, почмакларда төеннәр ясап, югары күтәрелә һәм типманда төрле милли график бизәкләр рәвешенә керә. Бизәкнең уртасыннан 6–7 см түбәндәрәк ярымай силуэты ясалган. Ярымайдан 6–7 см түбәндә гарәп графикасында иман кәлимәсе китерелә. Аннан пөхтә, матур стильдә хәзерге татар әлифендә мәрхүм турында мәгълүмат бирелә:

«Таразов Равил Нургали улы. 03.03.1967–01.04.1993.
Урының җәннәтнең
түрендә булсын.»
Ташбилге бер баскычлы басмага ныгытылган.

№ 6. Арматурадан эшләнгән карасу зәңгәр төстәге чардуган. Ташбилгесе юк. Чардуганның стенасына, 14×30 см зурлыгындагы

корыч пластинкага, уеп, «Тимганов Фаил Хәмит улы. 25.X.1964–26.XII.2007» дип язылган.

№ 7. Арматурадан эшләнгән карасу зәңгәр төстәге чардуган. Чардуган эчендә мәрмәр валчыгыннан ясалган дүртпочмаклы ташбилге. Аның үлчәмнәре – 7×50×90 см.

Ташбилгенең өске, сул як почмагында ярымай сурәте төшерелгән, овал пластинка кыса эченә мәрхүмәнең фотосурәте урнаштырылган. Үлчәмнәре 8х15 см чамасындагы зурлыкта.

Портрет астында: «Габдерәшитова-Таразова Саҗидә Гайсә кызы. 14.06.1922–20.12.2005» дип язылган.

№ 8. Арматурадан эшләнгән чардуган эчендә мәрмәр ватыкларыннан тупланган турыпочмаклы ташбилге. Үлчәмнәре – 7×40×60 см.

Йөзлекнең сул ягында – ярымай сурәте, уң ягында мәрхүмәнең 7×15 см овал эчендә фотосурәте бирелгән. Ярымай астында агач ботагына кунган пар күгәрчен сурәте күпертеп ясалган. Астарак «Таразова Хадича Мостафа кызы. 28.08.1916–.... 2004» дип язылган.

№ 9. Арматурадан эшләнгән карасу зәңгәр төскә буялган чардуган эчендә турыпочмаклы ташбилге куелган. Аның сул як почмагында мәрхүмнең фотосурәте урнаштырылган. Уң як почмакта ярымай сурәте күпертеп ясалган.

Портреттан 15–20 см астарак эпитафик текст бирелә. Анда «Таразов Шамиль Кәлим улы. 1950–2005» дип уеп язылган. Язма тексттан өстә матур гөл яфраклары контурлары төшерелгән.

№ 10. Арматурадан эшләнгән зәңгәр төстәге чардуган. Аның эчендәге турыпочмаклы чәчәклекнең мәрхүм башы турысында мәрмәрдән эшләнгән ташбилге. Ул бер катлы басмага ныгытылган. Ташбилгенең өске ягы көянтәсыман итеп ясалган. Тимпанда аксыл дүртпочмак эчендә ярымай сурәте төшерелгән. Аннан аста «Таразов Шархумулла Хөсәен улы. 20.02.1925–14.03.2010» дип язылган.

№ 11. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган эчендә металл пластинкалардан эшләнгән, кара төскә буялган эпитафик һәйкәл куелган. Аның тимпан ягы көянтәсыман дугаланып ясалган. Ташбилгенең йөзлегендә аксыл пластинкага «Дусаков Ринат Заудатович, 1979–2010» диеп язылган. Әлеге билге бер баскычлы басмага ныгытылган.

№ 12. Зәңгәр төстәге арматурадан эшләнгән чардуган. Чардуганның стеналары ныгытылган, трубадан эшләнгән почмак баганалары очына ярымай силуэтлары ныгытып куелган. Чардуганның эчке

ягында, мәрхүмнең баш очында мәрмәр ватыкларыннан декоратив бизәкләр белән зиннәтләнгән ташбилге тора.

Аның тимпан очында ярымай сурәте. Аннан аста, сул якта – мәрхүмнең овал фотосурәте, уң ягында ике мәчет манарасы ясалган. Алар астына иман кәлимәсе язылган.

Түбәндәрәк мәрмәр плитәне уеп «Муратов Ринат Нигматулла улы. 22.VIII.1940 – 27.II. 2009» дип язылган.

Эпитафик билге бер баскычлы күтәртмә өстенә ныгытып утыртылган.

№ 13. Мәрмәр ватыгыннан коелган ташбилге. Тимпанда –ярымай һәм аның астында – мәрхүмнең портреты. Астына «Казанбаев Мәтдин Нажа улы (1908–1992)» дип язылган.

№ 14. Мәрмәр ватыгыннан коеп утыртылган ташбилге. Тимпанда ярымай силуэты һәм аның астында, гарәп язуында, иман кәлимәсе бирелгән. Мәрхүмәнең исеме – «Казанбаева Сафия Мөхәммәтҗар мулла кызы, 1907–1992» дип күрсәтелгән.

№ 15. Ташбилгегә «Савинова (Таразова) Хәдичә Хөппухуҗа кызы. 18.01.1906 – 15.12.2008» дип язылган.

№ 16. Мәрмәр ватыгыннан коеп эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 2,5×40×60 см. «Тимганов Рәфхәт Миниәхмәт улы. 29.XI.1929–2.VIII.2003» дип язылган.

№ 17. Ташбилгегә «Казин Ильдус Ильфаиль улы, 1952–2012» дип язылган.

№ 18. Ташбилгегә мәрхүм «Абукаева Тагазима Шархум кызы, 1952» дип язылган.

№ 19. Ташбилгегә «Таразов Хәниф Хәбиб улы, 1924–2009» дип язылган.

№ 20. Мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән ташбилгенең, йөзлегенә мәчет манарасы, ярымай силуэты ясалган һәм мәрхүмәнең фотосүрәте күчермәсе төшерелгән. Астына «Масагутова Сакине Шарифулла кызы, 1924–2005» дип язылган.

№ 21. Мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән ташбилге. Анда да ярымай силуэты, фотосурәт күчермәсе ясалган. Мәрхүмнең һәйкәленә «Таразов А... рах... Габдрахман улы, 1924–2001» дип язылган.

№ 22. Зиратта XX гасырда корылган бер гаҗәп төрбә бар. Ул – түгәрәк рәвешендәге корылма, анда түгәрәк буенча җирдән күренгән өлеше 38×38×160 см биеклектә булган баганалар ясалган.

Алар дүрт катлы кирпеч нигезләр белән бер-берсенә тоташалар. Баганалар өстән дә араталарга сугылган рәшәткәләр белән үзара тоташалар. Төрбәнең кем, ни өчен корганын әйтә алучы булмады. Янында язулар да юк иде, кирпеч баганалар аралары төрлечә: 237, 262, 314, 325 см һ.б.

№ 23. Сараш зиратының икенче башында традицион буралар да очрады. Алар бишәр ниргә рәвешендә өелгән корылмалардан гыйбарәт. Өсләренә матча рәвешендә бер бүрәнә дә куелган.

## Сарашның икенче зираты

№ 1. Арматурадан эшләнгән чардуган, зәңгәр төскә буялган. Үлчәмнәре – 120х220 см, биеклеге – 138 см.

Эпиграфик текст, кечкенә овал пластинкага язылып, чардуган стенасына беркетелгән. Аның тексты «Батыркиева Хөмәйрә Нәзи кызы. 15.01.1931–21.05.2002.»

№ 2. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның почмакларындагы торба баганаларның башларына ярымай силуэтлары утыртылган. Чардуганның эчендә мәрхүм башы турысына мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән ташбилге утыртылган. Аның түбәсе дугаланып тора.

Ташбилгенең йөзлеге декоратив бизәкләр белән зиннәтләнгән. Аның оч ягында, тимпанда ярымай силуэты уеп ясалган. Ташбилгенең сул як өске почмагына Аллаһ исемнәре төшерелгән. Урта һәм уң канатында мәчет, манара сурәтләре бар. Алар астында мәрхүмәнең исем-ыруы, яшәгән еллары язылган «Айтакова Әлфинә Мулламәхәмәт кызы, 1963–2007».

Ташбилге бер баскычлы басмага ныгытып утыртылган.

№ 3. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Үлчәмнәре – 127×218×110 см.

Кара мәрмәрдән шомартып ясалган турыпочмаклы ташбилге, үлчәмнәре – 8×40×80 см. Ташбилгенең сул ягында өстәге почмагында ярымай силуэты урнашкан, тимпан эзе монда күренми. Өстән 30 см түбәндә эпиграфик текст рус теле кысаларында башкарылган: «Тимганов Мулламухамат Тамимдарович, 13.03.1937–18.04.2002».

№ 4. Ташбилгедә «Мансуров Хәмидулла Нажмутдин улы, 1938–2003».

№ 5. Ташбилгедә «Мансурова Әдибә Нәзи кызы, 1943–2009». Ташбилгенең тимпанында ярымай силуэты бар.

№ 6. Тимпанда ярымай, аннан түбәндә мәрхүмнең портреты куелган. Кара мәрмәрдән шомартып ясалган ташбилгедә «Мансуров Даниль Галим улы, 1978–2009» дип язылган.

№ 7. Мәрмәр ватыгыннан коеп эшләнгән ташбилге. Аның йөзлегендә, тимпанда ярымай символы, аның астында иман кәлимәсе, аннан түбәндә мәрхүмнең портреты күчермәсе төшерелгән.

№ 8. Мәрмәр ватыгыннан коеп эшләнгән ташбилге, аның тимпанында сул почмагында ярымай символы һәм мәрхүмнең портретының күчермәсе.

№ 9. Ташбилге тимпанында ярымай символы. Эпитафик текст: «Ижбулатова Нәсимә Сәлим кызы, 1924–2005».

№ 10. Ташбилге тексты: «Батырова Закирә Гарибҗан кызы, 1934–2012».

№ 11. «Тякина Вәзифә Фархатша кызы, 1931–2012».

№ 12. «Касимов Наил Хәкимович, 1948–2012».

№ 13. «Таразова Сөгдә Хәлим кызы, 1931–2009».

№ 14. «Тимганова Мөнирә Шәрифулла кызы, 1930–2009».

№ 15. «Аксаметов Наиль Нәзи улы, 1950–2011».

№ 16. «Алимова Миннегалимә Габдрахман кызы, 1918–2011».

№ 17. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән ташбилге. Йөзлеге декоратив бизәкләр белән зиннәтләнгән. Бу тип һәйкәл үзенең архитектур формасы белән Казан ханлыгы чоры ташбилгеләренә охшый. Аның сул яктагы тимпан мәйданы астына мәрхүмәнең сурәте күчермәсе урнаштырылган. Уң яктагы тимпан мәйданы астына мәчет манаралары сурәтләре ясалган. Сурәтләр астына бер юл Коръән кәлимәсе язылган. Аннан астарак мәрхүмә хакында мәгълүматлар бирелгән «Муратова Саҗидә Ибраһим кызы, 01.08.19... – ...05.2009». Ташбилге бер баскычлы басмага беркетелгән.

№ 18. Арматурадан ясалган, ак төскә буялган чардуган. Аның эчке ягына мәрхүмнең баш очына кара мәрмәрдән турыпочмаклык рәвешендә шомартып ясалган ташбилге куелган. Йөзлегенең өске сул як почмагына – ярымай символы, уң як почмагына биш почмаклы йолдыз урнаштырылган. Өске якта, тимпан астына мәрхүмнең сурәте күчермәсе ясалган. Сурәт астында «Касыймов Хәким Гаптелҗан улы, 15.01.1923–23.09.2010» дип язылган. Язма астына

яфраклы агач ботагы рәсеме төшерелгән. Ташбилге бер баскычлы басмага ныгытылган.

№ 19. Арматурадан эшләнгән, матур яшел төскә буялган чардуган. Чардуган үзенең билгеләгән мәйданыннан 15 см чамасы һәр ягыннан чыгып торган таш мәйданчык өстенә куелган. Стеналарга терәк булып торган труба баганаларының югары очларына шар формасындагы бизәк тә беркетелгән.

Чардуганның эчке ягында ташбилгедән 10 см. га киңрәк булган чәчәклек урыны ясалган. Чәчәклекнең читләре хәйран гына күтәртелгән, аңа кара туфрак салынган. Ташбилге шактый катлаулы композиция тәшкил итә. Аның түбә ягында шартлы мәчет гөмбәзе, ярымай символы һәм катлаулы стильдә иман кәлимәсе язылган. Йөзлегенең өске ягына таба мәрхүмнең зур портреты куелган. Портрет астында русчалап «Батыров Рашид Закиевич, 28.12.1972 – 18.12.2011» дип язылган.

№ 20. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның эчендә байрак тибында металлдан эшләнгән кара төстәге һәйкәл тора. Ташбилгенең биегрәк булып торган сул почмагына алтын ярымай символын күпертеп ясап куйганнар. Һәйкәл йөзлегенең уртасыннан югары ягында зур алтын боҗра мотивын күпертеп ясап, аны чәчәкләр белән бизәгән рәвешкә китергәннәр. Аннан аста мәрхүмә турында татарча мәгълүматлар, аерым аксыл плитәгә язылып, ташбилге йөзлегенә шөрепләр белән беркетелгән. Һәйкәл бер баскычлы басма өстенә ныгытылган. Анда «Мусалева Мөнирә Шаймагусум кызы, 1941.15. IX. – 12.01.2013» дип язылган.

## Үдик (Елпачиха) авылының беренче зираты

Үдик – зур татар авылы, мәчете дә бар. Анда ике зират тора. Беренче зират (борынгысы) – авылдан 600–700 метр чамасы читтә.

Зиратның төп зур капкасы урман эченә кергән юл буенда, юлның бер кырыеннан – урман, икенче кырыенда агачлар үскән чокыр уза.

Зур капкадан кереп, сукмактан йөз адымлап баргач, уң якка борылып, ун-унбиш метрлар күтәрелгәч, агачлар арасында борынгырак (XIX йөз) каберләре күренә.

Зиратның зур капкасына җиткәнче, уң яктагы кырында, сирәк кенә агачлар үскән яланда соңгырак чор каберләре тезе-

леп киткән. Өсләренә, нигездә, арматурадан ясалган чардуганнар утыртылган.

Зиратның ялан ягында агач рәшәткәләрдән ясалган, коңгырт төскә буялган чардуганнар күренә.

Үдик зиратында әлеге төбәктә шактый еш очрый торган кабер өсте буралары да очраштыргалый. Мондый корылмаларның Үдик ягы зират мирасларында саклануы – анда яшәүчеләрнең борынгы татар йолалары кысаларыннан тайпылмавы хакында сөйлиләр.

Гомумән, бу традициянең Барда төбәгендәге һәр татар почмагында яшәгәнен күрү, монда татар теле, музыкасы, кыйбласы гына түгел, тормыш-көнкүреш мирасларыбызның да саклануына инандыралар.

№ 1. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган: 125×223×62 см. Чардуган таянычлары булган труба баганалар кирпечләр өстенә утыртылган. Баганалар очына металл чыбыклардан ясалган ярымай символлары куелып эшләнгән. Чардуган эчендә мәрмәр ватыкларыннан коелган аксыл төстәге ташбилге тора, аның очы дуга рәвешендә эшләнгән. Һәйкәлнең үлчәмнәре – 7,5×48×100 см, ул бер баскычлы басмага беркетелгән. Ташбилгенең тимпан очында, урталыкта ярымай символы төшерелгән, аннан астарак мәрхүмнең зур гына фотосурәтеннән күчермә эшләнгән. «Адутов Тауфик Морат улы (1941–2012)» дип язылган. Язма текст кабер өстенә каратып куелган.

№ 2. Коңгырт төскә буялган арматурадан эшләнгән чардуган ике кабер урынын эченә ала. Аның биеклеге 60 см. Кабер янына керү өчен кечкенә ишек тә куелган. Чардуган стеналарының почмак баганалары очына металл чыбыклардан ясалган ярымай символлары ныгытылган.

Ташбилге мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән, аксыл төстә, турыпочмаклы. Аның тимпанына ярымай сурәте төшерелгән. Йөзлегенең астында кириллица хәрефләре белән «Амиров Закий Закирович 19.10.1923–27.08.2008» дигән мәгълүмат язылган.

Һәйкәл бер баскычлы басмага куелган, аның каршында кирпечләрдән тәбәнәк кенә чәчәклек эшләнгән.

№ 3. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Анда металлдан ясалган ташбилге ике баскычлы басмага ныгытылган. Ташбилге тимпанында иң өстә – йолдыз, аның астында –

мәрхүмнең портреты, түбәндәрәк «Амиров Даниф Зәки улы. 1957–1984. Тыныч йокла, кадерлебез» дип язылган.

№ 4. «Арзыев Тауфик Закир улы, 1927–1979. Тыныч йокла, кадерле ирем, әтиебез». Ташбилге мәрмәр валчыкларыннан коелып эшләнгән. Тимпанда яфраклы ботак символы сурәте төшерелгән.

№ 5. Кызыл граниттан эшләнгән ташбилге. Йөзлегенә «Арзыев Таһир, 1962–1992» дип язылган.

№ 6. Зираттагы иң борынгы чардуган тибының үрнәге буларак сакланган бура. Ул диаметрлары 10–12 см булган өч ниргә бүрәнәләрдән тора. Иңе – 124 см.

№ 7. XIX гасырдан калган бай эчтәлекле ташбилге. Зурлык үлчәмнәре – 10×35×100 см, известь ташыннан ясалган. Дүрт ягы да берберсенә керешеп торган вак кына гарәп әлифендәге язмалар белән тулган. Шуларның бер яктагысын без түбәндәгечә укыдык:

*«Һуаллаһи әл-ләзи лә-мәвәт вә көлли...*

*Бу мәркад сахибе Кадыйр... бине Низаметдин бине Баһаветдин 1838 нче сәнәдә вөҗүдә килүб, 1895 сәнә 18 августда 57 йәшендә рихләт әйләде*

*Рәхмәтә Аллаһ, рәхмәтә вәсәгатә...»*

Янә икенче ягында язма түбәндәгечә башланып китә:

*«Мәрхүм галим вә мәгърифәт сахибе вә гарәб телендә булган...»*

Ташбилге йөзлегендәге соңгы язмада мондый сүзләр таныла:

*«...үзе тәнәммел (камилләшү – М.Ә.) вакытында варисларыны тәкәммел эчерүб, вә мөселман башкордларның җир хакында дәгъваләрүн белдерүб, күб җир вә урманлар алыб...»*

Ташбилгенең ян ягында иң аста бу ташбилгене эшләүче останың *«Кятибе Мотыйгулла әл-Кәбир»* дигән имзасы куелган.

Үдик авылының бу зираты тимерчыбык белән әйләндереп алынган. Авыл ишанының әйтүенә караганда, ташбилгеләрне Түбән Кама шәһәреннән алып кайтып, язуларын монда язып куялар икән.

Әлеге каберлекнең борынгы чикләрен билгеләгән, җиргә казылган вал зират эчендә беленә.

### Үдик (Елпачиха) авылының икенче зираты

Куе агачлык, урман рәвешендә, авыл эченә кереп тора. Авылга караган ягында зур капкасы бар. Капкадан кергәч тә, сул якта зират әсбаблары: колаша, көрәкләр, ломнар, комганнар һ.б. куя тор-

ган кыр вагоны бар. Зиратның кырга карап торган буеннан урман эченәрәк кергәч кабер өсте корылмалары тезелеп китә. Июль аенда зират мәйданында печәннәр биек булып үскән, алар чабылмаган. Сирәк-мирәк кенә зиратның бу кырыена машина, йә ат арбалары белән кергәнлекне белдергән эзләр күренә.

№ 1. Арматурадан ясалган, зәңгәр төстәге чардуган. Чардуганның эчендәге затлы итеп бизәлгән ташбилге тимпанында гарәп язуының татар стилендә башкарылган бөек кәлимәсе ак нурлар чәчеп тора.

«Бисмилла әр-рахман әр-рахим» язмасы астына шагыйребез һәм дәүләт эшлеклебез Кол Мөхәммәд Шәриф сәйед истәлеген мәңгеләштергән Казан мәчете сурәте белән янына «Байкиев Наил Мөхәмәт улы, 14.09.1937–30.11.2011» дип язылган.

№ 2. Арматурадан эшләнгән, яшелгә буялган чардуган. Аның эчендә мәрмәр ватыгыннан коелып эшләнгән ташбилге. Тимпанында ярымай һәм аның янында мәрхүмнең рәсеме урнаштырылган. Ташбилге язуы: «Ермакаев Ильдар Назибович, 1962–2007. Дорогой сынок ты был и останешся эталоным чести и совести».

№ 3. Ташбилге. Амирова (Ермакаева) Рәмзия Корбангали кызы, 1958– 2006.

№ 4. Яңа кабер өсте бурасы, 13–15 см диаметрлы бүрәнәләрдән алты ниргә салып эшләнгән, яшькелт төскә буялган. Бураның үлчәмнәре – 135×240 см, биеклеге – 120 см.

Зиратта дүрт ниргәдән торган бишенче бүрәнәне матча итеп куйган буралар да бар. 1960 елларда таралыш алган металлдан эшләнгән тумба тибындагы кабер өсте һәйкәлләре дә күренә. Ташбилгеләргә сурәт кую гадәте нык таралган.

Яшел, зәңгәр, сыек яшел төсләргә буялган арматурадан ясалган күп чардуганнар һәм сирәк кенә соңгы елларда куелган буралар да күренә.

## Әрәмә (Конюково) авылының беренче зираты

Бу ташландык зират, анда күммиләр икән инде. Шулай да җимерек рәшәткәле агач чардуганнар сакланган әле. Арматурадан эшләнгән, күгәреп беткән металл чардуганнар да торалар. Зират эчендә язулары кырылып беткән таш билгеләр авып ята.

Зират заманында, татарның борынгы гадәте буенча, канау белән әйләндерелеп алынган булган. Аның эзләре әле хәзер дә шактый беленә.

## Әрәмә (Конюково) авылының икенче иске зираты

Рәшәткә койма белән әйләндерелеп алынган. Рәшәткәләр хәзер тузып таралу хәленә җиткәннәр.

Зиратта буялган һәм буялмаган арматурадан эшләнгән чардуганнар да күп саклана. Мәрхүмнәр турында мәгълүматлар, овал формадагы – 16–18 см озынлыгындагы металл пластинкаларга язылып, чардуган стеналарына беркетелгән.

Мәрхүмнәр турындагы мәгълүматлар:

№ 1. «Абубакирова Минкамал Шайгаскәр кызы, 1929–2008».

№ 2. «Аитов Габдулгани Солтан улы, 1930–2003».

№ 3. «Аптракова Рәйханә Мулланур кызы, 1922. – 26. II. 1996».

## Искер авылы зираты

№ 1. Арматурадан эшләнгән чардуган, зәңгәр төскә буялган. Ташбилге язмасы: «Кучкова Гадиля Гарибзяновна, 1959– 1994»

№ 2. Арматурадан эшләнгән чардуган зәңгәр төскә булган. Үлчәмнәре – 140×240 см, биеклеге – 185 см. Кара граниттан ясалган ташбилге язмасы: «Кульмашов Саит Садыртдинович (1923–1993)».

№ 3. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган ташбилге, үлчәмнәре – 5×40×80 см «Кучков Шарифулла Шархулла улы (1948–1978)» дип язылган.

№ 4. Арматурадан эшләнгән чардуган. Стенасына 2×20×35 см зурлыктагы пластинкага «Тайсина Гәйшә Фазул кызы (еллары юк. – *М.Ә.*)» дип язып элгәннәр.

№ 5. Ак таштан эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 12×25×65. «Тайсин Фатих Н. (1888–1977)». Мәрхүм турындагы язма хәзерге татар графикасында башкарылган.

№ 6. Мәрмәр таштан эшләнгән ташбилге, ак төстә, үлчәмнәре – 5×40×65 см. Мәрхүм турындагы мәгълүмат: «Тайсин Мөхәммәтҗан Фатих улы (1924–1995)» дип, уеп язылган, татар телендә, хәзерге графикада башкарылган.

№ 7. Ташбилгегә уеп «Тайсин Рафиг, 1916–1989» дип язылган. Үлчәмнәре – 13×30×65 см.

№ 8. Эпитафик текст чардуган стенасына беркетелгән, 20×30 см зурлыгындагы плитәгә язылган: «Кучков Хәмзә Габделбәр улы, 1936–1993».

№ 9. Арматурадан эшләнгән, көмеш төсенә буялган чардуган, үлчәмнәре – 204×273 см. Биеклеге – 205 см. Эпитафик текст 30×30 см. үлчәмендәге мәрмәр плитәгә язылган: «Мөхсинов Шәрифулла Шартдин улы, 1878–02.IX.1960».

№ 10. Ташбилге йөзлегенә, беркетелгән металл плитәгә (15×30 см) язылган мәгълүмат: «Кульмашев Рафхатулла Габделхатович, 1938–1993».

№ 11. Ташбилгедә мәрхүмә турындагы мәгълүмәт язылган «Кучукова Фагиля ...., 19..– 19..» (язмалар бозылган, барысын да танырлык түгел. – *М.Ә.*).

№ 12. Арматурадан эшләнеп, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның эчендә кабер өстенә йөзлеге белән каратып куелган мәрмәр ватыгыннан коеп эшләнгән ташбилге. Хәзерге заманның мастерскойларында эшләнгән типик, стандарт форма. Йөзлеге, сәнгатьле итеп, үсемлек сабаклары мотивлары белән бизәлгән. Тимпанда иң югарыда ярымай силуэты. Аннан астарак стильләштереп язылган гарәп әлифендә «Аллаһ» сүзе һәм түбәнрәк иман кәлимәсе гарәп хәрефләре белән уеп язылган.

Тагын да түбәндәрәк мәрхүмнең исем – фамилиясе һәм гомер сөргән еллары күрсәтелә: «Салихов Габдрауф Нурислам улы, 1946–2012». Ташбилге бер баскычлы басма өстенә ныгытылган, кабер өсте төзәтелмичә калган (убылып тора).

### Каенавыл (Березники) музеендагы кайбер мәгълүматлар

Халык җәүһәрләре традицияләрен саклаучылар (чигүчеләр):

Аптукова Рафига
Дускаева Ильвина
Аптукова Марфуга
Сакиева Әнүзә
Аптукова Айсылу
Алимова Фаукия
Илькаева Рамиля

Авылның имамы – Назиф Балтаев.

## Каенавылда төзелгән Сакаевлар шәҗәресе

(*төзүчесе – Рәшидә Сакаева*)

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Ситдыйк Сакаев, хатыны Бибисәрвәр Казан ягыннан килгән | |
| | *II буын* | |
| 2. | Фатих, хатыны Сәрби Каенавылдан | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Шәрифулла Сакаев, хатыны Өммегөлсем Каенавылдан. Шәрифулла 1943 елда сугышта үлә | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Габдерәшит Сакаев (1940–1998). Хатыны Рәшидә 1943 елда туган | 3 |
| | *V буын* | |
| 5. | Алмаз Сакаев, 1973 елда туган. Хатыны Ильзира | 4 |
| 6. | Арсен Сакаев, 1980 елда туган. Хатыны Гүзәл | 4 |
| 7. | Чулпан Сакаева, 1968 елда туган | 4 |
| | *VI буын* | |
| 8. | Марат Сакаев | 7 |
| 9. | Лилия Сакаева | 7 |
| 10. | Юлия Сакаева | 7 |

## <u>Сакаевның хатыны </u>Рәшидә Искәндәрова (әнисенең??) шәҗәрәсе (?)

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Параветдин, хатыны Шәппә (Шәрифә) Картинә | |
| | *II буын* | |
| 2. | Фәррахетдин, хатыны Әфизә | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Шәрифә, ире Таһир | 2 |
| 4. | ? | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Мәгъфүрә (1900–1984), әтисе Таһир | |

## Искәндәровлар шәҗәрәсе

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 1. | *I буын*<br>Шаһап (Үдиктән) | |
| 2. | *II буын*<br>Хуҗа Насретдин, хатыны Гайшә | 1 |
| 3. | *III буын*<br>Низаметдин (1887–1966)? | 2 |
| 4. | *IV буын*<br>Рәшидә Сакаева | 3 |

Рәшидә Сакаева сүзләре: «Безнең әти 1914 елгы сугышта Австриядә әсирлектә була. Аның шул чакта язган бер дәфтәр бәетләре була. Аны Казаннан Мәгафә (Мәхмүд) Мөхәммәдиев Академиягә алып киткән иде. Бер генә бәете басылды.

Низаметдин (1887–1966) Бардада үлде, хатыны (1900–1984) шулай ук Бардада үлде».

### Каенавыл зираты

№ 1. Арматурадан ясалган, көмеш төсенә буялган чардуган. Чардуганның стенасына үлчәүләре 35×35 см булган мәрмәр плитә беркетелгән. Плитәдә «Дускаев Назиф Агзам улы 1971–2012. 17.IX» дип язылган. Анда шулай ук ай символы уеп төшерелгән, гарәп телендә иман кәлимәсе язылган.

№ 2. Арматурадан эшләнгән чардуган, яшел төскә буялган. Стенасына мәрмәр плитәгә, уеп, ярымай символы төшерелгән һәм гарәп язуында иман калимәсе язылган. Анда «Шакманаев Марсель Габделбәр улы, 1948–2012» дип тә язылган.

№ 3. Арматурадан эшләнгән, көмеш төскә буялган чардуган. Стенасына 20х30 см. үлчәмле мәрмәр плитәгә «Бакунов Сәйедхан Нәҗмехан улы, 1932– 2008» дигән сүзләр язылган.

№ 4. Арматурадан эшләнгән, яшел төскә буялган чардуган. Чардуган стенасына беркетелгән мәрмәр плитәгә «Кучукбаева Назмисафа Гарай кызы, 1933–2007 ел» дигән сүзләр язылган.

№ 5. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның стенасындагы плитәдә ярымай символы, мәрхүмә портреты

төшерелгән. «Уразаева Әлфия Сәлимовна, 1951–2004» дип язып куелган.

№ 6. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның стенасына мәрмәр плитәгә (үлчәмнәре – 30×30) Мәрхүмнең портреты төшерелгән һәм «Дускаев Сайфутдин Шамсутдин улы (1927–2006)» дип язылган.

№ 7. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган стенасына мәрмәр плитәгә (үлчәмнәре – 30×30 см) «Дускаев Рәүф Сайфутдин улы» диелгән сүзләр уелган.

№ 8. Арматурадан эшләнгән, яшел төскә буялган чардуган эчендәге 30×30 см зурлыктагы мәрмәр плитәгә «Сакаева Фәрихә Шамсетдин кызы (1920–2008)» дип язылган.

№ 9. Арматурадан эшләнгән, яшел төскә буялган чардуган эчендәге ташбилге йөзлегенә «Сакаев Наил Әхәт улы (1939–2009)» дигән мәгълүмат язылган.

№ 10. Арматурадан ясалган, яшел төскә буялган чардуган эченә куелган ташбилге йөзлегенә мәрхүмәнең портреты ясалган һәм исем-фамилиясе, әтисенең исеме язылган: «Сакаева Нәҗ... бану Мөхәррәм кызы».

№ 11. Арматурадан эшләнгән, көмеш төсенә буялган чардуган стенасына үлчәмнәре 20×32 см булган мәрмәр плитәгә мәрхүмә «Чурмаева Мәрзия Мухаматгали кызы (1924–2008)» дип язып элгәннәр.

№ 12. Ташбилге тимпанына ярымай, аның астына мәрхүмнең портретын төшергәннәр. Аскарак «Габдрашитова Нафига Габдрахимовна (1935–2009)» дип язганнар. Ташбилгенең үлчәмнәре – 6×42×94 см.

№ 13. Ташбилгенең тимпанына ярымай символы, гарәпчә иман кәлимәсе язылган һәм мәрхүмнең портреты урнаштырылган, алардан түбәндәрәк аның исем-фамилиясе теркәлгән: «Сакаев Лотфырахман Ахат улы (1927–2007)».

№ 14. Ташбилгенең тимпанында ярымай символы уеп ясалган, аның астына мәрхүмнең сурәте беркетелгән. Ташбилгенең үлчәмнәре – 8×45×85 см. «Амиров Таваф Тухфатулович,1924–2003» дип уеп язылган.

№ 15. Кабер өстенә арматурадан ясалган, яшел төскә буялган чардуган корылган. Аның бер аратасына үлчәмнәре 2×20×30 см булган, эпитафик мәгълүмат язылган мәрмәр плитә

беркетелгән. Анда «Дускаев Даниф Агзам улы, 1958–2010» дип язылган.

№ 16. Арматурадан ясалган чардуганга беркетелгән, үлчәмнәре 2х20х30 см булган мәрмәр плитәдә мәрхүм турында мәгълүмат бирелә: «Амиров Хәким Сәлим улы, 1955–2010».

№ 17. Арматурадан ясалган чардуган Аратасына 2×20×30 см үлчәмендәге мәрмәр плитә эленгән. Анда «Дускаева Халидә Мәдияр кызы, 1928–2007» дип язылган.

№ 18. Арматурадан ясалган чардуган, аның стенасы аратасына мәрхүм турында мәгълүмат язылган, үлчәмнәре 0,5×18×22 см булган калай эленгән. Анда: «Баянголова Нурифә Мөхәммәтзаевна, 1911–2005» дип язылган.

№ 19. Арматурадан эшләнгән чардуган, аның аратасына үлчәмнәре 2×30×30 см булган мәрмәр плитә эленгән. Анда «Нурсубина Зәкия Гали кызы, 1935–2012» дип язылган.

№ 20. Арматурадан эшләнгән чардуган, аның эчендә үлчәмнәре 7,5×45×115 см булган ташбилге бар анда: «Тугумов Шархум Абубакирович, 1926–2012. Вечная память» дип язылган. Ташбилгенең тимпанында ярымай символы һәм мәрхүмнең портреты төшерелгән.

№ 21. Арматурадан эшләнгән чардуган. Аның аратасына үлчәмнәре 2×20×30 см булган мәрмәр плитә эленгән. Плитә йөзлегендә «Амирова Хәкимә Гәрәйша кызы, 1929 – 2005» дип язылган.

### Барда район үзәге зираты

Зират бүгенге көндә авылның үзәгендә үк калган диярлек. Ул күпчелек урында куе агачлык белән капланган. Анда чыршы, нарат, каен, усак, юкә, сәрби, ирга һ.б. агачлар үсә.

Бу зират янында Барданың икенче мәчете урнашкан. Аның түбәләре, манарасы, ярдәмче хуҗалык каралтылары һәм арматурадан ясалган киртә белән тотылган әйләнәсе, капкасы төбәк халкы бик ярата торган зәңгәрсу буяу белән буялган. Әйтергә кирәк, Барданың бу мәчетенең манарасы Казан ягындагы манаралардан ике кыска буын булып күтәрелеп, очлаеп торган түбәсе белән шактый аерылып тора. Әлеге мәчет Барда төбәгенең типик рухани корылмасы. Ул ике катлы; беренче катында тәрәзәләр күренми. Мәчет михрабына каршы як стенасына уелган ишектән керә торган баскычы бар. Мәчеттән бер 15 метрлар читтә зиратның төп керү юлы,

капкасы тора. Зират мәйданы мәчет мәйданы белән уртак түгел, алар бер-берсеннән аерылып торалар.

Зиратның әйләнәсе, аеруча янәшәдән уза торган трасса буендагы өлеше чуен баганаларга беркетелгән бизәкле чәчәк мотивлары белән бизәлгән. Аларның шактый өлеше кара төстәге чәчәк (тюльпан) шәүләсен хәтерләтә. Бу кара чәчәкләр эченә кечерәк үлчәмле, ак төсләргә буялган тюльпан силуэтлары урнаштырылып, зират киртәләре бер гүзәл күренеш тәшкил итә.

Әйләндереп алынган матур киртәле урыннар, металл челтәрләр тарттырылган чуен баганачыклардан гыйбәрәт.

Әлбәттә, күпчелек зур торак пунктлардагы кебек, Барданың да зиратында ятимлек хәсрәте саркып тора. Үлгән өлкән буыннарның бик тиз онытылуы күзгә ташлана… Әле бездә сугышчан атеизм зәхмәте эзләре ярылып ята.

Барда зираты зур һәм иркен. Анда Татарстандагы кебек кабер урыны табуга мохтаҗлык күренми. Шунлыктан монда каберләр төркемләп урнашканнар. Татарстан ягы зиратларындагы кебек рәтрәт булып тезелеп китмәгән. Ләкин бу күренеш төбәктәге барлык татар зиратларына да хас дигән сүз түгел әле.

Барда зиратында татар-мөселман кабер өсте корылмалары булган чардуганнарның үзгәрә бару этаплары шактый тулы күзгә чагыла. Ләкин башка авылларда сирәк кенә булса да сакланып калган кабер өсте буралары биредә күренмәде.

Бу бураларны алмаштырган, дүрт багана сугып, такта белән әйләндереп ясалган чардуган үрнәкләре сирәк булса да бар.

XX гасыр урталарыннан такта чардуганнарга алмашка килгән, дүрт баганаы бер-берсенә араталап сугып, аларга тар такталардан рәшәткәләр тезеп ясалганнарының традициясе Барда зиратлары хәзинәсендә әле дә саклануы ачыкланды. Рәшәткә чардуганнар дүрт почмакка ташлар өстенә утыртылган дүрт баганачыкка таянып тора. Аларның матур зәңгәр, яшел төсләргә буялганнары һәм буялмыйча табигый кыяфәттә калган үрнәкләре дә бар. Агач рәшәткәле, такта чардуганнар инде буралы чардуганнан бераз гына кыскарак, аларның уртача үлчәмнәре – 130×220 см, биеклекләре – 90–120 см.

Хәзер инде чардуган ясау материалы бик кызу рәвештә арматурага алышына бара. Алар, нигездә, 5–6 см диаметрлы металл торбалардан һәм киңлеге 5 см булган каты металл тасмаларны буйга урталай бөкләп, почмаклап ясалган. Араталары өстенә 0,5 см диа-

метр калынлыктагы каты металл чыбыклардан эшләнгән декоратив бизәкләр беркетелгән. Бу металл чардуганнар зәңгәр, яшел, кара төсләргә буялып, карап торырга сәнгатьле күренеш ясыйлар. Аларның баганалары очларындагы куышлык башына юка калайдан яки каты тимер чыбыктан бөгеп ясалган ярымайлар, шар сыннары һ.б. беркетелә. Металл чардуганнарның ялгыз һәм гаиләви каберләр өстенә зур, киң итеп ясалганнары да бар. Андый зур чардуганнарның бер ягына, кереп-чыгып йөрү өчен, тимер чыбыклардан җилкапкалар эшләнгән, алар келә белән бикләнеп торалар. Шулай ук чардуганның озын ягын урталай бүлеп, капкасыман урын ясалу очраклары да бар. Дүрт почмактагы баганалар җиргә кирпеч яки таш плитә өстенә утыртыла, шунлыктан аларның эченә кереп, чүп-чардан арындыру мөмкинлеге бар. Чардуган баганаларын тоташтырган араталар өстенә дүрт ягында чыбыклардан бөгеп ясалган бизәкләр урнаштырылу очраклары да шактый. Барда зиратындагы кабер өстендәге ташбилгеләрне тасвирлап үтү урынлы булыр.

№ 1. Мәрмәр ватыгыннан коеп эшләнгән аксыл төстәге турыпочмаклы ташбилге. Ул яшелгә буялган, стеналары чардуган эчендәге ике баскычлы басма өстенә, мәрхүмнең баш очына каратып урнаштырылган. Һәйкәлнең арткы ягында кабер өстенә ак кирпечләрдән чәчәклек ясалган.

«Абайдуллина Зөһрә Әхмәтша кызы. 1898–26.03.1976» дип язылган. Аның йөзлегенең сулъяк почмагына ярымай, аның белән янәшә, ләкин тимпанның урта бер җирендә борынгы калфаклы ханымның портреты урнаштырылган. Ташбилгенең үлчәмнәре – 5×45×50 см. Язмалар бүген гамәлдәге графикада уеп һәм аның өстеннән буяп эшләнгән.

№ 2. Яшькелт төстәге металл чардуган эчендә аксыл төстәге мәрмәр валчыгыннан коеп эшләнгән турыпочмаклы ташбилге. Аның йөзлегендә тимпанның сул ягында ярымай силуэты, тимпан уртасында, ярымай белән янәшә мәрхүмәнең портреты урнаштырылган.

Эпитафик текст: «Юлаева (Абайдуллина) Фәридә Шиһабетдин кызы, 18.12.1919. – 31.03.2010». Язмалар бүгенге татар графикасында бирелгән.

№ 3. Металлдан эшләнгән пирамида кыяфәтендәге тумба. Металл пластинкага язылган эпитафик текст: «Нурсубин Габдулла

Садретдинович. 1897–1976». Язмалар кирилл графикасында. Тумба башында йолдыз символы тора.

№ 4. Рәшәткәдән эшләнгән, зәңгәр төстәге чардуганның мәрхүм баш очындагы тар ягында 20×30 см зурлыктагы калай пластинга «Максиева Расмия Шарип кызы. 1953–2002.15.06» дип язылган.

№ 5. Рәшәткәдән эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Мәрхүмәнең баш очындагы рәшәткәгә 2×30×3 см зурлыктагы мәрмәр плитәгә эпитафик такта язып эленгән: «Киндяшева Әминә Вильдяр кызы. 24.01.2011. – 10.03.2011».

№ 6. Арматурадан эшләнгән зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның металл баганалары кирпечләр өстенә утыртылган. Чардуганның мәрхүмәнең баш очы ягындагы стенасына 20×30 см зурлыктагы калайга эпитафик язма беркетелгән «Иманаева Мөнирә Тимершәйех кызы, 1936–1966».

№ 7. Агач рәшәткәдән эшләнгән, буялмаган, почмакларындагы терәк баганалары кирпечләр өстенә бастырылган чардуган. Мәрхүмәнең баш очы ягы стенасына беркетелгән ак мәрмәр плитәгә «Ишбулатова Хәтимә Хәйдәр кызы» дип язылган. Язмадан өстә уң почмакка ай-йолдыз символы төшерелгән Чардуганның үлчәмнәре – 125×220 см, биеклеге – 80 см.

№ 9. Карасу төскә буялган арматура чардуган. Мәрхүмнең баш очы ягындагы стенасына үлчәмнәре 2×30×30 см булган мәрмәр плитәгә эпитафик текст язылган: «Митриев Гаптелмәннаф Әндәрҗан улы, 1923–1959».

№ 10. Эпитафик плитә, үлчәмнәре – 8,5×40×100 см, тексты калкытып язылган, тимпанында ай-йолдыз символы бар. «Суяргулов Габдулахат Габдулхакович, 1927–2008» дип язылган.

№ 11. Арматура чардуган. Баш очы ягына беркетелгән плитәдә эпитафик язма: «Юртаева Тәслимә Миннигул кызы, 1935–1993».

№ 12. Мәрмәр ватыгыннан коеп ясалган ташбилге. Йөзлегендә ярымай силуэты, иман кәлимәсе бар. Эпитафик тексты: «Исмакова Әлфия Котдус кызы, 1973–2007».

№ 13. Эпитафик тексты: «Ибраева Саима Мухаматгали кызы. 01.03.1926–21.06.2005».

№ 14. Барда зиратында 1990 елларда татар азатлык хәрәкәтдә актив катнашкан, шагыйрь һәм галим Ягъфәров Рәшит Фәйзерахман улының да мәңгелек йорты бар. Барда якларында аңа хөрмәт зур һәм аны халык хәтерендә нык саклый. Безнең галим-

нәребез дә Барда җиренә килгәч, аның каберенә бардылар, аңа булган хөрмәтләрен күрсәттеләр.

№ 15. Арматура чардуган, зәңгәр төскә буялган, башка чардуганнар кебек биек түгел. Арматура почмаклары баганалары очларына ай силуэтлары ясап куелган. Ташбилгедәге эпитафик текстка: «Мәҗитов Ф. Гарифович» дип язылган.

№ 16. Эпитафик текст: «Мазитов Әхияр Мәҗит улы, 1872 – 1966».

№ 17. Арматура чардуган, яшел төскә буялган. Чардуганга беркетелгән плитәдә: «Әмирова (Мазитова) Нәҗмехәнә Мөхәмәтсыйтдыйк кызы, 1882–1967» дип язылган.

№ 18. Эпитафик текст: «Әмиров Мөхәммәтсыйтдыйк Шәйхулислам улы 1849–1945».

№ 19. Арматурадан корылган чардуган. Стенасына эпиграфик плитә беркетелгән. Зурлыгы – 20×30 см. Анда: «Ишгузин Руслан Фаиз улы, 29.X.1973 – 19.V. 2005» дип язылган.

## Төнгнүк авылы зираты

Зират авылның урта бер җирендә калган, кырыеннан олы юл үтә. Аның буе 350 м чамасы булыр.

Зиратта каберләр олы юл ягыннан уем-уем булып урнашканнар.

Ташбилгеләрдән күренгәнчә, бу авылда Балтаев, Максиев фамилияле кешеләр күпчелекне тәшкил итәләр.

Олы юл буеннан зиратка керү өчен өч кечкенә капка ясаганнар.

Зиратта арматурадан ясалган һәм инде буяулары, төсләре җуелып, күгәреп беткән арматура чардуганнар да күп. Сирәк кенә агач рәшәткәле чардуганнар очрыйлар. Аларның да череп, көйрәккә әйләнеп беткәннәре шактый. Яңа ясалган агач рәшәткәле чардуганнар матурлап буяп куелганнар.

Чардуганнарның хәзер тәбәнәкләре дә, элеккечә биекләре дә гамәлдә икән. Алар эченә мәрмәр ватыкларыннан коеп ясалган ташбилгеләр утыртылган.

Соңгы елларда ташбилгеләр урынына кечкенә мәрмәр плитәләр һәм калай пластинкаларга язылган эпитафик текстлар артуы күзгә ташлана. Аларны чардуганның баш яки ян стенасына беркетеп куялар.

Төнгүк зиратында эпитафик язмалар куелмаган яңа каберләр дә шактый.

№ 1. Бу авылның зиратында атаклы татар артисткасы Дамира Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның да мәңгелек йорты куелган икән. Аның гомер еллары – 1948. 16.05. – 18.12.1993. Аның кара мәрмәрдән эшләнгән плитәсенә (үлчәмнәре – 5х50х98 см): «Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исмендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлмәт татар дәүләт драма театрыннан» дигән сүзләр дә язылган. Тимпаныда «Бисмилла әр-рәхман әр-рәхим» диелгән.

№ 2. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Мәрхүмнең баш очындагы стенасына эленгән кара мәрмәр плитәгә, уеп, эпитафик текст язылган. Плитәнең өске сул почмагына мәрхүмнең портреты, уң почмагына ярымай урнаштырылган. Алар астына:

*«Югалсаң да тормыш юлыннан,*
*Югалмассың йөрәк түреннән*
*Аков Фәнәвил Шәриф улы*
*10.01.1946–26.05.2007»* – дип язылган.

№ 3. Тәбәнәк арматура чардуган, яшькелт төскә буялган. Эчке ягына чәчәклек һәм мәетнең баш очы турысына мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән ташбилге утыртылган, ул декоратив чәчәк сурәтләре белән бизәлгән. Тимпанда ярымай сурәте, аның астына сул якка мәрхүмнең портреты төшерелгән. Портрет белән янәшә ике манаралы мәчет сурәте дә уелган. Сурәт астына гарәп графикасында иман кәлимәсе язылган. Түбәндәрәк мәрхүмнең исем-фамилиясе һәм гомер итү еллары күрсәтелгән: «Аков Юныс Сафиулла улы 1938–2007».

№ 4. Мәрмәр ватыкларыннан коелып эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 6×39×80 см.

Тимпанына ярымай һәм аның янына мәрхүмәнең портреты төшерелгән. Гарәп хәрефләре белән, уеп, иман кәлимәсе язылган. Түбәндәрәк мәрхүм турындагы мәгълүмәт китерелә: «Нурсубина Факия Шәрәфетдин кызы 17.03.1940–19.01.2010».

№ 5. Арматурадан ясалган чардуган. Аратасына мәрмәр плитә беркетелгән, үлчәмнәре – 2×20×30 см. Дини билгеләр күренми. Эпитафик текстта фәкать «Максиев Галихан Бәйрәм улы, 28.06.1930–16.01.1999» мәгълүматы гына бирелгән.

№ 6. Ташбилге арматура чардуган эчендә урнаштырылган. Аның тимпанына ярымай төшерелгән. Эпитафик язмада «Максиев Габтрафик Галихан улы, 11.09.1959 – 15.11. 1992» диелгән.

№ 7. Эпитафик текст үлчәмнәре – 1×20×30 см. «Максиева Халисә Фәйзрахман кызы, 09.05.1937–24.06.1998». Ташбилгедә ай, бисмилла догасы төшерелгән.

№ 8. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Чардуган эчендә, мәетнең баш очына куелган ташбилге. Ташбилгенең язулы ягы кабер өстенә карап тора. Ташбилге алдында чуер ташлардан коеп ясалган чәчәклек урыны.

Мәрхүмгә башта табаклы тимер пластиналардан байраксыман формада кабер өсте истәлеге куйган булганнар, аның алдында хәзерге заманча кара мәрмәрдән шомартып эшләнгән, оригиналь конструкцияле матур истәлек тора. Тимпанның иң очында ярымай силуэты ап-ак булып күренеп тора. Аннан астарак зур планда мәрхүмнең хәрби киемдәге портреты тора. Киемнәрдәге билгеләренә караганда ул очучы офицер булган.

Портрет астында: «Максиев Максут Махмутович, 31.05.1958–03.02. 1993» дип язылган. Мәрхүм ниндидер катастрофа вакытында һәлак булган күрәсең.

№ 9. Мөселман атрибутлары күрсәтелмәгән, эчтәлеге ярлы ташбилге: «Максиев Махмут Гатилхан улы, 15.09.1917. – 22.III.2001».

№ 10. Мөселман атрибутлары күрсәтелмәгән ташбилге: «Нурсубина Мөслимә Фасих кызы, 1932–1981». Эпитафик текст гади калай кисәгенә язылган.

№ 11. Мәрмәр ватыкларыннан байраксыман фигурада коелган ташбилге. Аның алдында бортлар белән төзелгән чәчәклек.

Ташбилге тимпанының, сул почмагында байраккка төшерелгән сыман ярымай күренә.

Бу һәйкәл катлаулырак конструкциядә эшләнгән. Аның йөзлегенә турыпочмаклык рәвешендә ак мәрмәрдән ясалган пластина ябыштырылган. Аның өске ягында – кырыйларыннан лавр ботаклары белән бизәлгән мәрхүмнең хәрби киемдәге портреты.

Аннан түбәндә эре басма хәрефләр белән «Балтаев Илфат Тауфик улы» дип, тагын да түбәндәрәк мәрхүмнең яшәгән еллары – «1967 19/06 –13/07 1993» һәм «Тыныч йокла абый» дигән сүзләр язылып, аста лавр яфракларыннан бизәкләр төшерелгән.

№ 12. Мәрмәр ватыкларыннан коелган ташбилге, чардуганы да, чәчәклеге дә юк, үлән һәм берничә чәчәк янында ялгыз тора. Ташбилге мәрмәр ватыкларыннан байракка охшатып коелган һәм аның йөзлегенә кыяфәте белән ташбилгене хәтерләткән ак плитә

ябыштырылган. Аның урта бер җирендә хәрби киемдәге яшь офицер сурәте бар. Аннан астарак эре хәрефләр белән «Балтаев Ильдус Тауфик улы, 24.05.1962–30.07.1988» дип язылган.

Тагын да астарак: «Тыныч йокла Ильдус» дигән гыйбарә бар. Мәрхүм, күрәсең, тыныч шартларда һәлак булмаган.

№ 13. Искә алып үтелгән мәрхүмнәрдән ике татар офицерының да атасы, күрәсең үзе дә хәрби кеше булган. Аның каберендә: «Балтаев Тауфик Фасих улы, 15.02.1924–27.06.2000» дигән сүзләр бар. Ташбилгесенең тимпанында портреты да урнаштырылган.

№ 14. Ташбилгедә ярымай һәм матрос портреты бар Анда «Маматов Дамир Маулихан улы 05.10.1969–1993.03.06» дип язылган. Күрәсең, бу егет тә 1993 елның җәендә ниндидер хәрби һәлакәттән корбан булган.

Төнгүк зиратындагы мондый ташбилгеләр бүгенге җәмгыятебезнең кешене юкка чыгару коралына әйләнгәнлеген күрсәтә.

## Күчтәнти авылы зираты

Күчтәнти авылына килгәч тә галимнәр мәктәп бинасындагы Рәшит Ягъфәровка багышланган музей бүлмәсендә булдылар. Музейда Рәшит Ягъфәровның шәхси әйберләре киемнәре, шәҗәрәсе саклана икән. Шәҗәрәдән күренгәнчә, Рәшитнең мәгълүм булган иң ерак бабасы Ягъфәров Әбрар, аннан туган Минсафа, аннан туган Фәйзерахман, аннан туган Минсара, аннан туган Фәйзерахман, аннан туган Рәшит. Рәшитнең уллары Илдар белән Юлдаш. Юлдаштан туган Мәликә. Без бу шәҗәрәнең ян буыннарын калдырып, үзәк тамыр буенча гына нәсел барышын күрсәттек.

Күчтәнти авылының зираты да зур, агачлык белән капланган. Ул да Барда төбәгендәге башка зиратлар белән күп охшашлыкларга ия. Ләкин анда борынгы фамилияләр саклануы кызыклы.

№ 1. Яшелгә буялган, арматурадан ясалган чардуган эчендә мәрмәр ватыкларыннан коеп эшләнгән ташбилге, зурлыгы – 9×48×120 см. Ташбилгенең очы үзенчәлекле, аның сул ягы уң ягыннан 15–20 см га биегрәк тора. Сул якка, өске почмакка ярымай символы куелган. Ташбилге йөзлегенең уң як кырыена агач сыны, аның кайгырып иелгән ботаклары астында мәрхүмә кызның портреты ясалган. Портрет астында бүгенге татар графикасында. – «Юлушева Раиса Гариф кызы, 1968.04.XI–1987.01.III. Сөекле кызыбызга, әти-әнисеннән» дип язылган.

№ 2. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган, тәбәнәк чардуган. Чардуган аратасына мәрхүмә турында мәгълүмат язылган мәрмәр плитә эленгән (үлчәмнәре – 2×33×55 см). Анда: «Ишимбаева Дания Файзрахмановна, 27.09.1948–27.02.2009» дигән текст язылган. Плитә йөзлегенең уң почмагында ярымай силуэты, сул почмакта мәрхүмәнең портреты төшерелгән. Чардуганның үлчәмнәре – 115×205 см, биеклеге – 63 см.

№ 3. Озын бурага бәйле ташбилгедә «Рангулов Зайнагетдин Хаҗи улы, 1907–20.12.1990» дип язылган. Ташбилгенең тимпанында ярымай ясалган, язмалар уеп язылган. Алдында кирпечләрдән ясалган чәчәклек бар. Ташбилге бер баскычлы басмага беркетелгән. Аның артында 15–16 см диаметрлы бүрәнәдән өелгән биш ниргәле озын кабер өсте бурасы тора. Бу уникаль бура. Мондый озынлыктагы бураның башка зиратларда саклануы мәгълүм түгел. Бураның иңе матчалары буенча 300 см үлчәмгә туры килә, бөтен буеның үлчәме – 465 см. Бураның өстенә аны өчкә бүлеп ике матча куелган. Беренче һәм өченче бүлекләрнең озынлыклары 125 см.

Бураның ниргәләре, йорт буралары кебек, почмаклары уеп ясалган. Матчалар бура өстендәге, уентылар эченә яткырылган. Бураның җир тигезлегеннән матча өстенә кадәр биеклеге 115 см.

Күчтәнти зиратында, башка урыннарда очрамаган, буралар һәм рәшәткәле чардуганнар күп сакланган. Шулай ук ташландык хәлендәге арматуралыларының саны да күп.

№ 4. Арматура чардуган. Аның аратасына эленгән плитәдә «Рангулов Рагит Шавалиевич, 1939–1995» дип язылган.

Күчтәнти зиратын Барда төбәгендәге иң каралмаган, чистартылмаган урыннарның берсе дип санарга була. Анда тау-тау черек рәшәткәләр өелеп тора. Күгәргән, арматурадан ясалган чардуганнар күп. Аларның кайберләрендә ташбилгеләр яки элмә такталар сакланмаган, мәгълүматсыз калганнар. Арматурадан ясалган һәм яхшы хәлдә яшел, зәңгәр төсләргә буялган тәбәнәк һәм вә биек күп кенә чардуганнарда да элмә такталары юк.

Инде әйтеп үтелгәнчә, бу зиратта XVIII–XIX йөзләр татар кабер өсте культурасы традициясе саклана. Шуңа күрә Күчтәнти зираты бураларын музей күренешләре итеп саклау кирәк, чөнки ул традиция хәзер бездә югалып бетеп килә. Гомумән алганда, борынгы зират каберләребезгә игътибар – ата-бабаларыбыз рухына хөрмәт билгесе ул.

## I Әрҗән зираты

I Әрҗән (русча – Краснояр I) авылының зираты авылдан читтә – елганың икенче ягында, тау битендәге урман буенда урнашкан. Әйләнәсе ныгытылган.

Бу зират яңа, анда каберләр рәтләр белән тезелеп урнашканнар. Араларыннан йөрер сукмаклар да калдырылган. Монда ташбилге куелган каберләр сирәк, гарәби язулы ташбилгеләр гомумән юк. Күпчелек эпитафик язмалар арматурадан ясалган чардуганнарның өске араталарына кечкенә күләмле мәрмәрдән эшләнгән такталар рәвешендә элеп куелган. Мәрхүмнәр турындагы мәгълүматлар тактага уеп, бик саран эчтәлек белән язылган. Авылда Сәбәләев, Балтаев, Абузов, фамилияләре еш очрый. Балтаева Роза Хөрмәт кызы сүзләреннән (1947 елда туган) аңлашылганча, бу фамилия аңа ире ягыннан (ул – хәзерге Татарстаннан) булган.

I Әрҗәннең Үрләр тавында изгеләр кабере бар.

Казган тау – изге тау санала.

I Әрҗән авылы 1924 елда Әрҗән районы үзәге була. Аның рәисе Абдуссалямовны 1930 елда, халык дошманы дип, атып үтерәләр. 2012 елда Әрҗәннең 460 еллыгы билгеләп үтелгән.

Зиратта, чардуганнар, нигездә, арматурадан эшләнгән.

№ 1. Арматурадан эшләнгән, үлчәмнәре – 115×212 см, биеклеге – 125 см.

Ташбилгесе кара мәрмәр плитә, үлчәмнәре – 5×40×90 см. Тимпанында ярымай символы, янында – мәрхүмнең сурәте. «Ахмаров Рәшит Гариф улы, 1935–1912».

№ 2. «Чубаркин Нәҗиб Лотфулла улы, 1937–19... (?)» ташбилгесендә ярымай символы куелган.

№ 3. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган, үлчәмнәре – 1115×200 см, биеклеге – 90см. Аратасына мәрмәрдән ясалган пластинага мәрхүмнең исем-фамилиясе язылган: «Ахмаров Ильдар Идият улы, 1963–2002».

№ 4. Арматурадан ясалган, яшел төскә буялган чардуган. Аратасына мәрмәрдән ясалган эпитафик плитә эленгән, үлчәмнәре – 2×30×30 см. Анда: «Баязитов Рушан Нурихан улы. 13.09.1971 – 19.05.2012» дип язылган.

№ 5. Агач борыслардан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Эпитафик тексты: «Габзалилова Гулсина Кашфулловна, 19..–2010».

№ 6. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Мәрхүмнең баш очындагы стена аратасына мәрмәр плитәдә эпитафия тексты хәзерге татар графикасында язылган: «Абузов Ильшат Габдулла улы 28.10.1975 – 09.05.2010». Плитәнең үлчәмнәре – 2×30×30см. Чардуган почмакларындагы торбадан ясалган баганаларның очларына ярымай силуэтлары ясап куелган.

№ 7. Зәңгәр төскә буялган чардуган. Аның баганалары башларына ярымай силуэтлары беркетеп куелган. Чардуган аратасына үлчәмнәре 2×20×30 см булган ак мәрмәр эпитафия плитәсе элеп куелган: «Абузов Габдулла Фатих улы, 26.04. 1943 – 12.11.2010». Язмалар хәзерге татар графикасында бирелгән. Чардуганның биеклеге – 110 см.

№ 8. Мәрмәр ватыкларыннан ясалган, ак төстәге ташбилге. Үлчәмнәре – 8×45×90 см. Тимпанының уң як почмагында ярымай силуэты, сул ягында манаралы мәчете рәсеме контурлары. Эпитафик текст: «Кучумова Рәйсә Әхмәтҗан кызы, 15.12.1927 – 12.12.2009». Йөзлеккә төшерелгән бизәкләр һәм язмалар уеп эшләнгән. Ташбилге бер баскычлы басмага ныгытылган. Ул бизәкләр төшереп плитәләрдән ясалган чәчәклек эчендә калган.

№ 9. Арматурадан эшләнгән, яшел төскә буялган чардуган. Баганалары башларына ярымай силуэтлары урнаштырылган. Эпитафик тескт мәрмәр плитәгә (үлчәмнәре 2×20×30) язылып, чардуган аратасына эленеп куелган: «Рангулов Ринат Тәлгат улы, 20.09.1971 –17.07.2008».

№ 10. Арматурадан ясалган чардуган стенасына (аратага) элеп куелган калай пластинка. Аның үлчәмнәре – 18×25 см. Эпитафик текст: «Ахмаров Наиль Аухатович, 12.10.1940–23.06.2004».

№ 11. Мастерскойда эшләнгән хәзерге заманның типик мөселман ташбилгесе, мәрмәр ватыкларыннан коеп ясалган. Тимпан турысына гарәп язуында иман кәлимәсе бирелгән. Ташбилгенең үлчәмнәре – 5×42×85 см. Аңа төшерелгән эпитафик текст уеп язылган: «Кучумов Лотфулла Ахматгариф улы, 9.01.1920–24.12.2004».

№ 12. Ташбилге дүртпочмаклы итеп коелган, тәбәнәк дүрт стена эчендә калган. Стеналарга үсемлек бизәкләре төшерелгән «Иманаев...» ташбилгесе. Заманнар үтү белән инде чатнап коела башлаган ташбилгедәге күп сүзләрне укып та булмый.

№ 13. Мәрмәр ватыкларыннан эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 8×50×120 см. Тимпанында ярымай белән йолдыз композициясе

уеп төшерелгән. Эпитафик текст: «Мустакимов Гусман Закирович 1919–1992».

№ 14. Кабер өсте бурасы, биш ниргәле һәм матчалы. Үлчәмнәре – 120×220 см. Биеклеге – 1 метр. Бүрәнәләрнең диаметрлары – 12–13 см.

№ 15. Мәрмәр ватыкларыннан коелып эшләнгән ташбилге, үлчәмнәре – 8×43×110 см. Тимпанында ай сурәте уеп ясалган. Эпитафик язмасы: «Кучумов Шарафетдин Мухетдин улы, 24.04.1908 – 17.10.2006».

№ 16. Арматурадан эшләнгән чардуган аратасына үлчәмнәре 2×20×30 см булган ак плитә эленеп, аңа «Иманаев Мухаметзян, 1934–2007» дип язылган.

№ 17. Арматура чардуганга эленгән эпитафик плитә, үлчәмнәре – 2×20×30 см. Аның тексты: «Акҗигитова Вәлимгә Фатыйх кызы 1940–2003».

№ 18. Мәрхүм: «Тукачёв Раиль Шариф улы, 06.09.1947 – 18.09.2008». Текст мәрмәр плитәгә уеп, хәзерге татар графикасында язылган.

№ 19. Мәрхүмә «Назарова Нәҗибә Закир кызы, 1974–2008». Текст хәзерге татар язуында, уеп төшерелгән.

№ 20. Арматурадан эшләнгән чардуган аратасына мәрмәр плитә (үлчәмнәре – 2×20×30 см.) эленгән. Аңа, уеп, хәзерге татар графикасында эпитафик текст язылган: «Рангулов Рәфхәт Тауфик улы, 01:10. 1947 – 19.05.2009».

№ 21. Арматура чардуган аратасына эленгән мәрмәр плитәгә (үлчәмнәре – 2×20×30 см), уеп, хәзерге татар графикасында «Тагирова Галимә Хәмид кызы 20.01.1928 – 22.04.2009» – дип язылган.

№ 22. Арматурадан эшләнгән чардуганның торбадан ясалган багана башларына ярымай силуэтлары куелган. Аның аратасына эленгән мәрмәр эпитафик плитә (үлчәмнәре – 2×20×30 см), уеп, хәзерге татар графикасында «Биктимиров Наиф Фәрит улы 18.01.1961 –15.06.2009» дип язылган.

№ 23. Агач рәшәткәдән эшләнгән чардуган, аның стенасына 2×20×30 см үлчәмле мәрмәр эпитафик плитә беркетелгән. Анда, уеп, хәзерге татар графикасында «Балтаева Зиядә Нуртдин кызы, 1920–2010» дип язылган.

№ 24. Арматура чардуган аратасына эпитафик плитә эленгән, үлчәмнәре – 2×20×30 см. Анда, уеп, хәзерге татар язу-

ында «Атнабаев Ф. – Амин Назмулла улы, 1955 – 2010» дип язылган.

№ 25. Арматурадан ясалган чардуган, аның аратасына үлчәмнәре 2×30×30 см зурлыктагы эпитафик плитә эленгән. Язулары уеп, хәзерге татар графикасында башкарылган. Тексты: «Иманаева Саҗидә Кәрим кызы, 19.06.1934 – 25.12.2010». Бу чардуган яшел төскә буялган.

Каберлектә Иманаевлар истәлегегенә куелган эпитафик текстлар күп күренә.

№ 26. Арматура чардуган эчендә кара мәрмәр ташбилге. Ташбилге ике баскычлы басмада тора. Аның тимпанының сул як почмагында ярымай силуэты аннан түбәндәрәк йөзлек уртасында мәрхүмнең портреты бирелгән. Аста эпитафик текст. Ул, уеп, хәзерге татар теле графикасында язылган: «Ахмаров Рәшит Гариф улы: 10.05.1935 –19.06.2012».

## Байавылның (Куземьярово) иске зираты

Арматура чардуганнар зәңгәр, сыек зәңгәр һәм яшел төснең төрле төсмерләре белән буялган. Ташбилгеләр саны азрак. Алар урынына чардуган араталарына эленгән күгәрми торган металлдан эшләнгән эпитафия плитәләре кулланылган. Ул плитәләрдә мәрхүмнең портреты, аның янына кечкенә генә ярымай һәм йолдыз композициясе, алар астына мәрхүмнең исем-фамилиясе, яшәү дәвере уеп язылган. Чардуганнарның биеклекләре кими бару юнәлеше дә сизелә.

№ 1. Пластинкада: «Абулова Нәгыймә Рәхмәтулла кызы, 1930–2009»

№ 2. Пластинкада: «Мансуров Рахип Саляхетдинович, 1952–2012» дип язылган. Рәшәткәле яшел чардуган тактасына беркетелгән пластинка үлчәмнәре – 12×18 см.

Зиратта рәшәткәдән ясалган агач чардуган үрнәкләре дә очрый.

№ 3. «Минкин Насибулла Мухлис улы, 1941–2010».

№ 4. Арматурадан эшләнгән, зәңгәр төскә буялган чардуган. Мәрхүмнең баш очында, кабер өслегенә йөзе белән торучы стандарт татар ташбилгесе бер баскычлы басма өстенә беркетелгән. Ташбилгенең үлчәмнәре – 6×45×90 см. Андый ташларны, Татарстанның Түбән Кама шәһәреннән кайтарталар, дигән сүзләр бар. Ташбилге йөзлегенең кырый полосалары буйлап өч ягыннан да

үсемлек орнаменты әйләнеп үтә. Тимпанда, ай урынына, овал рамда әби сурәте урнашкан. Ташбилгенең тимпан мәйданының сул ягына уеп, гарәп язуында «Илаһи Аллаһ» дип язылган. Әби портреты астында киң генә итеп мәчет һәм аның манарасы сурәте ясалган. Аннан да түбәндәрәк йөзлеккә ябыштырылган турыпочмаклык эченә татар телендә һәм хәзерге графикада эпитафия тексты бирелгән: «Мансурова Җәмилә Габдулла кызы 1892 – 02.06.2010».

№ 5. «Чуганаева Мөнирә Исхак кызы 1939 – 2009».

№ 6. «Юлаев Рустам Шамилевич (1977–2001)».

№ 7. «Юлаев Фоат .....»

№ 8. «Минкина (1912–2007)».

№ 9. «Савинова Хәбибә Сәетгали кызы (1937–2007)».

## Байавылның II иске зираты

Байавылның уртасында зур гына иске зират бар. Зират мәйданы ерганак, чокырларга бай. Биредә кирәкле мәгълүмат табуга өмет юк иде.

Монда килгәндә авылның I иске зиратын карап бетерә алмаган идем, шуңа үкенергә туры килде, II иске зиратка килгәндә, юл читеннән бер чакрым читтәге зиратка күз салырга туры килде. Шунда мине Байавыл эчендәге зиратка өндәп алып киттеләр. Зиратка барганда мәчет күреп, анда керергә булдым. Аннан безнең ике хезмәттәш чыгып килә иде. Бу авылда имам юк икән. Мәчеттә бер әби генә китаплар караштырып тора иде.

## Танып авылы зираты

Зират Барда төбәгенең башка зиратларындагы кабер өсте һәйкәлләре төркеменнән аерылмый. Монда да шулай арматурадан татар орнаменты мотивлары белән зиннәтләп язган чардуганнар рәте тезелеп киткән. Чардуганнарның дүрт терәге булып торган металл баганаларның башларына ярымай силуэтлары беркетелгән. Чардуганнар зәңгәр, яшел төсләргә буялганнар.

Зиратта шулай ук әле каралып-сакланып килгән, исемнәре язылган эпитафик билгеләре булмаган арматурадан ясалган чардуганнар да күп күренә.

Таныпның бу зиратында да урман кебек. Каен, усак агачлары үсә.

Традиция буларак такта рәшәткәле чардуганнар да сакланган, тузган-искергәннәре дә бар. Ташбилгеләргә һәм чардуган стеналарына кечкенә плитә һәм металл пластинкаларга язылган эпитафик язмалар беркетелгән. Биредә дә эпитафик язма янына мәрхүмнең портретын төшерү гадәте таралган.

№ 1. Арматурадан ясалган, зәңгәр төскә буялган чардуган. Чардуган баганаларының (торбаларның) башларына ярымай символы куелган. Ташбилгедә мәрхүмнең портреты төшерелгән. Аста: «Мансуров Наил Баянович, 1951–2010» дип язылган.

№ 2. Арматура чардуган, аның стенасына эпитафик пластинка элеп куелган. Пластинка үлчәмнәре – 25×35 см. Ул пластинкага ярымай, мәрхүмнең портреты төшерелгән. Эпитафик тексты: «Зайдуллин Хатымҗан, 1930–2008».

№ 3. Арматура чардуган, зәңгәр төскә буялган. Чардуган эченә эпитафик ташбилге утыртылган, үлчәмнәре – 8×40×140 см. Аның тимпанында ае бар. Мәрхүмәнең исеме ташка уеп, бүгенге татар язуы кысаларында, басма хәрефләр белән язылган: «Гумарова Мәликә Садыйк кызы...»

## Таныпның II (борынгы) зираты

Бу зиратның иң кызыклы һәйкәле булып кызыл кирпечтән тау битенә терәп салынган төрбәсе санала.

Төрбә эчендәге ташбилгенең үлчәмләре – 36×41×150 см. Ясалу рәвеше – турыпочмаклы (дүрт кырлы). Ташның дүрт ягында да язулар бар. Алар гарәп графикасында язылган. Кайбер урыннарда язмалар бозылган (ватылган), укырлык түгел. Укыла алган юллар хәзерге татар графикасына күчерелеп бирелә.

1 нче ягында

1. Тарих румийә илән
2. Беңдә сигез йөз дә йитмеш
3. Тукызынчы йылда
4. Мәгърүрә мәрхүмә
5. Гайникамал мулла

2 нче ягында

1. Болади кызы
2. Дарел-фанадин дар-
3. элбакайа рихләт әйләди

4. Гаффар Аллаһ бу...
5. Амин

3 нче ягында

1. Хәлали
2. Дар икрар рухына
3. Б.... ...... .... әл-аһар
4. Амин йа могайан[1]
5. Фи сәнә 1879

4 нче ягында

1. Һу аллахи әлләзи әл-мәвәт
2. Сахиб-әлмәркад[2] хи Әҗлә
3. Әлмин һазә ..... ... гур
4. әлмәрхүм Хәйреззаман
5. бине мулла Габди бине Әл Кенәви

Бу шәхеснең тормыш юлы һәм татар мәгърифәтен күтәрү өлкәсендәге эшчәнлеге хакында беркадәр мәгълүмат Ризаэддин бине Фәхретдин хезмәтләрендә саклана[3].

Хәйреззаман бине Габдешнең, шәхесе генә түгел, аның гүре өстенә корылган затлы төрбә дә аның белән кызыксынуны күтәрә торган корылма булып санала.

Төрбә яндырылган кызыл кирпечтән тау битенә бер кадәр эчкә кертеп салынган. Аның тышкы яктан үлчәүләре – 920×950 см (эчке яктан – 816×838 см) Төрбә эченә керә торган юлда агачтан ишек ясалган. Ишекнең биеклеге – 180 см, ишек оясы киңлеге – 118 см.

Төрбәнең түбән ягы диварының биеклеге 450 см чамасы. Тау ягына кертеп салынган дивары биеклеге 200 см.

Дөрбәнең дүрт почмагыннан дүртәр кирпечтән өелгән баганалар күтәрелеп тора.

Баганаларның үлчәмләре – 50×50×136 см. Моннан тыш багана башына калайдан 45 см биеклектәге конуссыман корылма эшләнгән. Баганаларның биеклек үлчәве стена өстеннән алып хиса-

---

[1] Могайан – ачык, айык.
[2] Сахиб-әлмәркад – кабер хуҗасы, иясе.
[3] Фәхретдин Ризаэддин. Асар. Өченче һәм дүртенче томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 110.

плана. Почмаклардагы баганалар бер-берсенә аратага сугылган 105 см озынлыгындагы рәшәткә системасы белән тоташтырылганнар.

Төрбәнең иң биек стенасы почмакларда җекләрдән аерыла башланган. Тора-бара аның ишелеп төшүе дә мөмкин.

Бу төрбәгә күмелгән Хәйреззаман мөдәррис мәдрәсәсендә атаклы татар шагыйре Гали Чокрый да укыган.

Ризаэддин бине Фәхретдиндә Хәйреззаман мөдәррис турындагы мәгълүмат бик кыска. Аннан соң бу заратка 1897 елда күмелгән Гайникамал шәхесе дә безнең өчен билгесез кала. Гәрчә, Барда төбәгенә багышланган юлкүрсәткечтә, Танып төрбәсенә муллалар күмелгән, дип язылган булса да[1], анда бер генә мулла һәм хатын-кыз кабере булганлыгы ташка язылып калган. Язмалар теркәлгән ташбилгенең үлчәмнәре – 36×41×150 см.

Бу гүзәл бина соңгы гасырларда төзелгән татар төрбәләре арасында иң зурысы һәм иң матуры булып тора. Ләкин аның, вакытлар узу белән, ныклыгы какшаган. Диварларның шактый ярылган урыннары күренә. Аның эчен һәм аеруча тирә-ягын тәртиптә тотсалар иде, чөнки монда бит татарның Барда ягындагы иң атаклы мәгърифәтчесе күмелгән.

### Солтанай авылындагы яңа зират[2]

№ 1. Ташбилгедәге текст:

1. Әгузе билләһи миннәш-шәйтанир-раҗим
2. Бисмиллаһир-рахманир-рахим
3. Көлли нәфсин даикател – мәвәт
4. Садыйк Аллаһә әл-газыйм
5. Әрмәншаһ улы Мөхәммәд – Гата
6. Хаҗи Мансуров, 1834
7. Йылда дөньйага килеб 1924 йыл-
8. ның 21 гыйнварында мәңгелеккә күчте
9. Аллаһның рәхмәтендә булсын.

Ташбилгенең үлчәмнәре – 8×50×120 см.

[1] Пермский край. Барда: путеводитель. СПб.: Изд-во Маматова, 2009. С. 73.

[2] Текст Солтанай авылының яңа зиратындагы яңартылган ташбилгедән күчереп алынды. Аның иске зиратын карап өлгермәдек.

Бу мәхрүм Солтанай авылында «Мансурия» җәдид мәдрәсәсен салдыра. Мәдрәсә 1917 елгы инкыйлабка кадәр Уралның иң зур мәгърифәт учакларыннан берсе була. Мәгърифәтче һәм иганәче ишан хәзрәтне һәрчак зур хөрмәт һәм ихтирам белән искә алалар.

№ 2

1. Бу мәркаддә йолдызда
2. Хак Тәгалә-и әмринә разыйа
3. Латифа Нәүширован хәзрәт
4. Кәримәсе, Мөхәммәд –Гата хәзрәт
5. Хәлиләсе 60 йәшендә
6. Рабигыль-ахыр 17 сендә, сәнә-и 1325 һиҗрийәдә
7. Аллаһ урныйна тоташтыргай
8. Амин

Искәрмә: 1325 елның 17 рабигыль – ахыры румия 1907 елның 28 июленә туры килә.

Текст ташбилгедән күчереп алынып, хәзерге графикага күчерелде, ул гарәп язуының сөлес ысулында язылган, сакланышы яхшы хәлдә. Күпертеп язылган, каллиграфик матур язу белән башкарылган.

№ 3

1...
2. Муллаҗан
3. бине Мөхәммәдҗан
4. Корбангалиев
5. Пирме губирнасы
6. Уса өйәзе
7. Барда ...
8. ...

Искәрмә: Эпитафик текст гарәп графикасының тәгъликъ ысулында язылган. Ташбилгенең сыйфаты бик начар, кайбер юлларында коелып төшкән урыннар бар.

№ 4

1. Бихөкем Аллаһ
2. Сахибел кабер ахунд
3. Мулла Касыйм бине мулла

4. Мөхәммәд–Гата Мансури – галим бәндә
5. күб иҗтиһадлар кыйлуб
6. 1326 нче сәнәи һиҗрийәдә
7. ...

Искәрмә. Ташбилге гарәп язуының сөлес ысулында күпертеп язылган. Вакыт азлык сәбәпле аны фотога гына алдык. Баштагы ике кадр укырлык булып, соңгы кадр бозылган иде. Шулай да эпитафик текстның күпчелек өлеше сакланганлыктан, аны монда тәкъдим итәргә булдык.

Төбәкнең ташбилгеләрен һәм зиратларын комплексլы өйрәнү беренче мәртәбә башкарылды. Дөрес, Солтанайда һәм Танып ягында күренекле кешеләрнең каберләре булу турында Ризаэддин бине Фәхретдиннең кыска искәрмәләрендә һәм Барда төбәгенә багышланган юлкүрсәткечтә Танып авылы төрбәсе искә алып үтелгәнен әйткән идек инде.

Барда төбәгендәге 13 авылның 18 зираты белән танышып чыктык. Нигездә безнең эшебез уңай барды һәм татар эпиграфика фәненә өстәмә бай мәгълүмат өстәлде.

Төбәктә язулы ташбилгеләр кую традициясе 1880 еллардан башлана. Татар дөньясында ташбилгеләр кую йоласының күп гасырлык тарихы бар. Ул, беренче чиратта, дәүләтчелек традициясе булу белән бәйле күренеш. Аннан соң XIII–XVIII гасырларда ташбилгеләр куйдыру гадәттә укымышлы галимнәр һәм имамнарга, югары катламга караган затларга хас булган. Икътисади күтәрелеш дәверләрендә бу йоланы атаклы һөнәр осталары, сәүдәгәрләр дә үз итә башлыйлар. Татар культурасы тәэсирендә ташбилгеләр кую гадәте 1880 елларда, хәтта чувашларга, мариларга һәм мордваларга да керә башлый.

Татар зиратларына ташбилгеләр кую күренеше 1930 елларга кадәр тоташ бер милли юнәлеш булып үсеп, үзгәреп килә. Ләкин 1930 елларда милли алфавитыбыз булган гарәп алфавитына, ислам мәдәниятенә, мөселман руханиларына карата СССРда башланган кызыл террор безнең күп милли традицияләребезне юкка чыгаруга китерде.

Кабер өстенә ташбилге кую гадәте дә 1950 елларга хәтле өзелеп торды. Шунысы кызыклы, яңалиф алфавитының татар кабер ташларына керүе бик сирәк очракларда гына булган. Без аның үрнәкләрен Барда зиратларында бөтенләй очратмадык.

1960 еллардан халыкның күп авырлыклар күрүдән соң бераз гына сулу алып, зират традицияләренең яңаруы башлана. Дөрес, анда инде 1930 елларга кадәр дәвам иткән эпитафик текстлардан мөселман догаларын бирү традициясе нык кысылды. Ташлардагы ислам догаларыннан иң популяр булганы – иман кәлимәсе саклана, ләкин перспективада аның да яшәвенә өмет аз була. Ислам рухы буларак, ташбилге тимпаннарына ярымай символы куелуны әйтергә кирәк, кайвакыт ул ярымай-йолдыз композициясе рәвешен ала. Шулай ук ташбилге язма текстлары, хәзергә сирәгрәк булса да урыс телендә дә күренә башлады (бигрәк тә исем-фамилияләрне язганда). Кайбер текстлар татарча язылган булса да, сирәк кенә, мәрхүмнәрнең якыннары урысча христиан теләкләрен дә өстәп язалар.

Гарәпчә язылган дәверләрдә Барда төбәге ташбилгеләрендә матур шигъри үрнәкләр теркәлү очраклары булган, хәзер исә алар күренми диярлек.

Гомумән алганда, Барда татарлары ташбилгеләрендә бу төбәктә яшәүчеләрнең туган телгә мәхәббәте көчле булуы чагыла.

# ДРЕВНИЕ КОРНИ БАРДЫМЦЕВ

*Мирфатых Закиев*

По этнической истории бардымцев написано много трудов. Особенно важные из них: сборник научных трудов «Пермские татары», опубликованный сотрудниками ИЯЛИ КФ АН СССР в 1983 году; Фатыйхов Әмир. Гайнә иле. Борынгы Гайнә олысы, Пермь татарлары тарихыннан (Барда, 2002); Черных А.В., Устемирова Л.И., Моргун Д.Ф., Мулланурова Д.Д., Плюхин А.А. Этническая история и культура татар и башкир // Бардымский район: от прошлого к настоящему (Санкт-Петербург: Изд-во Маматова, 2009). Во всех этих и других подобных исследованиях этническая история бардымцев выводится из этнической истории казанских татар и башкир.

Как известно, усилиями некоторых современных татарских ученых этническая история современных татар идентифицируется с историей татаро-монгольских завоевателей. И монгольские завоеватели назывались *татарами*, и современные татары носят этот этноним, следовательно, утверждают они, современные татары – это потомки Чингизхана. Между тем, эти завоеватели состояли из представителей различных племен, но поскольку в авангарде их шли обреченные на смерть племена, названные со стороны чингизидов татарами, вся рать Чингизхана носила название *татары*.

Примерно по такой схеме объясняется этническая история «пермских татар» в вышеназванных трудах, лишь Амир Фатыхов пытается установить более древние дотатарские периоды развития «пермских татар».

В книге «Пермские татары» высказывается мысль о том, что в Бардымские земли переселились казанские татары в период завоевания Казанского ханства русскими[1].

Д.Б. Рамазанова в статье «К истории формирования говора пермских татар», подробно изучив говоры этого региона, делает вывод, что «решающая роль в формировании говора пермских татар как одного из говоров татарского языка принадлежит поволжско-татарскому компоненту»[2]. По ее мнению, пермские татары – это потомки казанских татар.

В результате заблуждения европоцентристской тюркологии, широко распространилось мнение, считающее всю Европу и наиболее плодотворные регионы Азии исконными землями европейцев и, в целом, индоевропейцев. Европоцентристы утверждают, что тюрки как дикие кочевники формировались якобы только в VI–VII вв. нашей эры на Алтае и оттуда распространились на свои современные территории только в VII–IX вв. нашей эры.

Между тем **адекватная тюркология** доказывает, что тюрки жили в различных регионах Евразии, может быть и Африки, еще 20–30 тыс. лет тому назад, т.е. еще до переселения сибиряков на Американский материк, жили, естественно, не под названием *тюрк*, а под другими этнонимами. Самые известные из них носили или носят нижеперечисленные древние первичные этнонимы или образованные на их основе вторичные и третичные этнонимы:

1) *ар*/*ир* ‘люди, мужчины’, *субар* ‘речные люди (варианты: *сумер, сабир, сибир, суар*)’, *дагар*/*тохар* ‘горные люди’, *тавр*/*тауэр* ‘горные люди’, *биар*/*бекар* ‘богатые люди’; *балкар*/*болгар* ‘городские ары’ и др.

2) *ас(алан)* ‘молодые’, *суас* ‘водные асы’, *огуз(ок-ас)* ‘окские асы’, *хорезм (хуар-ас-м, суар-ас-м)* ‘мои суарские асы’, *хакас (хак-ас, сак-ас)* ‘сакские асы’, *асгабад (ас-г-абад)* ‘населенный асами’ (город Ашгабад) и т.д.;

3) *сак/сака* ‘род, племя’, *косак/касак* ‘белые саки’, *сакалиба (сакалы-бай)* ‘богатые, в составе которых имеются саки’, *кыпчак/кусак* ‘белые саки’, *сакалы/сакады/скъдъ* ‘племена, в составе которых имеются

[1] Пермские татары: сборник трудов: отв. ред. А.Х. Халиков. Казан, 1983. С. 156.

[2] Там же. С. 150.

саки' (*скъдъ* = рус. *скиф)*. При этом часть хакасского народа носит название *сагай,* а якуты называют себя *саха;*

4) *сюн/хун (хунну)* 'люди, человек', *жужан/сусюн/сусан* 'водные сюни', *кусюн/кусан/косан* 'светлые сюны', *усунь (ас-сюн)* 'асские сюны' и т.д.;

5) *бай(бек/би/пи)* 'богатые', у огузов концепт 'богатые' передается словом *вар-лы>барды>парды* (рус. *парфы), биар* 'богатые люди', *биляр* 'владеющие люди', *каспи (кас-пи, кас-би)* 'богатые скалистых гор' и др.;

6) *ок (ак)* 'род, племя', древние тюрки называли себя *ок; огур (ок-ар)* 'окские люди', *тюрк (ту-эр-ок)* 'оки горных людей', *трак* – фонетический вариант этнонима *тюрк* и др.;

7) *мин (мен, ми)* 'человек', *туркмен* 'тюркские мены', *миде/миле* 'племена, в составе которых имеются племена *мин/ми* (отсюда *миндеде, ми-де= Мидия) ',* 'племена вместе с минями' и т.д.[1]

8) *кот/гот* 'душа, душевные', *визегот/бизәготы* 'раскрашенные готы', *гот+алан* 'готские аланы' (оттуда и *каталоны*), у которых прежний тюркский язык смешивался с испанским, французским и другими западноевропейскими языками.

В данном случае нас интересует этноним *бай/бек/би/пи*, носители которых вместе с носителями этнонима *ар/ир* еще в начале или в середине нашей эры создали государство *Биарм* 'Мой биар – моя страна богатых людей'. Скандинавские источники сообщают, что *Биармланд* был самой богатой страной. Наши исследования дали возможность утверждать, что столицей *Биарма* был город *Биляр*[2].

Кстати, и топоним *Пермь* восходит к названию страны *Биарм,* следовательно, в регионе нынешнего Пермского края жили *биары* 'богатые люди'.

По итогам исследований А.Н. Самойловича, в тюркских языках концепт 'богатый' сначала (еще до н.э.) выражался словом *пар/парлы/парды* (озвонченный вариант: *бар/барлы/барды*), лишь позже в этом значении появилось слово *бай/би/бек*[3]. В огузских языках и в наши

---

[1] Закиев М.З. История татарского народа: этнические корни, формирование и развитие. М., 2008. С. 127.

[2] Закиев М.З. Происхождение тюрков и татар. М., 2003. С. 378–396.

[3] Самойлович А.Н. *Богатый* и *бедный* в тюркских языках // Его же. Тюркское языкознание. Филология. Руника. М., 2005 (первое изд. 1936). С. 291–330.

дни значение ‘богатый’ передается словом *барлы/варлы*, а слово *бай/бей* означает ‘уважаемый господин, государь мой’. Естественно, и это значение связано со смыслом ‘богатый’.

Топоним *Барды/Барты* означает смысл ‘богатый’. Здесь аффикс *-ды, -ты* является синонимом *-лы*. Сравните: татарское *Таллы курган*, казахское *Талды курган*, татарское *Элмәле* (Элмә – ильм) ‘ильмовый’ в древности произносилось ка *Элмәте*, когда аффикс *–те* потеряло свое значение *-ле*, слово сузилось до *элмәт – Әлмәт* (Альметьевск). Этноним *барды* сохранился в названиях *Бардымский хребет*, реки *Барды* и сел *Барды, Бартым*. Поскольку в русском языке нет краткого звука [ы], слово *Барды* произносится как *Барда*. Народ с любовью называет свой топоним *Бардым* ‘мой Барды’.

По-видимому, племена *барды/парды* ‘богатые’ имели тесные контакты с огузами и продолжателями их языковых особенностей – мишарами, поэтому древний этноним *барды* стал пониматься только как топоним *Барды/Парты.*

Этнонимом *барды/парды* еще задолго до нашей эры назывались сильные, богатые племена Средней Азии. На иностранных языках, в частности в английском языке, этот этноним сохранился в первоначальном виде, например, этот древний народ *барды/парды* они называют «*The Parthians*». В русском языке тюркский или даже греческий *th* (интердентальный д) читается и пишется через *ф*: *парды > парфы* (парфяне), *сакады > скыды > скиф, Athena > Афина* – древнегр. ‘богиня мудрости’.

Как известно, в Средней Азии древнейшим государством (после Шумер/Сумер/Субар ‘речные люди’) был Хорезм, название которого восходит к *ху-ар-ас-ым ‘мой һу-ар-ас-ым/суарсм’* ‘моя страна асов речных людей’. С хорезмийцами были тесно связаны *парфяне* (т.е. племена барды ‘богатые’), которые создали свое мощное государство.

Парфянское царство – это древнее государство, возникшее около 250 лет до н.э. на юге и юго-востоке Каспийского моря и подчинившее в период своего расцвета (в сер. I в. до н.э.) обширные области от Месопатамии до границ Индии. Коренным населением Парфии были земледельческие парфы/парды. *Парды/парфяне* в течение нескольких веков выдерживали извечную борьбу с Римом. Основное ядро Парфянского государства сложилось под эгидой древнего Хорезма. Империя возглавлялась од-

ной из ветвей хорезмийских сиявушидов[1]. Она существовала до середины III в. н.э.

В самом начале нашей эры рядом с Парфянским царством появилось Кушанское (Косанское) царство, которое включало значительную часть Средней Азии, Афганистана, Пакистана, Северной Индии, возможно, Синьцзяна. Даже Хорезм находился в зависимости от Кушанского царства.

В европоцентристкой (т.е. традиционной) исторической науке считается, что и хорезмийцы, и парфяне, и кушаны были ираноязычными, их потомки отюречились лишь в IV–VII вв. н.э. под влиянием пришлых тюркских кочевников. Общеизвестно, что ассимилируются обычно пришлые под влиянием аборигенов. Следовательно, тюрки с самого начала были аборигенами. Еще в V в. до н.э. Геродот писал, что в войске иранского царя Ксеркса *парды, хорасмии, согды, гандарии и дадики* составляли вместе один отряд[2]. Этнонимы всех этих народов являются тюркскими. Так, *хорасм* – это *хуарас-м* 'мои суарские асы', *согды-сакды* 'сакские', *гандар-хандыар* 'люди, имеющие хана', *дадик — тат-ок* 'чужие оки', *парды/барды* 'богатые' Что касается этнонима *кушан,* то это только искаженная передача этнонима к*осан/кусян* 'белые сюны, т.е. хуны'.

В традиционный исторической науке регионами расположения парды *(парфяны), хуарасм/хорезм, кусан/кушан* считается в основном Средняя, Передняя Азия. Но все эти племена были распространены и в других регионах. Так, племена *суар, ас, кушан/косан/казан, парды/бырды* жили и в Урало-Поволжье.

*Парды/барды* зафиксированы и в Азербайджане, где до XIII в. существовал цветущий торгово-ремесленный центр *Барда/Барды,* который в 30-е годы XIII в. монголо-татарами был превращен в развалины. На Карабахской равнине центр *Бардинского* района называется также *Барда/Барды,* возможно, это и есть тот же торгово-ремесленный центр, разрушенный татаро-монголами. Но в азербайджанских справочниках название *Барда/Барды* ошибочно признается измененным вариантом арабского слова *Бердаа.*

---

[1] Толстой С.П. Устемирова Л.И., Моргун Д.Ф. и др. Этническая история и культура татар и башкир // Бардымский район: от прошлого к настоящему. СПб.: Изд. Маматова, 2009. С. 131–132.

[2] Геродот. История в девяти книгах. Л., 1972. С. 66.

В отличие от азербайджанских, прикамские *барды* имели очень тесные связи с среднеазиатскими *барды* (в русском произношении парфяне). Наличие тесного многовекового взаимоотношения между Средней Азией и Прикамьем отмечается исследователями Средней Азии. Так, С.П. Толстов, подробно изучив Древний Хорезм, пришел к выводу, что «по древним, проторенным еще в неолите (т.е. в 8–3 тысячелетиях до н.э.) путем Хорезм простирает свою гегемонию на далекое Прикамье»[1].

О тесных связях Средней Азии с Прикамьем еще задолго до нашей эры красноречиво говорят факты обнаружения в Прикамье так называемых хорезмийских, парфянских (пардымских) и кушанских монет и серебряных сосудов с надписями[2]. Они найдены в большом количестве у прикамского села *Бардым*/*Партым* в Пермском крае. Раньше, когда их обнаруживали, эти находки поступали преимущественно в переливку, лишь с XVIII века их начали коллекционировать[3]. Еще в XVIII в. Ф. Страленберг пытался находками «южного» серебра в Прикамье доказать существование великого торгового пути из Индии в Биармию и к Белому морю. Ту же мысль высказывали и в XIX в., утверждая, что серебряные драгоценности зарывались в землю Прикамья приезжими купцами и, следовательно, не имели отношение к местному населению [там же, 20]. Такое мнение было высказано исходя из представления людей севера неспособными иметь дело с цветными металлами. Пермский археолог конца XIX в. Ф.А. Теплоухов выступил против наличия торгового пути и высказал предположение об использовании серебра Урала в языческих святилищах ханти и манси[4]. С этим мнением затем согласились почти все исследователи, они предполагали, что использование серебряных сосудов на Урале и в Прикамье в культе обусловило огромный приток их с юга. По их мнению, в районе села Бартым, по-видимому, существовал

---

[1] Толстой С.П. Древний Хорезм (опыт историко-археологического исследования). М., 1948. С. 342.

[2] Мухаммадиев А.Г. Туранская письменность // Проблемы лингвоэтноистории татарского народа. Казань, 1995. С. 36–39.

[3] Бадер О.Н., Смирнов А.Н. «Серебро закамское» первых веков нашей эры. Бардымское месторождение. М., 1954. С. 5.

[4] Теплоухов Ф.А. Древности пермской чуди из серебра и золота и ее торговые пути // Пермский край. III. Пермь, 1895.

большой экономический центр, где сосредоточилось большое количество импортных вещей[1].

Как было сказано выше, эти связи Прикамья и Средней Азии осуществлялись главным образом тюрками: и в Прикамье, и в Средней Азии еще до нашей эры жили тюркоязычные племена. Об этом говорит и тот факт, что хорезмийские, пардымские (парфянские) и кушанские надписи на монетах и серебряных сосудах, найденных в Прикамье, оказались тюркскими. Это доказано в исследованиях А.Г. Мухамадиева[2]. Долголетние попытки прочитать их на основе иранского языка не дали никаких результатов.

Осталось выяснить: что привлекло внимание древних хорезмийцев, пардов, кушанов в Прикамье? Наш ответ: по-видимому, не только пушнина, а главным образом прикамские серебряные месторождения. До сих пор ученые не догадывались, что обнаружение в Прикамье серебряных монет и сосудов непосредственно связано с **наличием здесь же серебряных месторождений.** Местное население Прикамья – предки булгаро-татар еще задолго до нашей эры занимались добыванием серебра, это привлекало внимание и хорезмийцев, и пардов, и кушанов Средней Азии, а также и скандинавов, и вообще западноевропейцев. О том, что в Прикамье были серебряные залежи и население занимались добыванием серебра, во-первых, говорит слово *нократ* ‘серебро’, которым назвали и булгарских добытчиков серебра в районе верхнего течения Вятки, и саму эту реку, во вторых, об этом написано и в старинных русских источниках XIV в. В них отмечены наличие «закамского серебра» и взимание серебряной дани с населения Приуралья и Прикамья.

В результате добывания серебра у прикамского населения наладилась торговля серебром и, может быть, серебряными изделиями. Вряд ли было разумно хорезмийцам привозить в Прикамье готовые серебряные сосуды с надписями, они были изготовлены здесь же возле месторождения серебра. Поэтому в Прикамье находили эти сосуды в большом количестве. Это показывает, что из Прикамья были проложены серебряные пути в разные стороны. Основным,

---

[1] Бадер О.Н., Смирнов А.Н. «Серебро закамское» первых веков нашей эры. С. 23–25.

[2] Мухаммадиев А.Г. Туранская письменность. С. 36–83.

вероятно, был путь между Прикамьем и Средней Азией, который связывал тюркские племена обоих регионов.

Удмурты до сих пор называют булгаро-татар этнонимом *бигер,* который восходит к *бэк-ар* ‘богатые иры’. *Биары, бекары, биляры, байлары, барды/парды* зафиксированы в Урало-Поволжье еще в материалах XII–VI вв. до н.э.

Судя по буквам надписей Хорезмийских и Парфянских чаш, можно заключить, что эти серебряные чаши изготовлены литьем в самом начале нашей эры до активного применения рунического алфавита в V–VII вв. н.э.

Следовательно, тюркские племена *барды, биар, биляр, бигер (бэк-ар)* старались максимально использовать серебро месторождений на Среднем Урале. Надо полагать, что племена *барды-парфяне,* находясь в тесном общении, организовали изготовление серебряных изделий в районе Среднего Урала, а именно на месте современных сел *Бардым/Бартым.* Таким образом, мы можем заключить, что возраст *деревень Бардым, Бартым составляет* более 1500 лет. На добывание серебра среднеазиатские барды (парфяне), по-видимому, посылали и своих людей. Поэтому среди местных блондинов мы часто встречаем южных смуглых.

Серебряные чаши, изготовленные на Среднем Урале



Парфянская серебряная чаша.
Государственный Эрмитаж



Хорезмийские чаши [Толстов С.П., 1948]

В начале статьи мы сказали, что этническую историю не только бардымцев, но и казанских татар нельзя свести к появлению этнонима *татар* и *тюрк*. Применение этнонима *тюрк* активизировалось лишь в VI–VIII в. н.э., а этноним *татар* – лишь в начале XX в.

Мы считаем, город Казань был основан более чем полутора тысяч лет назад *кусянами*/*косанами* ‘белыми сюнами, т.е. белыми хуннами’ и *усунями* в русском произношении. *Усунь* – по-тюркски это *ас-сюн* ‘асские сюны-хунны’. Следовательно, вокруг Казани, как ее основатели, жили *сюны*/*хунны* и *асы*. В древнейшее время *асы* по Волге и Каспийскому морю распространились по многим регионам. Например, в Туркменистане в древности *асы* также оставили свои следы: современный Ашхабад раньше назывался *Асгабад* ‘заселенный асами’. Название города *Астрахань* также восходит к *Ас-тархан* ‘асские тарханы’. Монгольское государство вынесло решение о том, чтобы Батый, после трех поражений от булгар, завоевал земли *асов, булгар и русов*. Город *кусян* (косан) в то время назывался *Асил*. Батый хан сравнял с землей *Биляр* и *Асил*. Асил был позже восстановлен, ему было возвращено его прежнее название *Кусян*/*Косан*.

Биляр был столицей народа *биар* (страны Биарма/Биармланда). В то время именно Биляр организовал три булгарских решающих отпора Батыю, поэтому Батый не дал согласия на восстановление Биляра. *Булгары* – одни из предков современных татар – затем были вынуждены восстановить населенный пункт *Булгар* и объявить его своей столицей.

Я выше уже говорил, что удмурты даже современных татар называют *бигер*/*бәкир* ‘богатые иры’.

В XVI в. при первой переписи населения, организованной русским правительством, все тюркское население вокруг Казани записывались этнонимом *суас* ‘водные или речные асы’. Кстати, марийцы современных татар называют *сюасами*, а чувашей – *сюасламари* ‘осюасившимися марийцами’. Позже в русских и иных источниках сообщается, что в Среднем Поволжье и Приуралье живут *косаны*/*казаны* и *булгары*. Как исследователь этнической истории современных татар и целом тюрков, мы пришли к выводу, что современные татары формировались в результате консолидации *косанов* ‘белых сюнов’, асов (сюасов) и булгар в один народ.

Этноним *татар* применялся русскими уже в конце XV в.и особенно XVII–XIX вв. как название сначала всех восточных народов,

а с XVIII в. – только всех тюрков. В 1920 г. название *татар* узаконилось среди косанов и булгар, а другие тюркские народы сбросили навязанный русскими этноним *татар* и возвратили свои прежние этнические самоназвания.

Бардымцы, говорящие испокон веков на своем родном языке, который был идентичен с биарским, булгарским, косанским говорами, постепенно забыли о своем древнем этнониме *барды* ‘богатые’, в период формирования *булгаро-татар* (совр. татар) и *башкир* начали называть себя башкирами или татарами.

Этноним *татар* воспринимается народом не всегда положительно, т.к. в учебниках истории русских и зарубежных народов к татарам отношение сугубо отрицательное, ведь в них татарские завоеватели и современные татары идентифицируются. Поэтому отрицательное отношение переходит и к современным татарам – потомкам косанов, асов и булгар. Такое отношение к татарам в какой-то степени принято и бардымцами, поэтому они предпочитают называть себя башкирами. Так, по переписи 1989 года общая численность татар и башкир в Бардымском районе составляла 26411 чел (24952 башкир – 94,5%, 1459 татар – 5,5 %. «Перепись 2002 г. отметила в Бардымском районе 16606 тыс башкир (59,9% от населения района, 64,79% от численности татар и башкир района). 9025 тыс. татар (32,3% от населения района, 35,21% от численности татар и башкир)»[1].

Эти данные говорят о том, что бардымцы в XVIII–XX вв. не приняли этнонима *татар*, по-видимому, продолжали называть себя древним самоназванием *барды* ‘богатые’.

---

[1] Черных А.В., Устемирова Л.И., Моргун Д.Ф. и др. Этническая история и культура татар и башкир. С. 131–132.

## БАРДА ЯГЫ – БАРЛЫ ЯК

*Фирдәвес Гарипова*

Барда ягында әйбәт, кунакчыл, эш сөючән, кеше ярата торган мәгънәле халык яши. Алар матур көн итәләр. Бу төбәктә үткәннәренә зур игътибар бирәләр. Чөнки «Үткәннән башка – киләчәк юк»ны алар бик яхшы аңлыйлар. Бу фикерне басма хезмәтләр дәлиллиләр[1].

Пермь крае, Барда районындагы халыкның 92 процентын татарлар һәм башкортлар тәшкил итә. Шулай ук анда руслар һ.б. милләт халыклары да яши. Бу районда халыкның күбесе авылларда көн күрә. Барда бәрәңгеләре бөтен Пермь крае халкы тарафыннан тәмле дип, яратып кабул ителә, ул бөтен өлкәдә данлыклы ризык. Бу районда җитештерелә торган бөтен авыл хуҗалыгы продукциясе дә Пермь крае халкы тарафыннан яратып кулланыла.

Биредә ел саен үткәрелә торган «Барда җыены» күңелле һәм матур уздырылуы белән, районнан тыш, башка күп урыннарда да билгеле һәм үз була. Ә 2013 елда ул бөтен Россиягә билгеле булып киткән авыл сабан туе дәрәҗәсендә үткәрелгән. Кунаклар күп килгән.

---

[1] Бардымский район: прошлое и настоящее. СПб.: Изд-во Маматова, 2009; Валиуллин Р.Ш. Очерки по истории родного края: учеб. пособие. Барда, 1998; Валиуллин Р.Ш. География Бардымского района: учеб. пособие. Барда, 2002; Зимасов Н.Ш. Барда сүзлеге. Барда, 2005; Казанцева О.А. Каталог археологических памятников Бардымского района Пермской области. Ижевск, 2004; Кәримов Г.З. Якты йолдызлар. Барда, 2005; Пермский край. Барда: путеводитель. СПб.: Изд-во Маматова, 2009; Эш күрсәткән ирне ил онытмас. Барда, 2010; Пермский край. Бардымский муниципальный район. Приглашение к сотрудничеству. Барда, 2013.

Бардалылар эштә дә, тормыш итүдә дә, мәдәният, спорт, уку-укыту һ.б. өлкәләрдә дә сынатмыйлар, тырышлар, максатчаннар һәм булдыклылар. Татар кайда гына яшәсә дә гөлләр кебек чәчәк ата. Буыннан-буынга бирелгән уңганлык, сәләт, талант, сабырлык, эш сөю гадәтләре аларны гел алга әйди, «хәрәкәттә – бәрәкәт» дигән гыйбарәне онытмауларын күрсәтә.

Бу мәкаләдә халык хәтерендә сакланган мәгълүматларга, тарихи чыганакларга таянып *Печмән* һәм *Зязелга* географик атамалары турында сүз барачак.

**Печмән.** Һәр географик атаманың үз язмышы, барлыкка килүе сәбәпләре, үсеше, бераз гына булса да үсеш-үзгәреше булырга мөмкин. Менә шундый топонимнар оясына Печмән атамасы да керә.

Барда районында Печмән исемен йөрткән рус авылы Печмән елгасы буена урнашкан. Ул – җирле үзидарә үзәге. Андагы 172 хуҗалыкта 538 кеше яши.

Татарстан җирендә һәм башка төрки халыклар яши торган төбәкләрдә дә Печмән дигән географик берәмлекләр байтак. Бу гаҗәп түгел. Бер яңгырашлы, бер язылышлы атамаларның төрле урыннарда очравы юкка гына түгел. Халык билгеле тарихи сәбәпләр нигезендә төрле урыннарга күчеп утырган һәм алар җаннарына, халәтләренә якын исемнәрне үзләре белән алып киткәннәр һәм алар белән яңа утырган урыннарын атаганнар.

Татарстан төбәге белән Пермь крае халкының тугандашлыгы, бер-берсенә бәйләнеше көчле. Чәчелгән, сибелгән татарның яшәгән урыннары күп.

Татарстанда *печмән* лексик берәмлеге белән утыздан артык географик атамалар очрый. *Печмән елгалары* – Зәй, Калмия, Кече Мишә, Куак, Мичән, Сәрдә һ.б. елгалар бассейнында (Лениногорск, Тукай, Мөслим, Саба, Арча районнарында) урнашканнар. Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылы янында *Печмән сазы*. Әтнә районының Түбән Шашы авылы янында *Печмән тавы*, Кукмара районының Поршур авылы янында *Печмән үзәне* бар һ.б.

Арча районында Печмән-Тау исемендәге авыл бар. Саба районында Печмән исемендә җыен бәйрәме дә үткәрелгән. *Печмән* сүзе белән ясалган атамаларның инде тарихтан төшеп калганнары да бар. Элек Яңа Писмән исеме йөрткән авыл хәзер Лениногорск исеме алган шәһәргә әйләнде. Ә шул ук районда Иске Писмән авы-

лы әле дә яши. Бөгелмә районындагы Солдат Писмәнкәсе авылы да яши әле.

Бу очраклар *печмән* сүзенен кайчандыр *писмән* дип әйтелүен һәм язылуын раслый. Халык телендә һәм рәсми кулланмаларда да алар шулай бирелә. Татар телендә *ч ~ с ~ т* авазлары күчешен дә истә тоту зарур.

*Печмән* сүзе белән ясалган атамалар чит төбәкләрдә көн итә торган татарлар телендә дә кулланыла. Башкортстанның Бәләбәй районындагы *Писмән* – Үсән елгасының уң кушылдыгы. *Печмән сазлыгы,* Дүртиле районының Урман асты авылында *Печмән чокыры*. Оренбург өлкәсенең Куандык районында *Бесмән* авылы бар.

Адлер Камил улы Тимергалин төзегән «Миллият сүзлеге»ндә *печмән* тарихи дип ныгытылган һәм «Татар теленең урта диалектында *печмән* сүзе өч алымда билгеләп үтелә торган язгы бәйрәмне белдерә (*бәләкәй печмән, икенче печмән, өченче печмән*). Аны язгы чәчүдән соң кырауларны куып җибәрү максаты белән бәйрәм иткәннәр. Атаманың этимологиясе ачык түгел. Дөрес, Р. Әхмәтьяновта бу сүз русча *веснянка* сүзеннән, дигән фикер очрый. Охшаш сүз удмурт һәм мари телләрендә дә бар («ызан, җир очы» мәгънәсендә дип ачыкланган)», дип бирелә.

*Печмән* сүзе нәрсәне аңлата? Казан дәүләт университеты доценты Әнвәр абый Әфләтунов фикеренчә, «типтәрләр сөйләшендә олы буын телендә генә сакланып калган *печмән* сүзе – урманның агачлары кисеп алыну нәтиҗәсендә барлыкка килгән ачык урыны»[1]. Борынгы бабаларыбыз елга буена йортлар салып, урман кисеп чәчүлек җирләр ачканнар. Бу басулар әле дә өлкән буын телендә ышна басулары дип аталалар.

**Зязелга.** Барда районының Печмән авылы җирлегенә Зязелга авылы да керә. Авылда бары 50 хуҗалык, халкы – 150 кеше.

Бу очракта Зязелга атамасын Сазъелга дип аңларга кирәк дип уйлыйм. Мондый типтагы атамалар Татарстанда да очрый. Кукмара шәһәр тибындагы бистәгә (поселокка) җитәрәк, тимер юл буенда Состамак тукталышы бар. Бу тукталыш та *Сазтамак* урынына *Состамак* дип бозып кулланыла. Станциядән якын гына Сазтамак исемендә матур һәм зур гына татар авылы да бар.

---

[1] Әфләтунов Ә. БАССРның көнбатыш, көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләшенең тел үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1960. Б. 165.

Инде авыл атамасының *елга* компонентына тукталып үтик.

**Елга.** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *елга* – башланган урыныннан койган җиренә чаклы үзе салган үзәнлек буенча табигый рәвештә туктаусыз агып торган су[1].

«Елга» компоненты турында Р.Г. Әхмәтьянов мондый мәгълүмат бирә: «Елга (йылга), диалекталь *җылга* «река», диалекталь (Будагов 1 : 439) «суходол» > чуваш *йалка* «шеш үзән», мари *йылга* «елга» < гомумкыпчак: нугай *йылга,* кыргыз *җылга,* казакъ, каракалпак *җылга* ~ уйгыр *йылга,* уйгыр диалекталь, үзбәк *җилға* ~ язма монгол *Qilga,* бурят *жалга* «елгасы булган сай үзән». Бу сүзнең *-у-, -ү-* варианты бар: башкорт *йүлгә* «сай үзән» ~ үзбәк *җулга* «үзән», казакъ *жулга* «елга чык» һ.б. һәм бу вариант сүзне хакас *жул, жүл,* чуваш *ҫăл,* алтай диалекталь *йул* < борынгы төрки[2], «*Jul, jül* «чишмә, кое; тау елгасы» сүзе белән бәйләргә хокук бирә. Ләкин фонетик җәһәттән кайбер сораулар җавапсыз кала. Морфологик җәһәттән *йылга* «йулғай (гай < кай «урын, төш») булса кирәк, кара: рус теле диалектларын да *жалгай, ялгай* «коры яки бик кечкенә сулы үзәнчек» < төрки *йолғай*»[3].

Элек *елга* сүзе бары уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен кулланылган. Хәзерге татар телендә исә ул сүз зур һәм кечкенә елгаларны атау өчен дә файдаланыла: Идел елгасы, Зәй елгасы, Шушма елгасы, Агыйдел елгасы, Кирәмәт елгасы һ.б.

*Елга* апеллятивы үзе генә дә, аерым елга атамалары булып та кулланыла ала, мәсәлән: Елга – Кама кушылдыгы (Балык Бистәсе районы), Олы Сөлчә кушылдыгы (Аксубай районы), Олы Үләмә суы кушылдыгы (Апас районы), Бөре елгасы кушылдыгы (Олы Чура авылы, Кукмара районы), Ык елгасы кушылдыгы (Күҗәкә авылы, Актаныш районы), Эстәрле елгасы кушылдыгы (Уразай авылы, Азнакай районы) һ.б.

Татарстан елга атамаларының күбесендә *елга* апеллятивы атама составында кулланыла: Татарстанның Актаныш районындагы Иске Кадермәт авылында Сабыр елгасы бар. Ул бары яз көне кар сулары ярдәме белән ага. Кар суы җыелып, ташусыз акканга аны

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. I т.: А–Й. Б. 329.

[2] Древнетюркский словарь. М., 1969.

[3] Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Бирск, 2005. Б. 176.

Сабыр елгасы дип атаганнар. Бу елгада кешеләр яз көне кер чайкаганнар, хәтта суын да эчкәннәр. Элек экология әйбәт булган шул. Атау елга – Кече Чирмешән кушылдыгы (Әлки районы), Нарат елгасы – Зөя суы кушылдыгы (Буа районы), Урта елга – Карлы суы кушылдыгы (Буа районы), Артышлы елга – Олы Чирмешән елгасы кушылдыгы (чаг.: Украина гидронимиясендә Артыш/Артиша; Таулы Алтай гидронимиясендә Артыш инеше). Зират елгасы – Уратма суы кушылдыгы (Түбән Кама районы).

*Елга* термины авыл атамалары һәм микротопонимнар составында еш килә. *Елга* компоненты Татарстанда егерме сигез авыл атамасында очрый: Куәтле Елга, Карамалы Елга, Кәкре Елга, Кара Елга, Мөгезле Елга һ.б. Микротопонимнар: Елга басуы, Елга ышнасы, Елга күпере, Елга урманы, Елга тавы һ.б.

Терминның аерым елга атамасы булып кулланылуы, Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә күзәтелә. Ульяновск өлкәсендә: Елга – Кулаткы елгасы кушылдыгы (Усть-Кулаткы авылы, Кулаткы районы), Чалга – чокыр исеме (Богдашкино авылы, Чардаклы районы) һ.б. Самара өлкәсендә: Жигули тирәсендәге Торново авылының төньягында басу уртасында калган Югары Елгуша (Верхние Елгуши) исеме алган үзән, кипкән урын бар. В.Ф. Барашков һәм Э.Л. Дубман фикеренә күрә, атама рус һәм татар теле сүзләре кушылып ясалган. Аның составындагы «елга» сүзе татар теленә нисбәтле. Камышлы районының Яңа Фәйзулла авылында Кондырча елгасын Елга дип атыйлар ягъни термин конкрет зур елганың бер кисәген атау өчен кулланыла. Камышлы районының Татар Байтуганы авылында Елга – Сок суы кушылдыгы. Башкортстанда: Елга – Димнең, Мәтәү елгасының уң кушылдыклары (Әлшәй авылы, Бәләбәй районы), Юеш Калмаш елгасы кушылдыгы (Калтасы районы), Буй һәм Ык елгалары кушылдыклары (Туймазы һәм Янаул районы). Буйның кушылдыгы Елга Башкортстан картасында да күрсәтелгән.

Елга компоненты Татарстаннан читтә яшәгән татарлар телендә атамалар составында еш кулланыла. Ульяновск өлкәсендә: Труша елгасы, Сыерчык елгасы, Киндераш елгасы, Сулак елга, Аркылы елга, Ислай ягы елгасы, Башсыз елгасы – Тирешкә суы кушылдыгы (Яңа Кулаткы, Яңа Зимница, Иске Яндука авыллары, Кулаткы районы) һ.б. Самара өлкәсендә: Тиләгәҗе елгасы, Нәзекәй елгасы, Камышлы елга, Торна елгасы, Соргыт елгасы, Карамалы елга (Иске

Ярмәк, Тат. Байтуганы авылы, Камышлы районы) һ.б. Башкортстанда*:* Абалак елга – Бәрделәк елга кушылдыгы (Баймак районы), Азак елга – Тиләгән суының сул кушылдыгы (Зианчура районы), Ачы елга – Агыйделнең (Ишембай районы) һәм Нәкәс суының уң кушылдыгы (Күмертау районы) һ.б.

Башкортстан җирлегендә *елга* термины кергән авыл атамалары шулай ук күп: Булат елга (Янаул районы), Каен елга (Бәләбәй, Туймазы районы), Утар елга (Тәтешле районы), Сары елга (Стәрлебаш районы) һ.б. Шулай ук бу термин микротопонимнар составында да еш очрый: Ульяновск өлкәсендә: Сәнҗүк маңгае елгасы ачыклыклары, Чебеш елгасы күпере, Тирән елга өсте урманы, Иван елгасы кыры һ.б. Самара өлкәсендә: Имәнле елга басуы һ.б.

Татар теле сөйләшләрендә елга термины төрле фонетик вариантлар белән еш очрый. Гәйнә сөйләшендә җылга, Д.Г. Тумашева мәгълүматлары күрсәтүенчә, Тубыл өлкәсенең Тубыл районы, Лайтамак авылы халкы урталык арасыннан ага торган елганы *Йыгыш* дип йөртә. Татар диалектларында *җылу, җалу* «елга» мәгънәсендә кулланыла. Казан арты сөйләшләрендә һәм әдәби телдә дә көчле яңгыр вакытында һәм язын гына су ага торган ерганаклар *елга* дип атала. Темников, хвалын сөйләшләрендә *елга* дип үзән һәм тарлавыклар[1], мәләкәс сөйләшендә чокырлар йөртелә. Кузнечиха урынчалыгында *елгалык* «кечкенә болын»ны аңлата.

*Елга* терминының таралышы бик киң. Ул элеккеге СССРның төркиләр яши торган төбәкләрендә һәм Көнбатыш Кытай мәмләкәтләрендә дә очрый: каракалпакларда – *җылга,* уйгырларда – *йылга* (чокыр, коры елга юлы, юлга), чувашларда – *йалка* (җылу, елга), *йалкав* (юеш урын), *йалма* (баткак, пычрак), башкортларда – *йылу,* казакъларда – *жалу, жылым, ңылу,* алтай телендә – *јылым* (чокыр, текә тау бите). Шулай ук: Казакъстанда – *жилга* (джилга, жылга), Төркмәнстанда – *джульга* (чокырдагы елга, елгачык), якут телендә – *элгә* (биек текә ярлы, тирән елга), Монголиядә – *жалга* (чокыр, коры елга юлы), Бурятиядә – *жалга, ялга* (чокыр, уйсу җир, коры үзән, канау, киң озын чокыр). Жалга, Жалгай, Елгай, Ялгай – күп санлы түбән урыннарның атамалары (Бурятия). Эвенкиядә – *дэлгэ* (чокыр, елганың кипкән үзәне, киң һәм озын чокыр, канау), Тывада *джалга* (ялпылык, уйсулык, уйсу җир; киң иңкү җир; тар сай

[1] Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. Б. 178.

чокыр), балкар гидронимиясендә – *җайыу* (сайлык, кичү урыны), карачай-балкар телләрендә «елга» мәгънәсендә *суу, къобан, баргъан су* терминнары кулланыла. Шунысы игътибарга лаек: Чыңгыз-хан нөгәренең (нөкеренең) бер улы Илга исемен йөрткән.

Рус язучысы С.Т. Аксаков фикеренчә, элекке Сембер губернасындагы Муелга дигән атаманы руслар Иволга дип үзгәрткәннәр. *Ока* (Ука) суы бассейнында да Елха һәм Жилка атамалары очрый. Иркуртск өлкәсендә Ленаның сул кушылдыгы Илга исемен алган. Кырымдагы Мариуполь греклары телендә – *ялага* (чокыр, инеш, озын чокыр, сыза, коры инеш). Галим И.Ф. Фальк мәгълүматларына караганда, Иртыш, Ом, Тара елгаларын элек себер татарлары Иртыш-Елга, Ом-Елга, Та-Елга дип атаганнар. Ул Бараба иңкүлегендә Уба күле (Яглы-елга) кушылдыгы Кокьяглы, Бакса елгасы кушылдыгы Елгайчик атамаларын теркәгән[1]. *Елга* апеллятивы Көнбатыш Себер елгалары арасында (Тубыл бассейны һәм Иртышның урта агымнарында) еш кулланыла. *Чул* компоненты хакас телендә «елга, кечкенә елгачык» мәгънәсендә йөри: Аншуль, Үзәнчул, Шепчул һ.б. В.В. Радлов «Опыт словаря тюркских наречий» хезмәтендә *чул* сүзенең сагайларда «елга» төшенчәсендә кулланылуын язган. *Чул/йул* – шор топонимиясендә, мәсәлән, Йул елгалары Мундыбаш һәм Кондома кушылдыклары, *чул* – чулым төркиләрендә, *дьул* – алтайлыларда (мәсәлән, Балыкты-Дьул) «елга» мәгънәсендә йөри. М. Кашгари хезмәтендә *jul* сүзенең «чишмә», «чыганак» мәгънәсендә кулланылуы теркәлгән.

Хантылар яшәгән төбәкләрдә *игол (jыгъл)* компонентын алган гидронимнар шактый күп очрый. XVIII гасырда Васюган хантылары телендә *jилга* термины «елга» мәгънәсендә кулланылган. Л.И. Калинина язуына караганда, *jилга* формасы хантылар тарафыннан төрки *jыгъл* терминыннан бераз үзгәреп кабул ителгән. Соңгы форма тобол һәм тура татарларында әле дә кулланыла. А.П. Дульзон *игай* компоненты белән ясалган гидронимнарны да төрки катламга кертә. Мондый атамалар Васюган һәм Юган елгалары арасында күп очрыйлар.

Г.Ф. Саттаров *чул, йул, йулга, йылга* сүзләренең бер тамырдан булу мөмкинлеген әйтә. Элек-электән елгалар тайгада юл күрсәткеч

[1] Фальк И.П. Записки путешествия // Полное собрание ученых путешествий по России, издаваемое Академией наук. СПб., 1824. Т. 6. С. 435, 525.

хезмәтен үтәгәннәр. Елга буйлап баргач, һичшиксез, берәр авыл, поселок һ.б. торак пунктлар очрый.

Экспедиция-сәфәрләр вакытында информант хезмәтен үтәгән өлкән яшьтәге аксакаллар сөйләвенчә, борынгы бабаларыбыз бер-берсен, елга буенча агып килгән йомычкадан белеп, йомычка агымына каршы барып таба торган булганнар. Елгалар, Себер тайгаларындагы кебек үк, безнең якларда да урман арасында йөрү өчен төп ориентир хезмәтен үтәгәннәр һәм үтиләр.

Пермь краеның иң күренекле районнарының берсе – Барда районы. Мондагы халыкның тормышы таза, күңеле көр. Һәр ике авыл җирлегеннән күренекле кешеләр күп чыккан. Ныгытып эшлиләр, матур итеп ял да итә беләләр. Халык бию, җырга да оста. Уңган кешеләр бер өлкәдә дә сынатмыйлар алар. Барда районында яши торган халык бәхетле һәм сәламәт булсын, яңадан-яңа уңышларга ирешеп, теләкләре кабул килеп яшәсеннәр. Дөнья матур, дөнья киң, ул бөтен кешегә җитә.

Район хакимиятендә эшләүчеләрнең күңелләре бай күренә, йөзләре иманлы. Шуңа күрә ул төбәккә уңыш та, бәхет тә килә.

## ТОЛ БУЕНДАГЫ ТЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ

### Барда төбәге татарлары сөйләше

*Дария Рамазанова*

Тол буйлары ... куаклыклар белән капланган яланнар куе кара урманнарга тоташа. Тау менәсең, тау төшәсең, тагы тау менәсең. Чәчәкләр белән бизәлгән, җиләкләр белән тулган таулар. Тау араларыннан чыккан мул сулы чишмәләрне үзенә ияртеп, талгын гына җәелеп Камага таба ага ул Тол. Тагын да көнчыгышка табарак Ирен исемле кушылдыгы белән таулы-кыялы ярлар арасыннан Сөлил елгасы ага. Ул да Камага килеп кушыла. Менә шушы елгалар буенда татарларның үзенә аерым бер төркеме сакланып килә. Аларны галимнәр Пермь татарлары дип тә, Урта Урал татарлары дип тә йөртәләр. Соңгы елларда аларны өйрәнүгә аеруча нык игътибар итә башладылар.

1962 елда Казан дәүләт университеты студентлары, укытучылары Нил Юзеев, Юныс Әминовлар җитәкчелегендә, Урал якларында булдылар, татар әдәбияты һәм тел тарихы өчен әһәмиятле материаллар алып кайттылар.

1965–1967 елларда СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Пермь татарларының сөйләм үзенчәлекләрен өйрәнү максаты белән, берничә экспедиция оештырды. Экспедицияне мин үзем җитәкләдем. Анда Институт хезмәткәрләре Флера Баязитова, Тәнзилә Хәйретдинова һәм университет студенты Эльмира Ягафарова катнашты. Бу экспедицияләр барышында, сөйләм үзенчәлекләрен өйрәнү белән беррәттән, Пермь татарларының тормыш-көнкүреш культурасы һәм аларның аваз иҗаты буенча да шактый бай, зур материал тупланды.

1969–70 елларда шушы ук Институт хезмәткәре, музыка белгече Наргиз Мөштәриева да Пермь өлкәсендә (хәзер – крае) булып кайтты һәм анда табылган җырларны җыентык итеп әзерләү өстендә эшләде.

2013 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан бер төркем галимнәр Пермь крае, Барда районына комплекслы экспедиция оештырдылар һәм бай материал тупладылар.

Пермь краеның авылларда гына да 67 мең татар яшәгәнлеге мәгълүм. Шунысы характерлы, аларның сөйләме үзенең төп үзенчәлекләре, борынгы күренешләре буенча нократ, касыйм татарлары һәм керәшен сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә.

Пермь татарларының формалашу тарихы бик катлаулы юл үткән. Бер яктан, алар Себер татарлары белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Икенче яктан, бу территория берничә гасырлар дәвамында Идел буе төрки халыклары йогынтысы астында булган. Уралның Идел буе белән бәйләнеше бик борынгы чорларда ук башланган булырга мөмкин. Болгар дәүләте чорында да бу бәйләнешләрнең сизелерлек көчле булуы һәм хәтта аерым Болгар кенәзләренең Кама буйлап менеп шушы тирәләрдә утырып калуын да күрсәтә торган дәлилләр җитәрлек. Бу бәйләнеш Казан ханлыгы чорында да һәм аннан соң да дәвам иткән. Шуңа күрә дә, Пермь татарларының сөйләш үзенчәлекләре генә түгел, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, рухи мәдәнияте, гореф-гадәтләре дә Казан татарларыныкына бик якын тора.

Ләкин Пермь татарлары берничә гасырлар буе төп татар халкыннан читтәрәк, башка төр халыклар белән чолганган хәлдә яшәгәннәр. Шулай итеп үзләрендә һәртөрле борынгылыкларны саклап калганнар. Шул ук вакытта алар күршедәге коми-пермяклар, ханты-мансилар, башкортлар белән дә якыннан аралашканнар. Алар белән тормыш-көнкүреш тәҗрибәсе уртаклашканнар. Шундый катлаулы процесс Пермь татарларының, үзләренә генә хас билгеләре булган, тормыш уклады, рухи дөньясы барлыкка килгән.

Пермь татарлары Казанны элек-электән үк бөек культура үзәге, мәгърифәт һәм белем учагы итеп санаганнар. Шуңа күрә татар әдәбияты һәм сәнгате белән тирән кызыксыналар, яңалыкларны белеп торалар, сәнгать эшлеклеләребезне яхшы таныйлар. Авылларда культура сарае, радиоузеллар эшли, татар телендә тапшырулар оеш-

тырыла. Район үзәгендә татар телендә газета чыгарыла. Барданың үзендә татар халык театры эшли.

Пермь татарлары арасыннан күренекле галим, профессор Хатип ага Госманов, Советлар Союзы Герое Шәриф Казанбаев, телче галим Дания Сарманаева, композитор һәм җырчы Мәсгут Имашев, язучы Таһир Госман-Сулмаш, галим һәм актив җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфаров һәм башка күренекле шәхесләр чыккан.

Пермь татарлары эш сөючән, киң күңелле һәм җырны, күңел ачуны ярата торган халык. Аларда кызыклы гадәтләр, үзенчәлекле йолалар бар һәм бу йолалар еш кына җыр, музыка белән башкарыла.

Барда төбәге татарларының формалашу тарихы бик борынгы чорларга барып тоташа. Тарихтан билгеле булганча, Идел – Кама – Урал төбәгендә төрки кабиләләр безнең эрага кадәр үк барлыкка киләләр[1]. Пермь татарларының бабалары шул борынгы төркиләр белән бәйле булырга мөмкин.

Эзләнүләр тирәнәя һәм материаллар, тарихи фактлар күбәя барган саен М.З. Зәкиев үзенең тикшеренүләрен үстерә бара. Нәтиҗәдә, галим, *барда* һәм *парфян* сүзләренең бер этнонимга кайтып калу мөмкинлеген фаразлап, бардалыларның бабалары борынгы парфяннар белән бәйләнгән, дигән фикер язып чыга. Кайчандыр Месопотамия, Алгы Азия тирәләрендә безнең эрага кадәр III гасырда Барды империясе төзелә. Аларның эзләре хәзерге Кама буйларында, Азәрбайҗанда да табыла, төрекмәннәр белән дә бәйле булырга мөмкин, М.З. Зәкиев аларның төрки телле булуларын да дәлилли[2].

Соңга таба Барда төбәге яши торган җирләрдә бик борынгы заманнарда ханты-мансиларның, коми-пермякларның бабалары яшәгән. Аларның бер өлеше руслашкан, ә бер өлеше татарлашкан, бер өлеше исә тагын да көнчыгышка яки төньякка таба күчеп киткәннәр. Бу турыда Пермь краеның танылган тарихчылары А.А. Дмитриев, В. Шишонко, С.В. Бахрушин, Б.Н. Вишневский һәм башкаларның хезмәтләреннән укырга мөмкин.

---

[1] Зәкиев М.З. Проблемы истории и формирования волжских татар. Казан, 1989.

[2] Зәкиев М.З. Хәзерге татар халкының тирән тамырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 260–287.

Археологлар Чусовой, Сылва бассейннарында, Урта Кама буенда IX–XV гасырларда яшәгән кабиләләрне рус документларында *остяклар* дип йөрткәннәр, аларның культурасын «сылва культурасы» дип аерып атыйлар һәм аңа аерым мөстәкыйль культура итеп карыйлар. Сылва культурасын калдырган кешеләрне угорлар булган дип саныйлар. Соңгы еллардагы археологик эзләнүләр сылва культурасының Агыйдел һәм Ык бассейннарындагы шул чор культурасына якын булуын фараз итәргә мөмкинлек бирделәр[1]. Бу фикерне Д.М. Исхаков та яклап чыга, тик ул сылва культурасы вәкилләренең кем булуы мәсьәләсенә карата башкачарак фикердә: автор аларны төркиләшкән угорлар дип санау ягында тора[2].

Билгеле булганча, Барда яклары *гәйнә ягы* дип йөртелә. Ул Барда ягы татарларының бабаларына килеп кушылган бер компонент белән бәйле[3]. Бу компонентны башкорт галимнәре башкорт кавеменнән булган дип саныйлар. Танылган башкорт тарихчысы Р.Г. Кузеев гәйнәләрне болгар белән бәйле кабиләләр дип саный, әлеге фикрен бик бай һәм төрле характердагы фактлар белән нигезле дәлилли[4]. Мин үзем, гәйнәләр угыр кавеменнән булырга мөмкин, тик алар болгарлашканнар, Тол буйларына аларның бер кечкенә генә өлеше килгән һәм алар монда килгәндә инде болгарлашкан-татарлашкан булганнар, дигән фикердә. Чөнки Р.Г. Кузеев болгарлар белән бәйле, болгар тәэсиренә бик нык бирелгән юрми, юрматы, тархан, еней, гәйнә һ.б. кабиләләрнең дәвамчылары хәзерге вакытта барысы да саф татар телендә сөйләшәләр, мондый хәл аларның Болгар дәүләте һәм аның дәвамчылары булган Алтын Урда, Казан ханлыгы дәүләтләре яшәгән чорда бер казанда кайнаганлыклары, шушы дәүләтләрдә аралашу чарасы буларак кулланылган телдә сөйләшкән булулары белән аңлата. Шулай итеп, Пермь татарларының формалашу тарихында, борынгы чорда фин-угырлар белән бәйләнешләре һичшиксез булган. Тик бу бәйләнешләрнең

---

[1] Казаков Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978. С. 83–99.

[2] Исхаков Д.М. Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX века // К вопросу об этнической истории татарского народа. Казань, 1985. С. 53.

[3] Рамазанова Д.Б. К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996. С. 3–40.

[4] Кузеев Р.Г. Происхождение башкирского народа. Уфа, 1974.

характеры турында төрлечәрәк карашлар бар. Фин-угырлар белән контакт Рус дәүләте составында вакытта да сакланып килә. Мәсәлән, алар удмуртлар, марилар белән, соңрак руслар белән аралашып яшиләр, комилар белән, янәшә күршеләр булып торалар.

Академик М.З. Зәкиев үзенең «Проблемы истории и формирования волжских татар» (Казан, 1989) дигән хезмәтендә *остяк* сүзенең килеп чыгышына киң туктала. Күп төрле чыганакларга һәм хезмәтләргә таянып, бу сүзнең бик борынгы төрки кабиләләр – *аслар* белән бәйле булуын дәлилли һәм, аслар Болгарларга кадәр үк Идел–Кама регионында яшәгән, дип фараз итә. Барда төбәге халкының болгарлар белән уртаклыгы турында ышанычлы фактлар бик күп.

Рус язма чыганакларында чагылыш тапкан, остяклар белән бәйле булган кайбер фактларга тукталып үтү урынлы булыр.

1570 елларда Пермь краена Трифон Вятский барып чыга. Ул бу яклардагы мәҗүсиләрне дингә өндәү максаты белән килә. Җирле халык арасында яши һәм «Житие святого Трифона Вятского» дип аталган хезмәт язып калдыра[1].

Бу хезмәттә Пермь татарларының бабалары турында кызыклы мәгълүматлар табарга мөмкин. Анынча, Сылва буе остякларының кенәзе – Амбал, Югары һәм Түбән Мулянка бассейны остякларының кенәзе Зевендук була (соңгысы төрки Сөендек дигән исемгә кайтып кала). Хезмәттә бу ике кенәзлек кешеләренең тормыш-көнкүреше, гадәтләре, йолалары сурәтләнгән. Шунысы характерлы, А.А. Дмитриев бу хезмәтне анализлаганда, Тулва тирәләрендә (Мулянка елгалары Тулвадан ерак түгел) шул ук вакытта татарлар да яшәгән, тик алар тормыш-көнкүрешләре һәм гореф-гадәтләре буенча остяклардан бер дә аерылмаганнар, дип күрсәтә[2]. Трифон Вятскийның «Житие...»сында кемнәрнедер нинди дә булса дингә кертү факты теркәлмәгән. Чөнки, «остяк» дип йөртелгән әлеге халыкның бабалары инде динле булган булса кирәк.

Чыганак буларак халык санын алу кенәгәләре Пермь татарларының бабалары турында мәгълүматлар халык санын исәпкә алу кенәгәләрендә дә теркәлгән.

---

[1] Вятский Т. Житие святого Трифона Вятского // Пермская ученая архивная комиссия (ПУАК): труды. Пермь, 1905. Вып. IX. С. 65.

[2] Дмитриев А.А. «Житие св. Трифона Вятского» как источник сведения о Перми Великой XVI века. Пермь, 1893. С. 14–18.

Рус хөкүмәте чиновниклары тарафыннан Пермь татарлары беренче мәртәбә 1579 елда исәпкә алыналар. Тик исәпкә алу кенәгәләре юкка чыкканнар булса кирәк. Алардагы мәгълүматларның кайберләре аерым хезмәтләрдә өзек-өзек рәвештә сакланып калганнар: бу кенәгәләрдән билгеле булганча, 1579 елда Сөлил буйларында остяклар һәм татарлар яшәгән[1].

М. Кайсаров тарафыннан 1623 елда язып алынган кенәгәләр Ирен, Шауба, Сөлил, Тол, Муллы, Бөрмә, Сеп елгалары һәм аларның кушылдыклары бассейнында (хәзерге Пермь краеның көньяк өлеше) татарлар һәм остяклар яшәгәнлеген хәбәр итә. Шунысы кызыклы, *татар* һәм *остяк* сүзләре бәрабәр терминнар булып, бернинди аерымлыксыз кулланылалар[2]. А.А. Дмитриевның язуынча, М. Кайсаров кенәгәләрендә дә остяклар ике улуска бүленеп күрсәтелгәннәр: Карьево улусы һәм Рожин улусы. Карьево авылы хәзер дә бар. Аны халык телендә Иске авыл дип йөртәләр. А.А. Дмитриев, Рожин шулай ук торак пункт исеме булган һәм анда остяклар кенәзенең резиденциясе урнашкан булырга тиеш, дип фараз итә. М. Кайсаров тарафыннан татар һәм остяк терминнарының бернинди дифференциациясез кулланылуыннан чыгып булса кирәк, А.А. Дмитриев, остяклар татарларга шул хәтле кушылып бердәйләшеп киткәннәр ки, әлеге ике халыкны инде аерырга мөмкин булмаган, дип яза. Кенәгәләрдән күренгәнчә, татар һәм остякларның төп һөнәрләре аучылык, балыкчылык, умартачылык һәм игенчелек булган[3].

1679 елгы исәпкә алу кенәгәләрендә санап үтелгән елгаларның бассейннарындагы халык татарлар дип кенә аталганнар, остяклар телгә алынмый һәм шунысы характерлы, татарлардан тыш монда берән-сәрән чувашлар, марилар, удмуртлар да теркәлгән, алар сосед, захребетник һ.б. дип аталганнар. Бу вакытта әлеге территория Көнгер өязе дип йөртелгән һәм ул Себер приказына караган. Казан өязе кебек үк, Көнгер өязе дә 4 өлешкә бүленгән булган. Ләкин аерма шунда, Казан өязендә Казан ханлыгындагы бүленеш дәвам итә, бүленгән төбәкләр *даруга* дип аталганнар (Җөри, Арча, Нугай,

---

[1] Дмитриев А.А. Пермская старина. Пермь, 1884. Вып. I. С. 102–115.

[2] Шишонко В. Писцовые книги Пермской губернии Соликамского и Кунгурского уездов. Пермь, 1872. С. 119–150.

[3] Дмитриев А.А. «Житие св. Трифона...» С. 13 и др.

Гәлеч даругалары; XVI гасыр ахырында яңа төзелгән Уфа провинциясе дә шул традиция буенча 4 даругага бүленгән була. Алар Оса, Себер, Казан, Нугай даругалары дип аталганнар). Ә Көнгер өязенең бүленеше исә *чирекләр* дип аталган. Мәсәлән, 1679 елдагы кенәгәләрдән күренгәнчә, көнгер татарлары Карҗәү, Югары Ирен, Шауба, Югары Сөлил чирекләренә бүлеп йөртелгәннәр.

Аеруча игътибарга лаек фактларның берсе шул, 1679 елгы исәпкә алу кенәгәләрендә Пермь краенда хәзерге көндә яшәп килә торган татар авылларының барысы да диярлек теркәлгәннәр.

Бу 1679 елгы исәпкә алу кенәгәләренең үзенчәлеге шунда, аларда инде остяк сүзе телгә алынмый. М. Кайсаров күрсәткән елгалар бассейннарында 1679 елда татарлар һәм алар арасында удмуртлар, марилар, чувашлар яшәгән, Югары Сөлил бассейнында исә мариларның саны шактый зур. Бу документның игътибарны җәлеп итә торган тагын бер ягы бар: Көнгер өязендә яшәүче халыкның социаль катламнарына да шактый төрлелек хас. Ясаклылар, күрәсең, хөкүмәткә билгеле ясак түләп торганнар. Ә *оброк* сүзенең мәгънәсе төрлечәрәк булган. Мәсәлән, Урал алды территорисендә берәр ияле җиргә килеп утырган кешенең шул җир хуҗасына түли торган түләве дә XVII–XVIII гасырларда *оброк* дип йөртелгән. Шуңа күрә, оброклыларның чагыштырмача соңрак килеп утыручылар булып чыгуы мөмкин. XVII гасырда патша хөкүмәтенең, буш җирләрне тизрәк үзләштерү өчен, халыкларны оброк (ул «черносошное тягло» дигән салымнан күпкә җиңелрәк булган) түләү шарты белән утыртуы билгеле. *Сосед, подсосед, захребетник* дигән төркемнәрнең үз юртлары булмаган күрәсең, алар йә яңа килгән, яисә берәр сәбәп белән бөлеп йортсыз-җирсез калган кешеләрдән торганнар булса кирәк.

Шулай итеп, бу документта остяклар инде телгә алынмый. Кая киткәннәр соң алар? Алар беркая да китмәгән, ә татар дип йөртелә башлаган. Соңгырак чорга караган документларда Пермь татарларының бабалары үзләрен «без элек остяклар дип йөртелгәнбез» дип күрсәтә торган булганнар. Җир мәсьәләсендә бәхәс чыкса да җирләренең үзләренеке икәнен исбат итү өчен төп дәлил итеп М. Кайсаров кенәгәләреннән өзекләр китерә торган булганнар. Мәсәлән, Басино (хәзерге Октябрь районы) авылы татарлары үзләренең 1798 елда Пермь губернасы идарәсенә биргән үтенечләрендә болай дип язалар: «в писцовых книгах 7131 и 7132 (ягъни 1623,

1624. – *Д.Р.*) за предками их, именуемыми Остяками, Байсою (димәк авыл исеме шушы кеше исеменнән барлыкка килгән – *Д.Р.*) Албашевы и Ураметом Таисиным и братом его Батырем, при двух юртах вотчинного их владения...»[1].

Хәзерге Пермь татарлары М. Кайсаров кенәгәләрендәге остякларның дәвамчылары булуын тарихчы галимнәрдән А.А. Дмитриев, А.А. Преображенский, Д.М. Исхаков һ.б. ачыклаганнар.

В. Шишонко үзенең елъязма характерындагы хезмәтендә, Сөлил (Сылва) бассейнында улус яки юртларда 1578–79 елларда остяклар яшәгән, хәзер алар *татар* дип аталалар, дип яза. Остяк-татар параллельләре – кеше исеменә ономастик материаллар. Мәсәлән, М. Кайсаров кенәгәләрендә теркәлеп калган төрки исемнәр (русча язылышта): Тогабарда/Тугаберде, Камалтинко, Екшеит//Якшеит Кулышев, Кичкеняшай Колычбаев, Болонтай Сигизяков, Тугулбай Мурзакилдин, Мурзакилдейко Тулубаев, Юсуп Алагузин, Кузембердей, Кодабердей, Турчебей, Терегулов, Аккилдеев, Девлеткилдей, Яригин, Яныч Толгузин (Пермь районында Яныч авылы бар), Козебахта Карьев (хәзер Карҗәү авылы бар, халык арасында ул Иске авыл дип йөртелә) һ.б.[2]

Инде 1679 елгы кенәгәләрдәге исемнәрнең бер өлешенә тукталыйк: Бисердачко Батырев, Сылгазейко Бочкарев, Алайко, Бисюряйко, Канчурайко, Канмурзачко, Исенейко, Ураско Урмаметев, Алексейко, Ишинбайко, Айгиндейко, Козайко, Сибыкайко, Аргузко Бекбердиев, Крымко һ.б.

Көнгер татарларының XVII гасырның икенче яртысындагы исемнәренә игътибар итик: Истечко Ижболдин, Алий, Егитай Балбеков, Асякайко Маметов, Бекбулатко, Любишко Кизилбаев, Акманко Токобаев, Ижбулатко, Акшы Девлетов, Турайко Байгозин, Байтемирко Батряков, Мамык, Кошымбайко Маметев, Кузекайко, Любишко Кинзибаев, Семейко Арасланов, Бекбулатко Бекмурзин, Ирыспайко Актаев, Акаска Кокобаев, Девлеткилдеев, Тимяк Балантаев, Янбулат, Акбаш, Таймаметев, Кураз, Кучюков, Юнуско Розмагильдеев, Мурзагилдий, Табалдин, Исенейко Баранчин, Кусейко Салкаев, Юкперда Янзигитов, Темерчи/Темярча, Кусякай

---

[1] Шишонко В. Пермская летопись: Пермь. Период I, 1881.

[2] Шишонко В. Писцовые книги Пермской губернии Соликамского и Куржского уездов. С. 126.

Саламбердиев, Байметко Салтанаков, Ишкулко Кунглуков, Булатко Битин һ.б.[1]

1721 елгы документтагы исемнәр: Бекбулатов, Тулугуза Оекбаев, Беклыбаев, Бахметев, Асманов, Козаевы, Баймурат, Атанабай Сорокин, Карина Утяшев, Султан Кусяков, Саитко Ишимов, Митка Ижбулатов, Коза Козябаев, Атналя Тебенеков һ.б.[2]

Китерелгән материалдан күренгәнчә, буыннан-буынга күчеп барган исемнәр һәм фамилияләр бар. Кайбер исемнәр хәзерге татар авылларының исемнәре белән туры килә: Карьев, Яныш (Пермь районы, Янеч авылы), Тайсын//Тасимов (Пермь районы, Кояново авылының икенче исеме; 1623–24 елгы кенәгәләрдә Тасим тегермәне телгә алына), Бекбердино, Исенейко (Березовка районында Иссиняево авылы бар), Ишимово (Барда һәм Октябрь районнарында), Крым (Сөлил бассейнында) һ.б. Шунысы характерлы, бу исемнәр М. Кайсаров кенәгәләреннән үк киләләр.

Шулай итеп, остякларның исемнәре XVI гасырда төрки исемнәр булганнар.

Барда төбәге татарлары сөйләшенең болгар чоры белән бәйләп карый торган үзенчәлекләре күп табыла. Гомумән, Пермь татарларының болгарлар белән бәйле булуы турында ышанычлы фактлар бик күп.

Мәсәлән, аларның сөйләше татар теленең урта диалектына карый, ягъни алар Казан арты татарлары белән бер төсле сөйлиләр. Шунысы әһәмиятле, бер төркем борынгы үзенчәлекләре белән аларның сөйләше касыйм, нократ, керәшен сөйләшләре белән аерым уртаклык күрсәтә, чөнки бу сөйләшләр вәкилләренең бабалары, кайчандыр, XIII–XIV гасырларда читкәрәк күчеп, яисә диннәре үзгәреп, төп татар халкыннан бераз аерымланыбрак яши башлаулары тарихи әдәбиятта бәхәс тудырмый. Танылган татар диалектологлары Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова әйткәнчә, әлеге уртаклыкның нигезе, һичшиксез, болгар чорында салынган булган, ә күчеп киткәч, нократ, касыйм, керәшен, бәрәңге, Урал төбәге сөйләшләре изоляцияләнгән хәлдә үзләренең телләрен, гореф-гадәтләрен саклап яшәүне дәвам иткәннәр.

---

[1] Кунгурские акты XVII века (1688–1699). СПб, 1888.

[2] Центральный государственный архив древних актов (г. Москва), ф. 350, оп. 1, ед. хр. 5862.

Пермь татарлары сөйләшендә борынгы чорда болгарлар белән уртак тарих кичергән Кавказ ареалындагы башка телләр белән дә уртак сүзләр бар. Мәсәлән, *конжҗырыйк* – сыер, ат яки болан аягы тиресеннән тегелгән аяк киеме. Бу сүз пермь сөйләше йогынтысында формалашкан златоуст сөйләшендә һәм Башкортстанның төньяк-көнчыгышында таралган күрше башкорт сөйләшләрендә генә билгеле. Башка төрки телләрдән *конжҗырыйк* сүзенең параллельләре әлегә бары Кавказ ареалындагы телләрдә генә табылган: карачай-балкар телендә *гёнчарыкъ* – ‘чүәкләр’, кабарда, адыгей, абаза телләрендә, осетин теленең дигор диалектында бу сүз ‘чи тиредән чабата рәвешендә тегелгән аяк киемен’ белдерә[1]. Чагыштыр: тагын удмурт телендә *ген сапог* – киез итек. Менә бу ген (татар. йон) сүзе борынгы болгар һәм алар белән контактта булган кавказ телләрендә генә теркәлгән булу Пермь татарларының Болгар чорындагы үзара бәйләнешләре турында сөйли. Боларга өстәп, пермь сөйләшенең Кавказ төбәгендәге төрки телләр белән аерым уртаклык күрсәтүен билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, бу уртаклык карачай-балкар телендәге бертөркем сүзләрнең татар теленең башка сөйләшләрендә, башкорт сөйләшләрендә дә табылмавы, бары пермь сөйләшендә генә булуы билгеле.

Топонимик материаллар да хәзерге Пермь краенда болгарларның эзе калуына шаһит булып торалар. Пермь районында Болгары авылы бар. Красноуфим шәһәре янында Болгары дигән харәбәләр бар. Пермь краеның танылган тарихчылары – археологлар О.Н. Бадер һәм В.А. Оборин, Очер районы Черти дигән авыл халкының яртысы әле дә *болгар* атамасын йөртә, дип язалар.

Танылган археолог Т.А. Хлебникованың хезмәтләрендә Пермь краеның көньяк районнарында табылган борынгы керамиканың болгар керамикасы белән зур уртаклыгы булуы фәнни дәлилләр белән исбатланган.

Тарихи әдәбиятта Идел Болгариясе һәм Кама Болгариясе (соңгысында Пермь татарлары яшәгән территория күздә тотыла) дигән тәгъбирләрнең кулланылуы да шуңа ишарә булып тора. Язма чыганакларда безнең борынгы бабаларыбыздан бер төркемнең, Кама буйлап күтәрелеп, хәзерге югары Муллы тирәләренә уты-

---

[1] Шагиров А.К. Этимологический словарь адыгских (черкесских) языков. М., 1977. С. 112.

рып калуы турындагы фактлар теркәлгән. Бу төркемнең башында кенәз Маметкул (мулла?) торган. Аның олы улы – Югары Муллыда, ә кечесе Түбән Муллыда яшәгән, әлеге елгаларның исеме исә мулла сүзеннән килеп чыккан икәнлеге ачык күренеп тора. Казан ханлыгы җимерелгәч, Пермь татарларының бабалары һәр юрттан бер сусар түләү шарты белән, рус дәүләтенә буйсына. Бу хәл исә хәзерге Тол буйларының Казан ханлыгы составында булганлыгын дәлилли торган факт булып тора. XVI–XVII гасырларга караган язма документларда да Пермь өлкәсендәге Оса шәһәре (ул Барда төбәгенә бик якын урнашкан) Казан яны шәһәрләре («пригороды Казани») исемлегендә теркәлгән. Идел буе татарларының бу җирләргә күчеше Казан ханлыгы җимерелгәннән соң да, XX гасыр башларына кадәр дәвам иткән. Шуңа күрә дә Барда төбәге татарларының сөйләш үзенчәлекләре генә түгел, көнкүреш итү, рухи мәдәният, гореф-гадәтләр һ.б. да Казан татарларыныкына бик якын тора. Шуның белән бергә, алар берничә гасырлар буе төп татар халкыннан читтә, күрше коми-пермяклар, ханты-мансилар, башкортлар белән дә якыннан аралашып, тормыш-көнкүреш тәҗрибәсе уртаклашып яшиләр. Менә бу фактлар барысы бергә Пермь татарларының, шул исәптән Барда төбәге татарларының да үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен барлыкка китергән.

**Кайбер йолалар турында.** Татар халкының яраткан милли бәйрәме – Сабан туе Барда төбәге татарларының да иң яраткан һәм иң зур бәйрәмнәре булып санала. Бу бәйрәм берәр көн алдан *сөрән сугу,* ягъни, сабан туе өчен сөлге һәм башка әйберләр җыю белән башлана. Иң алдан сөлгеләр уралган озын колга тотып авылның иң ихтирамлы картлары килә. Янәшәдә, гармун, скрипка, курай һ.б. уен коралында уйнап, музыкантлар атлый, алардан соң кунаклар, яшьләр һ.б. Сөрәнчеләрне, бездәге кебек, капкаларны төбенә кадәр ачып көтеп тору гадәткә кергән. Ишек алдында бию-ләр, җырлар, уеннар, шаян сүзләр, уен-көлке. Безнең үзебезгә дә Барда районында Сараш авылында сөрән сугуда катнашырга туры килде. Ул вакытта алган ләззәтләнү хисләре һаман да күңелдә саклана. Гомумән, бездә – галимнәрдә – Барда төбәге татарларының олы җанлы, җитди һәм хезмәт сөючән булуы, матур итеп күңел ача белүләре яхшы тәэсирләр генә калдырды.

Авылларда сабан туйлары үткәч, Бардада Олы сабан туе уздырыла. Аны *«Барда җыен»* дип атыйлар. Ул инде бөтен район

халкының бәйрәменә әверелә. Сабан туйларында да, җыенда да бертуктаусыз М. Ногман сүзләренә С. Садыкова көй язган «Тол буйлары» җыры яңгырап тора. Ә җыен сүзе исә Казан арты төбәгендә билгеле бер төркем авыллар җыелышып бәйрәм итә торган җыен белән, әлбәттә, аһәңдәш.

Туй ясау, кыз алу-бирү йолаларында да үзенчәлекләр бар аларда. Мәсәлән, кияү белән кәләшне кавыштыру өчен 3 яки 5 катлы-катлы (ул так булырга тиеш) түшәкләрдән урын әзерләнә. Урынны чаршау (аларча чымылдык) белән корып куялар. Ә кыз исә калфаклар киеп, яка чылбырлары, матур бизәлгән изүләр тагып, камзулдан шул биек түшәкләр өстендә утыра. 2 җиңгә ике чаршауның читен тотып «Хан кызы» бәетен җырлап торалар:

*Хан кызы, ач ишегеңне, бән керәем,*
*Сәнең тешең энҗе, диләр, бән күрәем,*
*Бәнеп тешем энҗесенә сән ни диярсең,*
*Асламчыда асыл энҗе күрмәймесең.*

Шулай итеп, кәләш хан кызы белән тиңләнә Барда якларында, ул тәхеттә утырган бикәчне хәтерләтә. Яшьлек сафлыгы, кызның намусы һәрчак югары булырга тиеш дип карала безнең татар халкында. Ә егет исә хан кызын зур тырышлык белән яулап алырга, ишек төпләрендә көмеш акчалар чәчеп, һавага аткан мылтык тавышлары астында килеп керергә, керү белән түшәккә сикереп менәргә тиеш, үзенең булдыклылыгын, егетлеген күрсәтергә тиеш. Шуннан соң гына «зипәк баулы асыл кош» асыл бөркет егетнең яры булып китәчәк.

Әнә шулай итеп, безнең татар халкының күркәм традицияләрен үзләренчә матурлап үстерә, яшәтә киләләр Барда якларында, бай мәдәниятебезне саклап яши бирәләр алар.

**Риватьләр.** Барда төбәге татарларында да хәзерге кешеләрне кесәсенә генә салып алып китәрлек эре кешеләр (пәһлеваннар) турындагы риваятьләр киң таралган. Әкиятләрдә бер күзенә сөрмә сөртеп бүтән кешеләргә күренмәгән әйберләрне күрә торган кешеләр турындагы мотивлар еш очрый. Һәртөрле ышанулар игътибарга лаек. Мәсәлән, күке гөлҗимеш чәчәгенең матурлыгына сокланып сакауга әйләнә, кычкырмый башлый имеш. Күке, имеш, үзенең туганы Зәйнәпне сагынып шулай моңлы кычкыра, чөнки алар Сак белән Сок кебек күрешә алмыйча яшиләр.

Аларда *ярымтык* турындагы риваятьләр бик кызыклы. Ул Казан артының шүрәлесенә бик якын. Имеш, ярымтык кешеләрне адаштыра, куркыта, аларга исемнәре белән эндәшә. Имеш, ул атларны, атланып йөреп, шабыр тиргә батыра. Аны ялангач хатын-кыз рәвешендә сурәтлиләр. Ярымтык дигән сүз башка бер халыкта да очрамый.

Барда төбәге татарларының авыз иҗаты композиторларыбыз өчен дә бәрәкәтле чыганак була ала. Без аларда «Туганнар», «Муллы көе», «Ак перчатка», «Гөлчирә», «Алмалы гөл» һәм башка күп төрле җырлар язып алдык.

Гомумән, күрше республикалардагы безнең туган халкыбыз үзенең милли йөзен саклап яши, иҗат итә һәм үсә тора. Аларның иҗаты бай һәм үтә дә үзенчәлекле. Аларда әле бүген дә сакланып килә торган борынгы йолалар, телдән-телгә сөйләнеп, буыннан-буынга тапшырылып килә торган риваятьләр, һәртөрле ышанулар, авыз иҗаты әсәрләре күп һәм бу күңелле күренеш. Аларны туплап өйрәнү, фәнгә кертеп җибәрү, татар халкының рухи мирасын барлау, үстерү өчен бик әһәмиятле. Барда төбәге татарлары халкыбызның лаеклы бер өлеше булып тора.

**Пермь сөйләшен өйрәнү тарихыннан.** Барда районы сөйләше татар теленең урта диалектына карый торган пермь сөйләшенең бер урынчылыгын тәшкил итә. Башка урынчылыклар: карьево, (югары) ирен, сөлил, муллы, шауба. Барда төбәген гәйнә ягы дип йөртәләр. Татар халык сөйләшләре атласына материал җыйнау Программасы (ул 300 ләп сорауны эченә ала) нигезендә өйрәнеп чыгу күрсәтелгән урынчылыкларның, нигездә, бер төсле булуын күрсәтте. Аларга хас үзенчәлекләр, мәсәлән, сөйләштә *таскак, куныч*, ә шауба урынчылыгында *таксак, кунчы*, сөйләшкә хас *-мага/-мәгә* формасы ирен урынчылыгында күзәтелмәү, сылва урынчылыгында гына *-дагын/-дәген* формасының кулланылуы һәм башка кайбер тар күләмдә генә күзәтелә торган күренешләрне тәшкил итәләр. Сөйләшне характерлый торган төп үзенчәлекләрнең бай системасы барлыкка килгән һәм аларның кулланылышы ягыннан пермь сөйләше бертөсле.

Тагын шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, барда төбәге сөйләшендә, гомумән бөтен пермь сөйләшендәге кебек үк, башкорт теленә хас күренешләр бөтенләй табылмый: авазлар системасы, лексик-семантик төркемнәр, морфология *(ачык, чәчкә, сарык, сөт, чәй, инәй/әни,*

*яка чылбыры, калпак, эчә, чалу, чабу, чалгы; карады, барды, атлар, сарыклар, энәләр һ.б.)* барысы да татар телендәгечә әйтелә.

Билгеле булганча, телгә даимилек хас, ул халыкның милли нисбәтлеген билгеләүдә, халыкны идентификацияләүдә төп һәм иң әһәмиятле билгеләрнең берсе булып тора.

Шунысын ассызыклап күрсәтергә кирәк, пермь сөйләшенең нәкъ татар сөйләше икәнен барлык тикшеренүчеләр дә бердәм рәвештә раслыйлар.

Бу сөйләшне тасвирлауга беренче омтылыш XIX гасыр башында ясалган. «Историко-географическое описание Пермской губернии, сочиненное для атласа 1800 года» дигән хезмәттә Пермь һәм Оса өязе (бу хәзерге Барда төбәгенә туры килә) «башкорт»ларның теле турында беренче фикер йөртү чагылыш тапкан (бу өзектә рус телен саклау кулайрак): «...говорят своим языком, которой столько сходствует с татарским, что почти немножко сказать чтоб оныя были два особливыя языка: ибо только некоторые в оных слова разнствуют отличным произношением, так, например, *один* по башкирски ‘бер’, по татарски ‘брав’, *два* по башкирски ‘ики’, по татарски ‘икав’, *семь* по башкирски ‘зита’ ( чагыштыр: сөйләштә ‘җите’ (йете. – *Д.Р.*), по татарски ‘зида’, *девять* по башкирски ‘тогись’ по татарски ‘токуз’ (интервокаль позициядә саңгырау тартыклы вариант мишәр диалекты вәкиле булган информаторның сөйләм үзенчәлеге булса кирәк. – *Д.Р.*). Напротив того, большая часть слов как у тех, так и у других равно произносятся: *отца* те и другие называют ‘атай’ и проч., для сего башкиры и татары, неучась, одни языки других могут говорить между собою. Из всего видно, что татары одного происхождения с башкирами, что неменьше доказывается сходством их лиц, нравов, обычаев и проч.» (1837).

Димәк, 200 ел элек үк Барда төбәге татарлары бер халык – татар халкы булганнар.

1881 елда А.Г. Бессонов «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» дигән күләмле мәкаләсен бастырып чыгара. Ул анда пермь сөйләшен, Казан татарлары теленә, типтәрләрдән кала, иң якын сөйләш, дип билгели. Мәкаләдә, пермь сөйләшенең фонетик, морфологик үзенчәлекләрен тикшерә, алар сөйләшендә борынгы көн исемнәре сакланып килүенә игътибар итә (*баш көн, атланган көн, кан көн* һ.б.).

Барда татарлары теле турында мәгълүматлар Л. Җәләйнең «Татар диалектологиясе» (1947) дигән хезмәтендә «урал татарлары», «барда татарлары» турында берникадәр мәгълүмат биреп үтә. Алга таба Л. Җәләй татар сөйләшләрен өйрәнүче кадрларны туплау буенча да эшчәнлек алып бара. Мәсәлән, пермь сөйләше вәкиле Д. Сарманаева белән танышып, аның фәнни эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, кандидатлык диссертациясе әзерләнә һәм Д. Сарманаева фәннәр кандидаты дигән гыйльми исем яулый.

Нәтиҗәдә, пермь сөйләше буенча әһәмиятле материал туплана һәм фәнгә кертелә. Д. Сарманаева Урта Урал татарларының теле генә түгел, тарихы, этнографиясе буенча да бай материал туплый, аны фәнгә кертеп җибәрүгә ирешә. Сөйләшнең фонетик, морфологик, синтаксик, лексик үзенчәлекләрен шул заман дәрәҗәсендә тулы тасвирлый, Пермь, Свердлов өлкәләренең шактый районнарын эченә алган зур территориядә ул *барда, өя* сөйләшләрен һәм *красноуфим-манчаж* диалектара сөйләшен бүлеп чыгара.

Бу диссертациянең тагын бер әһәмиятле ягы бар: анда автор тарафыннан язып алынган әкиятләр, җырлар, такмазалар, кушаматлар һәм фразеологизмнардан торган бай кушымта бирелгән.

Шулай итеп, татар диалектологиясендә әлеге сөйләшләр шактый тулы тасвирлана, Д. Сарманаева тарафыннан татар диалектологиясенә билгеле бер өлеш кертелә.

50 нче еллар азагында сөйләшләрне лингвогеографик ысул белән өйрәнү башлангач, татар диалектлары таралган территория квадратларга бүленә һәм яшь диалектологлар Атлас өчен материал туплауга керешәләр. Урта Кама төбәге (аңа Пермь краеның көньягы да керә) минем үземә тапшырыла. Шулай итеп пермь сөйләшен лингвистик география ысулы белән өйрәнү башлана, паспортлаштырылган бай материал туплана, микроатлас төзелә.

Мин үзем пермь сөйләшендәге диалекталь күренешләрне татар теленең башка сөйләшләренә янәшә куеп чагыштыру белән генә чикләнмәдем. Башка төрки телләргә мөрәҗәгать итеп тикшерү дә кызыклы нәтиҗәләр бирә, сөйләштә оригиналь үзенчәлекләр барлыгы ачыклана. Аларның чыгышын, характерын ачыклау өчен борынгы төрки ядкәрләрне өйрәндем. Шулай итеп, пермь сөйләшендә, шул исәптән барда төбәгендә дә уникаль диалекталь күренешләрнең катламнары барланды; бай диалекталь лексика 1969, 1993 елгы диалекталь сүзлекләрдә урын алды, фәнгә әлегә билгеле

булмаган диалекталь сүзләр генә түгел, морфологик, синтаксик күренешләр, фонетик үзенчәлекләр кертелде.

Лингвогеографик ысул белән өйрәнү материалларның паспортлы һәм фактик дөрес булуына, нәтиҗәләрнең объективлыгына китерә[1].

Нәтиҗәләр:

– пермь сөйләше татар теленең урта диалектына карый торган сөйләш;

– татар теленең теге яки бу сәбәпләр (конфессиональ, территориаль, административ һ.б.) белән бәйле рәвештә барлыкка килеп, изоляцияләнгән хәлдә үсеш-үзгәрешләр кичергән, борынгылыкны саклап килгән касыйм, нократ, керәшен сөйләшләре белән аерым якынлык күрсәтә;

– пермь сөйләшенең нигезе болгар чоры белән бәйле;

– Пермь татарларының этник формалашуында көнчыгыш төрки халыклар белән бәйле этник компонент катнашлыгы күзәтелә;

– тау ягы сөйләшләре, аеруча норлат сөйләше белән аерым уртаклыкка ия;

– пермь сөйләшенең борынгы уйгыр теле белән дә аерым уртаклыгы булу ачылды.

Күрсәтелгән нәтиҗәләр фактик материалларга таянып чыгарылды, алар телнең барлык ярусларыннан да материаллар белән расланды. Мәсәлән, норлат сөйләше белән аерым уртаклык һәм фонетик (алмашлыкларда һәм кайбер сүзләрнең азагында *ай* дифтонгының тараюы: *алый, болый* һ.б.), һәм грамматик (*бардыг ыйы* – барган идек; *баргас*–баргач һ.б.), һәм лексик (*орчокбаш сүwәк* – шайтан ашык, *тырнаwыч* – тырма һ.б.) үзенчәлекләрдә чагыла.

Шулай итеп, Барда төбәге сөйләше күпсанлы мәкаләләрдә, монографиядә тикшерелгән. Барлык татар сөйләшләрен сурәтләүне максат итеп куйган «Татар халык сөйләшләре» исемле тупланмада (ул 2 китаптан тора) пермь сөйләше шушы язма авторы тарафыннан тасвирланган.

Биредә тагын бер әһәмиятле моментны билгеләп үтәргә кирәк. Фәндә билгеле булганча, халыкның теле белән тарихы үзара бәйләнгән була, тел – тарих көзгесе, дигән гыйбарә яшәп килә.

[1] Пермь, шул исәптән барда, сөйләшенең үзенчәлекләрен «3 томлы Татар халык атласын»нан интернетта да карарга мөмкин (2012, http://atlas.antat.ru).

Пермь сөйләшен тарих белән бәйләп өйрәнгәндә миңа Пермь, Уфа, Мәскәү шәһәрләре үзәк архивларындагы материалларны эзләп табып файдалану да уңышлы алымнарга ирешергә ярдәм итте[1].

**Телебезне саклыйк, тарихыбызны онытмыйк**

Тормышыбызның бөтен өлкәләрендә дә глобальләшү процессы бара.

Мондый вазгыятьтә аз санлы халыкларның телләренә, башка телләр чолганышындагы диалектларга яки сөйләшләргә аеруча көчле куркыныч яный. Татар теленең дистәләрчә сөйләшләре Татарстаннан тыш өлкәләрдә таралган. Касыйм, Нократта, Пенза өлкәсендә, Себердә таралган сөйләш вәкилләре арасында көчле урыслашу күзәтелә. Чит өлкәләрдәге татар авылларында туган тел укытылмый, бу исә татар теленең яшәеш мөмкинлекләрен тагын да чикли. Безгә гореф-гадәтләребезне, милли үзаңны һәм мәдәниятебезне, бигрәк тә, «милләт сакчысы» (Ә.Г. Кәримуллин) булган туган телебезне саклап калу юлында бердәм рәвештә һәм нык кына эшләргә, тугандаш һәм башка күрше халыклар белән берләшеп эш итәргә кирәк.

Һәр халыкның, аның культурасының, теленең үзе өчен генә хас булган аерымлыклары мәгълүм. Тормыш-көнкүреше, кием-салымы, йөз-сын төзелеше, сөйләшкән теле белән һәр милләт үзенә генә хас сыйфатларга ия һәм шулардан чыгып алар аерылалар да. Һәр мөстәкыйль телнең үзенә генә хас билгеләре була. Мәсәлән, татар һәм башкорт телләрен чагыштырып карыйк. Башкорт телендәге *силәк, сәскә, бакса* сүзләре татар телендә *чиләк, чәчкә, бакча* дип әйтелә. Башкортча *һарык, һыу, һәнәк*, татарча *сарык, су, сәнәк,* башкортча *йәй, йил, йиләк,* татарча *җәй, җил, җиләк* һәм башкалар. Ягъни башкорт теле үзенең авазлар системасы белән татар теленнән шактый аерыла. Әлеге ике телнең грамматикасында да җитди аерымлыклар бар. Мәсәлән, башкортча *аттар* – татарча *атлар*, *кыззар – кызлар*, *һугандар – суганнар*, *таштар – ташлар* кебек тәңгәллекләрне китерү дә күп нәрсә турында сөйли. Гомумән тарихта башкорт теле белән татар теленең ике тел булуы беркемдә дә бәхәс тудырмаган әлбәттә. Башкорт теленең төп үзенчәлекләрен,

[1] Рамазанова Д.Б. К истории формирование говора пермских татар. Казань, 1996. 239 с.

аны мөстәкыйль тел итеп аерып карарга мөмкинлек бирә торган якларын күренекле галимнәр инде күптән ачыклаган. Мәсәлән, Урал тирәсе төрки халыкларның, бигрәк тә башкортларның халык авыз иҗатын җыю, аны бастыру өчен күп өлеш керткән А.Г. Бессонов 1881 елгы хезмәтләрендә үк бу мәсьәләләргә кагыла. Пермь краенда, Башкортстанда, Оренбург якларында яшәгән татарларның, мишәрләрнең Казан татарлары белән бер телдә сөйләшүен ассызыклап үтә. Төрки телләр буенча зур белгеч булуы белән мәшһүр Н.Ф. Катанов та Башкортстанда яши һәм, *мишәр, керәшен, башкорт, типтәр* дигән исем астында йөри торган татарлар теленең чын башкорт теленнән аерылып торуын ассызыклап, башкорт теленең үзенчәлекле төп билгеләрен берәм-берәм карап чыга, шул турыда хезмәтләр язып калдыра. Танылган тюрколог, СССР ФА мөхбир әгъзасы Н.К. Дмитриев башкорт телен беренче мәртәбә фәнни нигездә тасвирлап зур хезмәт яза. Ул анда башкорт теле авазлар системасының төп билгеләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтә: татар телендәге ***ч*** урынына башкорт телендә ***с; с*** урынына ***һ***; сүз башында ***җ*** урынына ***й***; сүз уртасында ***җ*** урынына ***ж*** (*хужа, бажа*); ***з*** урынына сакау ***з***. Менә шушы үзенчәлекләр башкорт телен мөстәкыйль тел итеп формалаштыра да инде. Тагын шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк, теге яки бу телнең авазлар системасы үзенең тотрыклылыгын аеруча нык саклый торган өлкә булып тора. Ә лексика бүлеге, ягъни теге яки бу телнең сүзлек составы тизрәк үзгәрүчән була. Сүзләр бер телдән икенче телгә тизрәк үтеп керә. Бу җәһәттән *тәү, тәүбашлап, токчай* һәм башка шундый кайбер сүзләрне кулланган өчен генә «без әзрәк башкортча сөйләшәбез инде» дип әйтүчеләр белән һич тә килешеп булмый, алар бик нык ялгыша. Мәсәлән, *ихата, зәңгәр, акыллы* һ.б. сүзләрне кулланган өчен генә без татар яки башкорт телен гарәп, фарсы теле дип атамыйбыз бит. Яки *комедия, бюро* сүзләре булган өчен генә руслар үз телләрен француз яки итальян теле дип атый алмыйлар һәм атамыйлар да. Алынма, ягъни башка телдән кергән сүзләр, һәр телдә дә бик күпләр. Мәсәлән, мондый бер генә мисал китерәсе килә: русчадан (рус теле сүзлеге дә ярый) башка телгә тәрҗемә ясый торган бер сүзлекне алып карагыз, андагы ***а*** хәрефенә башлана торган сүзләрнең бары бер-икесе генә рус сүзе, ә зур күпчелегенең алынма булулары фәндә мәгълүм әйбер. Ләкин, телне билгеләүдә сүзлек составының әһәмияте бөтенләй юк икән, дигән фикер калмасын. Төп сүзлек байлыгы, шул

исәптән, туганлык атамаларын (*әсә/әни* сүзләрен генә алыгыз), табигатьне, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын һәм башкаларны белдерә торган гаять күп сүзләр бик борынгы заманнардан яшәп киләләр һәм аларда халыкның күп гасырларга сузылган тарихы чагыла. Моны һич тә истән чыгарырга ярамый. Бу урында бер генә нәрсәне кисәтәсе килә: берничә башкорт сүзен кулланган өчен генә «без башкортчарак сөйләшәбез инде» дип нәтиҗә чыгарырга ярамый.

Кыскасы, авазлар системасы, сүзләрне төрләндерү чаралары һәм төп сүзлек хәзинәсе – барысы бергә теге яки бу телнең асылын, аерымлыгын, мөстәкыйльлеген оештыралар һәм татар теле дип, башкорт теле дип сөйләгәндә югарыда әйтеп үтелгәннәр, һичшиксез, истә тотылырга тиеш.

Фәндә мәгълүм булганча, кешеләрнең этник берлеген билгеләгәндә тел факторы зур әһәмияткә ия. Теге яки бу халыкның этник нисбәтлелеген хәл иткәндә иң башта нинди телдә сөйләвенә игътибар итәләр. Урал тирәләрендә яшәгән татарларның теле һаман да игътибар үзәгендә кала килә. Аларны өйрәнү буенча зур эш совет чорында башкарыла. Пермь краендагы татарларның сөйләше кырыгынчы елларда Д.М. Сарманаева (ул үзе шунда туып үскән), алтмышынчы елларда минем тарафтан, җитмешенче елларда бер төркем татар этнографлары тарафыннан өйрәнелде. Нәтиҗә бер үк: алар татарча сөйләшә, татарча көн итә. Оренбург өлкәсе татарлары З.Р. Садыйкова, Чиләбе һәм Курган өлкәләрендәге татар авыллары Ф.Ю. Йосыпов тарафыннан өйрәнелеп, күпсанлы хезмәтләр дөнья күрде. Әмма аеруча күп тикшеренүләр Башкортстандагы татар сөйләшләренә багышланган: Л. Мәхмүтова, Ә. Әфләтунов, Җ. Алмаз, Т. Хәйретдинова, Ф.Баязитова кебек галимнәр һәм мин үзем дә Көнбатыш Башкортстанда таралган сөйләшләрне татар теле диалектлары системасына керә, дип саныйбыз. Алай гына да түгел, бу сөйләшләрнең татар әдәби теленә аеруча якын торулары басым ясап күрсәтелә, күп төрле дәлилләр белән анык исбатлана һәм күп кенә мәкаләләрдә, монографияләрдә чагылыш таба.

Шушы ук фикерләр башкорт телчеләре тарафыннан да әйтелгән. Мәсәлән, Җ.Г. Киекбаев, Ә.Ә. Юлдашев, Н.Х. Ишбулатов, Т.М. Гарипов хезмәтләрен карарга мөмкин. Ләкин соңгы бер-ике дистә елда кайбер башкорт диалектологларының фикерләре үзгәреп китте. Гомумән, кайсыдыр бер заманда, бары җир алыр өчен генә башкорт булып язылган татарларны «башкортлаштыру»ның ямьсез

чаралары эшкә ашырыла башлады. Мәсәлән, аларның балаларына башкорт телен көчләп ана теле итеп укыта башладылар.

Урал тирәсендәге татар сөйләшләре телчеләр тарафыннан кырык ел буе төрле ысуллар белән өйрәнелде. Иң әһәмиятлесе – аларны бер уртак программа нигезендә, ягъни диалектологик атлас өчен өйрәнү уздырылды. Билгеле бер ераклыктагы авыллар буенча бер үк сорауларга язмача җаваплар алынды. Магнитофон тасмасына язган текстлар аеруча мөһим. Бу текстларның бер өлеше күп санлы хезмәтләрдә дөнья күрде инде (мәсәлән: «Материалы по татарской диалектологии». 1962, 1974, 1978, 1983, 1987, 1988, 1989, 1990 һ.б.). Урал төбәге татар сөйләшләренең тел үзенчәлекләре буенча карталар – атлас төзелде: казан арты сөйләшләрендәге үзенчәлекләрнең Урал төбәге, Көнбатыш Башкортстан, Пермь крае һәм Оренбург өлкәләрендә дә дәвам иткәнлеге анда ап-ачык ярылып ята. Һәм, киресенчә, әлеге җирләрдә башкорт теленең үзенчәлекле билгеләре табылмый. Ә бу картада Урал тирәсендәге 400 авылның сөйләше төшерелгән. Сөйләшләрне бердәм программа нигезендә өйрәнеп, паспортлаштырылган материалны картага төшерү телне өйрәнүнең иң объектив, иң ышанычлы ысулы санала. Безнең тикшеренүләр, атлас нәтиҗәләре түбәндәгеләрне күрсәтте: авазлар составы буенча да, грамматик төзелеше ягыннан да, төп сүзлек хәзинәсе белән дә Пермь краендагы, Башкортстандагы татар сөйләшләре татар теле белән тәңгәл килә. Бу фәнни нәтиҗәләрне беркем дә юкка чыгара алмый. Халык үзе дә туган телен, татар теле, дип күрсәтә бит. Менә шуңа күрә дә туган теле татар булган «башкорт»ларның ничек барлыкка килүен ачыклау, аларның тарихын өйрәнү өстендә зур эш башкарылды.

Билгеле ки, Урал алды төбәгендә дә катлаулы тарихи вакыйгалар була. Алар бу төбәктә төрле рәвештә барган күчешләргә этәргеч бирә. Монгол яуларыннан соң Болгар дәүләте тар-мар ителә. Ә халкының бер өлеше исә төньякка һәм көнчыгышка качып урнашырга мәҗбүр була. Казан ханлыгының 1552 елда тар-мар ителүе, гомумән, зур күчешләр китереп чыгара. Бер яктан, Казан белән тыгыз элемтәдә яшәгән Идел буе халыкларының зур дулкыны Урал буена чигенә, күчеш XX гасырга хәтле дәвам итә. Икенче яктан, Урал алдындагы башкорт кабиләләре каушап, куркып калып, Урал аръягына кача. Бу хәлләр белгечләр тарафыннан объектив рәвештә махсус өйрәнелгән инде.

* * *

Урал тирәсендә җирле сөйләшләрне өйрәнүче галимнәрнең һәркайсында бер сорау туа: ни өчен бу авылларда яшәүчеләр бер үк телдә сөйләшсәләр дә, төрлечә аталып йөртеләләр соң? Кайсы *башкорт* дип, кайсы *типтәр* дип, кайсы *Казан кешесе* дип, кайсы *ясашныйлар*, кайсы *керәстияннәр* дип атала, ләкин бер үк телдә сөйләшәләр. 50–60 нчы елларда Көнбатыш Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнгән галимнәрдән Л. Мәхмүтова, Ә. Әфләтунов, Җ. Алмаз һ.б. – барысы да, бу сорауны ачыклау йөзеннән, тарих, архив материалларына, легендаларга мөрәҗәгать иткән, һәм халыкның төрлечә аталуы аларның җиргә мөнәсәбәтләре белән бәйле булуын ачыклаганнар. Минем үземә дә мондагы татарларның күчү тарихын шактый озак өйрәнергә туры килде. Башкортстаның 27 районындагы татарлар яши торган 160 лап, Пермь краендагы 50 ләп авылда булып, аларның сөйләм үрнәкләрен магнитофон язмаларына тупладык. Бу материалларның зур өлеше матбугатта бастырып чыгарылды. Сөйләм үрнәкләре хәзер дә Институтның диалектология фондында саклана. Болар белән генә чикләнмәстән, Урал төбәгенең тарихы турындагы хезмәтләр белән танышкач, революциягә кадәр дә, совет чорында да бу якның тарихы, андагы катлаулы этнологик хәл күп төрле белгечләрнең игътибарын үзенә җәлеп иткәнлеге ачыкланды. Мәскәү, Оренбург, Пермь, Уфа шәһәрләре архивларында саклана торган күпсанлы документлар белән танышу исә тагын да кызыклы һәм бай материаллар белән эш итәргә мөмкинлек тудырды. Урал буе җирләрен үзләштерүнең күпьяклы һәм гаять катлаулы тарихын берникадәр яктырткан хезмәтләр дә язарга мөмкинлек бирде.

Тарих, этнография, археология белгечләренең нәтиҗәләре буенча, хәзерге Көнбатыш Башкортстан халкының килеп чыгышы Идел буе татарлары белән бәйләнгән. Бу якка чыгышы белән үк болгардардан булган яки болгарларның көчле йогынтысында яшәгән кабиләләр килеп урнашканнар. Бу турыда башкорт тарихчылары Р.Г. Кузеев, шулай ук С.И. Руденко, Н.С. Акимова, С.Н. Шитова, Р.З. Янгузин, Н.А. Мәҗитов һ.б.ның хезмәтләрендә бай мәгълүматлар тупланган. Алардан күренгәнчә, хәзерге Пермь краеның көньягында, Көнбатыш Башкортстан җирендә бик борынгы заманнардан бирле утрак тормышлы, җир эшкәртү белән көн күрүче халык яшәгән. Бу тирәләр Болгар дәүләте белән бик тыгыз

бәйләнештә торган, аерым чорларда хәтта Болгар дәүләте ватандары да булып киткән. Алтын Урда, аннан соң Казан ханлыгы заманында да шулай булган.

Монгол яулары соңында хәзерге Урал алдына күчеп килгән болгар кабиләләреннән түбәндәгеләрне саныйлар: *юрматы, еней, биләр, юрмый, гәйнә-тархан, бүләр, танып.* Бу кабиләләр хәзерге Танып, Тол, Агыйдел, Ык, Дим буйларында яшәгән. Хәзерге көндә менә шушы төбәкләрдәге татар сөйләшләренең татар әдәби теленә бик якын булуының нигезендә күрсәтелгән вакыйгалар ята күрәсең. Һәрхәлдә, хәзерге Пермь краенда, Көнбатыш Башкортстанда яшәүче татарларның саф татарча сөйләүләренә әлеге менә шушы Болгар дәүләте даирәсендәге кабиләләр нигез салган, хәлиткеч роль уйнаган.

Казан ханлыгы чорында бу уртак тамырлы бәйләнешләр дәвам итеп кенә калмый, бәлки тагын да үстерелә. Ык буе, Агидел тирәләрен биләү өчен бирелгән ярлыклар шул турыда сөйли. Мәсәлән, М.И. Әхмәтҗанов тикшеренүләреннән (1985) күренгәнчә, Ык буе җирләрен (хәзерге Башкортстанның Ярмәкәй районы) 1523 елда, Сәхип-Гәрәй хан биргән тархан ярлыгы нигезендә, хәзерге Питрәч, Саба районнарына керә торган авыллардан чыккан кешеләр биләгән.

Д.М. Исхаков күрсәтүенчә, хәзерге Татарстанның Актаныш (хәзер Минзәлә) районына керә торган Татар Мөшеге авылы игенчеләре кузгаткан бәхәсне хәл иткән чакта, аларның да үз җирләрен Казан ханы Сәхипгәрәй тарафыннан 1523 елда бирелгән ярлык нигезендә биләгәнлекләре мәгълүм була. Тайламас авылы татары Котлымәт Котлыгашевларга тарханлык грамотасы Ибраһим хан (1467–1478 елларда идарә иткән) тарафыннан бирелгән булган (Борынгы документларның үзәк дәүләт архивы – БДҮДА: 1173 ф., 1 нче тасвирлама, 196 сакл. бер.). М.К. Любавский, Ирәкте волосте кешеләренең бабалары Шәех-Әхмәт һәм аның иптәшләренә дә тарханлык Сәхипгәрәй тарафыннан бирелгән булган, дип яза.

Русия идарә итә башлагач, баштагы чорларда Казан ханнары биргән ярлыклар үз көчендә калдырыла яки тарханнарга шул ярлыкларны раслый торган өстәмә грамоталар бирелә. Мәсәлән, 1595 елгы грамота нигезендә Саралы авылында яшәүче Туктамыш һәм аның иптәшләренә Кабан, Ургузе, Тәкермән, Мәләкәс, Кузабы, Итнә, Карамалы, Каүҗияк, Тегермәнлек, Сурынчак һәм баш-

ка елгалар бассейннарындагы җирләрне биләргә грамота бирелә. XVIII гасыр ахырында исә, түбәндәге авыллар үзләрен Туктамыш нәселләре, дәвамчылары дип саныйлар: Саклаубаш, Өчиле Саклау, Иман, Сарсаз, Тәкермән, Сураш, Саралы Бикмәт, Сулюково, Абдул, Сәет, Сәмәкәй, Күгәш, Каран, Келәнчетамак, Сарман, Рангазар (БДҮДА: 1324 ф., 2 тасв., сакл. бер. 1249, 55–56 б.).

Казан ханлыгы җимерелгәч, Урал алды җирләренә Идел буе халыкларының күпләп күчүе башлана. Әлбәттә, бу күчеш кисәк кенә купмаган. Элек-электән яшәп килгән бәйләнешләр булган җирләргә күчә халык. Алда әйтеп үткәнчә, борынгыдан, Болгар дәүләте чорыннан ук яшәп килгән инде ул бәйләнешләр. Традицион бәйләнешләр күчеш юнәлешен билгеләүдә хәлиткеч роль уйныйлар.

Урал ягына күчүнең төп сәбәпләре фәндә билгеле: Идел буенда җирләрнең үзләштерелгән булуы, халыкның тыгыз утыруы, урыс хөкүмәтенең көчләп чукындыру сәясәте алып баруы һәм, әлбәттә, Казан ханлыгының җиңелүе, бетерелүе белән килешмәү. Идел буе халыкларының, аеруча татарларның, Урал тирәсенә күпләп күчүләренә ярдәм итә торган башка сәбәпләр дә булган.

Алар арасында иң әһәмиятлесе – Идел буе белән Урал тирәсенең Русиягә кушылу шартларының төрле булуы. Яңа кушылган халыкларның Русия составында төрле иҗтимагый-икътисади хәлдә булуы Урал алды җирләрендәге этник хәлнең алга таба үзгәрешендә зур роль уйнаган. Мәсәлән, Казан ханлыгы халкы үзенең җайлашкан яшәү урыннарыннан куыла, авыр салым (ясак) түләргә мәҗбүр ителә, ул салым һәртөрле өстәмә җыемнар исәбенә тагын да авырая. Халыкларны көчләп чукындыру башлана, колониаль изү көчәя. Ә Урал алды төбәкләрендә шартлар башкачарак була. Төрле якка сугышлар алып бару нәтиҗәсендә көчен шактый югалткан Русия дәүләте көнчыгыш чигендәге әлеге бик аңлашылып та бетмәгән төбәкләр белән саграк эш итәргә тырыша. Урал да үзенең катгый хакимлеген урнаштыруда бераз тыелыбрак тора. Мәсәлән, Урал тирәсендәге халыкка үз җирләре белән үзләре теләгәнчә идарә итәргә мөмкинлек вәгъдә ителә, ягъни андагы җирләр вотчина рәвешендә биләүчеләрнең үз карамагында кала (дөрес, вотчина хуҗасына җирләрне сату тыелган була). Сүз уңаенда күрсәтеп китәргә кирәк, рус дәүләтенә буйсындырылган бер генә төбәктә дә, бер генә халыкка да мондый вотчина хокукы бирелмәгән. Шулай итеп, хәзерге Урал төбәге мәйданында җир

биләгән һәркем (әлбәттә, аларның зур күпчелеге шундагы җирле төрки халык. Аларның татармы, башкортмы яки башка халыкмы икәнлеге белгечләр хөкемендә) вотчиналы башкорт (башкиры-вотчинники) булып исәпләнә башлый. Гомумән, Урал буендагы барлык кешеләр дә «башкортлар» дип аталып китәләр. Бу турыда архив документларын өйрәнү буенча зур эш башкарган башкорт тарихчысы У.Х. Рәхмәтуллин болай дип яза: *«Уфа өязенең көнбатыш һәм төньяк өлешләрендә яшәүче чувашлар, татарлар һәм марилар һәм хәтта руслар да XVII гасырда башкорт дип аталып йөртелә башлый».*

Ягъни, билгеле бер чорда, бигрәк тә XVI гасырның икенче яртысында һәм XVII гасырда башкорт сүзе адмиинистратив термин һәм сословие атамасы буларак кулланылган. Бу факт патша чиновниклары язмаларында да, тарих, этнография, география белән бәйле хезмәтләрдә дә, эш кәгазьләрендә дә билгеле, хәтта гадәти хәл буларак чагылыш тапкан һәм беркем тарафыннан да бәхәс тудырмаган. Бу язмада вотчиналылар, башкорт-вотчиналылар дигән атамалар кулланыла. Ләкин аларны хәзерге милли башкортлар белән тиңләү һич тә дөрес түгел. Шулай итеп, урыс дәүләтенә кушылгач, баштагы чорларда Урал буе җир биләүчеләре үз җирләрен вотчиналы буларак били башлыйлар, үзләре теләгәнчә идарә итәргә хокуклы булалар. Бусы – **беренчедән.**

**Икенчедән,** ясак түләү буенча да Урал буе элекке Казан ханлыгы территориясеннән аерылып торган. Язма чыганаклар, архив документлары *башкорт* ясагының Казан өязендәге халыкларга салган ясактан бермә-бер җиңелрәк булуы турында сөйли.

Мәсәлән, вотчиналыларга, үз җирләрендә яшәүче күчмәннәрне тотып, хакимнәргә бирергә кушылгач, алар болай дип җавап бирәләр: вотчиналылар 8 ясакка бер сусар тиресе түли, ягъни бер ясакка бер гривна булса, ә Казанда бер ясак 8 сум 26 барнау (русча: алтын) ярты тәңкә (осемь рублев двадцать шесть алтын с полу деньгою) хасил итә, менә шуңа күрә дә ул качаклар бездә яши дә, бездә татарлар гына түгел, башкалар да, урыслар да яши бирә, җир сөрә... (БДҮДА: 248 фонд, 3 тасв., 115 китап, 978 б.) Уфа провинциясендә ясакның икенче серле ягы да була: ул һәр аерым кеше тарафыннан түгел, ә җәмәгатьчелек тарафыннан гомуми рәвештә, бергәләп түләнә, ягъни нинди дә булса бер авылга ике ясак салынган икән, аны түләүдә ничә кеше катнашуының әһәмияте булмый, ул тикшерелми дә. Ясак түләүчеләр үз җирләренә кемне дә булса кертә һәм

ясак түләүне шул кергән кешегә тапшыра алганнар. Еллар үткән саен теге кергән кешеләр үзләре ясакчы «башкорт» булып китә алган. Башкорт ясагының чагыштырмача җиңелрәк булуы турында күп кенә дәүләт эшлеклеләре (П.И. Рычков һ.б.), тарихчылар (В. Филоненко, Р.Н. Степанов һ.б.) язып калдырган.

**Өченчедән,** Башкортстан дигән яңа территориаль берәмлек урыс дәүләтенең чигендәрәк булган, XVI-XVII гасырларда тиешле күзәтү булмаган, ә Урал буен идарә итү әле җайга салынып кына килгән. Бу исә мондагы халыкны барлау, аның санын алу кебек эшләрнең начар үтәлүенә китергән, Башкортстандагы халыкның саны беренче мәртәбә III ревизиядә (1762 ел) генә алынган.

**Дүртенчедән,** Урал тирәсе чагыштырмача иркен булган. Урал алды табигатенең әле кул тимәгән почмаклары җирсезлектән интеккән халыкны шулай ук үзенә тартып торган.

Менә бу санап кителгән факторлар, бер яктан, элек Казан ханлыгы составында яисә аның карамагында яшәүче халыкларның тормыш шартлары тагын да авыраюга, ризасызлык артуга китерсә, ягъни аларны кысып чыгарса, икенче яктан, Урал буена качып килгән халыкны кертә, сыйдыра һәм урнаштыра торган мөмкинлекләр тудыра.

Менә шушы шартларда хәзерге Пермь крае татарларының бабалары да формалаша башлыйлар. Билгеле булганча, хәзерге Пермь краенда 160 мең чамасы татар яши, тагын 30–32 мең кеше үзенең туган теле итеп *татар телен* күрсәтә. Шик юк, соңгыларының зур өлеше документларда башкорт исемендә йөрүче татарлар булырга тиеш. Алар Тол (Тулва), Муллы (Мулянка), Ирен, Сөлил (Сылва), Сеп (Сыпь), Шауба (Шаква), Бөрмә (Бырма) һәм аларның кушылдыклары буйларында яшиләр.

Аларның үз араларында үзләрен икегә бүлү гадәткә кергән: Гәйнә ягы һәм Көнгер ягы, Ләкин Гәйнә ягы вәкилләре үзләрен болай атауны яратып бетермиләр. Мондый бүленешнең сәбәпләре Пермь татарлары кичергән тарих белән бәйләнгән. Казан ханлыгы җимерелгән һәм аның протекторатындагы җирләр әкренләп Рус дәүләтенә кушыла барган чакта Пермь татарлары ике административ үзәккә карый башлыйлар.

*Гәйнәләр* дип хәзерге Барда районында яшәгән татарларның бер өлешен атыйлар. Революциягә кадәр алар Оса өязенә кергәннәр. Рус язма чыганакларыннан күренгәнчә, Оса шәһәре Казанның бер бистәсе булып саналган (БДҮДА: 1209 ф., 1 тасв., 153 китап).

Билгеле булганча, Урта Кама тирәләре, Агыйделнең түбән агымы борын-борыннан Урта Идел татарлары белән бер үк тарих кичергәннәр. XV–XVI гасыр язма чыганакларда Агыйдел җире, башкорт улуслары, Нугай Урдасы кебек мөстәкыйль бүленешләр булган. Урта Кама һәм Түбән Агыйдел тирәләре, билгеле бер традицион чикләр эчендә, мәйдан, административ нисбәтлек ягыннан тотрыклы даимилек саклыйлар: Болгар дәүләте составында; Ул монгол яулары тарафыннан җимерелгәч, аның дәвамчысы Казан ханлыгында; ул Рус дәүләтенә кушылгач, Казан Приказында; аннан соң Казан өязендә. Бу традицион административ нисбәтлек 1728 елга, ягъни губерналар оешканга хәтле сакланып килгән.

Казан ханлыгы җимерелгәч, «бөтен Көнбатыш Уралны Рус дәүләтенә кушарга мөмкинлек туа»[1] һәм Түбән Агыйдел – Оса төбәге Казан Приказына кертелә, ә Пермь татарлары яши торган мәйданның калган көнчыгыш өлеше Себер Приказына (башта Чердын өязенә, аннан соң Көнгер өязенә) карый башлый. Көнгер өязенә кергән татарларны ясаклы крестьяннар катламына (сословиясенә) язалар һәм алар *ясаклы татарлар* дип атала башлыйлар. Ягъни аларга карата татар этнонимын куллану дәвам итә.

Оса тирәсе татарларының язмышы исә бераз катлаулырак, Казан үзәгенә караган Уфа провинициясе (соңрак: өязе) оеша. Аңа Оса тирәсе һәм бөтен хәзерге Төньяк-Көнбатыш Башкортстан җирләре кертелә, андагы җирбиләүчеләр – татармы, чувашмы, удмуртмы – барысы да башкорт дип атала башлый, аларга үз җирләрен вотчина хокукында биләргә рөхсәт ителә. Шулай итеп, Пермь татарларының бер өлеше – хәзерге Барда районы тирәсендә булган берникадәр авыллар «башкорт» катламына кереп кала. *Башкорт* сүзенең билгеле бер тарихи чорда административ атама да, катлам да, милләт тә белдерә торган термин буларак кулланылуы тарихчыларга билгеле. Бу турыда киңрәк мәгълүмат аласы килгән кешегә түбәндәге галимнәрнең хезмәтләрен карап чыгу кызыклы булыр: Н.А. Гурвич[2], Р.Г. Кузеев[3], Д.Б. Рамазанова[4] һ.б.

---

[1] История Урала. Пермь, 1976. Т. I. С. 45.

[2] Гурвич Н.А. Племенной состав населения Уфимской губернии и приблиз-я численность его в 1878 г. Уфа: Изд-во Уфимского статистического комитета, 1880.

[3] Кузеев Р.Г. Происхождение башкирского народа.

[4] Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии.

Башкорт катламына кергән кешеләр ясакны чагыштырмача азрак түлиләр, солдатка алынмыйлар, Рус дәүләтенең көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләрен саклауда катнашырга тиеш булалар, шулай итеп башкорт дигән, берникадәр өстенлекләре булган йомышлылар катламы барлыкка килә. Бу хәл яңа күчеп килгәннәрнең дә башкорт катламына керергә тырышуына, «башкорт» икәнлекләрен бик тырышып сакларга омтылуга китергән. Башкорт җирләрен тартып алып бетергәч, Себер җирләрен үзләштерә башлагач, Рус хөкүмәтенә башкорт дигән йомышлы катламның кирәге бетә һәм XIX гасырның урталарында бу катлам юкка чыгарыла, ә «башкортлар» исә башка крестьяннар белән бертөсле үк катламга кертеләләр. Ләкин «башкорт»ларга җан башына җир күбрәк бирелгән булган һәм алар революциягә кадәр үзләренең җирләрен традицион чикләрдә, аерым биләүне дәвам итәләр. Шул рәвешле, беркадәр өстенлекле катлам булу сәбәпле, «башкарт»лар берничә гасыр буе аерып йөртеләләр. Хәтта бер үк авылда «башкорт», «типтәр» яки «ясаклы татар» яшәгән очракта да, алар җирләрен аерым билиләр, төрле икътисади мәсьәләләрдә аерым идарә ителәләр.

Менә бу фактлар *Оса башкортлары* һәм *Көнгер татарлары* дигән ике төркемнең бүленеп чыгуына китерә, ул халык күңеленә дә сеңә бара. Шуңа күрә хәзерге Барда районында «без башкорт татарлары» яки «без ни башкорт, ни татар» дигән сүзләрне ишетергә мөмкин.

Әмма бу ике төркемнең тормыш үзенчәлекләре дә, сөйләм телләре дә бертөсле. Бу турыда тарихчылар да, телчеләр дә[1] күрсәтеп үтәләр.

Шушы ук хезмәтләрдә Пермь татарлары сөйләшенең татар теленә бик якын торуы төрле-төрле материаллар белән исбатлана. Татар теленең диалектологик атласы да (Казан, 1989), беренчедән, пермь сөйләшенең бөтен таралыш территориясендә дә бертөсле булуын, икенчедән, татар теленә каравын, бигрәк тә урта диалект сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтүен дәлилләде.

Билгеле булганча, халыкның теле аның тарихы белән турыдантуры бәйләнгән, тел халыкның төп билгеләреннән берсе булып

---

[1] Историко-географическое описание Пермской губернии, 1801: § 37, § 38; Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т. К вопросу об истории образовании и изучения диалектов и говоров // МТД, 2. Казань, 1962.

тора. Этносның үсеш-үзгәреше барышында булып үткән барлык мәдәни-икътисади һәм башка вакыйгалар аның матди һәм рухи мәдәниятендә генә түгел, бәлки телендә дә теге яки бу дәрәҗәдә эз калдыралар. Шуңа күрә дә теге яки бу халыкның телен өйрәнү аның этник нисбәтлелегеннән билгеләүдә әһәмиятле роль уйный.

Пермь татарлары сөйләшенең тел үзенчәлекләрен тикшерү, шул сөйләш вәкилләренә кагылышлы тарихи-этнографик әдәбиятны өйрәнү әлеге этнографик төркемнең этник яктан формалашу юлы үзенчәлекле һәм катлаулы булуын күрсәтте. Пермь татарларының барлыкка килүе Урта Иделдә, Уралда һәм Себердә барган катлаулы тарихи вакыйгалар белән бәйләнгән. Ул ерак гасырларга барып тоташа һәм, әлбәттә, татар халкы формалашу шартларында барган. Татар халкы этник составы һәм теле ягыннан Урта Идел һәм Урал алды тирәләрендә *скиф-сармат* чорларында ук җирле төрки һәм төркиләшкән фин-угыр кабиләләренең бергә тупланып укмашуы нәтиҗәсендә формалаша башлый. I меңьеллыкның IV–V гасырларында Идел–Кама ареалында төркемләшүнең әһәмиятле яңа чоры башлана: бу җирләргә төрки телле кабиләләрнең күпләп килүе күзәтелә[1]. Археолоик тикшеренүләр бу җирләрдәге каберлекләрнең *сөннәрнеке* булуы турында сөйлиләр (В.Ф. Генинг; А.Х. Халиков; Н.А. Мәҗитов; П.Н. Старостин; һ.б.). Урта Иделгә һәм Урал алды җирләренә төрки кабиләләр болгарларга чаклы ук күпләп килгәннәр. Болгар дәүләте чорында, мәсәлән, IX гасырда, фин-угырлар белән бергә, *суар, эскел, суаз, бортас* һ.б. кабиләләр яшәгәнлеге билгеле.

Этнолингвистлар күрсәтүенчә, бу атамаларның составында ас – *аз, яс, ус, уз, ош, иш, уш* компоненты бар. Ул компонент башка төрки халыкларны белдерә торган сүзләрдә дә күзәтелә. Бу яктан караганда, пермь татарларының бабаларына карата кулланылган *остяк* сүзе зур кызыксыну уята. М.З.Зәкиев, бу сүз дә *ас* компонентына нигезләнгән, дип саный[2]. Хәзерге көндә асларның төрки булганлыгы турында да күп кенә фикерләр тупланган. Бу сүз белән печенегларны, болгарларны һәм бортасларны да, карачай-балкарларны да атаганлыклары мәгълүм[3], шунысы кызыклы, Оса (шәһәр

---

[1] История Татарской АССР. Казань, 1968.

[2] Закиев М.З. Проблемы языка и происхождения волжских татар. Казань, 1986.

[3] Шунда ук.

иseme) атамасының да нигезендә шушы ук компонент булуы мөмкин.

Шулай итеп, кайчандыр Пермь татарларының бабаларын белдергән остяк сүзендә Идел–Урал ареалында булып узган бик борынгы тарихи вакыйгаларның эзе сакланып калган, дип фаразларга мөмкин.

Тарихчылар, хәзерге Пермь краеның көньяк яртысында, ягъни хәзер Пермь татарлары яши торган җирләрдә, кайчандыр угырлар яшәгән булган, дип саныйлар; аларның бер өлеше руслашкан, бер өлеше татарлашкан, ә бер өлеше исә көнчыгышка һәм төньякка таба күчеп киткән, дип аңлаталар.

Шунысын аерып күрсәтеп үтәргә кирәк, Сөлил, Чусовая бассейннарында һәм Урта Кама тирәсендә IX–XV гасырларда яшәгән кабиләләрнең культурасын, археологлар «сылва культурасы» дип аерып чыгаралар[1]. Галимнәр, бу культура Агыйдел һәм Ык елгаларының түбән агымы буендагы шул ук чорга караган культурага якын тора, дип саныйлар.

Тагын шуны ассызыклап үтәргә кирәк, халык санын исәпкә алу кенәгәләрендә Пермь татарларының Көнгер өязенә караганнары гына, ягъни Көнгер татарлары гына исәпкә алынган.

Бу кәнәгәләрдән күренгәнчә, Көнгер татарлары Тол елгасының югары агымы бассейнында да булганнар. Тол буйларындагы (Оса тирәсе) татарларның зур өлеше бу кенәгәләргә кертелмәгәннәр, чөнки алар Уфа провинциясе составындагы Оса өязендә булганнар, бөтен Башкирия[2] халкы кебек, башкорт-вотчиналылар исеме астында аерым исәпкә алына торган булганнар. Кызганыч ки, «башкорт» ясак кенәгәләре югалганнар, безгә килеп җитмәгәннәр.

Пермь татарлары тарихына ачыклык кертә торган тагын бер әһәмиятле чыганак бар. Бу документ «О начале и происхождении разных племен и иноверцев» дип атала. Ул 1784 елда төзелгән (Пермь өлкәсе дәүләт архивы, 316 фонд, 1 тасвирлама, 78 саклау берәмлеге). Бу документта башта Пермь тирәсендәге Кояново,

[1] Бадер О.Н., Оборин В.А. На заре истории Прикамья. Пермь, 1958; Генинг В.Ф. Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа // Труды КФАН СССР. Серия гум. наук. Вып. 2. И., 1959.

[2] Казан ханлыгы яулап алынгач, Русиягә көч кулланмыйча кушылган өлкә күздә тотыла.

Култаево һәм Янычево (хәзерге Югары Муллы һәм Пермь районнары) авыллары халкының килеп чыгышы турында риваять китерелә: «Аларның бабалары тархан нәселеннән булганнар һәм бу урыннарда бик борынгы заманнардан бирле яшиләр. Иван Васильевич Казанны алгач, алар Русия державасына буйсындырылганнар, ә аңа кадәр алар нугай ханы кул астында булганнар...». Алга таба аларның яшәү рәвешләре бәян ителә: «Алар күпсанлы һәм гадәттәгечә итеп салынган йортлары булган авылларда яшиләр; аларның бөтенесе дә ак келәтләре, ак бүлмәләре булган өйләрдә һәркем үз гаиләсе белән яши; өйләре һәм өй җиһазлары бар; үзләренә җитәрлек сөрү җирләре һәм чабынлыклары бар, һәрберсе булдыра алганча терлек тота...».

Бу өзекләр Пермь татарларының бабаларының утрак тормышлы булулары, иркен, чиста, матур өйләрдә, зур-зур авыллар булып яшәүләре турында сөйли. Аларда үз чорларына карата шактый алга киткән игенчелек булган.

Шунысы бик кызыклы, әлеге документның 68 нче битендә тагын бер «Сведение...» китерелә. Ул Гәйнә (башкортлар), Танып (татарлар) һәм Иштирәк (ясаклы татарлар) волостьларында яшәүчеләргә карый, анда югарыда күрсәтелгән документ сүзмә-сүз кабатлана.

Шулай итеп, бу документтан күренгәнчә, хәзерге Пермь крае Пермь, Барда, Орда, Чернушка, Өя (Уинский), Көнгер һәм Октябрь районнарында яшәүчеләрнең бабалары, килеп чыгышлары буенча да, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре буенча да, бер булган, ә аларны «гәйнә башкортлары», «көнгер татарлары» дип бүлеп йөртү соңрак барлыкка килгән. Югарыда күрсәтеп үткәнчә, мондый бүленеш өчен җирлек Башкирия составында Оса өязе, Себер Приказы составында Көнгер өязе барлыкка килгәч кенә килеп туган булырга мөмкин. Кайбер хәзерге тарихчыларның аларны гәйнә башкортлары һәм пермь татарлары дип икегә бүләргә маташуының тел ягыннан да, аларның матди һәм рухи мәдәниятләре ягыннан да бернинди нигезе юк.

XVI гасыр ахырында – XVII гасыр башында остяк сүзе белән пермь татарларының көньягындагы күрше халыкларны да атаганнар, монда да татар һәм остяк сүзләре бернинди аермасыз кулланыла. Мәсәлән: «Ирендә (Ирен елгасы бассейны) Аксиев волосте Беловкан, Кошчы, Балыкчы татарлары һәм остяклары сату

итә башласалар...» яки «Чердын өязе Сөлил, Ирен буйларына рус сәүдәгәрләре һәм Казан, һәм Уфа өязләреннән татарлар һәм остяклар килеп сату итәләр»... (документ 1618 елга карый)[1]. Соңрак Уфа краендагы җирбиләүче халыкка карата һәм катлам, һәм административ эчтәлекле «башкорт» термины ныклап урнашкач, бу өзекләрдә телгә алынган татарлар һәм остяклар документларда башкорт дип аталып китәләр.

Тарихи чыганакларны һәм әдәбиятны өйрәнү *остяк* сүзенең төрле халыкларга карата кулланылуын күрсәтә. Руслар хантларны остяк дип атаганнар, хантлар исә үзләрен алай атамыйлар. М.Е. Бударин болай дип яза: хантларны себер татарлары кимсетеп *уштяк* дип атаганнар, ә руслар бу сүзне *остяк* дип үзгәрткәннәр. Казаклар *иштәк* дип башкортларны йөрткәннәр. Остяк дип мансиларны да атаганнар[2].

Пермь татарлары бабаларының кайчандыр остяк дип йөртелүе турында соңрак чорда язылган документларда да фактлар теркәлгән. Мәсәлән, Ирен буендагы Басино авылы татарлары 1798 елда Пермь губернасы идарәсенә җир турында язган үтенечләрендә М. Кайсаров кенәгәләреннән мондый өзек китерәләр: «Бу авылның җирләре безнең бабаларыбыз Байса Албашев, Урамет Таисин һәм аның бертуганы Батырныкы булган, алар элек остяк дип аталганнар, хәзер исә шул ук авылда без «*татар*» дип аталабыз»[3].

Пермь крае тарихчыларыннан В. Шишонко да үзенең «Пермь елъязмасы» (I–V Период, 1881–1887) дигән хезмәтендә, 1578–1579 елларда анда остяклар яшәгән, хәзер алар *татар* дип аталалар, дип күрсәтә.

Галимнәр, ориенталистлар һ.б. Пермь татарлары арасында булып, алар белән якыннанрак танышкач, аларның документлардагы атамалары һәм үз араларында кулланыла торган атамаларның туры килмәвенә игътибар иткәннәр. Мәсәлән, П.И. Мельников Пермь өязе Кояново авылында була һәм 1841 елда «Көнгергә бару» дигән мәкалә язып бастыра. Н.К. Чупин, Кояново һәм Култаево

---

[1] Исхаков Д.М. К вопросу об «остяцком» компоненте пермских татар и его связи с носителями сылвенской культуры // Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья. Уфа, 1987.

[2] Бударин М.Е. Прошлое и настоящее народов северо-западной Сибирии. Омск, 1952.

[3] Пермь гыйльми архив комиссиясе хезмәтләре. Пермь, 1896. 3 нче чыгарылыш.

авылларының халкын бөтенләй татарлашып беткәннәр, дип күрсәтә һәм болай дип яза: инде күптәннән телләре белән дә, тормыш итү рәвешләре белән дә янәшәләрендәге татарлардан кечкенә генә дә аерылмыйлар һәм руслар аларны шул исем белән (ягъни татар дип. – *Д.Р.*) атап йөртәләр дә[1].

Менә мондый шартларда халыкның этник нисбәтлеген ачыклау шактый четерекле. Бу төп үзәкләрдән читтә, еракта яшәгән, әле яңа гына буйсындырылган тарафлардагы ныклап ачыкланып җитмәгән кечкенә төркем халыкларга карата аеруча катлаулы мәсьәлә булып торган.

Пермь татарлары сөйләшендә татар теленең төп диалектларыннан санала торган мишәр һәм урта диалектларда булмаган, ә себер диалектлары, көнчыгыш төрки (хакас, алтай, шор һ.б.) телләр белән уртак булган бер төркем күренешләр бар. Аларны себер татарларының соңгы чорлардагы йогынтысы нәтиҗәсе генә итеп карый алмыйбыз. Тулы система хасил итә торган уртак күренешләр борынгы чордагы катнашлык белән дә бәйле булырга тиеш, чөнки сөйләштә әле тагын уйгыр һәм борынгы уйгыр телләре белән уртак үзенчәлекләр табыла.

Менә шушы фактларга таянып, Пермь татарларының этник формалашуында ниндидер борынгы көнчыгыш төрки компонент та катнашкан булырга тиеш, бу компонент исә себер татарлары һәм кайбер башкорт кабиләләре өчен уртак булган булса кирәк, дип фараз ителә. Бу компонент шушы остяклар белән бәйләнешле булгандыр, дип әйтә алабыз, чөнки XVI гасырның ахырына, XVII гасырга караган сан алу кенәгәләрендә һәм башка документларда остякларның исемнәре төрки исемнәр: Бисердачко Батырев, Кунчурайко, Тасимко, Ураско Урмаметов, Алейко, Ишимбайко, Айгиндейко, Тогаберде (Дугаберде), Камалтинко, Кичкеняшай, Колычбаев, Болонтай, Сигизяков, Мурзакилдейко, Кузембердей, Турчебей, Терегулов, Яныш Толгузин, Козебахта Карьев һ.б. дип бирелгән.

Минемчә, Идел буе төрки компоненты, пермь сөйләше вәкилләре Казан татарларының бер этнографик төркеме булып, ә аларның сөйләше татар теленең урта диалектына караган бер сөйләш буларак формалашуда төп хәлиткеч рольне уйнаган.

---

[1] Чупин Н.К. Географический и статистический словарь Пермской губернии. Т. I–II (1873, 1878–1880).

Галимнәр Идел буе – Урал алды багланышларының мәдәни-икътисади гына түгел, бәлки, еш кына, сәяси характерда да булуын кабат-кабат күрсәтеп киләләр. Кайбер галимнәр Агыйделнең түбән агымы тирәсендәге җирләр Болгар дәүләте составына кергән булган, ә халкы исә Болгар дәүләтенә салым түләп торган, дип язалар. Төньяктарак яшәгән халыклар да Болгар дәүләтенең көчле йогынтысы астында булганнар. А.А. Дмитриев, зыряннар, пермяклар үзләренең тормыш-көнкүрешен, сәнәгатьләрен болгарлар тәэсире астында нык үстерделәр һәм күршеләреннән шактый аерылып торалар иде, дип яза. А.Х. Халиков, Е.П. Казаков һ.б. күп кенә галимнәр бу тирәләргә XIII–XIV гасырларда болгарлар күчеп килгән дип саныйлар.

Урта Идел буендагы утрак тормышлы халыкның бер өлеше яңа җирләр, чагыштырмача тынычрак урыннар эзләп, күптән таныш һәм элек-электән аралашып килгән юллардан, аеруча Кама буенча төньякка һәм төньяк-көнчыгышка таба күчәргә мәҗбүр була. XIII гасырда Чепца (хәзерге Киров өлкәсе һәм Удмуртия) елгасы бассейнына болгар кабиләсе килә. XIII–XIV гасырларда Ык бассейны һәм Түбән Агыйдел буйларына кече, кәлчер, йомран, бүләр, еней, юрми кабиләләре күчеп утыра; алар Болгар дәүләте составында булалар; Ык буена урнашып калган байлар кабиләсе дә болгарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә булган. Кайбер чыганакларга караганда, Пермь краенда төркиләр барлыкка килү дә шушы ук вакыйгалар белән бәйле. Бу хакта мондый юллар бар: «кайбер башкортлар (биредә Пермь татарларының Оса өязендә яшәгән өлеше күздә тотыла. – *Д.Р.*) һәм татарлар, бигрәк тә Болгар илендә яшәүчеләр, монгол яуларыннан соң монда күчеп килделәр... Болгар һәм татар исеме белән билгеле булган кайбер болгарлар Пермь губернасында урнаштылар; Пермь губернасы «башкорт»лары һәм татарлары үзләре дә легендаларында Шәһри Болгар дип аталган җирдән күчеп килгәнлекләре турында сөйлиләр». Революциягә кадәрге тарихи әдәбиятта «Кама Болгарстаны, Идел-Кама Болгарстаны, Кама буендагы болгарларның да, Идел буендагы болгарларның да атамалары» кебек тәгъбирләр очрый. А.А. Дмитриев фикеренчә, Идел-Кама Болгариясенең төньяк-көнчыгыш чикләре булып Оса һәм Красноуфим өязләре торган[1].

---

[1] Дмитриев А.А. Исторический очерк Пермского края. Пермь, 1896. С. 5–25.

Үзләренең килеп чыгышлары турындагы легендаларында Оса һәм Пермь губернасы «башкорт»лары һәм татарлары: «Без чыгышыбыз белән тарханнардан булабыз, бу җирләргә бик борынгы заманнарда күчеп килгәнбез, аннан соң Нугай хан кул астында булдык», дип күрсәтәләр (Пермь өлкәсе дәүләт архивы: 316 ф., 1 оп., сакл. берәмл. 78). Димәк, алар, Иван IV Казанны алганчы ук, шушы урыннарда яшәгәннәр. Икенче чыганакта исә, алар үзләрен, Шәһри Болгар дип атала торган илдән күчеп килдек, Болгар илен XIII гасыр ахырларында калдырдык, дип аңлаталар.

Р. Кузеев фикеренчә, гәйнә-тарханнар этник яктан болгар чорына караган кабилә булганнар. Автор, бик күп фактларга таянып, гәйнә-тарханнарның нигезе болгар булуын, Урта Идел халыклары белән бер булуларын исбатлый һәм болай дип нәтиҗә ясый: «Гәйнәләрнең бабалары, юрматы, юрми, бүләр, кече кабиләре белән бергә, болгар-угыр чолганышында булганлыгын катгый расланган факт, дип билгели алабыз». Автор гәйнәләрнең Тол буйларына килеп чыгуын, XШ–XIV гасырларда булган, дип исәпли[1].

Шунсы әһәмиятле, Р.Г. Кузеевның нәтиҗәләре тел материаллары белән тагын бер кабат раслана. Әле генә санап үтелгән кече, юрми һ.б. кабиләләрнең Көнбатыш Башкортстанда яши торган дәвамчы оныклары, гәйнә-тарханнарның оныклары кебек үк, саф татар телендә сөйләшәләр, аны үзләренең теле, ана теле дип саныйлар; аларның телендә башкорт теленә хас булган аерымлыклы, үзенчәлекле күренешләр бөтенләй юк[2].

Рус телендәге язма чыганаклар Пермь җирләренә күчеп килгән татарларның *би*ләр булуы турында сөйли: Урак би, Сөендек би. Аларның әтиләре мулла булган (Югары һәм Түбән Муллы елгаларының исемнәрен шуннан калган дип аңлаталар). Күрәсең, ул миссионер буларак шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән, чөнки XVI гасырда Трифон Вятский килгәндә, әлеге җирләрдә татарлар һәм остяклар яшәгәннәр инде. Һәм, иң әһәмиятлесе, бу ике халык тормыш-көнкүреше белән дә аерылмаган, исемнәре дә төрки исемнәр

---

[1] Кузеев Р.Г. Происхождение башкирского народа. Уфа, 1974.

[2] Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. 191 с., Ее же: К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996. 239 с.; Ее же: Татары Восточного Закамья: их распространение, формирование говоров. Казань, 2001. 208 с. и др.

булган, Трифон Вятский остякларны чукындыруга ирешә алмаган, җирле халык инде мөселман динендә булган.

Бу мөнәсәбәттә караганда шундый сорау туа: *гәйнә* атамасын «башкорт» Килейко Акзкильдин һәм аның иптәшләре алып килмәдеме икән?

Беренчедән, 1596 елга караган, Килейко Акзкильдиннең бу җиргә кертелүе турындагы документта[1] әлеге төбәк Ульвинская (рус скорописендә *т* хәрефе өскә чыгарып языла торган булган, шуңа күрә ул төшеп кенә калган булырга мөмкин, ягъни, «Тулвинская»?) дип атала, димәк ул чорда әлеге гәйнә терминының кулланылышта булуы шикле.

Икенчедән, алга таба да гәйнә атамасы хәзерге Барда районына туры килә торган мәйданда билгеле бер төбәктә генә яшәп калган. Бу төбәк К. Акзкильдинга бирелгән җирләр белән туры килергә мөмкин.

Өченчедән, гәйнә атамасы белән бәйле җир, авыл исемнәре, Пермь өлкәсендә түгел, Көньяк-көнбатыш Башкортстанда (Миякә төбәгендә) сакланып калган. Күрәсең, гәйнәләр шунда яшәгән булганнар.

Дүртенчедән, башкорт күчмә кабиләләренең төньяктагы урманлы җирләрдә яшәве бик шикле. Бу мәсьәләгә карата Р.Г. Кузеев та болай яза: «Урманлы җирләргә башкортларның күчүе масса төсендә булмаган; башкортларның тик кечкенә төркемнәре генә, төп башкорт халкыннан аерылып, баерак ау урыннары эзләп булса кирәк, төньякка күчеп утырганнар»[2].

Бишенчедән, гәйнә (Гайни – Гайнетдин) атамасының килеп чыгуы турындагы риваятьтә дә чагыштырмача соңгырак чорга караган вакыйгалар тасвирланган булса кирәк: Гайни Югары Урал алды тирәсендә җир ала һәм елына 5 әр тиен тиресен Чердынга илтеп түләргә тиеш була[3]. Югарыда әйтелгәнчә, Чердынга ясак түләү, Казан ханлыгы җимерелгәч, Урал тирәсендәге җирләрдә Себер Приказы оешкач (Чердын — шуның бер өязе; Көнгер өязе бераз соңрак, XVII гасырда төзелә) булган.

---

[1] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I. М. – Л., 1936.

[2] Кузеев Р.Г. Очерки исторической этнографии башкир. Уфа, 1957. С. 45.

[3] Ахметзянов М.И. Историческое предание об образовании пермских татар // Пермские татары. Казань, 1983. С. 161–163.

Шулай итеп, гәйнә атамасының килеп чыгышы соңрак килеп кушылган компонент белән бәйләнгән булырга да мөмкин. Тик ул Идел төрки компонентына зур йогынты ясый алмагандыр.

Пермь татарларының борынгы чыгышлары Идел буе төркиләре белән уртак икәнлеген исбатлый торган дәлилләрне фәннең тагын башка өлкәләренә караган фактлар да куәтли.

Пермь татарлары яши торган регионның топонимикасына игътибар итик.

М. Зәкиев әйтеп узылган хезмәтендә *пермь* сүзенең килеп чыгышын *би* + *ирем* (кешем) кушма сүзе белән бәйләп аңлата.

Красноуфим шәһәре янында *Болгары* дип атала торган сырт бар. Академик И.И. Лепехин 1771 елларда, бу сыртның урыны-урыны белән җимерелгән урыннары бар һәм алар ниндидер борынгы бина калдыкларын хәтерләткән кебек, дип язган[1]. Пермь районында Болгары авылы да бар.

О.Н. Бадер һәм В.А. Оборин Очер районындагы Черти авылы халкының яртысын әле дә болгар дип йөртәләр, дип язалар[2].

Пермь краеның җир-су атамалары, нигездә, пермь-фин-угыр характерында. Мәсәлән: Сылва, Шаква, Тулва һ.б. Аларның ва компоненты татарча *су* дигән сүз. Гәрчә елгаларның бик матур яңгырашлы татар вариантлары да бар. Мәсәлән, Пермь татарлары аларны *Тол суы, Сөл иле* дип атый. *Ирен* гидронимы *Иртеш* гидронимы белән бер үк тамырдан булырга мөмкин.

Пермь һәм Югары Муллы районнарында Югары Муллы, Түбән Муллы гидронимнары Пермь татарларының борынгы бабаларыннан калган атама. Риваятьләрдә Югары Муллы бассейнында Урак би Мәмәтколов, ә Түбән Муллы тирәсендә аның энесе Ирак би, Сөендек би Мәмәтколов яшәгәнлеге турында хәбәр ителә.

Авыл исемнәрендә дә төрки чыгышлы сүзләр бар. Мәсәлән: *Әри түз (Усть Арий), Башап түз, Тәләс түз, Тор түз* һ.б. *Истәк* авылы исемендә *остяк* сүзенең бер варианты чагылган.

Менә шул рәвешле топонимикада эз калдырырлык борынгы халык булган Пермь татарларының бабалары.

---

[1] Сборник материалов для ознакомления с Пермскою губерниею. Пермь, 1891. Вып. III. С. 39; Бадер О.Н., Оборин В.А. На заре истории Прикамья. Пермь, 1958. С. 177.

[2] Там же. С. 177.

Пермь татарларының формалашуында Идел буе төрки компонентының хәлиткеч роль уйнавын тел материаллары да раслый: Пермь татарлары сөйләше безнең әдәби телебезнең формалашуында нигез ташы булып торган урта диалектка карый. Алай гына да түгел, ул әлеге урта диалектның бераз читтәрәк урнашкан, борынгылыкны аеруча нык саклаган сөйләшләре (нократ, касыйм, подберезье, керәшен) рәтенә керә. Танылган телче Л. Мәхмүтова, бик хаклы рәвештә, бу сөйләшләрне аерым бер төркем итеп билгели; бу төркем сөйләш вәкилләренең бер чордарак, чагыштырмача зур булмаган тарихи аралыкта мәйдани, сәяси, икътисади яки мәдәни яктан Казан татарларыннан берникадәр аерымланган булганлыкларына басым ясый.

Бер-берсеннән шактый ерак урнашкан төбәкләрдә булуларына карамастан, бу сөйләшләр бер төркем борынгы күренешләре белән үзара берләшәләр. Мондый хәл, беренчедән, аларның кайчандыр бергә, бер берләшмә эчендә яшәгәнлекләрен турыдан-туры күрсәтә. Икенчедән, Казан татарлары сөйләм теленең төп билгеләре шул вакытта ук формалаша башлавы турында сөйли[1].

Шушы чорда ук татар теленең төп сүзлек составы да ныгый башлаган. Әлеге сөйләшләр бер төркем борынгы сүзләр белән зур уртаклык күрсәтәләр. Пермь татарлары сөйләшенә игътибар итик: *иләсә* (чув. алса) – бияләй, *озан* (чув. осан, себер, осан) – көртлек, *къәлүәт* – тукыма төре (Кыйссаи Йосыфта да шулай ук), *йемеш* – яшелчә; мордва-каратай сөйләшендә Коман мәҗмугасы (1303 елда төзелгән), И. Хәлфин сүзлегендә – шулай ук һ.б. Пермь татарлары сөйләшендә карачай-балкар теле белән уртак бертөркем диалекталь сүзләр табыла. Мәсәлән шундыйлардан *конҗорыйк* сүзен генә күрсәтик. Аның таралыш даирәсе бик чикле, ул тагын күрше златоуст сөйләшендә бар. Ул башкорт теленең дә төньяк-көнчыгыш Башкортстандагы сөйләшләрендә генә билгеләнгән, ә Кавказ телләренең барысында да таралган. Күрәсең, бу сүзне Пермь татарларының борынгы бабалары – болгарлар шул яклардан алып килгән булганнар. Аның кон элементы борынгы болгар теленнән удмурт теленә дә үтеп кергән: *ген сапог* – киез итек.

---

[1] Бурганова Н.Б. О формировании татарских говоров Заказанья // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1985. С. 18–19.

Шулай итеп, тарих, археология, этнография, топонимия, тел материаллары Пермь татарларының формалашуында Идел буе төркиләренең роле зур һәм хәлиткеч булуын ачык күрсәтәләр.

Урта Идел һәм Урал алды халыклары арасындагы этник бәйләнешләр соңга таба да көчәя, тирәнәя барган.

Күп кенә татарлар, чукындырудан качып, Урал якларына качалар. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Идел буеннан, татарлар белән бергә, чувашлар, марилар, удмуртлар да күчеп киләләр.

Күчеп килүчеләр татарлар яши торган мәйданның төрле төбәкләреннән булырга мөмкин. Мәсәлән, Пермь татарлары сөйләшенең тау ягы сөйләшләре белән аерым уртаклыгы бар. Ә сылва урынчылыгында татар теленең урта диалекты саналган мамадыш сөйләшендә генә табыла торган күренешләр бар, мәсәлән, *бардым дагын әйттем, күргән дәген сөйләгән* һ.б. Пермь районы тирәсендәге авылларда нократ сөйләше белән уртак үзенчәлекләр күзәтелә.

Революциядән соң Идел–Урал бәйләнешләре радио, мәктәп һәм матбугат аша бара.

Шулай итеп, борынгы чорларда ук булган тарихи бергәлек берничә гасырлар буе дәвам итеп килә. Күп кенә галимнәр Пермь татарларының Казан татарлары белән якын икәнлекләрен аерым ассызыклап күрсәтеп килгәннәр. И.Г. Георги Пермь татарларын «алар шул ук Казан татарлары»[1] дип яза.

### Фонетик үзенчәлекләр

Барда төбәге сөйләше татар диалектологиясендә билгеле булган пермь сөйләшенең бер өлешен тәшкил итә. Моның шулай икәнен авазлар системасы да ачык күрсәтеп тора.

Пермь сөйләше үзенең авазлар составы ягыннан әдәби телдән аерылмый. Сөйләшкә хас фонетик үзенчәлекләр барлык төбәкләрдә дә, асылда бер төсле һәм бу факт әлеге сөйләшнең аның бер нигездә, бер үк факторлар тәэсирендә, бер үк компонентлар катнашында уртак шартларда формалашкан булуын күрсәтә. Билгеле зур территориядә аерым утраучыкларны хәтерләтеп яши торган Пермь татарлары сөйләшендә кайбер аерымлыклар да күзәтелә, тик алар

[1] Описание всех обитающих в Российском государстве народов. СПб., 1799. С. 7–8, 97.

кайбер диалекталь үзенчәлекләрнең аерым урыннарда йә киңрәк, йә таррак күләмдә булуыннан барлыкка килә.

Төп фонетик үзенчәлекләре белән бу сөйләш татар теленең урта диалект сөйләшләренә якын тора. Бер төркем архаик күренешләр исә сөйләшнең мишәр һәм көнчыгыш диалектлар белән дә уртаклыгы бар икәнен күрсәтә.

**Сузыклар.** Сузык авазлардан бары тик *а* авазы гына үзенең әйтелеше белән әдәби телдән аерыла. Сөйләш өчен бу авазның ачык, саф, иренләшмәгән варианты характерлы.

Пермь сөйләшенең көнчыгышына таба шауба, сылва һәм карьево урынчылыкларында *а* авазы, дөбьяз сөйләшендәге кебек, артка этәрелгән булуы белән аерыла. Ирен урынчылыгында да абсолют сүз башында яки тирән тел арты авазларыннан соң шундый ук варианттагы *а* авазы әйтелә.

Иренләшмәгән, саф, ачык *а* авазы мишәр диалектының характерлы үзенчәлекләреннән берсе. Урта диалект сөйләшләренең нократ, касыйм, дөбъяз һәм керәшен сөйләшләрендә *а* авазының пермь сөйләшендәге кебек үк варианты әйтелә.

Сузыклар өлкәсенә карый торган башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләре һәм төрле позицион күчешләргә кайтып кала.

1. Киң әйтелешле иренләшкән сузыкларның тарайтылуы һәм, киресенчә, тар әйтелешле иренләшкән сузыкларның киңәйтелүе.

о ~ у: *сурау* – әд. сорау, *ғумер* – гомер, *ултан* – олтан, *уқшау* – охшау, *қумалақ* – колмак, *уланнар* – оланнар, *соң//сун* һ.б.; *отора*у – әд. утрау, *олақ* – улак, *олау//улау* – (эт) улау, *сосар* – сусар, *отау* – утау, *йоқа* – юка, *ойану* – уяну, *була//бола, була*, йуқ//йоқ – юк; *Йонос* – Юныс һ.б.

ө ~ ү: *үләшү* – әд. өләшү, *бүгү* – бөгү, *мүгез* – мөгез, *җүгерү* – йөгерү, *чүгиндер* – чөгендер, *сүлек* – сөлек, *бүкләү* – бөкләү, *җүгин//җөгин* – йөгән һ.б.; *җөтәл* – әд. ютәл, *чөмәлә* – чүмәлә, *төбә* – түбә, *көмәч* – күмәч, *төгөрик//түгәрик* – түгәрәк һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, кайбер сүзләрдә у, о ~ ү, ө күренеше факультатив. Тирбәлеш территориаль характерда да булырга мөмкин: *түгел/төгел* – әд. түгел, *соқа/суқа* – сука һ.б.

Тюркология фәнендә билгеле булганча, башка төрки телләрдәге *о,ө* авазлары урынына татар телендә *у, ү* һәм, киресенчә, *у, ү* авазлары урынына *о, ө* авазлары әйтелә. Татар телендә бу күчешне XIII гасырдан соң башланган дип саныйлар. Галимнәр *о, ө ~ у, ү*

күчешен ике яклы булган дигән караштa торалар. Мәсәлән, тат. *кул* – борынгы төрки *қол* (рус. рука), тат. *кол* – борынгы төрки кул (рус. раб), тат. *күл* – бор. төрк. *көл* (рус. озеро), тат. *көл* – бор. төрк. *күл* (рус. зола) һ.б.

Әмма күрсәтелгән ике яклы күчеш татарлар яшәгән территориянең барлык төбәкләрендә дә бертигез дәрәҗәдә бармаган. Мәсәлән, казан арты төркеме сөйләшләрендә *о* ↔ *у* күчеше *бутка* – ботка, *тукмач* – токмач янәшәлекләрендә генә күзәтелә. Перифериядә таралган сөйләшләрдә әлеге күчешләргә мисаллар күбрәк очрый. Югарыда китерелгән мисаллар Барда төбәгендә дә әлеге ике яклы күчешнең тәмамланып җитмәгәнлеге, кайбер сүзләрнең борынгыча әйтелешләрен саклап килүе турында сөйли. У, ү ↔ ө, о икеяклы күчешнең Пермь татарлары сөйләшендә тулысынча формалашып җитмәгәнлеген күрсәтәләр. Бу күренеш алынма сүзләрне үзләштерүдә дә чагыла: *мөк* – әд. мүк, *молла* – мулла, *Йок* – Юг (авыл исеме).

**Ә ~ е ~ и тәңгәллеге**. Киң әйтелешле *ә* авазы урынына тар әйтелешле *и* авазы әйтү сүз ахырында ябык иҗектә күзәтелә: *печин* – әд. печән, *имин* – имән, *итмик//итмәк* – икмәк, *җирин* – җирән, *белчин* – билчән, *чеприк* – чүпрәк, *мөрлигин* – бөрлегән, *чекмин// чепкин* – чикмән, *кәбин//кибен//кибин* – кибән, *мелиш//милиш* – миләш, *тирмин//тегермин* – тегермән һ.б. Тагын: *тирәзә* – тәрәзә, *чичкә* – чәчәк.

Беренче иҗегендә таррак әйтелешле аваз булган сүзләрдә *ә* авазының тараюы *ә* > *е* рәвешендә була: *чирем* – әд. чирәм, *күгерчин* – күгәрчен, *җирену* – җирәнү һ.б.

Урта күтәрелешле *е* авазы урынына тар әйтелешле, югары күтәрелешле *и* авазы әйтү төрле позициядә күзәтелә: *чигән* – әд. чегән, *чирек* – черек, *чиркәй* – черки; *күгерчин* – күгәрчен, *чүгиндер* – чөгендер, *мөрлигин* – бөрлегән; *әли* – әле, *бәлиш* – бәлеш, *шүрәли* – шүрәле, *беле//биле* – белән; *әрбир* – әйбер, *делбигә* – дилбегә, *кебит* – кибет; *ақрин//әкрин* – әкрен һ.б.

Мондый характердагы сингармонизм күренешләре урта диалектның касыйм сөйләшендә бар. Бу яктан сөйләш тагын караим теленең галиц диалекты белән дә уртаклык күрсәтә.

Тар әйтелешле *и* авазы урынына киң әйтелешле *ә* авазы әйтү сүз башындагы позициядә һәм, бигрәк тә, *к, ч, ш* авазларыннан соң күзәтелә: *кәм* – әд. ким, *кәрәк* – кирәк, *кәртә* – киртә, *кәгә-*

*wен, кәштә, кәләп* һ.б.; *шәкәр* – шикәр, *чәтләwек* – чикләвек, *әпәй* или һ.б. Сүз азагында: *җиңгә* – җиңги, *йезнә* – җизни. Мондый күренешләр Урал тирәсендә, башкорт теле йогынтысы астында формалашкан татар сөйләшләренә хас. *Кәбәк, кәгәwен* тибындагы вариантлар башкорт телендә әдәби норма булып тора.

Беренче иҗектә тар әйтелешле авазларны киңәйтү *э(е) > ә* күчешендә дә күзәтелә: *әшкәртү* – эшкәртү, *әнә* – энә, *әндәшү* – эндәшү; шулай ук: *гәл* – гел, *беләнми* – беленми һ.б.

*Ә ~ э(е) ~ и* алынма сүзләрдә, топонимик атамаларның әйтелешендә дә чагыла: *мешик//мешәк* – рус. мешок, *Мәнҗәлә* – Минзәлә, *әлбиттә* – әлбәттә, *белит* – билет, *йәкшәмбә* – якшәмбе, *черкәү* – чиркәү, *дәстә* – дистә, *шәрбәт* – ширбәт һ.б.

Тюркологиядә билгеле булганча, *ә-и* тәңгәллеге борынгы төрки телләрдә булып үткән тарихи күчешләрнең берсе дип аңлатыла.

Татар теленең үзенең җирле сөйләшләреннән тупланган материаллар гына да бу күчешнең акрынлап үзгәрү характерында (*ә – э – и*) барганлыгын раслыйлар. Беренчедән, нократ сөйләшендәге *ә, и* авазларының тар һәм киң вариантлары, көнчыгыш диалектлардагы «киң әйтелешле *е* гә якын яки *е-и* арасында торган авазлар», башка сөйләшләрдәге *ә > е, и > е, е > ә, е > и* һ.б. шундый күренешләр *ә ~ и* процессының төрле этапларын чагылдыралар. Икенчедән, *ә – э – и* тәңгәллеге кайбер сүзләрдә факультатив характерда булып, бер үк сүзнең ике яки, хәтта, өч вариантта әйтелүе, һичшиксез, әлеге авазлар күчешенең төрле дәрәҗәдә булуы белән бәйләнгән.

Барда төбәгендә *а ~ ы* тәңгәллеге дә системалы рәвештә түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *йаңы* – әд. яңа, *тагын* – таган, *аудыру* – аудару, *тайғылақ* – тайгалак; *чаңға* – әд. чаңгы, *қабақ* – кабык, *қапқан* – капкын, *қаңғырау* – кыңгырау һ.б.

Бу тәңгәллекнең мисаллары татар теленең башка сөйләшләрендә дә теркәлгән: чаңға, йаңы, қапқан вариантлары башка төрки телләрдә әдәби норма булып торалар, борынгы күренеш итеп исәпләнәләр.

Барда төбәге сөйләшенә, гомумән пермь сөйләшенә хас булган *у – ы – и* тәңгәллекләре бер төркем сүзләрдә күзәтелә: *ишану* – әд. ышану, *тастимал* – тастымал, *қашиға* – кашага, *утл'иқ* – утлык, *башл'иқ* – башлык (соңгы ике очрак нечкә әйтелешле *л'* сонар тартыгының йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килә булса кирәк).

*У > ы > и* күчешләре түбәндәге сүзләрдә сөйләшнең барлык авылларында да табыла: *минчақ//мынчақ* әд. – муенчак, *минча//мича//моча* – мунча, *мичала//мынчала* – мунчала; *сәндиғач* – сандугач, *қарлиғач* – карлыгач; *бийыл//быйыл* (< бу ел) – быел, бийау – буяу, бийақ (< бу як) – бу як һ.б.

*У, ы > и*, мисаллардан күренгәнчә, аеруча тел уртасы *й* сонанты алдындагы позициядә күзәтелә. Мондый күренеш Башкортстандагы татар һәм башкорт сөйләшләренә дә хас.

Бер төркем сүзләрдә алгы рәт сузыклары даими рәвештә арткы рәт сузыклары белән алмаштырып әйтеләләр: *айран* – әйрән, *сурат* – сурәт, *ачыту* – әчетү, *муклак* – мүкләк, *курка* – күркә, *акрин* – әкрен, *йанаша* – янәшә һ.б.

Билгеле булганча мишәр диалектында бу күренеш тагын да активрак.

Икенче бер төркем сүзләрдә исә, киресенчә, арткы рәт сузыклары урынына алгы рәт сузыклары әйтелә. Бу үзенчәлек сөйләштә, татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштырганда, киңрәк күләмдә күзәтелә. Мисаллар: *кечү* – әд. кычыту, *сәленү* – салыну, *әйсә* – алайса, *җән* – җан, *әтнә* – атна, *йәбешү* – ябышу, *зәмәнә* – замана, *чегерткин* – кычыткан, *җөн* – йон, *мөрҗә* – морҗа, *чептә* – чыпта, *ү бернә* – өй борынча һ.б.ш.

«Нечкәртеп» сөйләү кеше исемнәрендә дә актив: *Сәрә* – Сара, *Бәйән* – Баян, *Тәйпә* – Таифә, *Йәркә* – Ярулла, *Зәйерә* – Заһира.

Алынма сүзләр дә күбрәк алгы рәт сузыклары белән әйтелергә мөмкин: *әрзән* – арзан, *эшкәп* – шкаф, *сәмәлүт* – самолет һ.б.

Бу күренешләр теге яки бу күләмдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә очрыйлар. Арткы рәт сузыкларны алгы рәт сузыклар белән алыштырып сөйләүгә омтылыш минзәлә сөйләшендә чагыштырмача көчлерәк күзәтелә.

Сузыклар тәңгәллегенә карый торган характерлы үзенчәлекләрнең берсе – рус теленнән кергән сүзләрдәге басымлы иҗектән алда торган *о* авазының *у* авазы белән алмашынуы. Мисаллар: *рускут* (татар сөйләшләрендә – *расхут*) – расход, *прубурный* – проворный, *Рустыф* – Ростов, *пуказанҗә* – показание, *уграт* – огород, *дуйарка* – доярка, *утбит* – ответ, *дукемин* – документ һ.б.

Урта диалект вәкилләренең сөйләм телендә бу сүзләрне, гадәттә, *Растуф, расхут, дайарка, дакумент* һ.б. вариантта ишетәбез.

Барда төбәге татарлары исә *о*-лаштырып сөйләүче руслар арасында яшиләр һәм югарыда китерелгән үзенчәлек күршедәге рус сөйләшләре йогынтысы булса кирәк.

Шулай итеп, сөйләшкә кабул ителгән алынма сүзләр үзләренең фонетик яңгырашларында чыганак рус сөйләшләренең үзенчәлекләрен, өлешчә булса да, саклап киләләр.

**Сингармонизм күренешләре**. Иренләшү гармониясе. *О, ө* иренләшмә сузыклары, гомумән татар теленә хас булганча, икенче-өченче иҗекләрдә дә әйтеләләр: *борон* – борын, *соло* – солы, *тормош* – тормыш, *төлкө* – төлке, *көлөшеп* – көлешеп, *көтөп* – көтеп, *қоно* – мәчесыман, тик бераз зуррак ерткыч хайван, *сосон* – сусын, сусау, *өмөҗө* – кура җиләге, *дөңгөҗ* – төкле тура һ.б.

Димәк, сөйләштә *ө, о* авазларының әйтелеше татар әдәби теленең орфоэпик нормаларына туры килә.

Аңкаулашу гармониясе төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, шактый эзлеклелек саклый торган үзенчәлекләрнең берсе. Тасвирлана торган сөйләштә дә ул шулай. Бары тик берничә сүздә генә аңкаулашу гармониясенең бозылу очраклары күзәтелә: *қәл'пақ* (сир.) – калфак, *қорбән* – корбан, *машинә, суткә, тәлпан* һ.б.

*Алу* ярдәмче фигыленең юклык формасы, алгы рәт сузыклардан торган сүзләрдән соң килгәндә, системалы рәвештә нечкәртелә: *җитәлми* – җитә алмый, *beләлмийем* – белә алмыйм һ.б.

Бу Урал төбәгендә, Башкортстан территориясендә таралган татар сөйләшләрендә дә шулай.

**Аваз өстәү.** Төрки телләрдә билгеле бер төркем тартык авазлар сүз башындагы позициядә характерлы түгел. Шуңа күрә *р, ч, ш, з, w* авазларына башлана торган сүзләр алдыннан протетик *ы, е* авазлары әйтелә (протеза). Мәсәлән, Барда төбәге сөйләшендә: *эрәқәт* – рәхәт, *ырзық* – ризык, *эчәй* – чәй, *ычық су* – чык, *эшкәп* – шкаф, *озор* – зур, *эҗҗән* – җан, *ыwақ* – вак һ.б.

Шул ук вакытта кайбер сүзләрдә сузык авазлар әйтелмиләр: *рақы* – аракы, *зақ* – озак, *ләктерү* – элэктерү, *лаѓу* – олагу һ.б.ш.

Янәшә тартыклар белән башлана торган алынма сүзләрдә протеза ролен метатеза үтәргә мөмкин: *туритнә* – рус. трудодень, *пуржинә* – пружина, *кулып* – клуб, *Урмынҗә* – Румыния, *порт* – пруд, *полт'инә* – плотина һ.б.

Сүз башында аваз өстәү үзенчәлеге бигрәк тә өлкән буын кешеләренең сөйләм теленә хас.

Сүз эчендә аваз өстәү (эпентеза) күренеше бер төркем сүзләрдә даими характерда: *тәмесез* – тәмсез, *күреше* – күрше, *шоморот* – шомырт, *тамычы* – тамчы, *җөрөмә* – йөрмә, *керетү* – кертү, *әребир//әрбир* – әйбер; шулай ук гарәп-фарсы алынмаларында: *җомаға* – җомга, *зәғәперән* – зәгъферән, *Мәғәпүр* – Мәгъфүр, *нигәмәт* – нигъмәт һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, протетик *ы, е* сузыклары билгеле бер позициядә – сонорлар янәшәсендә, ә гарәп алынмаларында *ғ* тирән тел арты авазы тартыгы янында барлыкка киләләр.

Сүз азагында аваз өстәү берничә сүздә генә күзәтелде.

Аерылмышы тартык авазга башланганда, *үз* алмашлыгы *үзе* дип әйтелә: *үзе сүзле* – үзсүзле, *үзе кеше* – үз кеше һ.б.

*кт, нт* янәшә тартыкларга беткән сүзләрдә: *акты* – акт, *тыракты* – тракт, *кыранты* (< крант) – кран һ.б.ш.

**Дифтонглар.** Татар телендәге дифтонг дип йөртелә торган аваз кушылмалары, башка төрки телләрдәге кебек үк, сузык белән янәшә килгән тартыкның комбинатор, ягъни позицион үзгәрүе нәтиҗәсендә, телнең фонетик төзелешенә хас эчке закончалыклар белән бәйле рәвештә барлыкка килгәннәр. Билгеле булганча, дифтонгларның эволюциясе татар теленең үз эчендә дә төрле диалектларда төрлечәрәк характерда булган. Бу яктан өйрәнә торган сөйләш берникадәр үзенчәлекле урын тота.

*-ай/-әй* дифтонгы *үги, җизни* сүзләрендә генә әйтелә: *үгәй, йезнәй*. Хикәя фигыльләрдә *-ай/-әй* дифтонгы бары бер очракта гына күзәтелде: *җөри әлмәйем* – йөри алмыйм. *-ай/-әй* дифтонгы борынгы җырларда сакланып килә:

*Ағызбаларға керәйек,*
*Хуҗаларға сәләм бирәйек.*

Билгеле булганча, җырлар, бер яктан, халык сөйләм теленең традицион үзенчәлекләрен һәм формаларын саклый торган фольклор жанры булсалар, икенче яктан, аларның башка халыклардан үзгәртелмичә кабул ителгән булуы да мөмкин.

Бу очракта исә борынгы *-ай/-әй* дифтонгы сакланып калырга мөмкин. Туганлык терминнарында гына түгел, хәзерге заман I зат хикәя фигыльнең берлек формасында да бу дифтонг югалып бетмәгән: *сүлийем* (<сөйләйем) – сөйлим, *бармыйым* (< бармайым) – бармыйм һ.б.

Рәвеш алмашлыкларының һәм *-лай*/*-ләй* кушымчалы рәвешләрнең кушымчасындагы *а, ә* авазлары *й* тартыгы тәэсирендә тар әйтелешле *ы, е* авазлары белән алмашыналар: *алый* – әд. алай, *болый* – болай, *тегелий* – тегеләй, *чүрәлий* – тирә-яклап, *бушлый* – бушлай, *иңечелий* – икенчеләй һ.б.

*-ай* > *-ый, -әй* > *-ий* урта диалектның норлат сөйләшендә, китерелгән алмашлыклардан, рәвешләрдән тыш, кайбер башка сүзләрдә дә күзәтелә: *малый* – малай, *биағый* – биагай, *қалый* – калай.

Ачык иҗектәге яки абсолют сүз азагындагы *у, ү* авазлары урынына факультатив рәвештә *-ый*/*-ий* дифтонгы әйтелә: *җыw* – ю, *шыwма* – җума, *қыwып* – куып, *ыwрам* – урам, *сыw* – су, *сеwлек* (сүлек) – сөлек, *еwрелеw* (диал. үрелү) – әйләнү, *күзәтеw* – күзәтү.

Бу үзенчәлек ягыннан Барда төбәге сөйләше урта диалектның касыйм сөйләшенә, урал төбәгенең башка сөйләшләренә, көнчыгыш диалектларга якынлык күрсәтә.

Шундый ук позициядә *-ыw, -еw* дифтонгларын куллану башкорт телендә әдәби норма булып урнашып калган.

*-ой* дифтонгы, тараеп, *ү* авазына монофтонглаша: *үрә* – өйрә, *сүләү* – сөйләү; сузыклар арасындагы позициядә *w* соноры барлыкка килә: *бүwер* – бөер, *бүwәт* – бөят, *суwәм* – сөям һ.б.

Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә, *-ой* дифтонгы урынына *ү* авазының төрле вариантлары әйтелергә мөмкин: *сөли* – сөйли, *өрәнә* – өйрәнә, *сөрәгән* (ү > ө), *еw* – өй (дом), *кеw*//*кәw* – көй, *өwмә* (ү > еw > өw) – өймә һ.б.

Бу тәңгәллекләр чагыштырмача сирәк очрыйлар.

*Дөя, көймә* (лодка) сүзләрендә әдәби телдәге *өй* дифтонгы урынына даими рәвештә *ә* сузыгы туры килә: *тәwә, кәмә*.

Әдәби тел белән теге яки бу дәрәҗәдә таныш булган кешеләр (интеллигенция, яшь буын, Казан татарлары белән элек-электән үк тыгыз элемтәдә яшәп килгән өлкән буын һ.б.) сөйләмендә кайбер сүзләрдә *-өй* дифтонгы яки аның *-ий* варианты куллану очраклары күзәтелә.

Ачык иҗек оештыра торган югары күтәрелешле тар әйтелешле *-и* сузыгы факультатив рәвештә *-ей* дифтонгы белән алмашына. Мисаллар: *әней* – әни, *Хаҗей* – Хаҗи, *кей* – ки; *бәрәнней* – бәрәнли, *күрей* – көйри, *китмей* – китми, *кейем* – кием, *кейсәсең* – кисәсең һ.б.

Барда төбәге сөйләше, гомумән, пермь сөйләше кебек үк, әлеге үзенчәлеге белән Себер ареалындагы татар сөйләшләренә якыная.

Шулай ук урта диалектның касыйм сөйләшендәге *иј,* нократ сөйләшендәге озын *и* вариантлары белән дә уртаклык күрсәтә.

Ачык иҗектә килгән *и* авазы урынына *-ей* дифтонгы куллану башкорт телендә әдәби норма булып кабул ителгән.

Пермь татарлары сөйләшенең характерлы үзенчәлекләреннән берсе – *-ау*/*-әү* дифтонгларындагы киң әйтелешле *-а*/*-ә* авазларының редукцияләнүе. Редукция сөйләү темпы барышында төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Нәтиҗәдә, *-ау* /*-әү* дифтонглары төрлечә әйтелә: *-оу*/*-әү, -* $^{a}$*у, -*$^{ө}$*у, -у*/*-ү* һ.б. Мәсәлән: *бөзау*//*боз*$^{o}$*у*//*бозу*//*бозау; кырау*//*кыроw*//*кыру, чиаршау*//*шаршоу*//*шаршу, ашоw-эчү, кийәү*//*кийөү*//*кийү, берәү*//*берөү*//*берү, икәү*//*икөү*//*икү, қаңгыр*$^{o}$*w*//*каңгыру* һ.б.

Өйрәнүләребез бу күренешнең таралу территориясе тигез булмавын күрсәтте. Ул, пермь сөйләшенең, барда урынчылыгыннан тыш, тагын муллы урынчылыгында аеруча актив.

*-ау*/*-әү* дифтонгларын бу рәвешле үзгәртеп сөйләү урта диалектның тагын нократ сөйләшенә хас, аерым очраклар норлат сөйләшендә дә күзәтелә.

Билгеле булганча, хәзерге татар телендәге *-ау*/*-әү* дифтонгы урынында борынгы төрки телдә (мәсәлән, Орхон, Енисей бассейннарында табылган язмаларда) *-агу*/*-әгү* комплексы кулланылган. Телнең үсеш-үзгәреш процессында бу комплекс төрле төрки телләрдә төрлечә үзгәреш, (мәсәлән: татар, башкорт телләрендә – *-ау*/*-әү*, ә хакас, уйгыр һ.б. кайбер төрки телләрдә *-о-, -ү-* авазларына кайтып калган) кичергән.

**Тартык авазлар.** Тартыклар системасында авазлар әйтелешенә караган шактый үзенчәлекләр бар.

Сүз башында сузык алдындагы яки ике сузык, йә сонор белән сузык арасындагы позициядә тел очы шартлаулы саңгырау *т* тартыгының шартлау элементы бик нык йомшара һәм, артикуляцион-акустик яктан, әдәби телдәге *ч* авазына якыная. Бу авазның ясалу урыны тел уртасы белән өске тешләрнең альвеолалары арасында. Яңгырашы белән ул рус телендәге палатальләшкән *т* авазыннан нечкәрәк. Ул биредәге мисалларда шартлы рәвештә *т'* дип билгеләнде. Тупланган материалларга караганда, ул билгеле бер төркем сүзләрдә генә күзәтелә: *әт'и*//*ат'и* – эти*, карт'әт'и* – бабай, *т'әпи* – тәпи, *қыт'ық* – кытык, *т'ит'и* – чәчәк, уенчык, *бет'еки* (чаг.: бәләкәй) – кечкенә, *бот'ока* – болганчык, куе су яки сыек балчык, *т'өней*//*т'үни* – йоннан басып эшләнгән носки, *т'әгаҗ* – кәгазь һ.б.

Рус теленнән кергән сүзләрдә дә югарыда күрсәтелгән позициядә *т'* авазы әйтелә: *пат'ир* – квартира, *инт'ирнат* – интернат, *т'үркә* – кыргыч, *пат'и* – боты, *Бит'ә* – Витя һ.б.

Бер төркем сүзләрдә *л* фонемасының Европа телләренә хас булган нечкә варианты кулланыла: *л'апайу* – яньчелү, *л'апаķ* – кандала, *л'ыңķу* – күп, мәгънәсез такылдау, *л'ыķķыл* – алдагы фигыльдән ясалган сыйфат, *л'амбык* – базык, *карамал'* (< кара+мал' + җиләк) – кара җиләк, *ķәл'пайу* – кабарып чыгып тору (мәсәлән, обой тур.), *ышкол'а* – мәктәп һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә апикаль *л'* тартыгының кулланылышы чикле. Ул, асылда, алынма яки диалекталь сүзләрдә очрый.

Европеик характердагы *л'* Урал алды территориясендә таралган рус сөйләшләрендә дә билгеләнгән. Мордва, мари, манси телләрендәге *л* авазының үзенчәлегенә таянып, Л.П. Смолякова әлеге сөйләшләрдәге *л'* авазын, җирле халыкның (мансиларның) ассимиляцияләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән субстрат күренеш, дип саный. Пермь сөйләшендә дә әлеге *л'* авазы җирле пермь телләре белән бәйле субстрат күренеш булса кирәк.

Тартык авазларның әйтелеш үзенчәлекләре белән бәйле тагын бер күренешкә тукталып үтәргә кирәк: билгеле бер төркем сүзләрдә тирән тел арты *ķ* авазы урынына, даими рәвештә, тел арты *к* авазы әйтелә: *туракан* – таракан, *куйык* (сычь), *купка*/*кумка* – чүмеч, *курка* – күркә, *калпак* – калфак һ.б.

Шунысы характерлы, әлеге күренеш иркәләү-кечерәйтүне белдерә торган *-кай* кушымчасында да күзәтелә: *анакай* – анақай/ әникәй, *танакай* – танакай, ачыкай һ.б.

Калган авазлар артикуляцион һәм акустик яктан әдәби телдәгечә. Тартыклар өлкәсендәге башка диалекталь үзенчәлекләр, нигездә, аваз тәңгәллекләренә, ассимиляция, диссимиляция күренешләренә һәм башка шундый комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

**Аваз тәңгәллекләре.** Артикуляциясе белән бер-берсенә якын булган тартык авазларның тәңгәллекләренә тукталып үтик.

Әдәби телдәге тел арты *х* тартык авазы урынына тирән тел арты *ķ* авазы кулланыла: *ķан* – әд. хан, *ķатын* – хатын, *йаķшы* – яхшы, *аķыķ* – ахак, *ķыр-ķыр* – хыр-хыр (йоклау), *пәрķәт* – бәрхет, *ķәтфә* – хәтфә һ.б.

Алынма сүзләрдәге *х* авазы, шулай ук, *ķ* авазы белән тәңгәлләшә: *ķәтер* – хәтер, *ķәл* – хәл, *мәķрүм* – мәхрүм, *Ķәмит* – Хәмит,

*Мөқәмәт* – Мөхәммәт, *Қөснийә* – Хөсния, *сиқырләү* – сихерләү, *қәзерәт* – хәзрәт, *нақақ* – нахак, *қәреп* – хәреф, *сәқнә* – сәхнә, *қөқәмәт* – хөкмәт, *чипүқа* – чепуха, *қүқна* – кухня, *қутыр* – хутор һ.б. Экспедиция материаллары Барда төбәгендә әлеге күренешнең шактый сирәк табылуын күрсәтте. Ул татар теленең кама-тамагы, тархан, касыйм, подберезье сөйләшләрендә күзәтелә. Мишәрләрдә, киресенчә, күчеш, ягъни *к* > *х* күренеше дә күзәтелә. Барда төбәгендә дә вакыт, кадәр, куәт, канәфер сүзләре еш кына *вахыт, хәдәр, хүwәтле, хәләнфүр* дип әйтеләләр, *хайын*//*қайын, ахринлап*// *ақрынлап, Мусатиха*//*Мусатиқа* кебек очраклар бар.

Барда төбәгендә дә татар теленең үз сүзләрендәге ирен-ирен шартлаулы *п* тартык авазы сакланып килә: *тупрақ* – туфрак, *җибәк* – ефәк, *йапрақ* – яфрак, *қалпақ* – калфак, *керпек* – керфек һ.б. Алынма сүзләрдәге татар теле өчен характерлы булмаган ирен-теш өрелмәле *ф* авазы да сөйләштә *п* яки (п >) б йомык тартыклары белән алмашына: *пәлән*//*бәлән* – фәлән, *Батимә* – Фатыйма (*ф* > *п* > *б*), *пайда* – файда, *шипер* – шифр, *пураж* – фураж, *шупир* – шофер, *Нәпиға* – Нәфига, *Шәпиқ* – Шәфикъ һ.б. Билгеле, алынмалардагы *ф* авазы үзе дә язма һәм, өлешчә, әдәби сөйләм теле аша сөйләшкә кереп бара: *камфит* – конфет, *фирме* – ферма, кофта дип әйтү очракларын шуның белән аңлатырга мөмкин.

Кайвакыт, киресенчә, күчеш, ягъни алынмалардагы *п* авазының спирантлашу күренешләре күзәтелә: *фамидор, сифарат, айрофлан, фадийан, фырактиханнар* (практикантлар) һ.б. Бу үзенчәлек *ф* авазының сөйләшкә тулысынча кереп бетмәгәнлегеннән килә.

*Ф* һәм *п* авазлары арасындагы мондый тәңгәллекләр татар теле җирле сөйләшләренең гомуми характердагы үзенчәлекләреннән берсен тәшкил итә.

х > қ, ф > п күчешләре пермь сөйләшенең барлык төбәкләрендә дә күзәтелә. Ул тагын Зәй һәм Кама тирәсе, керәшеннәр, нократ һ.б. сөйләшләрдә дә бар.

Барда төбәге сөйләше, шул исәптән гомумән пермь сөйләше, *з* тартыгының кулланылышы белән дә мөстәкыйльлек күрсәтә. Мәсәлән, сөйләштә *з* авазы үзе кулланыла: *зат, заман, Зарип, Узакаев* (фамилия), *озур* – зур, *зәрәтә* – сәрдә һ.б. Бу үзенчәлек белән Барда төбәге сөйләше кайбер күрше (мәсәлән: минзәлә) сөйләшләрдән һәм шулай ук башкорт сөйләшләреннән дә аерылып тора.

Шундый ук хәл ике сузык арасындагы *д* тартык авазы кулланылышында да күзәтелә. Мәсәлән, мамадыш, бөре һ.б. кайбер сөйләшләрдәге *изән* / минз. идән, *казак* / минз. кадак, *Изел, Фәризә* кебек күренешләр Барда төбәгендә бары Новая Казанка авылы сөйләшендә генә табыла. Шулай итеп, Барда төбәге сөйләше *җ*-ләштерү, *с, ч, з, д* авазларының кулланылышы, *һ* авазының кулланылмавы белән башкорт теленнән кискен аерыла.

Ирен-ирен *б* һәм *м* тартыкларының тәңгәлләшү очраклары бар. Алар түбәндәге күренешләрдә чагылалар:

а) бер төркем сүзләрдә сүз башындагы ирен-ирен, йомыкшартлаулы *б* авазы, регрессив ассимиляция нәтиҗәсендә булса кирәк, *м* авазына күчә: *мерлиген* – бөрлегән, *митун//битун* – бидон һ.б.;

б) киресенчә, *буйын, буйынса* (әд. хәситә) сүзләрендә һәм кайбер очракларда мин һәм бу алмашлыкларының кыек килеш формаларында (мәс. *бийән* – әд. миннән, *бийең* – әд. минең, *бунда* – әд. монда, *буныңча* – моныңча һ.б.) сүз башындагы *б* авазының, ягъни татар әдәби теленнән аермалы буларак, борынгырак форманың яшәп килүен күрәбез.

*М* авазының *б* авазы урынында әлегә билгеле булмаган сәбәпләр нәтиҗәсендә дә кулланылу очраклары бар: *чымылдық, майтақ* – байтак, *мөр//мөре* – бөре, *мөрләнү* – бөреләнү, *чымық* (сир.) – чыбык, *кәкре-мөкре, печтек//бечтек//мечтек* – үлән исеме: пестик һ.б.

*М* һәм *б* авазларының бер-берсенә тәңгәл килү очраклары татар теленең башка сөйләшләрендә дә бар. Мәсәлән, Себер, Тау ягы ареалларында, Пенза өлкәсендә һәм Мордовиядә, Башкортстанда һ.б. төбәкләрдә.

Барда төбәгендә, берничә генә сүздә булса да, тел очы *с* тартыгының *ч* авазына күчүе күзәтелә: *чаташу* – саташу, *челкәwеч* (селкү фигыленнән) – җилпуч, *чидерү* < *сидерү* (кычыткан чагу), *буйынча* (< *буйынса* – әд. хәситә). Соңгы икесендә *с* > *ч* факультатив характерда.

Күргәнебезчә, Барда төбәге сөйләше, башкорт теленнән аермалы буларак, *ч* авазын, әдәби тел белән чагыштырганда, активрак та куллану белән аерылып тора.

Киресенчә күренеш, *ч* авазының *с* булып әйтелүе Барда төбәгенә, гомумән пермь сөйләшенә хас түгел.

Барда төбәгендә үткән заман хәл фигыль кушымчасындагы *ч* тартыгы факультатив рәвештә *с* авазына күчә. Мәсәлән: – *Әни кебег*

*үк булам қартайғас. – Эчкәс рәхмәт әйтербез. – Бүлнискә барғас қына җән кергән* һ.б.

*-гас-гәс* формасы белән өйрәнелә торган барда төбәге сөйләше урта диалектның касыйм, норлат сөйләшләренә якынлык күрсәтә.

Барда сөйләшендә, пермь сөйләшендәге кебек үк, кайбер сүзләрдә *л~н* тәңгәллеге дә табыла: *тешни* – әд. тешли, *исне* – исле, *сөрнегү* – сөрлегү, *қатнау* – чабата катлау, *чәнтер* (мәләкәс, чистай сөйләшләрендә *чәлтер*) – сыйрак, *Индус* – Илдус, *алчеприк//анчеприк* (сирәк) – алъяпкыч, *тастимал//тастыман* (сирәк) һ.б.

Ирен-ирен *м* тартыгы һәм тел очы *н* тартыкларының бер-берсе белән алышыну очраклары бар. Мондый күренеш түбәндәге сүзләрдә күзәтелде:

*н > м: йалқым* – ялкын, *чормау* – әд. чорнау, *берәм-сәрәм* – берән-сәрән, *нәстә//мәстә, чабымлық* – чабынлык һ.б.

*м > н:* туғын – тугым, *иләнтәк//иләмтек* – көрпә, *буwам//буwан* – буа; *ағын* – агым (чаг.: себер диал. *ағын*, каз., к.-калп., башк., алт., караим – *ағын*); *йаwын* (< явым) – яңгыр һ.б.

Артикуляциясе белән бер-берсенә якын булган авазларның тәңгәлләшүе тагын яңгыраулаштыру-саңгыраулаштыру күренешләрендә чагыла.

Сүз башындагы ирен-ирен саңгырау *п* авазы түбәндәге сүзләрдә системалы рәвештә үзенең яңгырау пары белән алмашына: *эч бошу* (эч пошу), *бешерү* (пешерү), *бот* (авырлык үлчәве – пот), *бәке* – пәке, *быр тузу* (пыртузу), *бота* – пута, *керпеч* – кирпеч//*кербич* – кирпеч, *бочмақ* – почмак, бештек (< пештек – булган, хәстәрле), қалдық-босток (калдык – посток), қурбы (курпы) һ.б.

Өлкән буын сөйләм телендә *п > б* күчеше алынма сүзләрдә дә системалы рәвештә чагылыш тапкан: *ысбылош* – сплошь, *тубил* – тополь, *будрат* – подряд, *бикәрни* – пекарня, *ботулук* – потолок, *башборт* – паспорт, *беринник* – прянник һ.б.

Кайбер сүзләрдәге *ф > б* күренеше шулай ук *п* авазы аша бара, ягъни *ф > п > б: бирмә* – ферма, *Лотбула* – Лотфулла, *Бәсиқа* – Фәсиха, *Кәшибә* – Кәшифә, *Бәрқеттин* – Фәрхеттин, *Бати* – Фатыйма, *бәлән* – фәлән, *биғамбәр* – пәйгамбәр һ.б.

Шулай булса да, *п* авазының яңгыраулашуы инде сирәк күренешләр булып тора.

Сөйләштә киресенчә күренеш, ягъни ирен-ирен *б* яңгырау авазының саңгыраулашу очраклары да бар. Ул барда татарлары сөйлә-

шендә түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *пот* – бот (әгъзә), *порос* – борос, *палан* – балан, *пелен* – белен, *этпорон* – сөйләштә гомуми форма этборон, *пичә* – бичә (сирәк), *пичура* – бичура (сирәк), *пежмин* – бизмән, *пикә* (*в* > *б* > *п*) – вика , *патинка* – ботинка, *пати* – боты.

Әдәби телдәге *б* авазы урынына *п* авазы куллану очраклары подберезье керәшеннәре, кузнецк сөйләшендәге бар. Пермь татарлары сөйләшендә саңгыраулаштыру күренешенең яшәп килүендә татар теленең башка сөйләшләреннән аеруча саңгыраулаштыру үзенчәлеге белән аерылып тора торган Себер диалектларының да роле булмый калмагандыр.

Тел очы саңгырау *т* тартыгының яңгыраулашуы сүз яки иҗек башындагы позициядә түбәндәге сүзләрдә даими рәвештә күзәтелә: *дары* – әд. тары, *дуғым* – тугым, *дуғару* – тугару, *дегәнәк* – тигәнәк, *қаралды* – каралты; *тарма*//*дарма* – киндер орлыгы, *төгөрик*// *дөгөрик* – түгәрәк сүзләрендә факультатив характерда.

*Тип, тиде* (*ди* фигыленнән), *җите, аташу, тулқын, тәwә* (дөя) сүзләре әдәби телдәге шул ук сүзләрдән *д* > *т* күренеше, ягъни саңгыраулаштыру белән аерылалар, шул ук вакытта, татар теленең аеруча көнчыгыш диалектлары белән уртак формалары булып торалар.

*Д* һәм *т* авазлары чиратлашу очраклары татар теленең башка сөйләшләрендә дә билгеләнеп үтелгән.

Тирән тел арты *қ* һәм тел арты *к* тартык авазлары сүз башында сузык алдында яки интервокаль позициядә яңгыраулашырга мөмкин: *гөдрә* < *көдрә* – әд. бөдрә, *йаға* – яка, *чегерткин* – кычыткан, *чегерткә* – сикерткә, *бағыр* – бакыр; *гүләү* – көйләү, *гәрәчин* – керосин, *тағыл*/*тақыл* – сау, яхшы, *ғомбағыш*//*қомбағыш* – көнбагыш, *гәрниз* (сирәк), – қарниз, *қәләнфур*//*хәләнфүр*//*гәләнфур* – канәфер, *чағарда* – чехарда һ.б. Ләкин: *қырықар* (бүлем саны), *сулақай* (сул).

Шушындый ук позицияләрдә *к, қ* авазларының яңгыраулашуы – Себер ареалы татар диалектларының характерлы үзенчәлекләреннән берсе. Ул тагын мишәр һәм керәшен сөйләшләренә хас, аерым сүзләрдә кама тамагы һәм норлат сөйләшләрендә дә күзәтелә.

Татар сөйләшләрендә сирәк очрый торган күренешләр дә бар. Сүз яки иҗек башында һәм интервокаль позициядә тел очы

саңгырау *с* авазының яңгыраулашуы түбәндәге сүзләрдә даими күзәтелә: *зәрәтә* – сәрдә (үлән исеме), *мазайу* – масаю, *зөңге* – сөңге, *зумнау* – агачны кирәкле размерда эшкәртү, гомум төрки формасы – *сумлау*; (чаг.: якут телендә *умла*, чөнки сүз башындагы позициядә башка төрки телләрдәге *с* авазы якут телендә бөтенләй әйтелми).

Сүз башындагы позициядә *җ* авазын *ч* белән алмаштыру очраклары бар: *чиназа* – җеназа, *чумарт* – җумарт – юмарт, *чепа-йаланғач* – җапа-җалангач – яп-ялангач. Бу үзенчәлеге белән Барда төбәге сөйләше, гомумән пермь сөйләше кебек үк, урта диалектның касыйм сөйләшенә якыная.

Артикуляцияләре төрле булган тартык авазлар арасындагы тәңгәллекләр дә очрый.

Л. Җәләй, Д.М. Сарманаева хезмәтләреннән билгеле булганча, пермь сөйләше *җ*-ләштерүче сөйләшләрдән санала.

Дөрестән дә, әдәби телдә, гомумән татар телендә *й* белән әйтелә торган сүзләр пермь сөйләшендә, шул исәптән Барда төбәгендә дә, күбесенчә тел очы ярым йомык *җ* тартыгы белән әйтеләләр. Мәсәлән: *җақшы* – әд. яхшы, *җаңыш* – ялгыш, *җастық* – ястык һ.б.

Бу күренеш сүз уртасында да күзәтелә: *мөрҗә* – моржа, *арҗақ* – аръяк, *дөнҗа//дөнйа* – дөнья.

*Җ*-ләштерү әдәби әйтелеш белән чиратлашырга да мөмкин: *йәшел//җәшел; йул//җул; йуқ//җуқ* һ.б. Параллельлек бер төркем диалекталь сүзләрдә дә сакланып килә: *йаматай//җаматай* – ямьсез, *начар; җомақ//йомақ* – табышмак; *җаwын//йаwын* – яңгыр һ.б.

*Й*-ләштереп яки *җ*-ләштереп сөйләүнең закончалыгын билгеләве кыен. Алар бер үк кешенең сөйләшендә, бер үк вакытта да параллель күзәтелергә мөмкин.

*Җ*-ләштерү күренеше Пермь краеның барлык төбәкләрендә дә бер үк дәрәҗәдә түгел. Барда төбәге татарлары сөйләшенә көчле *җ*-ләштерү хас. Көнгер татарларында исә, аеруча өлкән буын сөйләм телендә, *җ*-ләштерү күренеше, барда татарлары белән чагыштырганда, сирәгрәк.

*Җ*-ләштерү урта диалектның төп үзенчәлекләреннән берсе, димәк тикшерелә торган сөйләш, бу үзенчәлеге белән урта диалектка якын тора.

*Җ* һәм *й* авазлары тәңгәллеге тагын *җ* > *й* күчешендә чагыла. Мондый күренеш факультатив характерда һәм, асылда, түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *йемеш, йер, йеббәр, йебәрү, йезнәй, йыру* һ.б.

*Җ > й* күчешенең тар әйтелешле *ы-е* сузыклары алдындагы позиция белән бәйләнгән булуы мөмкин.

Әдәби телдәге *җ* авазы урынына *й* сонанты әйтелү, нигездә, көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләрнең берсе булып саналса да, урта диалект сөйләшләрендә дә табыла, мәсәлән, нократ сөйләшендә *җ* авазы билгеле очракларда гына әйтелә. Л. Җәләй бәрәңге һәм минзәлә сөйләшләрен, *җ* һәм *й* гә бәрабәр булган сөйләшләр, дип саный, бу соңгы еллардагы экспедиция материаллары белән дә раслана.

*К ~ т* тәңгәллеге. *Итмәк* – әд. икмәк. *Итмәк* формасы борынгы татар әдәбиятында да кулланылган, мәсәлән: *«...коруг итмәккә канәгать кылмадин...»* (Нәһҗел фәрадис). Хәзерге көндә урта диалектның касыйм сөйләшендә – үтми’, көнчыгыш диалектларда *итмәк* формаларының барлыгы билгеле. (чагыштыр: алт. *итпек, өтпөк,* караим теленең тракай диалектында этмяк; XII–XIII гасырга караган язма истәлекләрдә *ӓтмӓк, өтмӓк* һ.б.).

*Чәтләwек* – әд. чикләвек. Чагыштыр: кузнецк *читлавык*; кар. *четлявюк*, башк. *сәтләүек* һ.б.

*Теләү//keләү*. *Теләү* фигыленең *keләү* варианты сөйләштә сирәк очрый. Бу форма аеруча көнбатыш диалектка һәм керәшен сөйләшләренә хас.

*Н ~ к* тәңгәллеге. *Искәү* – әд. иснәү. Шушындый ук модельдә *тосқау* – әд. төсмерләү сүзе ясалган. *Искәү* формасы урта диалектның минзәлә, казан арты сөйләшләрендә, көнбатыш диалектның кузнецк, темников, ләмбрә, хвалын сөйләшләрендә билгеләнеп үтелгән.

Сирәк күзәтелә торган тәңгәллекләр:

*җ ~ д: қаралдым* – әд. каралҗым;

*нл ~ нд: салқындық* – әд. салкынлык;

*к ~ ң: иңече* – әд. икенче (> игенче > иңече);

*лп ~ рб: шурба* – әд. шулпа;

*г ~ д: диктар* – әд. гектар;

*w ~ г: угалу* – әд. увалу.

*Шурба, угалу* сүзләре, әдәби шулпа, увалу формалары белән чагыштырганда, борынгырак формалар булып санала.

Күргәнебезчә, артикуляцияләре төрле булган тартык авазлар арасында күзәтелгән тәңгәллекләрнең күпчелеге, беренчедән, өйрәнелә торган сөйләшнең керәшен, касыйм сөйләшләре һәм

көнбатыш диалекты белән зур уртаклыкка ия, икенче яктан, борынгы күренеш калдыклары булып торалар.

**Алынма сүзләрдә кайбер үзенчәлекләр.** Рус, гарәп, фарсы һәм башка телләрдән кергән сүзләрдәге татар теле өчен характерлы булмаган авазлар бу сөйләштә дә төрле фонетик үзенчәлекләр кичерәләр: татар теленең үз закончалыкларына яраклаштырылалар, артикуляцион һәм акустик яктан аларга якын булган авазлар белән алмаштырылалар.

Югарыда Барда төбәге сөйләшенә хас диалекталь үзенчәлекләрнең алынмаларда да берникадәр чагылу очракларын күреп үткән идек.

Инде алынма сүзләрдә очрый торган кайбер аваз тәңгәллекләрен тукталыйк.

1) Фарингаль *h* авазы өлкән буын телендә гомумән әйтелми, ягъни сөйләш башкорт теленнән аерылып тора: *әр* – һәр, *аман* – һаман, *Таир* – Таһир, *awa* – һава, *әргиз* (< фарсыча *һәргиз*), *өнәр* – һөнәр һ.б. Яшь буын һәм мәктәп яшендәге балаларның сөйләм телендә ул тел арты *х* спиранты белән алмашына: *хәр* – һәр, *хәм* – һәм, *xawa* – һава һ.б.

2) Ярым йомык ирен-теш *в* тартыгы ирен-ирен тартыклары *б* яки *w* белән алмашына: *бупча* < вовсе, *wич*//*бич* < весь, *wыбеска* < вывеска, *утбит* < ответ, *лисбәнкә* < лиственница, *wыдрә* < выдра һ.б.

3) Рус алынмаларындагы *ц* аффрикаты *с* спиранты, тел очы ярым йомык *ч* авазы яки тел очы тартыклары *тс* кушылмасы белән алмашына.

*ц* > *с: ударниса* < ударница, *балнис* < больница, *гәрчис* < горчица, *силикум* < целиком, *мутысикыл* < мотоцикл, *насиналныс* – национальность һ.б.

ц > ч: *көзнөч* < кузнец, *чемет*//*симет* < цемент, *гүрчичә*//*гәрчис* < горчица, *гөрничә* < горница, *угурча* < огурец һ.б.

*ц* > *тс*: *апирәтсә*//*әперәтсийә* < операция, *риwалүтсә* < революция һ.б.

4) Тел очы *с* тартыгы, бигрәк тә өлкән буын телендә, ясалу урыны буенча үзенә якын торган *ч* тартыгы белән алмашына: *рыч* < рысь, *чистыра* < сестра, *мәчник* < мясник, *Чибә* < Сива (елга исеме), *Уч Ашап* < Усть Ашап, чила < село, *кәчтүм* < костюм, *чимҗә* < семья, *Күчтәнти* < Костентиново < Константиново (авыл исеме), *читсы*//*читче* < ситец, *чичта* < чиста һ.б.

5) Рус теленнән булган алынмаларда *з* тартык авазы урынына *җ* авазы әйтелә. Бу күренеш шактый системалы характерда: *Кеҗҫе* < Козья (авыл исеме), *мәгәҗҫин* < магазин, *маложҫимный* < маловемный, *җҫәт* < зять, *җҫәп* < зябь, *генәжҫ* < князь, *минжҫин//билжҫин* < бензин, *пежҫмин* < бизмень, *геруҗҫ* < груздь (гөмбә ис.), *Кижҫел* < Кизел һ.б. Шулай ук: *Мәнжҫәлә* < Минзәлә.

6) Алынма сүзләрдәге *д* тартык авазы еш кына артикуляцион яктан аңа якын булган *җҫ* авазына күчә: *әҗҫийал* < одеяло, *Җҫеменеwо* < Деменево (авыл исеме), *бергажҫир* < бригадир, *бужҫилник* < будильник, *сужҫийә* < судья, *җҫикий* < дикий, *җҫириктор* < директор, *гәржҫирөп* < гардероб, *өмөжҫе//әмежҫе//межҫе* < *эмидә* – кура җиләге һ.б.

Алынма сүзләрдәге мондый фонетик күренешләр төрки телләрнең (шул исәптән татар теленең дә) үз закончалыклары белән бәйләнгәннәр һәм татар теленең барлык сөйләшләрендә дә табылалар. Барда төбәгендә, гомумән пермь сөйләшендә, күзәтелә торган әлеге үзенчәлекләр бу сөйләшнең бигрәк тә урта диалект сөйләшләренә якын торуын күрсәтәләр.

Соңгы еллардагы экспедиция материаллары алынмаларны үзләштерүдә күзәтелә торган мондый күренешләрнең шактый сирәгәя баруын күрсәтте. Күпчелек алынмалар, аеруча рус-европа алынмалары язма әдәбияттан, радио яки телевизор аша үзләштереләләр.

**Аваз өстәп сөйләү очраклары.** Әдәби тел белән чагыштырганда аваз өстәү күренеше булып санала торган диалекталь үзенчәлекләрнең кайберләре, тарихи яктан караганда, еш кына дөрес форма булып торалар.

Мәсәлән, мондыйлардан барда татарлары сөйләшендәге *йөзлег өст* сүз тезмәсендә борынгы *ст* кушылмасы сакланып килә; бу сүздән нисби сыйфат *-ке* кушымчасы белән түгел, ә *-е* кушымчасы ярдәмендә ясала: өсте ягы – әд. *өске ягы*; чаг.: нократ сөйләшендә: *өст, йомортқа* сүзләрен күрсәтергә мөмкин.

*Рт* кушылмасы сөйләштә тагын түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *шарт* – шат, *чыбыртқы* – чыбыркы, *себерткә* – себерке, *қортлау* – котлау, *чортма* – чорма, *чегерткин* – кычыткан һ.б.

*Йомортқа, чыбыртқы, себертке* кебек формалар белән сөйләш урта диалектның минзәлә, нократ сөйләшләре һәм көнчыгыш диалектлар белән уртаклык күрсәтә.

Билгеле булганча, аваз өстәлү күренеше чит телдән кергән сүзләрне үзләштерү процессында да барлыкка килә. Мәсәлән, *эскәмбийә* < скамья; шулай ук, минзәлә һәм бөре сөйләшләрендә дә, *Илдин* < Ильин (день),– *кәшәмби* – кашемир, *пырзумит* – позумент, *ҡәләмфүр* – қәнәфер һ.б. Бу сүзләрдәге өстәлеп килгән *б, д, р, м* тартык авазларының үзләре янында торган *м, л, з, ф* тартык авазларына ясалу урыннары буенча охшаш булулары күзгә ташлана. Икенчедән, аларның ике иҗек арасында барлыкка килүе үзенчәлекле.

Гөлбәдия < гөбәдия (эченә бары җиләк-җимеш кенә тыгып берничә катлы итеп әзерләнә торган туй ашы) сүзендә халык этимологиясенең роле йогынты ясаган булырга мөмкин.

**Комбинатор үзгәрешләр**. Барда сөйләшендә авазларның аерым фонетик шартларда яки билгеле позициядә үзгәрү күренешләре дә киң таралган. Сузыклар белән янәшә килгән яңгырау һәм саңгырау тартыкларның өлешчә охшашлану яки охшашсызлану (ягъни, *п–б, т–д, с–з, к/ҡ–ғ* күчешләре) очракларына тартыклар тәңгәллеге турында сөйләгәндә тукталган идек. Сөйләштә ассимиляция һәм диссимиляция күренешләренең тагын мондый очраклары бар.

**Туры ассимиляция**. 1) *лы-ле, лык-лек, лай-ләй, лар-ләр* кушымчаларындагы *л* сонор тартыгы *м, н, ң* сонорларына беткән сүзләргә ялганганда өлешчә охшашлана: *тәмне, йәмне, бетеннәй, печәннек* һ.б.

2) Берничә сүздә саңгырау *ш* авазы *ч* авазына системалы рәвештә тулысынча охшашлана: *чич* – чиш, *чичен* – чишен, *чебеч* – чебеш (тавык).

3) *с > ш: Шәмши, шиш* < шест, *шиштырна* < шестерня.

**Кире ассимиляция.** 1) Тел очы *н* тартыгы ирен-ирен *б* тартыгы алдында торганда өлешчә, ирен-ирен *м* тартыгы алдында торганда тулысынча охшашлана: *ҡомбағыш, симме, мимме, умбиш, умбер* һ.б.

2) Шул ук *н* тартыгы тел арты *к, г* һәм тирән тел арты *ҡ, ғ* тартыклары алдында килгәндә өлешчә охшашлана: *йалаңға, урмаңға, чолаңға, уңға* (унга - сан), *уңғанчи, күреңгели, Кеңгер*; алынмаларда: *биләңке* – гөмбә исеме һ.б.

3) Тел очы *с, ч* тартыклары саңгырау *ч, ш* тартыклары йогынтысында тулысынча охшашланалар: *Шараш* – Сараш (авыл исеме), *шуғыш* – сугыш, *шүләшү* – сөйләшү, *шишмә* – чишмә, *шаршау* –

чаршау, *шыршы* – чыршы, *бачқыч* – баскыч; алынмаларда: *шушилкә* – сушилкә, *шәҗин* – сажень һ.б.

Мондый кире ассимиляция күренешләре урта диалектның күпчелек сөйләшләре өчен характерлы һәм барда төбәге сөйләшенең урта диалектка якын торуын күрсәтәләр.

4) Бер төркем сүзләрдә тел очы саңгырау т тартыгы өрелмәле *ч* авазына тулысынча охшашлана: *чөчкөрү, чичқан, чөчө*. Бу сүзләр сөйләштә системалы рәвештә шулай кулланылалар.

Күргәнебезчә, сөйләш мондый үзенчәлеге белән аеруча көнчыгыш диалектларга якын тора.

**Авазларның кыскаруы (йотылуы)**. Сөйләш өчен бу өлкәдә күзәтелә торган характерлы үзәнчәлекләрнең берсе икеләтелгән тартыкларның (геминантларның) кыскаруы. Мондый күренеш Барда төбәге, гомумән пермь сөйләшендә шактый актив күзәтелә. Ул төрле сүз төркемнәрендә сүз эчендә дә, морфемаларның ялганган урыннарында да була ала һәм авазларның сыйфаты белән дә бәйләнмәгән булса кирәк. Мисаллар: *лл > л. Ғаптула* – Габдулла, *Лотбула* – Лотфулла, *Хәмдилә* – Хәмидулла, *шикеле* – шикелле, *әлә* – әллә, *мәлә* – мәллә, *Шәйқулин* – Шайхуллин, *Патқула* – Фәтхулла һ.б.;

*нн > н* бәйлек сүзләр, исемнәр һәм алмашлыкларның чыгыш килеш формасында: *анан* – аннан, *монан* – моннан, *артынан* – артыннан, *агачынан//ағачнан* – агачыннан, *суғынан* – соңыннан; фигыль формаларында: *орғанап* – орғаннау – агачның яки сәгать теленең, багананың тирбәлеп торуы; кеше исемнәрендә: *Қанан* – Ханнан һ.б.;

*сс > с.* II зат киләчәк заман хикәя фигыльнең юклык формасы (берлектә һәм күплектә): *алмасың* – алмассың, *әйтмәсез* – әйтмәссез, *тапмасын* – тапмассың, *қайтмасынмы* – *қайтмассыңмы* һ.б.; башка сүзләрдә: *эсе, эселей /эсселәй* – эссе килеш һ.б.

*кк > к. урақайым* < ураккаем; *йерәкәйем* < йөрәккәем; *элке* < *элеке* < элекке, *теләкәйем* < теләккәем, *қарчықай* < карчыккай, *қырықач* < кырыккач, ақош < аккош һ.б.

*тт > т: чатқыты* (диал. *чатқытты*) – чап итеп сукты, *Шәйхәтәр* < Шәйхәттәр һ.б.;

*рр > р: үткерәк (< үткеррәк)* – әд. үткенрәк һ.б.;

*җҗ > җ: дәҗәл* < дәҗҗал һ.б.

Ләкин: *сүккеләү, йеппәрү//йеббәрү* һ.б. Бу сүзләрдә тартыкларның икеләтелүе эмоциональ-экспрессив чара булып тора.

Галимнәр күрсәтүенчә, борынгы төрки телләрдә икеләтелгән тартыклар булмаган. Күп очракларда алар ассимиляция йә тамыр яки нигезгә кушымча кушылган урында ике бертөрле авазның янәшә килүе нәтиҗәсендә хасил булалар, ләкин бу вакытта да икеләтелгән тартыкларның бер авазга әйләнү тенденциясе бар.

Н.А. Баскаков алтай теленең туба-кеше диалектын тикшергәндә дә геминантларның кыскару күренешләрен билгеләп үтә һәм мондый үзенчәлекне «озын сузыкларның нормаль сузыкларга күчү тенденциясенә аналогик күренеш» дип атый.

Башка очракларда аваз төшерү күренешләрен карыйк.

Билгеле булганча, тартык авазлар ике сузык арасындагы позициядә тизрәк төшереләләр. Тартык авазның йотылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән бертөсле янәшә сузыклар тартылып гадәти авазга кадәр кыскаралар.

1) Тел очы *н* тартык авазының төшерелүе түбәндәге очракларда күзәтелә:

а) сүз азагында. Бу аеруча бәйлек һәм ярдәмче сүзләрдә табыла: бармас боро – бармас борын, *күргән сайы* < саен; (көнчыгыш диалектларда бу бәйлекнең тагын да кыскартылган вариантын күрәбез: *сай*); *белә*/*беле*/*биле*/*былы*//*билә*; бу рәвешле кыскарту татар теленең башка сөйләшләрендә дә бар; язма әдәби телдә илә формасы XX йөз башында да кулланыла); *икә* һәм *микә* (икән; микән) һ.б.

*Н* авазы *р, л* авазлары кебек үк тотрыксыз булган авазлар рәтенә карый.

Сүз азагында *н* авазы төшерелүнең Барда татарлары сөйләшендәге кебек үк очракларын хамий уйгырлары теленнән күрсәтергә мөмкин: *ікӓ(н)* – икән, *мӓ* < *ман* – мин, *шта* < штан һ.б.;

б) *н* тартык авазының төшерелүе тагын кайбер сүзләрдә тел очы тартыклары алдындагы позициядә күзәтелә: *асат* – ансат, *мунча*/*муча*; *монсо*/*мосо* һ.б.

2) *р, л* сонорларының төшерелүе. *Югалту, утырту* сүзләрендә *р, л* сонорлары даими рәвештә йотылалар: *җуғату, утыту.*

*Р* авазы тагын инфинитивның *ырга-ергә* формасында спорадик рәвештә кыскарырга мөмкин: *барыға, күрегә* һ.б. Мондый күренеш башка сөйләшләрдә дә бар. Сөйләштә *көчләү, күзләү* (әд. энә саплау), *бирле* сүзләрендә дә *л* соноры даими рәвештә төшерелә: *күзәү, көчәү, бире*;

3) ирен-ирен йомык *б* авазы интервокаль позициядә килгәндә йарым йомык *w* авазына күчә яки бөтенләй төшерелә. Мондый күренеш, аеруча, түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *қаwып/қāып* – әд. кабып; *таwып/тāып* – табып; *йаwып/йāып* – ябып, *чаwып/чāып* – чабып; *кебек/кеwек/күк; қаат* – кабат һ.б.;

4) *к* авазының төшерелүе: *арбыз* – карбыз, *байна* – баягынак.

5) сөйләштә кайбер сүзләрдә авазлар гына түгел, хәтта авазларның бөтен бер комплексы яки бөтен бер иҗек тә йотылырга мөмкин. Шунысы характерлы – мондый күренешләр гадәти темптагы сөйләмдә дә күзәтеләләр: *мә қыныпп* < мәстә кыланып; *қāм белим* < каян белим; *ичақ* < иртәнчак; *әйсә* – алайса; *арта* < арты табан; *қәйләнеп* < *хәйләләнеп* – әд. хәйләләп; йөшенеп < яшеренеп; *шуwи* < *шуwый* < *шулый* < шулай; *шуннары* < *шуннан ары*; *қәймикә* < каенбикә; *қәртти* < карт әти; *нә* < *ни*$^{й}$*ә* < нийә < нигә; *әләйди* < әллә нинди; *қурқыч* < куркыныч; *ишегал, қапқал* (ишек алды, капка алды); *шамта* < *шырамта* – юыну өчен, яки идән юу өчен теленгән мунчала һ.б.;

6) авазларны төшереп сөйләү, сүзләрнең кыскаруы кебек күренешләр сөйләшнең лексик составының шулай ук аерылгысыз өлеше булган кеше исемнәрендә дә бик интенсив. Кайбер исемнәр бөтенләй танымаслык булып үзгәрәләр. Мәсәлән: *Апул* < Габдулла, *Әҗмек* < Әҗмөхәммәт, *Мөқәт* < Мөхеттин һ.б.

Еш кына кыскартылмаларның ахырына төрле кушымчалар кушылган була. Шундыйлардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

*қай/кәй/кә/ка: Йәркә* – Ярулла, *Миңкәй* – Миңнәхмәт, *Майкә* – Маһиҗамал, *Рапка* – Рафаэль, *Шәмкәй* – Шәмсеттин, *Әлкәй* – Әлхамра һ.б.

Борынгы язма документларга күз салсак, аларда татарларның гына түгел, мариларның, чувашларның һ.б. халыкларның исемнәренә дә даими рәвештә ка, ко кушымчалары кушылганлыгы күренә. Мәсәлән, 1679 елга караган салым кенәгәләреннән кайбер татар исемнәрен китерергә мөмкин: *Бисердачка, Батырка, Байгунко, Уракчийко, Аблайко, Кунчюрайко, Канмурзачко, Исенейко, Ураско, Алийко, Маматкунко, Төбенейко* һ.б. XVIII йөз башына караган язма документларда инде мондый күренеш бик сирәк. *Йәркә, Миңкәй* кебек формаларда шул күренешнең калдыклары яшәп килә булса кирәк;

*ч/ш: Данич* < Дания, *Ралич* < Ралия, *Бәлеш* – Валиулла, *Майкәш* < Маһикамал, *Чирач* < Сиражетдин, *Кубриш* < Квра, *Абыраш* < Габдрахман һ.б.

Мондый исемнәрне рус телендәге *Ванюша, Илюша* тибындагы формалар белән чагыштырырга мөмкин. Барда татарларының берничә гасырлар буе башка төр халыклар белән чолганышта һәм руслар белән аеруча тыгыз элемтәдә булулары әлеге формаларның рус теле йогынтысы астында барлыкка килүен дә фараз итәргә мөмкинлек бирә;

*и/әй: Бәрхи/Бәрқый* – Фәрхетдин; *Мипти* – Мифтах, *Сибәй* – Субхәттин, *Мәрпи* – Мәрфуга, *Мәпти* – Мәфтуха, *Җәмәй* – Җамалия, *Пәүҗи* – Фәүҗиан, *Нәпи* – Нәфисә, *Бәйти* – Бәйтулла, *Каупи* – Кауфетдин, *Сәқый*, *Шәйқый* һ.б.

Сөйләш өчен характерлы булган геминантларның кыскаруы яки татар теле өчен характерлы булмаган авазларның төшеп калуы кебек күренешләр кеше исемнәрендә дә еш күзәтелә: *Зарттин* – Заһерттин (*h* > *o*): *Кашпа* – Кәшифә, *Зәйерә//Зини* – Заһирә, *Зиһени* һ.б.

Кеше исемнәрен белдерә торган сүзләрдәге мондый үзенчәлекләр, беренчедән, кеше исемнәрендә дә гарәп-фарсы сүзләренең акрын үзләштерелүен, икенчедән, Пермь татарлары сөйләшенең бу яктан да көнбатыш диалект, нократ һәм керәшен сөйләшләре белән зур уртаклыгы барлыгын күрсәтәләр.

**Метатеза.** Метатеза күренешенең тикшерелә торган сөйләштә төрле очраклары бар.

Янәшә метатеза сузыклар белән тартыклар яки ике тартык арасында була: *азбар* – абзар, *чичкә* – чәчәк, *чипкин* – чикмән (чаг.: бәрәңге сөйләшендә – *чибкән*; алт. *чепкен*, кырг. *секреп//серкеп*, ∩∩к.-калп. *шепкен* һ.б.), *үрмәкче//үрмәкчә* – үрмәкүч һ.б.

Арадаш метатеза *ырдын* – ындыр, *чегерткин* – кычыткан, *қумалақ* – колмак сүзләрендә даими күзәтелә.

Сирәк кенә *сарана, манара, чәкән* сүзләрен дә метатезалап әйтәләр: *санара, марана, кәчән*.

Татар әдәби теле белән чагыштырганда метатеза булып санала торган формаларның кайберләре башка төрки телләрдә әдәби норма булып йөриләр.

**Ике сүз арасында очрый торган кайбер үзенчәлекләр**. Барда төбәге татарлары телендәге бер төшенчәне яки төгәлләнгән бер

уйны белдереп, гомуми бер фраза басымы белән әйтелә торган сүз тезмәләрдә ике сүз арасында күзәтелә торган фонетик күренешләр, нигездә, урта диалекттагыча һәм, шулай ук, әдәби телнең орфоэпик формаларына да туры киләләр: охшашлануга нигезләнгән булалар. Болар белән беррәттән, сөйләшнең үзе өчен генә характерлы үзенчәлекләре дә бар, дөресрәге, алар әле башка сөйләшләрдә билгеләнмәгәннәр.

а) Беренче сүзнең азагында һәм аннан соң килә торган икенче сүзнең башында бер төрле тартык килгәндә аларның берсе кыскара: *берәттән* – беррәттән, *ачыбеткән нимәләр* – ачып беткән нимәләр, *барамсыни – барамсынни – барасың мени, аша бет*//ашап бет – әд. ашап бетер һ.б.

б) Икенче сүзнең башында сузык яки саңгырау һәм өрелмәле тартыклар килгәндә беренче сүзнең азагындагы саңгырау *к, қ, п* тартыклары өлешчә яки тулысынча яңгыраулашалар, мәсәлән: *биг͡ усал, қысыг͡ икә, йазыб͡ утыра, йазыб͡ йөри* һ.б.

*Йебәрү* (әд. җибәрү) ярдәмче фигыле һәм *ып-әп* формалы хәл фигыль белән оешкан сүз тезмәләрдә *п* тартыгы бөтенләй төшеп калырга мөмкин: *Кем үрәте йебәрде?* – Кем өйрәтеп җибәрде? *Арта суққыла йеппәргән тегенеңә* – Аннан соң суккалап җибәргән тегеңә. *Бире йебәрдем* – Биреп җибәрдем һ.б.

в) *Кый* раслау кисәкчәсе сузык авазга башланган сүз алдында торганда, сөйләү темпы белән бәйле рәвештә булса кирәк, еш кына фонетик деформациягә дучар була: *Әли китте қº әнә* – Китте бит әле әнә. *Әлдә дә була қ әл анда* – Әле дә була бит әле анда. *Йуқ қале wыл* – Юк бит әле ул һ.б.

**Фонетик-морфологик характердагы үзенчәлекләр**. Бу төр үзенчәлекләр, аваз күчешләре рәвешендә булсалар да, төрле грамматик формаларга карыйлар һәм тарихи морфология белән дә бәйләнәләр.

Бер төркем фонетик-морфологик үзенчәлекләр минем тарафтан фигыльләр өлкәсендә күзәтелде.

1) Хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльнең II зат берлек формасы, әдәби телдән аермалы буларак, *-сын*/*-сен* кушымчасы белән формалаша. Мондый күренеш, асылда, өлкән буын кешеләре сөйләшендә факультатив характерда очрый һәм таралышы ягыннан сөйләшнең гомуми характердагы үзенчәлекләреннән берсен тәшкил итә. Мисаллар: *чәчәсен* – чәчәсең, *итәрсен* – итәрсең, *сытасын* –

сытасың, *туқыйсың* – туглыйсың, *саласын* – саласың, *ойалмыйсынмы*? – оялмыйсыңмы? һ.б.

2) Барда татарлары сөйләшендә киләчәк заман хикәя фигыльне киң әйтелешле варианттагы кушымчалар белән формалаштыру очраклары бар. Бу күренеш, нигездә, өлкән кешеләр телендә сакланган: *көн айазар, кичкедә қайтармын, шунда керәрсез, үзегез күрәрсез* һ.б.

3) Кабатлаулы фигыльләрдә *-ғала/-гәлә//-қала/-кәлә* кушымчасындагы беренче *а-ә* сузыкларын тарайту сөйләш өчен системалы күренеш: *орғыла*, бәргелә, *чийғыла* – сызгала һ.б.

Бу күренеш белән барда төбәге сөйләше татар теленең көнчыгыш диалектлары, мордва-каратай кебек үзенчәлекле сөйләшләр белән зур уртаклык күрсәтә.

*-гыла/-гелә//-кыла/-келә* формасы күпчелек төрки телләр (аеруча кыпчак, алтай һәм уйгыр телләре) өчен характерлы.

4) Киләчәк заман хәл фигыль (*барганчы, килгәнче*) кушымчасындагы *-ы/-е* сузыклары факультатив рәвештә *и* сузыгы белән алмаштырылалар. Мисаллар: *Аталары қартайғанчи тороп үлделәр. Кызыллар килеп кергәнчи қачып йатты wы (ул). Элег үк кит тә өмөҗе ашарсың туйғанчи* – Иртә үк кит тә кура җиләге ашарсын туйганчы. *Мунча индергән қәле беткәнчи* – Хәле беткәнче чабындырган мунчада һ.б.

Мондый үзенчәлек белән барда төбәге, гомумән пермь сөйләше әдәби телдән генә түгел, татар теленең башка сөйләшләреннән дә аерылып тора.

*-ганчи/-гәнчи* формаларында югарыда карап үткән *ы* > *и (е* > *и)* күчеше чагылса кирәк. Шул ук вакытта бу кушымчадагы -ы, -е > и күренеше позицион характерда да булырга мөмкин, чөнки тупланган материаллар сөйләм теленә хас *аңынчы, моңынчы* сүзләрендә һәм көчле теләк белдерә торган *булсачы, килсәче* формаларында да *ч* авазыннан соң килә торган *-ы, -е* сузыкларының *и* авазына күчүен күрсәтәләр: *аңынчи, моңончи, булсачи* һ.б. *Ч* тартыгыннан соң килгән сузыкларның тараюы аерым сүзләрдә дә очравын фонетик үзенчәлекләр рәтендә күрсәтеп үткән идек (*чирек бәрәңге, чиркәй* – черки , *күгерчин, чийон* – чуен һ.б.).

Фонетик-морфологик характердагы үзенчәлекләр исемнәр һәм алмашлыкларда да чагылалар, алар күпчелек очракта ассимиляция яки диссимиляция һәм аваз төшереп сөйләү күренешлә-

ре белән аңлатылалар. Шундыйлардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

*м, н, ң* сонорларына беткән исемнәрнең чыгыш килеш формасында -*дан*/-*дән* кушымчалары ассимиляцияләнми: *күндән* – әд. күннән, *Казандан* – Казаннан, *йаландан* – урманнан, *райундан* – районнан һ.б.

Исемләшкән -*ган*/-*гән* формалы сыйфат фигыльләрдә һәм *м, н, ң* сонорларына беткән башка сүзләрдә дә шундый ук үзенчәлек күзәтелә: *башлагандан, меңдән, кичтәндән, күптәндән* һ.б. Алмашлыкларда мондый күренеш юк дәрәҗәдә сирәк очрый: *үзендән, андан* һ.б.

Татар язма әдәби телендә мондый үзенчәлек Октябрь революциясенә кадәр дәвам иткән. Ә хәзерге көндә бу борынгы күренешнең касыйм, нократ һәм башка кайбер сөйләшләрдә барлыгы билгеле.

*Шул* күрсәтү алмашлыгының иялек һәм чыгыш килеш формасында -*н*- тартыгының бөтенләй төшерелү очраклары да күзәтелде. Бу вакытта төшерелгән аваз урынында янәшә килгән сузыкларның сыйфаты белән бәйле рәвештә *w* соноры барлыкка килә: *шуwан* – шуннан, *шуwың* – шуның.

## Морфологик үзенчәлекләр

Тикшерә торган сөйләштә сүз төркемнәре һәм аларга хас төп грамматик категорияләрнең (зат, сан, тартым, синтаксик бәйләнеш, төр һәм форма ясалышы һ.б.) зур күпчелеге әдәби тел белән бертөсле. Шуның белән бергә, сөйләштә характерлы гына диалекталь күренешләр дә сакланып килә.

**Нисбәтлекне белдерүдә күзәтелә торган үзенчәлекләр**. 1. Билгеле булганча, татар әдәби телендә -*нықы*/-*неке* кушымчалары, башка төрки телләрдәге кебек үк, исемнәргә яки исемләшкән башка сүзләргә һәм алмашлыкларга ялганып килә. Мондый сүзләр нинди дә булса әйбернең кемгә яки нәрсәгә караганын белдерәләр һәм җөмләдә, нигездә, ике функция башкаралар: а) нисбәтлекне раслыйлар (яки инкарь итәләр) һәм хәбәрлек оештыралар; б) аерылмышы төшеп калган аергычны хәтерләтәләр һәм бу вакытта алар җөмләнең тәмамлыгы яки иясе булып киләләр, ләкин беркайчан да аергыч функциясен башкара алмыйлар.

Барда төбәге сөйләшендә исә, -*нықы*/-*неке* кушымчалы сүзләр, нократ, подберезье керәшеннәре, кузнецк сөйләшләрендәге һәм

көнчыгыш диалектлардагы кебек үк, аергыч булып киләләр: *Тегеләрнеке сүләшкәне* (тегеләрнең сөйләшкәне...) *дә қолакқа кер-ми. Бирнәне қызнықы җиңгәсе*(кызның җиңгәсе...) *тарата қақ бәлешне ашағанда. Үзе белә қый үзенеке әдерисен* – Үзенең адресын үзе белә бит. *Қызларнықы терлеге була инде анысы* – Анысы кызларның бирнәсе була инде. *Сиңке исемең нимә?* – Синең исемең ничек? *Аның инәсе белен миңке әти бертуган* – Аның анасы белән минем әти бертуган. *Әниләр бик йақшы тордолар безнеке* – Безнең әниләр бик яхшы тордылар. *Шуңа җән қарайды шу миңке* – Шуңа ачуым килде шул минем. *Миңк ашыйсы килми дә* – Минем ашыйсы килми дә. *Безнеке читтә қыз бар, бу шуңқы малайы* – Безнең читтә кызыбыз бар, бу шуның малайы һ.б.

*-нықы/-неке* кушымчасы ярдәмендә ясалган аергычлар бер-берсен ачыклап та килергә мөмкин: *Килгәннәр безнеке аwылнықы истүрийә үрәнмәгә* – Безнең авылның тарихын өйрәнергә кил-гәннәр. *Шу қоданықы быратынықы хатыны үлгән* – Шул коданың энесенең хатыны үлгән. *Минеке сеңелнеке чәче ақсағ астынан* – Минем сеңлемнең чәче тез астыннан. *Безнеқе үзебезнеке фер-манықе мал бырачы бар, моно гел шушынықа уқшатам* – Безнең үзебезнең ферманың мал врачы бар, моны гел шуңа ошатам һ.б.

2. Аергыч функциясендәге *-нықы/-неке* кушымчалы исемнәр һәм алмашлыкларның тартымлашкан формалары да очрый: *Ғап-тулла абзыйнықысы сеңеле була* – Габдулла абзыйның сеңлесе була. *Сиңкесе әнийең бармы?* – Синең әниең бармы?

3. Киресенчә, нисбәтлекне хәбәр итү функциясен иялек килеш кушымчасы башкара: *Моносы Мәликәнең үзенең, тегесе қунақ* – Монысы Мәликәнең үзенеке, тегесе кунак. *Читтәге қызның бу ике мендәр* – Читтәге кызныкы бу ике мендәр. *Ул қайс аwылның кеше ни?* – Ул кеше кайсы авылныкы?

Күргәнебезчә, сөйләштә *-нықы/-неке* һәм *ның-нең* кушымчаларының функцияләре алмаштырылып кулланыла. Бу күренеш сөй-ләш өчен гомуми характерда һәм яшь буын, хәтта интеллигенция телендә дә күзәтелә. Шуның белән бергә *-нықы/-неке* һәм *-ның/-нең* кушымчалары әдәби телдәгечә дә кулланылалар һәм, тупланган ма-териаллар буенча аларның диалекталь функцияләренең нинди дә булса закончалыгын билгеләве кыен.

Шунысы характерлы, бу ике нисбәтлек кушымчаларының бер-берсе функциясендә куллану буенча Барда төбәге сөйләше-

нең нократ, Себер ареалы татар сөйләшләре белән зур уртаклыгы бар.

Иялек килештәге сүзләрнең хәбәрлек белдерә алулары тагын караим, төрек телләрендә билгеләнеп үтелгән.

Мондый күренеш борынгы уйгыр язма истәлекләрендә дә бар: *Bu tamγa män Tutsunuŋ ol* – Бу тамга мин Тутсуныкы. *Bu tamγa biz ikägünüŋ ol* – Бу тамга безнең икебезнеке.

**Исемнәр.** Исемнәр өлкәсендәге диалекталь үзенчәлекләр сүз ясалышында, килеш һәм тартым кушымчаларын куллануда һәм кеше исемнәрен әйтүдә күзәтеләләр.

1) Исем сүз төркемендә сүз ясалышы белән бәйле үзенчәлекләр кайбер исем ясагыч кушымчаларның әдәби тел белән чагыштырганда киңрәк кулланылуында чагыла.

*-ма/-мә*: *өтмә* (*өтү* фигыленнән) – мунча ташы; *чима* (*чию* – сызу сүзеннән) – шырпы; *шартлама* (*шартлау* сүзеннән) – җыйганда шарт-шарт итеп өзелүеннән чыгып җир җиләге; *бүкмә* (бүгү) – пирожки; *күтәрмә* – өйгә керә торган баскыч һ.б.

*-у/-ү* формалы исем фигыльнең исемләшүе: *йабу* – теләсә кая ябып куела торган әйбер (мәсәлән: ашъяулык, скатерть, клеенка, покрывало, мендәр япкычы һ.б.); *сөртү* – сөлге, тастымал; *чабу* – чабынлык һ.б.

*-ғыч/-геч, -қыч/-кеч: җәйгеч* – келчә, *чапқыч* – китмән, *тырнаwыч* – тырма, *җабуғыч* – юрган, *челкәweч* (селкү сүзеннән) – җилпуч һ.б.

*-ыш/-еш*: *қуныш, айырыш* (умартачылык белән бәйле терминнар) һ.б.

*-мтық/-мтек*: *иләмтек* – көрпә, *йарымтық* – шүрәле һ.б.

2) Исем сүз төркеменә караган икенче характерлы үзенчәлек аның килеш белән төрләнешендә табыла. Тартымлы исемнәр төшем һәм чыгыш килешләрендә сузык авазга башланган, ягъни көньяк төрләнеш тибындагы кушымчалар белән формалашалар.

Төшем килешендә: *этийеңе* – этиеңне, *әйбереңе* – әйбереңне, *қызымы* – кызымны, *чебечләреме* – тавыкларымны һ.б.

Чыгыш килешендә: *апаңан* – апаңнан, *ireңән* –ireңнән, *ачуwыман* – ачуымнан, *угратыңан* – ишек алдыңнан һ.б. Әлеге күренеш пермь сөйләшенең, шул исәптән барда төбәгенең дә, специфик үзенчәлеген тәшкил итә, чыгыш килешенең бу рәвешле формалашуы, бараба диалектыннан кала, башка сөйләшләрдә әлегә билгеләнмәгән.

**Алмашлыклар**. Алмашлыклар өлкәсендә дә характерлы гына күренешләр яшәп килә. Бу өлкәдәге үзенчәлекләре белән дә Барда ягы сөйләше, бер яктан, татар теленең борынгылыкны үзләрендә аеруча нык саклап килә торган сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Икенче яктан, анда татар теленең башка җирле сөйләшләрендә әлегә билгеләнмәгән архаик формалар да табыла.

1. Алмашлыкларның составы, нигездә, әдәби телдәгечә. Диалекталь формалар бигрәк тә күрсәтү алмашлыклары өлкәсендә табылалар. Алар да әдәби телдәге күрсәтү алмашлыкларының сөйләшкә хас диалекталь үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә барлыкка килгән вариантлары булып торалар: *шул/шу/шы; ул/у/wы/w; аныкъый/әныкъый/ныкъый (әнә + қый* кисәкчәсе*); менә/мона/мыны/менәкәй/мени; теге/тее/ти; шушы;* рус теленнән кергән күрсәтү алмашлыгы: *wат//wәт*. Мисаллар: *Кашаға аныкъый* (кашага әнә*). Әныкъый чима белән уйнамаға җарамый* – Әнә, шырпы белән уйнарга ярамый. *Менәкәй шуңқы заты-зөрийәте мондағы урманнар. Мона тағы килер әле. Мени бу қызлар белә бит, үрәнерсең. Тее кыз нимә йсемн әле? Тийаққа чығабызмы, басмаға басабызмы? Ана шушы бақчадайы те ызба* – Теге йорт шушы бакчада иде. *Теге қызны көтәбезме чәй эчмәгә? Wат исәр баш, уқымый қалдым шулый. Әйе, wәт, wәт шуғысы* һ.б.

*Ул, шул* күрсәтү алмашлыкларының сөйләштә борынгырак формасы да кулланыла: *У җулны үгеҗ җул диләр* – Ул юлны үгез юлы диләр. *Сездә дә у қумалағ үсәме* – Сездә дә үсәме ул колмак? *Каймағы булса, зәәр була wы мәшкә* – Каймак булса, бик шәп була ул гөмбә. *Сүләшкән қызы w аның элеке, менә самый үзе шу. Иң әwәл шу wаwыл булған, ди* – Иң башта шул авыл булган ди. *Шы күwенә қалдымы шең* – Эшең шул көе калдымы? һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, *у, шу* алмашлыклары, сөйләм темпы белән бәйле рәвештә, еш кына фонетик үзгәрешләргә дучар булалар.

2. Әдәби телдәге *нәрсә* сорау алмашлыгы Барда төбәгендә *нимә, мә/мәсә* формаларында әйтелә; *ашар имә, эчәр имә*; *мәгә* – нәрсәгә, нәрсә өчен.

Әдәби телдәге нәрсә эшләгән, нәрсә эшләп (сөйләм телендә нишләгән, нишләп) сорауларына сөйләштә *мә//мәсә қынған < қылнған < қыланған* формасы туры килә. Мисаллар: *Нимә шләб утырасың, қызықай? Мә йазасыз, әйдәң мине дә йазың* – Нәрсәгә

язасыз, әйдәгез, мине дә языгыз. *Бер мәм* (бер нәрсәм дә) *җуғ ийе, қалдым шунда. Башына мәсә* (нәрсә) *қаплаған. Мәә кермисен?* (нигә). *Мә қынып җатасыз*? – Нишләп ятасыз? *Мәсә қынған быса* (нәрсә эшләткәндер) һ.б.

3. Кайбер очракларда *мин* һәм *бу* алмашлыкларының *б* варианты әйтелә. Мисаллар: *Бийән* (миннән) *алғарақ килгәннәр. Боно* (моны) *қуй. Искечә булсын, буныңча* (моныңча) *булсын – анда инде. Мин үзем эшләмәдем буңа* (моңа) *барғанчы. Буғысын ишеткәнем җуқ* (монысын) һ.б.

Бүтән төр алмашлыклар үзләренең составлары буенча әдәби телдән аерылмыйлар.

4. Барда татарларында *-нықы/ -неке* кушымчалы *мин, син, ул, бу, шул* алмашлыкларының тагын да кыскарган фонетик варианты кулланыла. Мәсәлән: *Моңқо* (монықы) *исеме дә җуғ инде. Миңк* (минеке) *әти белән аның инәсе бертуған. Аңқы* (аныкы) *кебек җаматай ызба йуқ. Малайы шуңқы* (шуныкы) *читтә тора. Пажалуй, миңке ғыйлемлегем сиңкеннән артығрак* (минеке, синекеннән) һ.б.

Билгеле булганча, *-нықы, -неке* формасы иялек килеш *(-ның/ -нең)* һәм нисбәт *(-қы/-ке)* кушымчаларының кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Ләкин *-ныңқы/-неңке* кушылмасы төрки телләрдә, ул телләрнең фонетик закончалыклары белән бәйле рәвештә, төрлечәрәк үсеш алган. Татар теленең үзенең сөйләшләре дә моңа кызыклы гына мисал булып торалар: әдәби телдә һәм күпчелек сөйләшләрдә *-нықы//-неке;* касыйм сөйләшендә *-ны'ы//-не'е;* нократ сөйләшендә *-нынкысы//-ненкесе;* көнчыгыш диалектта *-ныңқы//-ненке* (ягъни, башлангыч форма). *-ныңқы/-неңке* формасын пермь сөйләшендә дә очратырга мөмкин, тик ул бик сирәк. Мәсәлән: *Минеңке сеңелем бар* (минеке – әд. минем). *Миңке иремнең элекке бичәсенеңке* (бичәсенең) *қызы була. Аныңқы* (аныкы) *аwылда камисийәләре була. Минең үземнеңке* (үземнең) *тормош бик җарлийы. Райун күләмендәге аwылныңқы* (авылның) *зурлығын әйтәм мин. Пиремнеңкеләр* (Пермьнекеләр) *килде тағы да Нәфисәнеңкеләрнең* (Нәфисәнекеләрнең) *урасы җирләре байтак иде әле* һ.б.

Өйрәнелә торган сөйләштәге *-ңқы/-ңке* (*аңқы, шуңқы* һ.б.) формалары ике бертөрле тартык авазларның тартылып кыскаруы нәтиҗәсендә килеп чыкканнар булса кирәк, чөнки алмашлыкларда тамырдагы *н* тартыгының аеруча тотрыксыз булуын югарыда күреп киткән идек инде. Мәсәлән: *мийә* (миңа), *сийә* (сиңа),

*мийән* (миннән), *сийән* (синнән), *мийң* (минең), *сийң* (синең), *шуwың* (шуның) һ.б.

*Миңке. сиңке* һ.б. шундый типтагы тартым алмашлыклары әлегә татар теленең бер генә сөйләшендә дә билгеләнмәгәннәр һәм алар пермь сөйләшенең специфик үзенчәлекләреннән берсен тәшкил итәләр.

Мондый характердагы күренешнең тагын нугай телендә барлыгы билгеле. Мәсәлән, ак–нугай диалектында зат *алмашлыклары менки, сенки, анкъы, бизтки, сизтки, оларткьи* формаларында да очрыйлар.

Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнешендә түбәндәге үзенчәлекләр бар.

Әдәби телдән аермалы буларак, *мин* алмашлыгы иялек килешендә, күбесенчә, *минең* формасында йөри: *Читтә минең қызлар күп. Қумрық минең ишегалдында да бар. Шушында рәдем минең белә қарт бар ийе. Күреште минең белән* һ.б.

*Мин, син* алмашлыклары юнәлеш килештә *мийә, сийә* формасында да әйтелә. Мәсәлән: *Бу мийә* (миңа) *ләкми қалды. Бабай сийә* (сиңа) *дә салыйммы май? Бирнә булғач бир сийә дә, бир мийә* (ягъни, кара каршы) һ.б.

Бу яктан караганда, әлеге үзенчәлеге белән барда төбәге сөйләше татар теленең казан арты дөбъяз сөйләше белән зур уртаклык күрсәтә, билгеле булганча, соңгысында *мийа, сийа* формалары кулланыла.

Беренче һәм икенче зат алмашлыкларының чыгыш килеш формасында да тамыр һәм кушымча ялганган урындагы тартыклар даими рәвештә төшереләләр. Мәсәлән: *Ул тутай була мийә, мийән* (миннән) *олораг ул. Ул сийән* (синнән) *биш йәш оло* һ.б.

Юнәлеш һәм чыгыш килештәге *мин, син* алмашлыкларының әдәби формасы традицион сөйләштә бөтенләй кулланылмый.

Барда төбәге сөйләшендә әдәби телдәге *анысы, монысы, шунысы, кайсы, шушысы* алмашлыклары *ағысы, боғосы, шуғысы, қайсығысы, шушығысы,* формасында да әйтеләләр. Мисаллар: *Тағы буғысына* (бу малаема) *бардым қышқыда. Кайсығысын* (кайсын) *әйтәсез икән ни?. Қурқаwы ағысы* (анысы) *бигрәк тә. Буғысын* (монысын) *ишеткәнем җуқ. Боғысы* (монысы) *күптән башлап җабығ инде. Шуғысы* (шунысы) *йақтырып китсә.... Килен төшкән җир тиләр ағысын* (анысын). *Зур була инде шуғысы* (шунысы). *Тегесе*

*тегеләй, боғысы* (монысы) *болый. Шушығысын әйтәмсең ни* (шушысын әйтәсеңме)? һ.б.

*Ағысы* һәм башка шундый формалар ясалыш үзенчәлекләре белән телебездәге *тегесе* алмашлыгы моделенә туры киләләр.

Күрсәтү алмашлыкларының мондый формалары да пермь татарлары сөйләше өчен генә характерлы үзенчәлек булып торалар һәм сөйләшне әдәби телгә генә түгел, татар теленең башка җирле сөйләшләренә дә каршы куялар.

Күрсәтү алмашлыкларының чыгыш килеш формасы урынны белдергәндә өстәмә *-тын* кушымчасы ала: *Тегеннәнтен* (тегеннән) *кийеwне барыб алалар. Суны шунантын* (шуннан) *ғына алың. Сез қунақлар қайантын* (кайдан) *килдегез. Ул ызба түбән ийе, анантын* (аннан) *мендерделәр. Монантын* (моннан) *тағын қайсы йаққа китәсез?* Шулай ук: *Йырақтын алды әтей, монда ағач йуғыйы элек. Суңынтын үзләре тапшыралар бирнәне.*

Китерелгән мисаллардагы *-тын* кушымчасы тарихи яктан борынгы уйгыр язма истәлекләрендә билгеләнеп үтелгән *-tyn (-lartyn, -larentyn)* кушымчасына барып тоташа. Татар телендә һәм сөйләшләрендә ул астыртын, яшертен, әкертен, эчкәртен, югартын, түбәнтен, бил тиңентен рәвешләрендә сакланып килә.

Барда төбәге сөйләшендә *ул* зат һәм күрсәтү алмашлыгының *а* һәм *о* вариантлары да язылып алынды: *А чақта* (ул чакта) *җүкәдән эшләгән сумка. Бармадыңмы о таба* (< *ул таба* – әд. анда таба). *О таба да чыға торгансыстыр инде* һ.б.

*Ул* алмашлыгының *а* варианты кыргыз, чуваш, лобнор телләренә хас.

Өйрәнелә торган сөйләшне әдәби телгә генә түгел, татар теленең башка сөйләшләренә дә каршы куя торган үзенчәлекле күренешләрнең берсе – зат һәм кайбер күрсәтү алмашлыкларының юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә катлауландырылган кушымчалар белән формалашуы. Түбәндәге мисалларга игътибар итик.

Юнәлеш килешендә: *Аныга* (аңа) *кереп-чыгып йөргән кеше булған. Аның кырлары челтәрле, шуныға* (шуңа) *күрә исем биргәннәр инде. Шуныңа* (шуңа) *сумнық тегәләр дә дүртне, аннар таба тәңкә тезәләр ий. Тулка йуwан агач салабыз аныға* (аңа). *Шуныға* (шуңа) *борчақны саласыз қортмаа. Моноға* (моңа) *қаршы зурырак балалар килеп чыққан да бу йығылған. Минеңә* (миңа) *зур кәрәк. Синеңә* (синңа) *йақшы күлмәкләр биремен.*

Чыгыш килешендә: *Ул минеңән* (миннән) *биш йәш олорақ. Безнең тутай аныңан* (аннан) *алда үлде. Тегенеңнән озур була, чара табақ тибез* (тегеннән). *Боноңан* (моннан) *зур аwыл бар. Шуныңнан* (шуннан) *иләп төшерсәләр қорт анасы өстә қала*.

Урын-вакыт килешендә: *Синеңдә* (синдә) *қайғы йуқ. Моноңда* (монда) *зур урман, қарағайлық. Ана шушыныңда (шушында) үскәмбез* (бишектә)*;* һ.б.

Бу рәвешле төрләнеш татар теленең җирле сөйләшләрендә булмаса да, башка төрки телләрдә очрый. Мәсәлән, башкорт теленең кайбер сөйләшләрендә, лобнор уйгырлары телендә *аныңа, минеңә, һинеңә* формалары теркәлгән.

Сары уйгыр телендә *мениңги (миңа), мениңдин, миннән* һ.б. формалар билгеле. Кыскасы, Барда төбәге сөйләшендәге бик борынгы күренешләр сакланып килә.

**Саннар.** Башка сөйләшләрдән аермалы буларак, Барда төбәге сөйләшендә саннар өлкәсендә дә шактый характерлы диалекталь үзенчәлекләр бар.

1. Төп сан урынына җыю саны килергә мөмкин, ягъни, әдәби телдән аермалы буларак, җыю саннары да аергыч була алалар. Мәсәлән: *Безнең аwылда берәw әби бар* – Безнең авылда бер әби бар. *Икәw қышлаған бозаwы бар* – Ике кышлаган бозавы бар. *Бишәw абзый* (биш абзый) *үлгән сугышта. Хәзер берәw малайы бар, икәw кызы бар* – Хәзер бер малае бар, ике кызы бар.

Мондый күренеш тикшерелә торган сөйләшнең специфик үзенчәлекләреннән берсе һәм бу яктан пермь сөйләше әдәби телдән генә түгел, татар теленең башка сөйләшләреннән аерылып тора.

2. Билгеле булганча, төрки телләрдә саннарның үзләренең саналмышын берлек санда башкаруы гомуми закончалык булып исәпләнә. Татар телендә дә ул шулай. Өйрәнелә торган сөйләштә исә саналмыш күплектә дә башкарылырга мөмкин. Мәсәлән: *Алт уланнарлы* (алты балалы) *бичә ти у.... Кананукадан килә ике малайллар* – Ханнановкадан килә ике малай. *Мин Пиремдә ике қызлар беләтордом* – Мин Пермьдә ике кыз белән тордым. *Биш оланнар беләкалдым ий* – Биш бала белән калган идем.

Күзәтүләргә караганда, саналмышның күплектә башкарылуы ике очракта күзәтелә: а) сөйләштә *уланнар* сүзе бары күплектә генә кулланыла; б) тупланган материаллар бары кешене белдергән саналмышларның гына күплектә башкарылуын күрсәтәләр. Мон-

дый күренеш татар теленең нократ сөйләшендә дә күзәтелә; тагын караим, якут һ.б. кайбер телләрдә дә теркәлгән.

**Сыйфатлар.** Сыйфат төркеме үзенең грамматик формалашуы, синтаксик функцияләре белән, нигездә, әдәби телдәгечә. Бу өлкәдә күзәтелә торган диалекталь күренеш итеп нисби сыйфат ясый торган -*қы*/-*ке* кушымчасының, әдәби тел белән чагыштырганда, активрак кулланылышта булуын күрсәтергә кирәк. Семантик яктан ул, әдәби телдәге кебек үк, әйбернең яки күренешнең нәрсәгә караганын, нисбәтне белдерә. Мәсәлән: *Йақынғы түгел ул, өч айға чыққан шулый сезнең кемек* – Бу тирә кешесе түгел ул, шулай сезнең кебек өч айга чыккан. *Әлисә башлапқысына барасың да инәсең* – Алайса мунчаның беренчесенә барасың да чабынасың. *Артабан (күчеп) киттеләр йақынғы байлар* – Аннан соң бу тирәдәге байлар күчеп киттеләр. *Кара, бездә йырақҡы қызлар бар* – Кара, бездә ерактан килгән кызлар бар. *Беркөннеге* (беркөнге) *хатыннар*. *Сәwит чыққачқы қапқачлы* (совет чорында эшләнгән) *қый шикәр саwытлары*. *Жырақҡы кеше у* – Ерактан килгән кеше ул. *Толбаш искедәңге* (борынгы) *аwыл ул*. *Башлапқы йылда* (беренче елында). *Беркөннеге җийылышта... қалдыққы* (соңгы) *кичегезне кунасыз.*

Сыйфат категориясе үзенең лексик составы белән дә беркадәр үзенчәлекле: анда әдәби телдә булмаган сүзләр күп табыла. Диалекталь сыйфатлар тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләренә карыйлар. Шулай да, аларның зур күпчелеге кешенең рухи халәте һәм физик төзелеше белән бәйле сүзләрне тәшкил итә. Шундыйларның монда кайберләрен күрсәтеп китәргә мөмкин: *апач әпәч* – көяз, матур киенгән. *Апач апалар килгән. Бик әйбәт малай, әпәчләнеп кенә йөри...* (язма эштән); *лыстыр, чылдыр* – теләсә нинди иске, ямьсез, начар әйбер яки күренеш: *лыстыр палас; чылдыр нимә* – иске әйбер һ.б.; *баштақ* – тәртипсез, шаян, башбаштак; *қолақай* – чуқрақ; *менчел* – нәзберек, талымлаучан; *мылҗы* – төче (ялагай кеше тур.); *әҗәме* – булдыксыз; бу сүз Дунай болгарлары телендә дә сакланган; *әшпә* – юаш; җаматай – начар, ямьсез; *җегәрле* – булган, уңган кеше (антонимы – *юньсез*); *сөре* – кире, аз сүзле; *тырқыш* – пычрак һ.б.

Диалекталь сүзләр белән бирелә торган сыйфатларның бер өлеше тагын лексика бүлегендә дә күрсәтелде.

**Фигыльләр**. **Инфинитив формалары.** 1. Пермь сөйләше өчен инфинитивның -*мағa*/-*мәгә* формасы характерлы: *Иптәш*

*қызын апкилгән қунақламаға* (кунарга). *Үдиккә уқымаға* (укырга) *йебәрделәр*. *Қазлар ашамаға* (ашарга) *сорыйлар*.

Инфинитивның -*маға*/-*мәгә* формасы татар теленең борынгы язма истәлекләрендә («Йосыф вә Зөләйха», Мөхәммәдъяр поэмалары һ.б.) дә күзәтелә. Ул татар язма әдәби телендә XX йөзгә хәтле кулланылып килгән. Хәзер бу форма, әдәби норма булып саналмаса да, җирле сөйләшләрдә, аеруча периферияләге сөйләшләрдә, саклануын дәвам итә.

Билгеле булганча, -*маға*/-*мәгә* формалы инфинитив урта диалект сөйләшләренең барысында да диярлек теге яки бу дәрәҗәдә табыла һәм шушы диалект өчен характерлы төп үзенчәлекләрнең берсе булып санала. Димәк, Барда төбәге сөйләше инфинитив формасы белән татар теленең урта диалектына якын тора.

2. Сөйләштә инфинитивның шулай ук урта диалект сөйләшләре өчен характерлы булган -*ма*/-*мә* формасы да күзәтелә. Ул чагыштырмача сирәгрәк кулланыла: *Казаннар итек басма оста булалар ый* – Казаннар итек басарга оста булалар иде. *Сез шунда чоланга йатма йтәмсез* – Сез шунда өй алдында ятмакчы буласызмы? һ.б.

*Ма-мә* формасы да татар теленең урта диалектында шактый киң таралган; чуваш һәм караим телләрендә дә бар.

Килеп чыгышы ягыннан -*ма*/-*мә* формасын тюркологлар борынгы -*маг*/-*мәг* формасының кыскартылган варианты дип карыйлар.

3. Билгеле -*маға*/-*мәгә* һәм -ма/-мә формалары белән бергә, инфинитивның әдәби варианты (-*ырга*/-*ергә*) дә сөйләштә шактый актив кулланыла. Ул, күбесенчә, Казан татарлары теле белән таныш булган кешеләр яки яшь буын һәм интеллигенция сөйләшендә күзәтелә.

**Инфинитивны куллануддагы үзенчәлекләр.** Сөйләштә инфинитивның кулланылыш үзенчәлекләре (синтаксик функциясе, семантикасы, төрле модаль сүзләр белән бәйләнешкә керә алуы һ.б.) бөтен авылларда да бертөсле. Сөйләшне өйрәнү барышында тупланган материлларга караганда, түбәндәге очракларда инфинитив үзенең семантик һәм грамматик функцияләре белән әдәби телдән аерыла:

а) *белү, башлау* сүзләре белән бәйләнешкә керә ала һәм әдәби телдәге -*а*/-*и* формалы хәл фигыльгә туры килә: *Җырламаға белмим* (җырлый белмим). *(Бала) қарамаға белмәсәң* (карый белмәсәң) *йәбешмә*. *Картайдым инде, уланнарның уланнарын күрегә йәбеш-*

*тем (*балаларның балаларын күрә башладым). *Бураны чāып та бетәләр, күтәрмәгә дә йәбешәләр* (күтәрә дә башлыйлар). *Шуннан суң башладылар бәрәңге утыртырға* (утырта башладылар).

б) *Бул* ярдәмче фигыле белән оешкан аналитик төзелмәдә инфинитив әдәби телдәге *-ып*/*-еп* формалы хәл фигыльгә туры килә: *Тырактыр үтәлми, бармага булмый* (барып булмый). *Тым бетә, җүгермәгә булмый* (йөгереп булмый).

Бу үзенчәлеге белән Барда татарлары сөйләше нократ һәм Урал төбәге сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

**Хикәя фигыль.** *-ыр*/*-ер* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльнең I зат берлек формасы *(барырмын, килермен)* кыскартылган рәвештә дә кулланылырга мөмкин *(барым, килерем)*: *Син дә булмагач картупны үзем җийарым* (җыярмын). *Ашарым* (ашармын) *әле, эссе қый*. *Мин сийа ни қайан алып пиререм* (бирермен) *икән инде* һ.б. Бу вакытта тамырлары *р* га беткән фигыльләрдәге янәшә килгән *-ры*/*-ре* еш кына тагын да кыскара: *җийыштырым әле* (җыештырырмын), *керем инде* (керермен), *бирем* (бирермен) *бурычын*.

*Бирем, барым* тибындагы кыскартылган формалар татар теленең күпчелек сөйләшләрендә табылалар.

*-ыр*/*-ер* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльнең юклыгын *-мар*/*-мәр* кушымчасы белән формалаштыру күзәтелә: *Сийә йурған йуқ, қатмассыңмы?* – Сиңа юрган юк, туңмассыңмы? *қатмарым* – туңмам һ.б.

Мондый үзенчәлек урта диалектның тепекәй, тубыл-иртеш диалектының саз ягы сөйләшендә дә бар.

*-ған*/*-гән*//*-қан*/*-кән* формалы сыйфат фигыльгә нигезләнгән нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль, семантик функциясе белән әдәби телдәгечә булса да, төрләнеше ягыннан бераз үзенчәлекле.

Барда урынчылыгында беренче зат системалы рәвештә тартымлы кушымчалар белән формалаша. Мәсәлән: *Урыс телен ничег өрәнәсең, шушығың шикелле үрәнгәнебез* (өйрәнгәнбез) *бит инде*. *Онотқаным көндез қыздырыб эчмәгә* 'Көндез җылытып ашарга онытканмын'. *Кичә белмәгәнебез* (белмәгәнбез) *шу без аны*. *Әнидән сигез йәштә қалғаным* (калганмын). *Кара, мин матур булғаныммы* (булганмынмы) һ.б.

Ә II һәм III затларның сөйләштә бары әдәби формасы гына кулланыла.

**Күптән үткән заман хикәя фигыль** Барда татарлары сөйләшендә категорик үткән заман хикәя фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала: *(барган идем)*. Грамматик күрсәткечләр, сорау кисәкчәсеннән кала, һәрвакыт төп фигыльгә ялганалар. Ә *иде* ярдәмче фигыле, урта диалект сөйләшләрендәгечә, *ийе* формасында йөри һәм, грамматик функцияләре тараю нәтиҗәсендә, сөйләм барышында төрле фонетик күренешләргә (охшашлану, тараю, кушылып китү, кыскару һ.б.) тизрәк бирелә. Мисаллар: *Боларның сумкәсен йастығарағa тығып куйдым ийе* (ястык арасына тыгып куйган идем). *Әле бүген килдегез ийме сез?* – Сез әле бүген килгән идегезме?. *Пенсийәгә күчте генәй әле* (чыккан гына иде әле). *Мин шуны ачытырым тидем и, ачытмадым әле* (әчетермен дигән идем...). *Әйттеләр* (әйткәннәр иде) *иүзләре, сиңә нимә җитми (тора бир) тип*. *Әле байна сүләдем и бит* – Әле бая сөйләгән идем бит. *Әнийең чормап қуйған булд ийе, җоқлап китәр дигән булып* – Әниең төреп куйган булган иде... *Өстеме дә алыштым ый* (алышкан идем)*, бақчаға чығам дип*.

Өйрәнелә торган сөйләш *-ды* + *иде* архаик формасының эчтәеге һәм ясалу юллары буенча урта диалектның тау ягы сөйләшләре белән аеруча зур уртаклык күрсәтә. Бу форманың тагын чистай, сергач һәм, өлешчә, куйбышев мишәрләре сөйләшендә дә барлыгы билгеле. Татар теленнән кала, тагын гагауз, төрек һәм кыргыз телләрендә яшәп килә.

Аналитик формаларда грамматик күрсәткечләрнең төп фигыльгә ялгану күренеше татар теле өчен, шулай ук, чит күренеш түгел. Мәсәлән, татар әдәби телендә аналитик үткән заманнарның өченче зат күплеге *алалар иде, алганнар иде, ала торганнар ид*е формалалрында да ясалырга мөмкин. Диалектларда исә мондый үзенчәлек киңрәк күзәтелә. Мәсәлән: пермь сөйләшендә, байкыбаш *(утырабыз ийе)*, саз ягы, тевриз сөйләшләрендә.

Шунысы характерлы пермь сөйләшендә, шул исәптән барда төбәгендә дә, *иде* ярдәмче фигыле белән булган башка аналитик формаларда да грамматик күрсәткечләрне төп фигыльгә ялгау тенденциясе күзәтелә. Мәсәлән: тәмамланмаган үткән заман һәм реаль булмаган теләк формаларында (аларга аерым тукталырбыз). Нәтиҗәдә, әдәби булган формалар да икенче төрле яңгыраш алалар һәм сөйләшнең үзенчәлеген формалаштыруда зур роль уйныйлар.

**Тәмамланмаган үткән заман** *-а//-ә, -ый//и* кушымчалы хәл фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала: *Элек озур итеп бәлеш пешерәбез ий* (пешерә идек). *Сийә барған чақта икмәк тә пешермәгә белмим и* (белми идем). *Йегерем бишне суғам ийе* (суга идем) *қапны*. *Чанасын сүрәп килә ләп-ләп т'ени белә, без қаз суйабыз ий* – Чанасын сөйрәп килә лап-лоп киез итек белән, без каз суя идек.

*а + иде* формасы һәм анда грамматик күрсәткечләрнең төп фигыльгә ялгану күренеше тагын байкыбаш һәм тубыл-иртеш диалектының саз ягы, тевриз сөйләшләрендә билгеләнеп үтелгән.

Сөйләштә бу форманың катлауландырылган төре дә киң кулланыла: *Киндер кийем кийәйег ий* (кия идек) *җитендән*. *Үз урманыңа барайың* (бара идең) *да кисәйең ийе* (кисә идең). *Җыл да сигезәрне суйайым ий* (суя идем) *әле қаз*. *Без Бардада эшлийег ийе* (эшли идек). *Иреңән ололары булд исә ireңнең ишенә-қушына күренмийең и* (күренми идең). *Бақчаға-мазарға чәчкелийег ийе тарманы* – Бакчага-фәләнгә генә чәчкәли идек киндерне. *Җыл да ат суйайыйғ ыйы* (суйа идек).

Китерелгән мисаллардагы тәмамланмаган үткән заман төшенчәсен белдерә торган *суйайым ий, йаратайым ий, йөрийем ий, эшлийег ийе* һ.б. төзелмәләрнең төп өлешләре үзләре генә дә сөйләм телендә очрый торган *барайык* (< бара идек) тибындагы тәмамланмаган үткән заман формалары булып торалар: *суя идем иде, җата идем иде, йөри идем иде, эшли идек иде* һ.б.

Бу рәвешле катлауландырылган формалар татар теле диалектларының бер генә сөйләшендә дә әлегә кадәр билгеләнмәгәннәр һәм сөйләш өчен специфик үзенчәлекләрнең берсе булып торалар.

Кабатлаулы үткән заман хикәя фигыль, әдәби телдәге кебек үк, *-а/-и* формалы төп фигыль һәм *тор* ярдәмче фигыленең күптән үткән заман формасы белән ясала. Мисаллар: *Чамасыз була торган ий у (җитен)*. *Казаннар безгә кийез итек басмаға килә торғаннар ийе. Шәпиқ бабай мәрхүмкәй әйтә торған ийе...*

Дәвамлы тәмамланган үткән заман тагын *–ыр + иде* конструкциясе белән дә бирелә.

Ә *-ыр + иде* формасы үзенең таралышы чикле булу белән аерылып тора: *Хатыны эшләмәс ий. Қалпақ тегәрләр ийе, монда уқа басқан була торған ийе, тәңкәле қалпақ тийерләр ийе ансын.*

**Теләк һәм ниятне белдерә торган формалар**. Сөйләштә аларның әдәби һәм диалекталь, аналитик һәм синтетик төрләре күзәтелә.

1. Фигыльнең *-асы/-әсе* формасы һәм *килә* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик төзелмә, әдәби телдәге кебек үк, субъектив теләкне белдерә торган төп форма: *Қазаңа қайтасығыз килдеме? Миңке чәй эчәсе килде. Ашасы килми дә минең. Йалан йырақ безнеке, бармасаң барасы килә.*

Билгеле булганча, фигыльнең *-асы/-әсе* формасы һәм аңа нигезләнгән теләк формасы татар теленең урта диалекты өчен характерлы һәм ул әдәби норма буларак та кабул ителгән. Димәк, бу яктан да Барда төбәге татарлары сөйләшенең татар теленең урта диалекы белән уртаклыгы зур.

Кайбер очракларда ия һәм *-асы/-әсе* формалы инфинитив затта, санда үзара ярашмаска, ягъни, алардагы нисбәтлек һәм иялек кушымчалары төшеп калырга да мөмкин: *Шуннан утырыб ашыйсы киләйе миңке* – Минем шунда утырып ашыйсым килә иде. *Алар җөгерәсе дә килми* – Аларның йөгерәселәре дә килми. *Мин тагы шун әйтәсе килә* – Минем тагын шуны әйтәсем килә. *Соң безнеке дә ликсийә тыңнасы килә* – Соң безнең дә лекция тыңласыбыз килә һ.б.

2. Ният, исәп итү һәм эчке теләк әдәби телдә *-макчы/-мәкче* формалы фигыльләргә нигезләнгән була. Тикшерелә торган сөйләштә исә, бу форма сирәк кулланыла, аны бары зыялылар һәм, кайбер очракларда, яшь буын телендә генә очратырга мөмкин. Бу форма сөйләштә түбәндәге аналитик конструкцияләр белән алыштырыла.

а) инфинитив һәм *итә* ярдәмче фигыле: *ашамаға итәсезме?* – Ашамакчы буласызмы?. *Әллә сез дә имнәмә итәсезме?* (әллә сез дә имнәмәкче буласызмы?. *Эченә кереп қарарға итә икән* (карамакчы була) *ул*. *Мин күлмәкчән генә чықма итәм* (чыкмакчы булам) һ.б.

Инфинитив + *итә* аналитик төзелмәсе ният белдерә торган төп форма булып тора. Мондый үзенчәлек татар теленең башка сөйләшләрендә дә бар.

б) Киләчәк заман хикәя фигыль һәм *ди* фигыленең үткән заман формасы *иде* ярдәмче фигыль белән берлектә килеп, шулай ук ниятне, тик инде үткән заманга караган ниятне белдерә. Бу конструкция, күбесенчә, беренче затта күзәтелә: *Мин отпуска чуттан сүләрем тидем эй* – Мин отпуск турында сөйләшмәкче булган идем. *Теге йағын да сырларым дийем и* – Теге ягын да буямакчы идем. *Әқлимәдән сорарым дидем и* – Әклимәдән сорармын дигән идем һ.б.

в) Әдәби телдәге *барасы бар, киләсе бар* формалары Барда төбәге татарлары сөйләшендә сирәк кулланыла, ул инфинитив + *кәрәк була* тезелмәсе белән алыштырыла: *Төзәттерергә кәрәк була йе* – Төзәттерәсе бар иде. *Суғa барамсы ни, йазынырға кәрәк була бит сийә* – Суга барасың мыни, язасың бар бит синең. *Чымылдық йасарга кәрәк була* – Чыбылдык ясыйсы бар. *Қаймақ туқыма кәрәк була йы, май җуқ* (май юк, май язып аласы бар). *Wахыт җуқ, өстәл сырламаға кәрәк була йе* – Вакыт юк, өстәл буйыйсы бар иде. *Тегесенеке энәсе кәкерәйгән ийе, шуны төзәтмәгә кәрәк була йы* – Тегесенең энәсе кәкерәйгән иде, шуны төзәтәсе бар иде. *Сәқиб абзый үдә йуқмы, сарық суйма кәрәк булайы* – Сәхип абзый өйдә юкмы, сарык суясы бар иде һ.б.

3. Сөйләштәге реаль булмаган теләк (Д.Г. Тумашева терминологиясе буенча шартлы теләк) формасы әдәби телдән бары грамматик күрсәткечләрнең күпчелек очракта төп фигыльгә ялганган булуы белән генә аерылып тора: *эчсәм әйтмәсем ий* (әйтмәс идем) *әле сийә*. *Миң кечкенә булмасам, хәтерләрем ий* (хәтерләр идем) *дә суң аларны*. *Миңке шундый таwыш булса, йырлап кына йөрем ийе* (йөрер идем).

4. Кушу аркылы киңәш итү төшенчәсе сөйләштә боерык фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән белдерелә. *Хәйбә тай, син бер сүздән туқтат ий* (туктатырга иде) *аны*. *Сез тығып қуйың ий* (куярга иде) *т'әғаҗегезне*. *Майлап йебәр ийе* (җибәрергә иде). *Син сату ит ий, эчмә ийе, туры өйгә кайт ый, акча китереп бир ий* – Син сату итсәң икән, эчмәсәң икән, туры өйгә кайтсаң икән, акчаңны китереп бирсәң икән... *Читег алып килең ий сез,* (алып килергә иде) *қайған читек*.

Кайбер очракларда шушындый ук функциядә *кирәк* модаль сүзе белән берлектә *-у/-ү* кушымчалы исем фигыль яки *-ма/-мә* формалы инфинитив килергә мөмкин. Мондый очракларда логик ия билгесез килештә башкарыла яки җөмлә иясез була: *Туп-туры безгә килү кәрәг ий сез* – Сезгә туп-туры безгә килергә кирәк иде. *Җәй көн килмә кәрәг икә сез урман қырына* – Урман буена җәй көне килергә иде сезгә. *Боларны кертү кәрәкми икә, аңгай мине сүлиләр. Монда тешү кәрәкмәс иде сез* – Монда төшмәскә иде сезгә һ.б.

5. Көчле эмоцияле теләк, әдәби телдәге кебек үк, шарт фигыль яки өченче зат боерык фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик форма ярдәмендә белдерелә: *Минең өч қарт йата*

(ягъни үлгән), *ичмасам берсе генә қайтсын ийе. Их, утыз йәшлек чақлар булса йкән, диб әйтеп қуйабыз. Бийек тауға менгән чақта, Таймас табан булсайде, Сезнең белән утырғанда, Таң атмас кич булсайде* (халык җыры).

6. Болардан башка, өйрәнелә торган сөйләштә теләк, исәп итү, ният төшенчәләрен белдерә торган, чагыштырмача сирәк кулланылышта булган түбәндәге аналитик конструкцияләрне, әйләнмәләрне күрсәтергә мөмкин: *Анда саwыт-сабаны җумаға бар ый* (юасы бар иде). *Гелби, монда чығ әле, киңәш итәремә бар* (киңәш итәсем бар)*, ти*. *Илә көнне* (Ильин день) *Сайысқанға* (авыл исеме) *китәргә булдығ ый, бал ашарға. Менә бу бичәкәй өмөҗегә* (кура җиләге) *барыға йөри шай* һ.б.

Күргәнебезчә, сөйләш нәрсә дә булса эшләргә теләүне яки ниятне, исәп итүне белдерә торган төп формалары белән әдәби телдән, нигездә, аерылмаса да, анда тагын үзенчәлекле генә теләк әйләнмәләре һәм күп төрле аналитик яки лексик-морфологик ысуллар да табыла.

**Боерык фигыльләр.** Боерык фигыльнең икенче зат күплеге *-ың/-ең/-ң* кушымчасы белән ясала: *дару ашаң* (ашагыз) *сез җаңа чағында*. *Сез җатып җоқлаң* (йоклагыз)*, мине көтмәң* (көтмәгез). *Мийә танытың* (танытыгыз) *әлә, кемнәр сез*. *Теендә кунихта карап китең* (китегез) *сез аны, шақ қатарсыз*.

Күзәтүләргә караганда, *-ың/-ең/-ң* формалы фигыльләр берлек санда да кулланыла. Бу, аеруча, катгый кушуны, үтенүне белдергәндә яки чит кешеләргә хөрмәт белән мөрәҗәгать иткәндә булырга мөмкин. Шулай ук, балаларга кисәтү ясаганда яки олы кешеләр яшьләргә эндәшкәндә дә шушы ук форманы әйтү очраклары күзәтелә: *Инде син кийеп қараң. А̄й* (< алай) *булса мине қалдырмаң әле, Сәкинә. Төшөң анан тын! Иршемәң* (үчекләмә) *аны* һ.б.

Өйгә яшүсмер яки мәктәп яшендәге бала килеп керсә, аңа гадәттә *«Әйдәң, утырың», «Түрдән үтең»* дип эндәшәләр.

*Ди* тамырыннан ясалган боерык фигыль, күбесенчә, диалекталь формада була: *Қурқам җыландан диң. Йуғ әле дийең, қызым* һ.б.

Өндәүне, кушуны белдерү өчен кулланыла торган *йә, әйдә, мә* кебек сүзләр дә икенче зат күплектә *-ң* кушымчасы белән формалашалар: *Йәң балалар, ашый башлаң. Әйдәң, қайтыйғ әле без дә. Мәң әле, алың* һ.б.

Икенче зат боерык фигыльне *-ың/-ең/-ң* кушымчалары белән формалаштыру татар теленең, нигездә, Урал тирәсе сөйләшләрендә таралган Башкортстан территориясендә, Курган өлкәсендә, Көнбатыш Себердә яшәүче татарлар телендә табыла. Семьядаш төрки телләрнең дә күпчелегендә икенче зат күплектәге боерык фигыль шушы форма белән бирелә, мәсәлән, төрекмән, төрек, якут, казакъ, уйгыр, тува һәм хакас, гагауз телләрендә, кыргыз, башкорт һәм үзбәк телләренең кайбер сөйләшләрендә.

Икенче зат күплектәге боерык фигыльне *-ың/-ең/-ң* кушымчалары белән формалаштыруның үрнәкләрен борынгы татар әдәбиятыннан да китерергә мөмкин:

*Йосыф әйде: «Йә кардәшләр! Боны кылмаң*
*Шәйтан сүзенә гомраһ улып, аңа оемаң,*
*Бәнем тәнем горьян кылып, туным суймаң*
*Ата хакын, кардәш миһрен саклаң имди.*
*(Йосыф вә Зөләйха)*

*Варың сезләр ул кордый эстәң, тотың,*
*Тотубән, ул кордый бәңа алып кәлең*
*Ушбу сүзә җемләңез мәтыйг улың...*

Орхон-Енисей һәм V–XIII гасырларга караган Көнчыгыш Төркестан язма истәлекләрендә бу кушымча, нигездә, хөрмәтләп эндәшү формасы булып йөртелгән.

**Хәл фигыль формалары.** 1. *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык формасы *-мый/-ми* (монысы сөйләштә иң актив кулланылыштагы вариант), *-мыйча/-мичә, -мыйынчы/-мийенче* кушымчалары белән ясала: *Белми үкенгәнче, белеп үкенерсең. Картуп җыйып бетми эш бетмәс инде. Барып қайтмый ярамый. Аwыл җирендә эшләмичә ничек торасың? Бәрәңгене қажҗамийынча ашқа турамыйлар. Үлән чықмыйынча сөрергә йарамый икенче қабат. Сүли торган нимә алдыңа килмийенчә қалмый у.*

*-мыйнча/-мийнча, -мыйынчы/-мийенче* формалары белән сөйләш урта диалектның минзәлә, бөре сөйләшләре, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектлар белән уртаклык күрсәтә.

Семантик функцияләре белән югарыда күрсәтелгән формалар әдәби телдән аерылмыйлар: 1) төп эш белән параллель яки бер үк вакытта һәм 2) төп эштән алда үтәлә торган эшне белдерәләр. Соңгы функциядә *мый/-ми* кушымчалы хәл фигыль еш кына *торып*

ярдәмче фигыле белән бергә килергә мөмкин: *Урын әзерләми тороп бер җирдә дә бура күтәрә алмыйсың. Балалары ашамый тороп үзе ашамый. Матча менми тороп пыталук салып булмый. Элек моллалар кәбен* (никах) *уқымый қыйышалар ийе, унсигез тулмый тороп* һ.б.

2. *-ғанчы-гәнче* формасының *-ганчи/-гәнчи* төрдәшенә югарыда туктап үткән идек. Сөйләштә аның икенче синтетик формасы *-мастан/-мәстән* кушымчасы белән ясала: *Пешмәстән үзе ачы булаwы* – Пешмәс борын үзе ачы була ул. *Миңке җуғалмастан алчеприк бар ийе* – Минем югалмас борын алъяпкычым бар иде һ.б. Мондый форма мөстәкыйль рәвештә сирәк кулланыла.

Болар белән беррәттән, киләчәк заман хәл фигыль әлеге синтетик заманнарга нигезләнгән күп төрле аналитик конструкцияләр белән дә бирелә ала.

а) *-мас//-мәс + боро(н): Бу эшләр ни сугыш чықмас боро булды wы. Бу хәлләр чықмас борондан ике йөз дум ийе аwыл* һ.б.

б) *-мастан//-мәстән + борон, элек*: *Элекке wақытта җир булмәстән борон атала йы гинәч* (кенәз) *тип. Печингә төшмәстән элек себертәбез ий җирне агач тырма белән* һ.б.

в) *-ғанчыға, -ғәнчегә* + бәйлек: *Учител буғанчыға қәдәр уқып, Қарманда тордо. Йаратамы-йаратмыймы торалар ийе үлгәнчегә қадәр. Армиягә киткәнчегә эшләде қый* һ.б.

3. Үткән заман хәл фигыль әдәби *-гач/-гәч* һәм аның фонетик варианты *-ғас/-гәс* кушымчалары белән беррәттән, *-гач(с)ын, -гәч(с)ен, қач(с)ын/-кәч(с)ен, -ғачтын/-гәчтен, -қачтын/-кәчтен* формалары белән дә ясалырга мөмкин. Семантик яктан бу формалар, әдәби телдәге кебек үк, төп фигыльдән аңлашылган эш һәм хәлләрнең үтәлү сәбәбен яки шартын һәм вакытын белдерәләр. Мисаллар: *Унны беткәсен қый Асада* (Оса шәһәре) *уқыды. Җул өсте булғачын да оланнар да кереб апчығып китәләр аны. Чәчкәчтен тырматабыз җирне. Туғаннан туған була әтиләр бер туған булғасын* һ.б.

Бу формалар татар сөйләшләрендә киң таралган.

**Сыйфат фигыльләр.** Хәзерге һәм үткән заман сыйфат фигыльләрнең ясалышы һәм аларның семантик функцияләре белән Барда төбәге сөйләше әдәби телдән аерылмый. Диалекталь күренешләр, киләчәк заман сыйфат фигыльләр өлкәсендә күзәтелде.

Билгеле булганча, бу төр сыйфат фигыль әдәби телдә өч төрле кушымча ярдәмендә формалаша: *-ыр/-ер/-р, -асы/-әсе* һәм *-ачак/*

*-әчәк*. Пермь татарлары сөйләшендә исә *-ыр/-ер/-р* формасы доминант форма булып тора. Формаль яктан бу форманың ясалышында әдәби телдән аерма булмаса да, аның семантик функциясе әдәби телдәгегә караганда киңрәк.

1) Әдәби телдәге шикелле үк, предметларның хәзергә караган билгесен һәм даими сәләтен белдерә: *Эләр җир тапмадым, тышта әйбәт қорый да суң кер. Әз булса да ақча керетер йирен уйлый бит ул. Ашлық төйәр нимәне пычыратып қузофқа төйәп аны, бер атқа төйәр аламаң бар* һ.б.

2) Шуның белән бергә, бу форма, әдәби телдән аермалы буларак, һичшиксез үтәлергә тиешле эшне белдерү өчен дә актив кулланыла, ягъни модаль мәгънә – тиешлек мәгънәсе ала һәм әдәби телдәге *-асы/-әсе, -ачак/-әчәк* формалы сыйфат фигыльгә туры килә. Мәсәлән: *Өчәр йөз митыр қазар* (казыйсы) *җирләргә тырактыр бирергә тиешләр. Ул малайның быйыл әрмийәгә китәр җылы* (китәсе елы). *Сыwға китте берәw қыз бала, беренчегә керер кыз* (беренчегә керәсе кыз) *ийе. Зифа, кил, утыр, йаса чәй, миңке тышқа чығар эшем* (чыгып эшлисе эшем) *бар. Айаз булыр* (буласы) *булса, салаwат күпер қороға төшә, шуңан беләсең аны. Инде у кичне мин бер дә уйламыйм кийәwгә чығарны* (чыгасың). *Мәсә күрерне* (күрәсен) *белеп булмый. Кем-кемгә килере* (киләсе) *кемнең исендә, уйында. Әйтереңне* (әйтәсеңне) *үзең әйтәсең инде, үзең алғач. Без аның килерен* (киләсен) *белдек, сүләшмәдег аннар таба*.

3) *-ыр/-ер/-р* кушымчалы сыйфат фигыльнең тартымлашкан формасы *бар* сүзе белән килгәндә шикләнүне, куркып саклануны, шөбһәләнүне белдерә һәм әдәби телдәге *-уы, -үе + бар* (мәс. *егылуы бар, төшеп китүе бар*) аналитик формасына туры килә: *Азаланып* (азып) *китәре бар* (китүе бар) *аның*.

Күргәнебезчә, *-ыр/-ер/-р* формалы сыйфат фигыльнең кулланылыш сферасы, әдәби тел белән чагыштырганда, шактый киң. Бу исә үз чиратында *-асы/-әсе* формасының сыйфат фигыль буларак чагыштырмача сирәк кулланылуына китерә.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, сөйләштә *-асы/-әсе, -ачак/-әчәк* формалары сирәк кулланылалар. Соңгы форма, аеруча *ал, бир, күр* тамырларыннан ясалган сүзләрдә исемләшкән хәлдә генә күзәтелә: *Бар икән күрәчәкләр. Йарар, алачак булса, бирәр қайчан алырбыз әле. Алачағым җуқ, бирәчәгем җуқ. Бабай сийә бирәчәк бар ийе* һ.б.

**Юнәлешләр өлкәсендәге үзенчәлекләр.** Аларны ике төркемгә бүлеп карага мөмкин.

1. Юнәлешләрне формалаштыру. Монда кайбер архаик кушымчаларның киңрәк кулланылышта булуы күзгә ташлана. Икенчедән, бер үк фигыль бер үк юнәлештә төрле кушымчалар белән ясала ала.

Йөкләтү юнәлеше, нигездә, әдәби телдәгечә, ягъни *-дыр, -тыр, -қыр, -кер, -ғыз, -гез, -т* кушымчалары һәм аларның фонетик вариантлары ярдәмендә формалаша. Ләкин кайбер кушымчалар, әдәби тел белән чагыштырганда, киңрәк сферада табыла. Мәсәлән, бер төркем фигыльләрдә *-тыр, -тер, -дыр, -дер* кушымчасы урынына архаик *-қыр, -кер, -ғыр, -гер* кушымчасы кулланыла. Бу күренеш түбәндге фигыльләрдә күзәтелә: *басқыр* – бастыр, *Барда җийында* (сабан туенда) *чүлмәк wатқырдылар ырды* – тарттырды.

*Үсү* фигыленең йөкләтү юнәлеше даими рәвештә *үскерү* формасында йөри: *Кызымныңы малайы ғына у, шуны қараб үскердек. Үксез генә қараб үскәрд ийе инәсе.*

Тамырлары *з* авазына беткән фигыльләрнең йөкләтү юнәлеше, әдәби телдән аермалы буларак, күбесенчә, *-ғыр-гер* кушымчалары белән формалаша: *сизгерми* – сиздерми, *күздән йазғыру* – күздән яздыру, *бизгерү* – биздерү, *узғыр* – уздыр, *Ишег алдым йәшел үлән, Кошларны қунақлатам; Қунақлатам бизгермимен, Сагынам, сизгермимен* (халык җыры).

*Аудару* сүзе даими рәвештә *аwдыру* дип әйтелә: *Кара, аwдырып қуйды бутылкамны. Менә монда нийә таш аwдырмыйлар микә, машиналар батып йатадыр әле шунда* һ.б.

*Кидерү, меңгерү, җиткезү* сүзләренең йөкләтү юнәлеше төрле формада булырга мөмкин, мәсәлән: *меңгерү//меңгезү//мендерү, кийерү//кийертү//кидерү* һ.б.

2. Әдәби телдәге төп юнәлешнең сөйләштә башка юнәлеш формасы белән бирелүе.

а) Бер төркем фигыльләр билгеле грамматик шартларда даими рәвештә кайтым юнәлеше формасында кулланылалар: *йазыну* – язу, *ашану* – ашау, *эченү* – эчү, *чигенү* – чигү, *бәйләнү* – бәйләү, *тегенү* – тегү, *үтүкләнү* – үтүкләү һ.б. Мисаллар: Монсо да бәйләнде, *Гәрәмәчидәгесе генә бәйләнмәде* – Монысы да бәйләде (челтәр), Гремячийдагысы гына бәйләмәде. *Сөтегезне тотоныйммы тағы* – Сөтегезне тагы тотыйммы?. *Тулкы күтәренмә ти, бик шәп урныққан булған сүwәгең, ди* – Тик әйбер күтәрмә, ди, сөягең

биртелгән көе нығыган булган, ди. *Син тотонор ақча йуқ, ти. Йазыну хәтәр эш, күзләрегез аwыртып бетә дә* – Язу читен эш, күзләрегез авыртып бетә лә. *Әле җықлап йатқанда да йазыналар ий, тордый, тағы йазына* – Әле йоклап ятканда язалар иде, торган иде – тагын яза. *Сез аңғай монда килгәндә генә ашанасызмы?* – Сез нәкъ монда килгән вакытта гына ашыйсыз мәллә?) *Ишегалда җилгәренеп* (җилгәреп) *җерибез шулай. Бик шәп ағынып* (агып) *җатты, бөтен җире шеш булып. Тегенмәгә белә* (теге белә), *машинә йуқ. Тегенмәгә генә килеп чықтылар ий бу җаққа, шунда тороп калдылар, монда әйбәт өчен. Алар ашана торғач та йазынмаға йәбешәләр. Бәйләнмәгә белмийем* (бәйләү эше белмим) *ий алый. Өwдә, ди, әле, үтүкләнә ти* (кер үтүкли). *Бик шәп чигенә йе миңке қыз бала* – Каенсеңлем бик күп чигә иде һ.б.

Күзәтүләргә караганда, мондый очракта фигыльләр күчемсез булалар һәм алар кешенең гомуми эшен, шөгылен белдерәләр, ә эшкә дучар булган әйбер анык билгеле түгел, сүз бары ниндидер эш төре турында гына бара. Кешенең конкрет бер әйбер эшләве турында сөйләнсә, җөмләдә тәмамлык та (эшкә дучар ителгән әйбер) аталган була һәм фигыльләр, әдәби телдәгечә, төп юнәлештә әйтеләләр. Мәсәлән: *Әнә у қашағанықын* (челтәр) *да ул бәйләде, бәйләнә йе у* (кызы турында сүз бара) *шулай теләсә мәстә.* Соңгы мисалда кайтым юнәлеше формасындагы фигыльнең семантик үзенчәлеге бигрәк тә ачык күренә. Шуңа күрә дә, *ашану*, *үтүкләнү*, *тотыну* кебек формаларны әдәби телдәге төп юнәлеш белән янәшә куярга һич тә ярамый.

Күрсәтелгән үзенчәлек ягыннан өйрәнелә торган сөйләш аеруча көнчыгыш диалектлар белән уртаклык күрсәтә, тик соңгысында мондый күренеш киңрәк күләмдә күзәтелә.

б) Түбәндәге фигыльләрдә әдәби телдәге төп юнәлеш төшенчәсе йөкләтү юнәлеше формасы белән белдерелә: *җығыту* – егу, *алдату* – алдау. Мәсәлән: *Алдатмасын ул кешене, алдатып җийа ул.*

в) Төп юнәлеш урынында уртаклык юнәлеше килү: *Җән баштағысы әтнә сайы тулышып аға* (шеш) һ.б.

г) Киресенчә, әдәби телдә кайтым, йөкләтү юнәлешләре формасында урнашып калган һәм хәзер инде тамыр фигыльләр рәтендә карала торган фигыльләр сөйләштә төп юнәлеш формасында кулланылалар. Мәсәлән: *Самыwар суwып* (әд. суынып) *бетә. Үрә суwый* (суына). *Сигезне генә бетте* (бетерде) *микән у. Сәли ағачка*

*асылдым да* (асылындым да) *шушылай, ҡарап тик торам. Ул үзе очраған Җағорны* (Егорны ул үзе очраткан).

Юнәлешләрне шушы рәвешле алмаштырып куллану очраклары татар теленең башка сөйләшләрендә дә очрый.

**Фигыльләрдә сорау кисәкчәсенең кулланылышы.** Әдәби телдән аермалы буларак, II зат хәзерге һәм *-ыр/-ер* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльләрдә сорау кисәкчәсе турыдан-туры фигыльнең тамырына ялгана. Мәсәлән: *Тыныґыб аламсыз?* – Ял итеп аласызмы?. *Тәләсне беләмсез?* – Тәләсне беләсезме? *Алма шийымсың?* – Алма ашыйсыңмы? *Сез бозауларны ҡарамийымсыз* (карамыйсызмы)?. *Йомролата пешеремсез күкәй* – Йомырканы йомры килеш пешерерсезме?

*-мы/-ме* сорау кисәкчәсенең зат кушымчаларыннан алда килү очраклары борынгы татар әдәбияты әсәрләрендә дә бар. Мәсәлән: – *И шәкертем! Беләрмүсән сәне бу йиргә нә мәгънә өчен кәлтердем?* (Нәһҗел фәрадис). Яки:

*Әйди: и мәрд, балыкың сатгаймысән,*
*Балык биреп, бу җепне алгаймысән.*
*(Төхфәи мәрдан).*

*Дидем аңа: болай канда кидәрсән?*
*Диде: белмәзмүсән, нигә сорарсән?*
*(Утыз Имәни).*

Сорау кисәкчәсен турыдан-туры фигыльнең тамырына ялгау үзенчәлеге хәбәрлек кушымчаларының чагыштырмача соңгырак чорда формалашуын раслый торган күренеш.

***Кирәк* модаль сүзенең кулланылышы**. Билгеле булганча, *кирәк* модаль сүзе әдәби телдә грамматик яктан ярдәмче фигыльләр белән генә формалаша. Барда төбәге сөйләшендә исә, ул фигыльгә хас кушымчалар (зат, сан, заман һ.б.) ала: *кәрәкте, кәрәккәч, кәрәксә, кәрәгә, кәрәгер* һ.б. Мисаллар: *Аҡча лґанда ыwаґ аҡча кәрәгеп* (кирәк булып) *китә. Wаҡ-түwәккә кирәгер* (кирәк булыр). *Йоморҡа кәрәкт исә* (кирәк булса) *хәзер шунан тырнап ҡына алалар айаґ арадан. Мә! Кәрәккәч* (кирәк булгач) *алып җийасың шифырын да.*

*Кирәк* модаль сүзен кулланудагы мондый үзенчәлек көнбатыш диалект өчен характерлы булган күренешләрнең берсе.

**Рәвешләр.** Барда төбәге сөйләшендә, гомумән пермь сөйләшендәге кебек үк, рәвеш категориясе шактый үзенчәлекле булуы белән

аерылып тора. Бу өлкәдә табыла торган диалекталь күренешләр, аеруча, рәвешләрнең ясалышы белән бәйләнгән.

1. Сөйләштә актив кулланыла торган рәвеш ясагыч кушымчалардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин.

*-лай//-ләй//-лей//-ли*. Бу кушымча беркадәр әдәби телдә дә кулланыла, ләкин сөйләштә аның аеруча актив булуы күзгә ташлана. Ул исемнәргә, сыйфатларга кушылып, шулардан аңлашылган билгенең үз хәлендә калуын белдерә торган рәвешләр ясый, ә саннарга кушылганда әдәби телдәге *тапкыр, мәртәбә* кебек сүзләргә туры килә. Мисаллар: *өченчелий* (өченче тапкыр) *мин әйтәм*; *иңечелий* (икенче тапкыр). *Икенчеләй* (икенче тапкыр) *барасы килми у*. *Мунча иңгән чақта җалаңғачлый* (ялангач килеш) *төшеп алам ийе су*. *Ашаң җылылый* (җылы көе), *шәңгә суwығач тәмсез була*. *Саwған сөтне чечелий* (төче көе) *ойотоп та эчәләр*. *Йәшләй* (чи көе) *суқмадық без, әwендә суқтық (ашлыкны)*. *Серемний* (сөремле көе) *кермибез мунчаға*. *Гөлбәдийәне теләсә нинди қатын пешерә алмый, аны тиклий* (бушка) *пешермиләр. Чөрәли кәртәләгән* (әйләндереп, тирә-ягын). *Мин эселей* (эссе көе) *ашаб алдым кәртүкне* һ.б.

*-лата/-ләтә.* Бу кушымча да исемнәргә һәм сыйфатларга ялганганда югарыда карап киткән *-лай/-ләй* кушымчасы белән бертөсле функцияне башкара, ә *берләтә бер* сүз тезмәсендә әдәби телдәге *бердәнбер* сүзенә дә туры килергә мөмкин: *Берләтә бер баласын анасыннан айырып кеше шулай җибәрми инде. Самыwар суwыған да суwықлата эчтек* (суык көе). *Анда Пиремдә* (шәһәр исеме) *ипиләтә бит, онната сатмыйлар. Элек йер пирейезләтәйе, диктарлата түгел ийе.*

*-ча/-чә: Боларның безнекечә ақ тегел. Сезнеңчә – пич баш, минеңчә пич түбә. Элекке кеше үзечә иген игәде, үзечә суқасын сөрде* һ.б.

*-ын/-ен.* Семантик функциясе белән бу кушымча да әдәби телдән аерылмый, тик аның кулланылышы бик чикле, чөнки сөйләштә вакыт рәвешләре, күбесенчә, *-қы/-ке* кушымчалы нисби сыйфат формаларына нигезләнәләр һәм ике төрле юл белән ясалалар.

а) Урын-вакыт килеш кушымчалары ярдәмендә: *қышқыда, язғыда, җәйгедә, көзгедә, кичкедә*. Мисаллар: *Көзгедә* (көз көне) *сатам аны*. *Чикерткә кебек сайрарсың арта қышқыда* (кыш көне яки кышын). *Йазғыда май чичласында абийымны барып җийдым* (яз көне яки язын). *Барып керәбез кичкедә* (кич белән), *ут қабызғач*.

Бу формалар нисби сыйфатларның аерылмыш кушымчаларын үзләренә алып исемләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Алар сөйләштә иң актив кулланыла торган, әлеге сөйләш өчен гомуми характердагы формалар булып торалар.

Икенчедән, Барда төбәге, гомумән пермь сөйләше мондый формадагы рәвешләр белән, әдәби телдән генә түгел, татар теленең башка күпчелек сөйләшләреннән дә аерылып тора, чөнки күрсәтелгән үзенчәлек, нигездә, бары көнчыгыш диалектларга гына хас.

Кайбер очракларда урын-вакыт килеш кушымчасы абстракт мәгънә белдерә торган *-лық*/*-лек* кушымчасыннан соң килә: *Җәйгелектә* (җәй көне) *урамдан уссам, йаннарына утырып сүләшеп китәм*. *Хәзер кәнүшнәй тиләр қышқылықта* (кыш көне) *мал йаба торғанны, мүкләп* һ.б.

Билгеле булганча, урын-ара килешләре урын һәм вакытны, төрле хәлләрне белдерүләре белән рәвешкә бик якын торалар, урын-вакыт килеше формасындагы вакыт рәвешләренең башка төрки телләрдә яки аларның сөйләшләрендә дә киң таралган булуы, һичшиксез, шуның белән аңлатыла да. Ә *қышқыда, кичкедә* тибындагы специфик формалары белән тикшерелә торган сөйләш ойрот, шор, хакас телләре белән зур уртаклык күрсәтә, ягъни, көнчыгыш диалект аша алтай телләренә барып тоташа.

б) Икенче форма вакыт рәвешләре *-қы*/*-ке* кушымчалы нисби сыйфатларның тартымлы формасына югарыда күрсәтелгән *-н* /*-ен* кушымчасы ялганып ясалалар. Мәсәлән: *Кәкүк йазғысын* (язын) *ғына чақыра да туқтый*. *Кичкесен* (кичен) *алтыда ача кибетне*. *Җәйгесен* (җәен) *эшлибез, хәттин ашқан атлар*.

Бу төр формалар, шулай ук, татар теленең бары көнчыгыш диалектларында гына билгеләнеп үтелгән.

Тикшерелә торган сөйләш бу яктан да алтай телләре (шор, хакас, кыргыз) белән зур уртаклык күрсәтә.

2. Дәвамлы вакытны белдерә торган рәвешләр дә сөйләштә берничә ысул белән ясалалар.

а) Әдәби телдәге кебек үк, *буе* сүзе белән ясалган *кыш буе, җәй буена, төн буена, көн буе, төн буе* тибындагы формалар. Бу иң актив кулланыла торган конструкция. Шуның белән бергә, *буе* сүзе, нинди килеш формасында килүенә карамастан, үзе бәйләнеп килә торган вакыт рәвешләрен иялек килешендә башкарырга мөмкин, ягъни ул үзенең мөстәкыйльлеген азмы-күпме саклап килә.

Мәсәлән: *Дүрт көннең буйына чаташа да чаташа. Җәйнең буйына шапир булыб эшләде. Бирмәдә* (фермада) *бер бозаw үтермәдем ун җылның буйына. Көннең буйына биг үк йәмсез җил булды. Без көннең буйы пелмин йасап пычраб йаттық қый. Кичә көннең буйға үдә булды да суң.* Бу соңгы мисалда сөйләшкә хас тартымсыз изафәне күрәбез.

б) Дәвамлы вакыт белдерә торган рәвешләр *кыш, көз, яз, җәй* сүзләреннән синтетик юл белән дә ясалырга мөмкин: *қышлый, җәйли* һ.б. Мисаллар: *Алар икесе қышлый* (кыш буе) *көрәштеләр, бетекийе җиңә. Йазлый* (яз буе) *чирләдем. Сыйыр суйдық, қышлый* (кыш буе) *ашадық. Сосонны җәйли* (җәй буе *ашамаға суйасың аны*).

в) *Төн* сүзенең *белән* бәйлеге белән берлектә ясалган сүз тезмәсе бик актив: *Төне белә* (төн буе) *йоқлый алмадым. Көндез урабыз, төне белә суғынабыз ий суғыш wахытта* һ.б. Мондый күренеш Себер ареалы татар сөйләшләрендә дә бар.

г) Дәвамлылыкны белдерә торган вакыт рәвешләренең өйрәнелә торган сөйләштә *озын* сүзе белән оешкан конструкцияләрен дә очратырга мөмкин: *Көн озон буйларына чәйләр эчәлмисең. Көн озонона җоқлады. Төн озонда никадәр печән чабарлар ийе* һ.б.

д) Дәвамлы вакытны белдерә торган рәвешләр әдәби телдәге *көне-төне* тибында да ясалалар: *Көне-төне эшләде, җәйе-қышы ит ашыйлар, киче-көндезе йулны арчып торалар, қышы-җәйе шуннан эчәбез* һ.б.

Күргәнебезчә, сөйләштә тартымлы вакыт рәвешләрен кабатлау юлы белән дәвамлы вакыт белдерү киңрәк сферада табыла.

3. Рәвеш дәрәҗәләре, аларның төрләре һәм ясалышлары белән бу сөйләш әдәби телдән аерылмый. Тик кайбер очракларда чагыштыру дәрәҗәсе икеләтелгән кушымчалар белән формалашырга мөмкин, Мәсәлән: *Мыча кергән сайын көй дә тизерәгрәк* (тизрәк) *китәр, кечерәгерәк, азырағырақмы? Ашап қараң әле ирмәккә, шәрбәте азырағырақ* һ.б. Шулай ук: *Сез чынлаплап сабан туйға килгәнсез қый* һ.б.

Рәвешләр өлкәсендә күзәтелә торган характерлы күренешләрнең берсе итеп сөйләштә әдәби телдә булмаган рәвешләрнең күп кулланылуын күрсәтергә кирәк. Рәвеш категориясе, ясалышы белән генә түгел, составы белән дә шактый үзенчәлекле. Сөйләшкә хас лексик рәвешләрнең кайберләренә тукталыйк.

Вакыт рәвешләре. *Бегәчә* – бүген кич белән. *Кичәдән элек, элекке көн* – өченче көн.

*Иртәгә суңга* – берсекөнгә. *Ичак, иртәнчак, иртәнчәк* – иртә белән, иртәгә иртә белән.

*Элек* – иртә: *Әле элек қый, мәә ашығасын ни* ‘әле иртә бит, нигә ашыгасың?’ *Әле утыртырга элегрәк (баланы).*

*Бер күлем, бер тын* – бераз, бер чама. *Бер шәптә* – бик тиз, тиз генә, аз гына арада; *бер шәп* – аз гына, кыска гына (вакыт).

*Сәғәт исәбе* – бер сәгать чамасы.

*Қайчан ара* – ни арада, кай арада.

*Заман* – тиз генә, хәзер. Чақ – әле генә, нәкъ. *Без чағ ашадық әле. Әйдәң утырың, эчең йасаб-йасап, без чағ эчкән ийег әле. Без чақ* (нәкъ) *бер көнне утыртқан идек аның белән. Йақты күздә* – йактырак вакыт. *Кайсы көнне* – беркөнне. *Кайсы көнне ишалға кергән ийе, мәстәгә кергән ийдер. Кич җары* – кичкә таба, кич: *Кич җары барып җитәрем. Мәк тә шундый була да, кич җары булд исә җомола. Алға* – алда.

**Билге рәвешләре.** Сыйфат ягыннан характерлый торган рәвешләр. *Унча* – аерым. Казан арты сөйләшендә шушы ук мәгънәдә *үзеңача* сүзе йөри. *Унча гына утыра бер дум. Чалқай* – чалкан. *Чибәр* – ипләп, саклык белән. *–Ралийә, жығылып төшмә, чибәр җөре, йарыймы. Аймақлап* – берьюлы, берничә, күпләп, күмәк. *Туйтақ-туйтақ* – аксап йөрү. *Айақ аwыртқач басып булмый, туйтақ-туйтак йөрисең шунда. Өwмә-өwмә* – өем-өем. *Безнеке, қайда қарасаң, утыннар инде өwмә-өwмә. Өйәләмә* – түбәләмә. *Өйәләмә итеп зур патнус белән утырталар қақ бәлеш. Бида* – бик. *Бала-чаға килеп керсә уйнаша инде исе китеп, баланы йарата бида. Йатқақлап* – ята-тора. *Аwрап китте, йатқақлап қына ашанды. Лыпын* – шып, шыплап. *Йарый лыпын йабылмаса да* (шкаф ишеге турында). *Ладум* – дөрес, яраклы итеп: *Күңгернеке бырачлар ладум бирмәгәннәр ыспырапканы. Уртара* – урталай: *Қалақларны, саwытларны уртара бүлеп алып чығып китте, мал уртара, кәртүк уртара* һ.б.

Күләм-чама ягыннан характерлый торган рәвешләр.

*Самай* – шактый, берникадәр. бераз. *Самай зур ғына йкә у, җөргәнем җуғ ый. Оноттом инде, читтә йөргәндә самай үрәндем ийе русча. Исең китәр* – искиткеч. *Қайаулы, чигелгән читек була у, исең дә китәр матур* – Каеган, чигелгән читек була ул, искиткеч матур һ.б.

*Уғата, бүтәнчә, имәнеч, биг үк, әллә ненди* – бик, искиткеч. *Уғата қылықсыз* (бигрәк холыксыз). *Уғата ирмәк қый бу* (бигрәк кызык бит бу). *Алар мәчитне бүтәнчә дә йасағаннар икә, ий йәмне инде. Ызба миңке әлә нинди сушыған* (бик нык суынган). *Биг үк қаты барып төштем дә сикереп тордом. Қолақай кеше көч лә бик әлә нендәй* (чукрак кеше бигрәк авыр). *Аша, аша, әлә нинди аша. Җиңе шушынантын, әләйди дә киң. Эштән чығып* – пыр туздырып. *Эй, бийергә йәбеште, эштән чығып бии. Тутай таза этән чыққан, симез* һ.б. Чагыштыр.: казан арты сөйләшендә *эштән чыгып ару* – бик нык ару. *Урин* – әкрен, тын, иплəп. *Урин сүли ни бу радио. Кычкырма, үриң ңына уқы.*

*Җимән төрле* – күп төрле. *Белгән* – күп. *Күлем* – шулай ук күп мәгънәсендә дә йөри. *У апаңда җимән төрле анда җепләр. Мендәрләр монда да күп, мич башында белгән. Күләм ақча кәрәг аңа* – Күп акча кирәк аңа һ.б.

*Мала-мала* (<мало) – әз-мәз. *Мала-мала безнең кебек кешегә тегеп бирә. Кийәw дә биргәли мала-мала* (акча). *Мала-мала урычча белгәч* ... һ.б.

*Таза* (белү) – яхшы белү. *Миндә тордолар ике йыл, алар бик таза беләләр мине. Берәwнеке малайы әрмийәдән килгәч урычча бик таза белә́м инде ди икә, арта үзе хелипне дә белмәгән. Бет'екий* – бераз. *Келәт алдығызны шықлаң аны бет'екей* – Келәт алдыгызны бераз каплагыз. *Айаққа басып торасың, табаға бет'екий саласың да рақыны. Башы белән* – бөтенләй. *Анда чаwынныҡ җуқ башы белән. Башуқ* – тулысы белән, тулысынча. *Әлеге хатны алып пир әле, аның әдерисе башуқ буғай. Тожҫо* (кийенү), *тожҫо* (тору) – чиста, җыйнак. *Қарт кеше тожҫо тормағач... Тожҫо ғына кийенгән, ыспай* һ.б.

**Урын рәвешләре.** *Элгәре* – түргә; *алдан утыру* – түргә үтү. *Қатын кеше кердисә «элгәре бар» диләр. Үткәрә* – үтә. *Әшбә қытат чыдамсыз була, үткәрә күренеп тора* (сүз юка тукыма турында). *Атқары* – югары, *эчкәре* – түбән. *Атқары мендем, эчкәре төштем, тапмадым сыйырны. Атқары чуқ* – югары урам, *эчкәре чуқ* – түбән урам һ.б.

Күргәнебезчә, Пермь татарлары сөйләшендә рәвеш категориясе шактый үзенчәлекле.

Беренчедән, бу категория, әдәби телдәге кебек үк, катып калган урын-ара килеш формалары һәм башка сүз төркемнәренең

изоляцияләнгән формалары, сүз яки сүзтезмәләр исәбенә формалашкан. Бу процесс бик борынгы заманнардан ук килгән һәм шуңа күрә сөйләштә архаик килеш кушымчалары белән формалашкан рәвешләр дә күзәтелә: *элгәре, эчкәре, атқары, үткәрә, йары* (*як* сүзенең борынгы юнәлеш килеше формасы) һ.б. Мондый типтагы күренешләр татар теленең башка сөйләшләрендә дә табылалар, шунда ук әдәби телдәге *югары, эчкәре, ары, бире, кире, тискәре* сүзләрен дә китерергә мөмкин.

Икенчедән, кайбер юнәлеш формалары яки кайбер рәвешләр, әдәби телдәге шундый ук формалар яки сүзләр белән чагыштырып караганда, башкачарак мәгънә төсмере белдерәләр. Мәсәлән, *элгәре* сүзе әдәби телдә вакыт төшенчәсен белдерә, ә өйрәнелә торган бу сөйләштә ул урын рәвеше, ягъни пространство ягыннан характерлый торган сүз буларак кулланыла. Тюркологиядә *элгәре* сүзен борынгы телдәге *ал* мәгънәсендә йөргән *әl* тамырыннан дип аңлаталар. Борынгы язма истәлекләр һәм башка кайбер төрки телләр материаллары -*ғары*/-*гәре* кушымчасының, күбесенчә, урын белдерә торган сүзләргә кушылуын күрсәтәләр. Димәк, сөйләштәге *элгәре* сүзе үзенең борынгырак эчтәлеген саклап калган.

Шулай ук, *элек* сүзенең *иртә* мәгънәсендә, *тәwлек* сүзенең – *ел тәүлеге*, *алга* сүзенең *алда* мәгънәләрендә йөрүенә дә игътибар итми булмый.

Өченчедән, сөйләштә рәвеш сүз төркеме, югарыда карап үткән *элекке көн, иртәгә соңга, кичәдән элек, бер күлем, бер тын, бер шәптә, сәғәт исәбе, қайчан ара, йақты күз, қайсы көнне, эштән чығып* тибындагы лексикалашып бара торган тотрыклы сүз тезмәләре исәбенә дә тулылана, байый бара.

Дүртенчедән, кайбер рус теленнән кергән рәвешләр дә сөйләштә татарлашып киткәннәр, татар теленең үз сүзе кебек үк кулланылалар. Мәсәлән, *мала-мала, дукил, буча*//*бупча* (вовсе), *бич* (весь), *ладум*, *самай* һ.б.

Шулай итеп, рәвеш категориясе формалашуы ягыннан да, составы буенча да шактый характерлы үзенчәлекләрне туплаган. Вакыт рәвешләрендә аеруча кызыклы формалар кулланылып килә.

Барда төбәге сөйләше *көн буе(на), көнозон, кышлыкта* тибындагы формалары белән әдәби телгә һәм татар теленең башка сөйләшләренә якын торса, *қышқыда, кичкесен* тибындагы формалары белән татар теленнән һәм җирле сөйләшләрдән аерыла һәм

көнчыгыш төрки телләр, мәсәлән, алтай, хакас, шор телләре белән уртаклык күрсәтә.

**Ярдәмлекләр. Бәйлекләр.** Сөйләш өчен характерлы бәйлекләр түбәндәгеләр: *кебек/кеwек/кемек/күк; шикелле; сыман/семән/сымақ/семәк; төсле; әмән* (сирәк); *хәтле/қәтле/хәдәрлеге/хәтлеге; чақ/чақлы; тиң/тиңне/тиңе/тиңке/тиклем* (сирәк); *шайы* (сирәк); *сайын/сай; борон/боро; бире* (әд. бирле);, *үзгә* (башка); *өчен; бала/бәлә/бола, чикле, таба, аша.*

Функцияләре белән бу бәйлекләр әдәби телдәге шундый ук бәйлекләрдән аерылмыйлар, бары *өчен, таба, бәлә//бола аша* һәм охшату-чагыштыру бәйлекләре турында гына берничә сүз әйтергә кирәк.

*Өчен* бәйлеге, әдәби телдәге кебек үк, баш (һәм иялек) килешен таләп итә һәм эш яки хәлнең сәбәбен, максатын, кемдер, йә нәрсәдер өчен билгеләнгәнлеген белдерә. Ләкин әдәби телдә ул сәбәпне белдергәндә яки иярчен сәбәп җөмләне баш җөмләгә бәйләүче буларак килгән вакытта *-ган/-гән* формалы фигыльләр белән бәйләнештә була: *алган өчен рәхмәт, килгән өчен шатландым* һ.б. Тикшерелә торган сөйләштә исә, *өчен* бәйлеге башка сүз төркемнәре янында килеп тә сәбәп белдерә торган конструкцияләр оештырырга мөмкин. Мәсәлән: *Ниг ачып җибәрдең тәрзәне? Эссе өчен* (эссе булганга күрә). *Чәче ишүдә тормый қый, қаты өчен* (каты булганга күрә). *Бездә алма wақ була, салқын өчендер* (салкын булганга күрә). *Инәсе үзе генә қалған өчен* (үзе генә калганга күрә) *монда килде. Бик халық керә мийә, җул өсте өчен* (юл өсте булганга күрә). *Күмер йуғ өчен мичкә йақтым ийе* (күмер булмаганга күрә, мичкә яккан идем). *Эссе қый, күләгә чен килдем* (күләгә булганга күрә).

*Өчен* бәйлегенең семантик функциясе татар теленең башка кайбер сөйләшләрендә дә, башка төрки телләрдә дә шактый үзенчәлекле.

*Таба* бәйлеге, татар телендә генә түгел, күпчелек төрки телләрдә дә юнәлеш килешне башкара. Әлеге сөйләштә исә бу бәйлек борынгы төрки телдәге кебек, баш килеш формасындагы сүзләргә бәйләнә: *йуғары таба* – югарыга таба, *бу таба* – бирегә (моңа) таба, *шу таба* – шунда таба һ.б.

*Бала/была/бәлә/бола* бәйлекләре исемнәрне яки алмашлыкларны юнәлеш килештә башкаралар һәм әдәби телдәге *өчен* бәйлегенә

туры киләләр. Семантик яктан караганда бу бәйлекләр ике мәгънә төсмере белдерәләр.

1) Әдәби телдәге *хакына* бәйлек сүзе ярдәмендә белдерелә торган *максат*, рус телендәге *ради* сүзенә туры килә: *Усатбага бәлә* (усадьбасы хакына) *генә чықтығ инде без анда. Маннапқа бала* (Маннап хакына, ягъни ире беркайда да эшли алмаган өчен) *ғына өстәделәр қый ақчасын. Суға бәлә* (су хакына) *дә килгәннәр инде* һ.б.

2) Сәбәп белдерәләр һәм *нәрсә аркасында?* дигән сорауга җавап бирә торган конструкция оештыралар. Бу вакытта *бала/была/белә/бола* бәйлеге рус телендәге *из-за* предлогына якыная: *Сәғәт ничәдә уйанам, йокламыйм, шул баланы җибәрмәгә была* (шул баланы җибәрәсе булган өчен). *Шушы суға бола төннән торам да* (чөнки соңга калгач, су болганчыклана) һ.б.

*Аша* бәйлеге, әдәби телдән аермалы буларак, чыгыш килешне башкара: *Қазларны шунан йөртәләр инде, үкәртәдән аша. Бездән аша өч чақырым аwыл бар, Қый Шауба тиғән* һ.б.

*Шикелле, кебек* һәм башка шундый охшату чагыштыру бәйлекләре сөйләштә хәбәрлек составында килә алалар. Бу вакытта алар модаль мәгънә – фараз итүне, чамалауны белдерәләр: *Әле Бит'ә килде кебек* (бугай). *Бүген кино йуқмы? – Йуқ шикелле* (юктыр). *Кичтән шикелле* (ахырысы) *қый әле, йокы килми.*

Орхон-Енисей язма истәлекләрендә: *күк* – фаразлау кисәкчәсе.

**Бәйлек ролендә йөри торган сүзләр**. Әдәби телдәге *бирле* бәйлеге урынына сөйләштә *башлап* сүзе кулланыла: *Қыштан башлап қына алдылар райунға. Күптәндән башлап чирли қый ул. Йаздан башлап* (яздан бирле) *қаты җуқ* һ.б.

*Тышында* – вакыт белдерә торган сүзләр янында килә һәм әдәби телдәге *арасында, эчендә, тирәсендә* сүзләренә туры килә: *Қарабодай ике-өч йыл тышында йуғ әле, чәчмиләр. Әле өч-дүрт көннең тышынңда ғына таптым ый.*

*Йары: кич йары* – кичкә таба: *Мәк тә шундый була, кич җары булд исә җомола* һ.б.

**Теркәгечләр.** Сөйләштә түбәндәге теркәгечләр үзләренең кулланылышы белән үзенчәлекле.

1. *Исә* теркәгече әдәби телдә тулы булмаган эчке каршылыкны белдерә. Аның грамматик функциясе – ике мөстәкыйль җөмләнең логик бәйләнешен формалаштыру. Бу теркәгеч бер төркем

сөйләшләрдә нократ, минзәлә, Урал төбәге сөйләшләрендә һәм, шулай ук, әле сүз бара торган Барда төбәге сөйләшендә дә, бик киң кулланылышта, аның функцияләре, әдәби тел белән чагыштырганда, киңрәк һәм үзенчәлеклерәк, мәгънәсе, синтаксик роле көчлерәк. Борынгы татар әдәбиятындагы кебек үк, *исә* теркәгече, гадәттә -*ды*/-*де* формалы фигыльләр белән килә һәм аның ике функциясе бар.

а) хәбәрләр яки җөмләләр арасындагы вакыт бәйләнешен белдерә һәм әдәби телдәге -*гач*/-*гәч*/-*гач*/-*гәч, -гач та*/-*гәч тә, гач ук -гәч үк, баруга, килүгә)* формаларына туры килә: *Җан ийәсе туд исә* (тудымы) *ашарга сорый*. *Тawны менден исә* (тау менгәч) *күренә инде*. *Мин қурықам да қойаш байыд исә* (кояш баегач) *чықмыйм*. *Айағына йөри башлад исә* (тәпи йөри башлауга...) *тебети аппирмә кәрәг әле малайға диләр* һ.б.

б) процессларның яки хәлләрнең үзара шартлы бәйләнештә булуын күрсәтә: *Ашасы килд исә чәй эчеб утырмас ий әле* (ашыйсы килсә). *Исемнәре белә эндәштем исә* (эндәшсәм) *сикереп торалар песиләр*. *Қарарым әле, ақча күп булд исә* (акчам күп булса) *биререм*. *Атка тланып килд исә у чакта абәзәтелни хәбәргә килә* – Атка атланып килсә, димәк, ул чагында хәбәргә килә.

Фигыльнең башка формалары яки башка сүз төркемнәре белән бергә килгәндә, *исә* теркәгече модаль мәгънә – икеләнүне, билгесезлекне, шөбһәләнүне белдерә: *Бер ни исемне исә* (кем исемнедер) *кеше килде – Барда кеше*. *Ғапту бичәдәнме кемнен исә* (кемнәндер) *чыып қалды*. *Қайда исә* (кайдадыр) *эленеп тора мамық*. *Фәрихә нимә тид исә шуны* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу очракта *исә* теркәгече сорау алмашлыклары белән бәйләнгән була.

Шулай итеп, *исә* теркәгеченең кулланылышы һәм семантик функцияләре белән тикшерелә торган бу сөйләш, аеруча, нократ, минзәлә, урал төбәге сөйләшләренә якын тора, борынгы татар теле белән зур уртаклык күрсәтә.

2. *Әгәр* теркәгеченең кушма формасы кулланыла: *Әгәренки ун йыл ғына элек шушы мәктәп чыққан булса, мәйтәм, без укуға эләгәбез ий.*

*Әгәренки* теркәгече тагын урта диалектның кама-тамагы һәм нократ һ.б. сөйләшләрдә бар.

**Кисәкчәләр.** Барда төбәге татарлары сөйләшендә, пермь сөйләшендәге кебек үк, кисәкчәләр өлкәсендә күзәтелә торган иң

характерлы үзенчәлек – әдәби телдәге *бит, ич* раслау кисәкчәләре урынына *қый* сүзен куллану. Мәсәлән: *Бул су Көңгергә төшә қый* – Бу су Кунгурга төшә бит. *Хәзер мона қый суранчылар йуқ* – Хәзер менә соранып йөрүчеләр юк бит.

*Қый* раслау кисәкчәсе белән Барда төбәге сөйләше, әдәби телдән генә түгел, татар теленең күпчелек сөйләшләреннән дә аерылып тора. Бу яктан да аның бары тубыл-иртеш диалекты белән уртаклык күрсәтүе үзенчәлекле. Чагыштыру өчен тагын каракалпак телендәге *гъой/ -гъо,* кыргыз телендәге *qo//до*, үзбәк һәм лобнор телләрендәге *ку*, монгол телендәге *кү* раслау кисәкчәләрен китерергә мөмкин.

Кисәкчәләр өлкәсендә әлеге сөйләш өчен гомуми характерда булган тагын мондый үзенчәлекләр бар: сөйләш әдәби телдән тагын *мыса/маса/мәсә/баса* кисәкчәсе белән дә аерыла. Бу кисәкчәнең беренче өч формасы сөйләш өчен гомуми, *баса* вариантын исә мин аерым авылларда язып алдым.

*Мыса/маса/мәсә/баса* кисәкчәсе сөйләм телендә шактый актив кулланыла һәм билгесезлекне, икеләнүне, фараз итүне белдерә, нәрсәне дә булса аерым-ачык белмәгәндә әйтелә. Мәсәлән: *Әле генә Бардадан килдейе, он алып қайтты мыса* – Әле генә Бардадан килгән иде, он алып кайттымы шунда). *Икәw-өчәw мыса әтәчләре* – Әтәчләре икәү-өчәүме шунда. *Авылда җҫез дум диләр мыса, илле диләр мыса* – Авылда йөз хуҗалык диләрме, илле диләрме шунда). *Шалқан беркә, мәгә беркә икән ни? Теш чығa маса* – Бала төкереген чәчрәтә, нигә чәчрәтә микән, теш чыга ахырысы. *Хәлwә салған мәсә* – Хәлвә салганмы шунда. *Чима чийып бақтық: мә! кеше маса, тим* – Шырпы сызып карасак... «кешеме соң» бу дим. *Биш тәwлек тулды маса үлүwенә* – Үлүенә биш ел тулдымы шунда.

*Уқ/үк* кисәкчәләре рәвешләрдән соң да кулланылалар һәм семантик яктан әдәби телдәге *ғына-генә* кисәкчәсенә туры киләләр: *Аз уқ үлмәдем* – Аз гына үлми калдым. *Биг үк рәхәт* (артыклыкны белдерә) – Бигрәк тә рәхәт һ.б.

Әдәби телдәге *нәкъ* кисәкчәсе урынына, *ярты, урта* сүзләре алдында, *қап* кисәкчәсе кулланыла: *Безнең бу урта чуқ, қап урта чуқ бу* – Бу безнең урта урам, нәкъ урта урам. *Қап йартысыннан сынып чыққан* – Нәкъ яртысыннан сынып чыккан һ.б.

Бу сүз башка төрки телләрдә дә бар, күбесенчә *урта* сүзе белән кулланыла һәм шулай ук *нәкъ* кисәкчәсенә туры килә. Мәсәлән: хак. *кап орта*, туба – *кеше*: *каборто,* як. *хаба* һ.б.

Сөйләш кайбер көчәйткеч кисәкчәләре белән дә әдәби телдән аерыла.

*Төмә надан* (чаг. тома сукыр һ.б.): *Җөремәсеннәр төмә надан булып, уқысыннар.*

*Томро қара* – кап-кара*: Томро қарайы чәче, шоморт кеwек.*

*Чепа (көчәйткеч алкушымча): Арта чепа йаланғач* – Шулай итеп яп-ялангач киттем һ.б.

*Шай* – ахрысы, бугай. Мәсәлән: *Қарағай мәшкә, терке биләңкә икесе бер шай алар* һ.б.

*Дөм (көчәйткеч алкушымча): дөм ач* – бик ач, бөтенләй ач. *Дөм ач йатқаннар атлар. Сыйыр булулық белә без дөм ач булмадық* һ.б.

Күргәнебезчә, бу сөйләштә ярдәмлекләр төркеме үзенең составы ягыннан беркадәр әдәби телдән аерыла. Җирле үзенчәлекләр бу категориянең башка сүз төркемнәре исәбенә байый төшүендә дә чагылганнар.

Ирен һәм сыльва татарларында әдәби телдәге *да/дә* теркәгеченең *дагын/дәген* формасы да кулланыла. *Пиканның сабағын ғына турыйсың дағын бәрәңге турыйсың. Ат җигәсең дәген эләктереп китәсең сүрәне* (волокушаны). *Килен әтнә йуғырақ қына китте, суңрақ килде дәген* – Киленнең килүенә бер атна да юк әле, соңрак кайтты да. *Балчық сылыйлар дағын сырлыйлар пытылукны да, эстинәне дә. Мәскәwтә апирәтсәгә барып қайтты дағын, шомортқа барған шы кеwе* һ.б.

Тикшерелә торган сөйләш бу үзенчәлеге буенча урта диалектның казан арты сөйләше белән зур уртаклык күрсәтә.

8) Муллы һәм шауба татарларында *да/дә* теркәгечләрен кабатлап әйтү очраклары да бар. Мәсәлән: *Бу қызны күрмәдек без көндез бер дә/дә. Магнитафунны бер дә/дә әйтмәбез. Арыш ашлық булмады быйыл бер дә/дә. Бер дә-дә эчми монысы, ачыңа үлмә йтәсеңме? Миңке түшлек бар хәзер дә/дә. Әлдә дә китерәләр әле* һ.б.

## Синтаксик үзенчәлекләр

**Сүз тезмәләренең ясалышы белән бәйле үзенчәлекләр.**

1. Исемле исем сүз тезмәләренең Барда ягы сөйләшендә өч төре кулланыла. Шулай да беренче тип изафә сөйләштә доминант булып тора һәм яшь буын, зыялылар телендә дә актив кулланыла: *Багун арада* (вагон арасында) *йөрибез, ыстансы эчтә*, (станция эчендә).

*Кул арйақта* (чокырның аръягында) *торалар. Милеш бәлеш* (миләш бәлеше) *йасап пирәм әле. Уч төп* (уч төбе) *зурлығында ғына оя күрдем. Сараш аwыл қалын қый* – Сараш авылы зур бит. *Тол аржаққа* (Тол аръягына) *минча итеп салдық*... һ.б.

Исемле исем сүз тезмәләренең катлаулы төрләре дә үзара бернинди кушымчасыз ялганырга мөмкин: *өстәл йабу асны* (өстәл ябуы, ягъни скатерть астын), *мич ут алда* (мич уты алдында), *дар җарма ботқа* (тары ярмасы боткасы), *машина күләсә арағa* (машина тәгәрмәче арасында) *қалды* һ.б.

Аергычы да, аерылмышы да исем булган сүз тезмәләренең янәшәлек юлы белән бәйләнүе татар әдәби телендә дә бар һәм, билгеле булганча, мондый изафә кушма сүзләр ясауда да катнаша, чөнки янәшәлек юлы белән бәйләнгән ике мөстәкыйль сүз, даими рәвештә бергә әйтелү һәм ниндидер бер өченче төшенчәне белдерү нәтиҗәсендә, лексикалашуга сәләтле булалар. Моның үрнәкләрен тикшерә торган әлеге сөйләштән дә китерергә мөмкин: *қапқал* (капкалга, капкалда, капкалны һ.б.) – капка алды; *этпорон* (эт борыны) – гөлҗимеш; *үкәртә* (< ү кәртәсе < өй киртәсе) – ишек алды; *дымқорт* (дым корты) – кыргаяк һ.б.

Исемле исем сүз тезмәләренең архаик төре татар теленең башка җирле сөйләшләрендә дә күзәтелә.

2. Билгеле булганча, әдәби телдәге санлы һәм сыйфатлы исем сүз тезмәләрендә иярүче кисәк төп кисәккә янәшәлек юлы белән бәйләнә. Тикшерелә торган сөйләштә исә бу төр сүз тезмәләренең бәйләнешендә дә әдәби тел нормаларыннан читкә тайпылышлар күзәтелә. Мәсәлән, бу өлкәдә безнең тарафтан түбәндәге диалекталь күренешләр язылып алынды.

а) Бер саны, кайбер сыйфатлар һәм алмашлыклар, ияртүче кисәк белән бергә килгәндә дә, тартым кушымчасы алалар: *берсе китап, олосы малайым, кечесе сеңлем, тегесе чебеч* һ.б. Күзәтүләргә караганда, мондый күренеш бер төркем әйбернең берсен нинди дә булса бер билгесе һәм характеры, эше ягыннан аерып күрсәткәндә күзәтелә. Шуңа күрә булса кирәк, тартымлашкан аергычка логик басым төшә. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу вакытта әйберләрнең яки күренешләрнең берсе йә билгесе, йә хәле ягыннан башкаларына карата кара-каршы куела. Мәсәлән: *берсе ызбаны сатып килдем ийе.* Бу мисалда сүз ике (яки берничә) өй булып, шуның берсе сатылу турында бара. Һәм «берсе ызбаны» сүз тезмәсе әдәби телдәге

«өйләрнең берсен» яки «бер өйне» тәгъбиренә туры килә. Тагын бер мисал: *Ансы ағач қысқа, озонон биререм.* Әдәби телдә бу фикер түбәндәгечә формалаша иде: *Агачның ансы (яки ул агач) кыска, озынын бирермен.*

Саннардан, югарыда әйтеп үтелгәнчә, аеруча, *бер* саны тартымлаша. Исемнәрне ачыклап килә торган *бер* санының *-се* кушымчасы алуы сөйләшнең бөтен районнарында да даими рәвештә күзәтелә. Мисаллар: *Берсе күзе йуғ анықы* (аның бер күзе юк). *Әле берсе қызыбыз* (кызларыбызның берсе... яки бер кызыбыз...) *йырақ, Башкерийәдә. Берсе бармағын* (бармагының берсен) *сындырған. Берсе балабыз* (бер балабыз, ягъни балаларыбызның берсе) *хезмәт итә. Қунақлар қайттылар: бүген берсе пары, кичә берсе пары* – Кунаклар кайтты: бүген бер пары, кичә бер пары һ.б.

Мондый күренеш инде әдәби тел белән теге яки бу дәрәҗәдә таныш булган укучылар, яшь буын, интеллигенция, хәтта укытучылар телендә дә күзәтелә.

Бер-берсен ачыклап килә торган иярүче кисәкләр дә тартымлашырга мөмкин: *Менә минем берсе кечесе малай* (кече малайларымның берсе) һ.б.

Аергычлы-аерылмышлы сүз тезмәләрендә иярүче кисәкнең *сы-се* кушымчасы алу күренеше татар теленең башка сөйләшләрендә әлегә билгеләнмәгән.

б) Өйрәнелә торган сөйләш өчен характерлы үзенчәлекләрнең берсе – ияртүче кисәк билгесез (төшем) килештә торганда саннар, сыйфатлар һәм алмашлыклар белән белдерелгән иярүче кисәкнең төшем килеш кушымчасы алуы. Мәсәлән: *Ана у кешеләр булса икенче кибин артық сала йық* – Әнә ул кешеләр дә булган булса ике кибән артык сала идек). *Бер җите-сигезне ат тота йы* – Җидесигез ат тота иде. *Әйдәң әле, берәрне күмәч ашап қарарсыз* (берәр күмәч ашап карарсыз).

Сыйфатлар: *Озонорақны қайын ал* – Озынырак каен агачы ал. *Озонно күлмәк кийәләр* – Озын күлмәк кияләр. *Кийеwе ызба йасый йаңыны* (яңа өй сала) . *Белекийне* (кечкенә) *сандық барыб алдық аwылдан. Икмәк китерсен ий йомышақны* – Йомшак икмәк китерсен иде.

Аергычлы-аерылмышлы сүз тезмәләрендә иярүче кисәкнең төшем килеше формасында килүе. – Барда төбәге сөйләшенең, шулай ук, специфик үзенчәлекләреннән берсе һәм сөйләш бу үзенчәлеге

белән, әдәби телдән генә түгел, татар теленең башка җирле сөйләшләреннән дә аерылып тора.

3. Исемле фигыль сүз тезмәләренең бәйләнешендә дә әдәби нормага туры килмәү күренешләре күзәтелә.

Билгеле булганча, мондый сүз тезмәләрендә бәйләнеш фигыльнең таләбеннән чыгып башкарыла. Сөйләштә дә ул, нигездә, шулай. Тик бер төркем фигыльләр үзләрен ачыклый торган исемнәрне һәм алмашлыкларны кайсы килештә башкарулары белән әдәби телдән аерылалар. Мәсәлән, минем тарафтан түбәндәге очраклар язылып алынды:

а) әдәби телдә чыгыш килешен таләп итә торган *көлү* фигыле сөйләштә даими рәвештә төшем килешен башкара: *Мине көләм дип, үзеңе көлдең дә, балаҗайым* – Миннән көләм дип, үзеңнән көлдең бит, балакаем. *Аны көлмәгә йәбештег икебез дә* – Аннан көләргә тотындык икебез дә. *Әй көләләр бу йаҗтағы телне* (телдән көләләр) һ.б.;

б) әдәби телдә юнәлеш килешен сорый торган бер төркем фигыльләр әлеге сөйләштә даими рәвештә төшем килешен таләп итәләр.

*Суғу* (бить, ударить, стукнуть): *Моно суҗсам* (моңа суксам) *да җурҗам*. *Җулға тотайыҗ та бер-беребезне суғайыҗ* (бер-беребезгә суга идек)*, шуңа күрә әбәк печин*[1] *тиләр*.

*Чапҗыту//шапҗыту/сугу, сугып җибәрү, чалтырату* мәгънәсендә: *Тағы җылаcа тығы чапҗытам мин аны, арҗырайып йеремәсен* – Тагы еласа тагы чалтыратам мин аңа, киреләнеп йөрмәсен һ.б.

*Тийү* (кагылу): *Сез аны тимәң, уланнар ғына җый әле wы* – Сез аңа тимәгез, кечкенә бит әле ул. *Төлке кешене тими* – Төлке кешегә тими. *Гөлнө нийә тийәсең ни, тимә җый!* – Гөлгә нигә кагыласың, кагылма! һ.б.

*Өрү* (эт тур.): *Сезне өрер әле у берәр әтнә торғанчи* – Берәр атна булганчы сезгә өрер әле ул;

в) гадәттә чыгыш килешен башкара торган *гарык булу, бизү* мәгънәсендәге *тую* фигыле сөйләштә юнәлеш килешен башкара: *Элек бетекий ызбаға туйдыҗ* – Элек кечкенә өйдән туйдык. *Шул надан балаларға туйдым инде* – Шул надан балалардан туйдым

[1] Сукыр кычыткан.

инде. *Ул анда қайынына-кәйнәсенә туйды.* – Ул анда каенанасыннан, каенатасыннан туйды һ.б.;

г) *кушкан* (исем куштыру) фигыле юнәлеш килешне таләп итә: *Молла бабай Шәми исемгә қушқан* (Шәми исеме кушкан) һ.б.;

д) *утыру, басу, йөрү, ис китү* фигыльләре (урынга утыру, аякка басу, идәнгә басу һ.б.) сөйләштә даими рәвештә чыгыш килешен таләп итәләр: *Бар, қәртәтийең йанынан тәрзә төптән утыр* – Бар бабаң янына, тәрәзә төбенә утыр. *Мәстәкәй булды? Қунақлар ишек төптән утыралар, без түрдәнме?* – Нәрсә булды соң әле бу? Кунаклар ишек төбенә, без түргә утырдыкмыни. *Сәғәтнең буйына айактан басып тормаға кәрәк* (аякка басып, ягъни аяк өсте). *Айағыннан йөри* (бу сөйләштә «аяктан йөрү» тәгъбире әдәби телдәге *тәпи йөрү* төшенчәсенә туры килә). *Челкәнең зурлығыннан ис киттейе* – Исем киткән иде оекның зурлыгына һ.б.

Югарыда *башлау, белү, булу* фигыльләренең инфинитивны башкару очракларын күреп киткән идек.

Исемле фигыль сүз тезмәләрендә күзәтелә торган диалекталь үзенчәлекләр татар теленең башка сөйләшләрендә дә табыла.

4. Ияртүче кисәге сыйфат яки рәвеш булган сүз тезмәләре:

а) *зәгыйфь* сүзе тәмамлыкны юнәлеш яки чыгыш килешендә башкара: *Кызыбыз бер күзгә зәғыйп* – Кызыбызның бер күзе зәгыйфь. *Үзем күздән зәғыйп булдым* – Үземнең күзем зәгыйфь булды;

б) *күп, күбрәк, артық* сүзләре иярүче кисәкнең баш килеш формасында килүен таләп итәләр: *иИле йәш күберәк* – Илле яшьтән күбрәк. *Без үзебезгә ике бидрә күбрәк* (ике чиләктән артыграк) *қуйабыз су*. *Җегерем биш күпләп бардыр җийәw бардық* – Егерме биш километрдан артык бардыр, җәяү бардык.

**Хәбәрлекнең формалашуы белән бәйле үзенчәлекләр**. Хәбәрлекне белдерү һәм аның функцияләре белән сөйләш әдәби телдән аерылмый. Диалекталь күренешләр аны формалаштыру ысулларында чагылалар.

1. Хәбәр, әдәби телдән аермалы буларак, фигыльдән башка сүз төркемнәре белән белдерелгәндә дә хәбәрлек кушымчалары ала: *Қайдалар* (кайда) *икә суң болар*. *Сез бупча Казанның үзенекесезме* (үзенекеме)?. *Қунақлар! без генә йуқбыз икән* (юк икәнбез). *Хәзер сиксән дүрттәмен* (сиксән дүрттә). *Тыwмышығыз Қазанның теге йағындасызмыни* (ягындамыни)?

2. *-ган*/*-гән* формалы фигыльләрнең *бар, юк* сүзләре белән берлектә хәбәр булып килгәндә түбәндәге үзенчәлекләре күзәтелә.

а) Билгеле булганча, әдәби телдәге мондый конструкцияләрдә хәбәр тартымлы була һәм субъект иялек килешендә башкарыла. Ә өйрәнелә торган сөйләштә субъект еш кына баш килеш формасында килергә мөмкин: *Сез әле элек килгәнегез җуғ ыйдыр бу аwылға? Бичәсен без күргәнебез җуқ. Килен* (киленнең) *килгәне йуқ. Миңкеләр кәртнәләренә менеп тә қарағаннары җуқ* – Минекеләрнең әбиләренә менеп тә караганнары юк.

б) Яки, киресенчә, хәбәрдәге тартым кушымчалары төшереп калдырыла: *Синең анда барған җуқ* (барганың юк)*, минем бар. Сезнең күргән җуқмы* (күргәнегез юкмы?) *андыйны Әллә синең аны йәбештергән бармы* (ябыштырганың бармы) һ.б.

в) Ия белән хәбәр бөтенләй ярашмаган очраклар да бар: *Казанға барған җуқ мин* (минем барганым юк). *Сез әллә урақ та күргән җуқтыр* (күргәнегез юктыр) *инде* һ.б.

Мондый үзенчәлекләр сөйләм теле закончалыклары белән бәйле һәм шуңа күрә татар теленең күпчелек сөйләшләрендә табыла.

3. Әдәби телдәге «миңа егерме яшь» яки «мин егерме яшьтә» тибында әйтелә торган җөмләләр сөйләштә бернинди грамматик күрсәткечсез формалашалар. Мәсәлән: *Мин үзем сиксән биш инде* – Миңа 85 яшь инде. *Аңан кече кызым ике йәш кенә йе, берсе малай өч җәш йарым ийе. Әле сиксән алтымы ул, сиксән өчме? Малайы бер генәйе, сиксән йәш артығыраг инде* – Малае бер генә иде, сиксән яшьтән артыграк инде аңа. *Мин алтмыш өч йәш, минең әби илле җите йәш. Тегесе кызыбыз җегерме йәш* һ.б.

**Сорау җөмлә төзелеше.** Барда төбәге сөйләшендә сорау белдерү, әдәби телдәге кебек үк, сорау кисәкчәсе -*мы*/-*ме,* сорау алмашлыклары һәм интонация ярдәмендә башкарыла.

а) Сорау кисәкчәсе *мы-ме,* урта диалект сөйләшләрендә һәм әдәби телдәгечә, хәбәр составында килә. Хәбәр икенче зат хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыль белән белдерелгәндә -*мы*/-*ме* кисәкчәсе фигыльнең нигезенә үк ялганырга мөмкин.

б) Сорау җөмләләр сорау алмашлыклары белән формалаштырылганда алмашлыклар еш кына *ни* алмашлыгы белән бергә киләләр. Мәсәлән: *Қайда ни у* (кайда ул)? *Кай китт икән ни Җамал апа?* – Җамал апа кая китте икән? *Сиңке йуқ мәллә? Мә кимисең*

*ни?* – Нигә кимисеӊ? *Мәгә кәрәк ни у сезгә?* – Нәрсәгә кирәк ул сезгә? һ.б.ш.

Шушындый ук күренеш алтай теленеӊ туба диалектында да билгеләнеп үтелгән һәм Н.А. Баскаков анны, туба диалектыныӊ бары себер төрки телләре белән генә уртак булган үзенчәлекләреннән берсе, дип күрсәтә.

в) Сөйләүченеӊ теге яки бу күренешкә мөнәсәбәте махсус интонация белән белдерелә, һәм, шуӊа күрә, сөйләм телендә интонациянеӊ мөмкинлекләре, язма әдәби тел белән чагыштырганда, бермә-бер артык була. Шунлыктан сөйләшләрдә бары интонация белән генә сорау белдерү очраклары күп табыла. Алар безнеӊ тарафтан Барда төбәге сөйләшендә дә күзәтелде. Мәсәлән: *Ә уқыйсыз монда? Сез мунчаға җитешә лерсез?* – Сез мунчага җитешә алырсызмы? *Әлә анда кердегез?* – Әллә анда кердегезме? *Җуwындығыз?* – Юындыгызмы?

Билгеле мондый күренешләр кара-каршы сөйләшкәндә, диалогларда күп: *Казан кешеләр икә.– Әйе. – Икегез дә?* – Икегездәме? *Икмәкләр уӊды?* – Икмәкләр уӊдымы?

г) Сөйләштә үзенчәлекле сорау җөмлә тибы бар.

Ул диалог барышында, бирелгән сорауны кире кайтарып сораганда күзәтелә һәм, гадәттә, бер сүздән тора. Мәсәлән: *Карағыш аwыл йырақмы? Карағыш аwыл?* – Карагыш авылымы? *Түбәгә менеп пулмый бит. Менеп пулмый?* Менеп булмый дисеӊме? *Без китә башлыйбыз. Китә башлыйбыз? Сез кемнәр буласыз ни? Қунақлар. Қунақлар* – Кунаклармыни? *Әни дә киттейе? Әни дә?* – Әниеӊ дәме? һ.б.

Китерелгән мисаллардагы *Қарағыш аwыл? Қунақлар? Әни дә?* тибындагы сорау җөмләләр, бары интонация белән генә белдерелгән сорау җөмләләрдән, үзләренеӊ яӊгырашлары, интонацион формалашулары белән аерылып торалар: аларда соӊгы иҗек үзенә бер тон белән сузып әйтелә.

**Җөмлә кисәкләренеӊ инверсияләнүе.** Татар теленеӊ башка сөйләшләрендәге кебек үк, Барда төбәге татарлары сөйләшендә дә инверсия, ягъни җөмлә кисәкләренеӊ кире тәртибе зур урын алып тора.

Күзәтүләр, аеруча, аергыч инверсиясенеӊ көчле булуын күрсәтәләр. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, *-нықы/-неке* кушымчалы сүзләр белән белдерелгән аергычларныӊ инверсияләнүе, кайбер оч-

ракларда, хәтта, даими төс ала. Моннан тыш сыйфат фигыльләр, нисби сыйфатлар, хәтта асыл сыйфатлар белән белдерелгән аергычларның да җөмләдә урыннары алыштырыла. Мисаллар: *Казанның урта төшендә мәчит хәттин ашқан* (хәттин ашкан – бик яхшы мәгънәсендә). *Өч апасы бар аwылда киленнеке* – Килennең өч апасы бар авылда. *Ул киткәс ызбалар җаnып китте безнеке* – Ул киткәннән соң безнең йортлар янып китте. *Шырамталарын тышқа қуйғаннар ийе йыwына торған* – Юына торган мунчаларын тышка куйганнар иде. *Т'үней була да суң ул, өйдә кийә торған, җомошақ қына. Кияүнәгәрнең биленә бота урыйлар озондан тегелгән. Малайы бар берәw бичә алмаған* (өйләнмәгән).

Хәлләрнең инверсияләнүенә мисаллар: *Уқыплар қуйдың биг әйбәт иттереп* – Бик әйбәт итеп укып куйдың. *Бүген иртән тордом дағын мунча киттем инмәгә* (мунча керергә). *Суны зурғайталар буwып* – Суны буяп зурайталар. *Каралдыны былтыр үзем төзәттем пумич иттереп* – Каралты-кураны өмә ясап төзәттердем. *Ашамады ике көн йатырғап* – Ятсынып ике көн ашамады. *Безнең дә суwыған әле ызба бүген* – Безнең дә бүген өй суынган әле. *Аны (борычны) аwызыңа қапқан аңайына җә үлеп китәрсен чәчәп, мә қынырға белми* – Аны авызыңа кабу белән тончыгып, нәрсә эшләргә белмичә үлеп китәрсең. *Сақайа, әкә шуңа өйдә көтеп кенә утыра да мине, бер қайа да китми* – Сагая, әнә шуңа күрә дә өйдә бер кая да китми көтеп утыра мине. *Аны эзләп тормыйсың қул күзендә генә булса* – Кул астында гына булса, эзләп тормыйсың аны һ.б.

Тәмамлыклар инверсиясе: *Кертеп салғаннарын ишетмәдем дә, күрмәдем дә сине* (сине кертеп салганнарын...). *Бәрәңге бирдем бер бидерә сарыққа* – Сарыкка бер чиләк бәрәңге бирдем.

Ия инверсиясенә мисаллар: *Әрмийәгә китәр чақта малай* (малай армиягә киткән чакта)*, алты кила бал алдык. Әнә шулай итеп дөнҗаны көттек без* – Без әнә шулай итеп дөнья көттек. *Тегенән тын ужы киләләр, ди, атлы қазақлар* – Тегеннән атлы казаклар инде киләләр, ди.

Шулай итеп, Барда төбәге сөйдәшенең төп грамматик категорияләре татар әдәби телендәгечә. Шулай булса да анда характерлы гына диалекталь үзенчәлекләр бар. Аларны татар теленең башка сөйләшләренә мөнәсәбәтле рәвештә ике зур өлешкә бүләргә мөмкин.

1) Татар теленең башка сөйләшләре белән уртак үзенчәлекләр.

Башка сөйләшләр белән уртак булган грамматик үзенчәлекләрнең зур күпчелеге урта диалект сөйләшләрендә табыла.

Үзенең күп кенә архаик күренешләре (инфинитивның *-мага*/*-мәгә, -ма*/*-мә* формалары, нисбәтлекне белдерү алымнары, *-ныкы*/*-неке* кушымчалы сүзләрнең синтаксик функциясе, архаик изафә, *исә* теркәгеченең семантикасы һ.б.) буенча Барда төбәге татарлары сөйләше, бигрәк тә, подберезье керәшеннәре, нократ, касыйм сөйләшләре һәм көнчыгыш диалектлар белән зур уртаклык күрсәтә. Билгеле булганча, соңгылары үзләрендә борынгылыкны күбрәк саклап килүләре белән татар сөйләшләре арасында аерылып торалар. Күп кенә үзенчәлекләре буенча әлеге сөйләшләрнең бер-берсенә якын торуын башка галимнәр дә раслый.

Мондый күренеш Барда төбәге һәм, гомумән, пермь сөйләше таралган территориянең Идел буе татарлары тарафыннан үзләштерелүе вакыйгалары белән бәйләнгән булса кирәк.

Кайбер үзенчәлекләр һәм характерлы архаик күренешләр буенча бу сөйләшнең көнбатыш диалект белән дә уртаклыгы зур.

Өйрәнелә торган сөйләш өчен характерлы булган бер төркем үзенчәлекләр татар теленең тагын көнчыгыш диалектында гына күзәтеләләр. Шунысы характерлы, бу төр күренешләр сөйләшнең көнчыгыш төрки телләр (шор, хакас, алтай, кыргыз һ.б.) белән уртаклыгы булуын раслыйлар.

2) Татар теленең башка диалектларында әлегә билгеләнмәгән грамматик үзенчәлекләр.

Болар сөйләшнең спецификасын тәшкил итәләр һәм аны татар диалектлары системасында мөстәкыйль берәмлек итеп тануда зуррак роль уйныйлар. Югарыда күреп үткәнебезчә, Барда ягы сөйләшендә аларны байтак язып алырга туры килде.

Бу өлкәдә әлеге сөйләш өчен үзенчәлекле моментларның берсе – специфик характерда булган кайбер күренешләрнең башка төрки телләрдә чагыштырмача аз күзәтелүе һәм, аеруча, уйгыр телләрендә генә табылуы. Шулай итеп, сөйләштә бик борынгы күренешләр яшәп килә, алар, татар теле генә түгел, гомумән төрки телләрнең формалашу тарихын өйрәнү өчен дә гаять әһәмиятле.

### Лексик үзенчәлекләр

Билгеле тарихи шартларда мөстәкыйль сөйләш буларак формалашу дәверендә, Барда төбәге сөйләшенең үзенә хас лексик-

семантик системасы да барлыкка килгән. Ул, нигездә, татар телендәгечә. Бу төбәккә хас бай диалекталь лексика татар теленең диалектологик сүзлекләрендә (1969; 1993; 2009) чагылган. Генетик яктан караганда аның нигезен, асылда, гомумтатар сүзләре һәм аларның тамырлары тәшкил итә, икенче зур өлешен алынма сүзләр алып тора.

Гомумтатар сүзләре һәм аларның тамырлары Пермь татарлары сөйләшенә хас сүзлек фондының иң зур өлешен, төп байлыгын тәшкил итәләр. Билгеле, аларның күпчелеге татар әдәби теле белән уртак. Бер өлеше исә шушы җирле сөйләш өчен характерлы булган, ягъни әдәби телдән теге яки бу үзенчәлеге белән аерыла торган яки әдәби телдә бөтенләй табылмаган сүзләрдән – диалекталь лексикадан гыйбарәт.

Сөйләшнең диалекталь лексикасы бай һәм үз эчендә шактый катлаулы. Ул әдәби телгә мөнәсәбәтле рәвештә дә, татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштырып караганда да зур гына төрлелек күрсәтә.

Гомумтатар характерындагы диалекталь сүзләрнең бер өлеше әдәби телдәге шундый ук сүзләрдән әйтелешләре (андый формалар фонетика бүлегендә шактый тулы анализланды), формалашу алымнары белән аерыла, икенче өлеше исә сөйләштә таррак яки киңрәк мәгънәдә кулланыла. Формалары белән әдәби телгә туры килә торган сүзләрнең дә кайберләре сөйләштә башка төрлерәк мәгънә төсмере белдерергә мөмкин. Дөрес, мондый очракта сүзләрнең диалекталь һәм әдәби мәгънәләре бер-берсеннән артык ерак булмый, аларның күбесе бер төргә караган яки теге йә бу функциясе белән үзара бәйләнештә булган төшенчәләрне белдерә. Мәсәлән, әдәби телдәге *тубық* сүзе сөйләштә – *тез*, *җир җиләге* сүзе – *каен җиләге, қарағай* сүзе *нарат* мәгънәсендә йөри. Шушы ук төр сүзләрдән инде омонимлаша бара торганнары да бар: *тию* – 1) тию; 2) керү: – *Taw awылға да тийәмсез* – Тау авылына да керәсезме?; қуу – 1) куу; 2) иярү: – *Кума мине, сықтақсын, шапасын* – Ияреп йөрмә миңа, үзең елак, үзең шапшак; сақлау – 1) караныллау; 2) күтәп тору: – *Бетекий генә сақлаң мине, чығам қәзер* – Аз гына көтегез мине, чыгам хәзер; қатыру – 1) катыру, 2) камыр басу: – *Элек ачытабыз қамырны ачыганчи, ачығач, қатырабыз* – Камырны башта изеп әчетәбез, әчегәч, басабыз; *асрау* – бәбиләү һ.б.

Диалекталь сүзләрнең бер өлеше, әдәби телдә булмаса да, татар теленең башка сөйләшләрендә, аеруча, урта диалект сөйләшләрендә табыла. Шул исәптән, бары көнчыгыш диалект белән генә уртак сүзләрне аерым билгеләп үтү кирәк.

Әдәби телдә дә, татар теленең башка сөйләшләрендә дә табылмаган сүзләр Барда татарлары сөйләшенең спецификасын хасил итәләр. Билгеле, мондый сүзләрне бары шушы сөйләш өчен генә характерлы дип булмый, чөнки аларның күбесе башка төрки телләр материалында җиңел аңлатыла ала.

Пермь татарлары сөйләшенең формалашу үзенчәлекләре борынгы сүзләр яки формаларның сакланып калуына яки кайбер борынгы сүзләрнең мәгънә ягыннан башкачарак үсеш алуына да китергән.

Татар теленең төп диалектлары белән уртак булган сүзләрнең кайберләрен карап китик.

Нажғай//нәҗәқай (Барда районының көньяк авылларында, Манышта)//*назығыш* (Башкултайда)//*йылдырым* (Кояново) – әд. аҗаган, арыш камчысы. Мәсәлән: – *Нажақай уйный, диләр қартлар, арыш пешә, дип әйтәләр. – Төн озайса да, көн озайса да, назығыш уйный, төнгә уйный ул, болот та булмый.* Чагышт.: минзәлә сөйләшендә – *нажҗагай//нәҗәгай*, тау ягы сөйләшләрендә – *әҗәган*, казакъ – *найзагай*, каракалпак – *жылдырым*, азәрбайҗан – *илдырым*, төрек – *yıldırım*, төрекмән – *йылдырым* һ.б.

*Алама* – чүп, чүп-чар: – *Үкәртәдән аламаларны сеперреп түгәбез; таб алама* – йомычка, балта чүбе; *пычқалама* – пычкы чүбе. – *Табаламасы инде балтадан түгелгән, шул алама ағып пара йкән йылға буйлап.*

*Аймақ* – күп, ишле: *Аймақ кийемне қайсыли җертәсен* – Күп әйберне ничек йөртәсең. – *Без аймақ булдық, туғыз оланнар ийе без.* Аймақлап – күмәк, бергә-бергә, күп итеп. *Аймақлап чебеч қарадым.*

Сөйләшләрдә *аймак*: 1) төбәк, участок, урын; 2) нәсел, кабилә, ыру.

Төрки телләрдә дә шулай ук: бер төркем телләрдә (казакъ, кыргыз, каракалпак, шор һ.б.) – ил, край, территория, ә кайберләрендә (мәсәлән, якут, лобнор уйгырлары һәм шулай ук монгол телендә) нәсел, ыру, буын төшенчәсендә кулланыла, соңгысы – аның борынгырак мәгънәсе булса кирәк.

*Минтәү* – 1) бетеренү, өзлегү. Мәсәлән: *Минтәп қаласың чир артыннан.* 2) авырлык күрү, җәфалану: *Безнең суғыш waқытта сыйыр булды да балалар минтәмәделәр.*

Урта диалектның тау ягы сөйләшләрендә *миндәү* – миңгерәүләнү, аңгыралану; минзәлә һәм казан арты сөйләшләрендә авыру, имгәнү мәгънәсендә.

*Сағызақ//сағадақ* (сир.) – шөпшә; күчмә мәгънәдә: *сағызақ булу* – бәйләнчек, сырышкак (навязчивый) булу. Шушы ук мәгънәдә *сағызақ* сүзе тагын урта диалектның бөре сөйләшендә дә билгеләнеп үтелгән, башкорт телендә дә аның шундый ук мәгънәләре бар. Үзенең семантикасы һәм мәгънә үзенчәлеге белән *сағызақ* сүзе чыгтай һәм сары уйгыр телләрендәге ук савыты, кыны мәгънәсендә йөри торган *сағадақ, сағатақ, сағыдаққа* барып тоташа булса кирәк.

*Сарана* – түбәндә суган шикелле җимеше булган, озын сабаклы, зәңгәр чәчәкле үсемлек (русча: саранка). Урта диалектның минзәлә сөйләшендә һәм тагын алтай, якут телләрендә дә бар.

*Җиләү* – туйю, гарык булу. *Җиләтмә апаларын, кызым!*

Урта диалектның бөре сөйләшендә *җиләү* – туйю, бизү, башкорт телендә *еләү* – ару, талу, ялыгу. Э.Н.Пекарский күрсәтүенә караганда, якут телендәге *сыла* (арыганлык, алҗыганлык) сүзе алтай һәм телеут телендәге *чыла*, монгол телендәге «чile» сүзләре белән тамырдаш.

*Бүксә* – күлмәкнең кысасы, блузка; костюм да шулай аталырга мөмкин. Мәсәлән: – *Аңа кәчтүнен биргән: итәге белә бүксәсен.* – *Күлмәг имеш тим, бүксә генә алгансың да.*

*Қазақ* – ялгыз, ирсез, тол хатын. Урта диалектның бәрәңге сөйләшендә *казак кода* (ялгыз, өйләнмәгән кода) сүзенең барлыгы билгеле. Чагыштыру өчен тагын тархан сөйләшендәге *казак ат* (печтерелгән айгыр) сүзен дә китерергә мөмкин.

*Кутару* – төрле мәгънә төсмерләре белдерә: *Элекке мәчетне қутардық* (җимердек, сүттек). *Мичне қутарып салдырабыз* (сүтү). *Қутарылған мени тегерминнәре* (ватылу). *Қолағың қутарылған қый* (җәрәхәтләнү, ертылу). *Марсил исемен қутарып* (исемен бозып)*, үлгән малайлары исеменә кучерделәр.*

*Басма* – гади ситсы; *тәртешкә* – кисәү агачы; *айақ* – чынаяк чокыры, стакан; *чапчақ* – мичкә; *күмер чапчақ* – күмер савыты; *ипи чапчақ* – күәс чиләге; *пабитла чапчақ* – повидло савыты; *ашлы су чапчақ* – ашлы су салу өчен куелган зур савыт; *май чапчақ//әйрән чапчақ* – гөбе һ.б.

Татар әдәби телендә кулланылмаса да, *чапчак* сүз сөйләшләрдә шактый киң таралган: минзәлә, тау ягы, казан арты сөйләшләрен-

дә *чапчақ* – кисмәк; касыйм *чепчәк*; байкыбаш *цәпцәк,* хвалын, мәләкәс *чәпчәк* – шул ук мәгънәдә. Алтай теле диалектларында *сапчак* (абакан), *чапчак* (телеут), *шапчак* (кондома) – чиләк, кисмәк, шундый ук мәгънәдә ул тагын кыргыз, башкорт һ.б. телләрдә бар.

*Чәкчүр* – калын табанлы, чүәк кебегрәк итеп күннән эшләнгән аяк киеме. Чагышт.: минзәлә *чәпчүр* – ботинка, көнбатыш диалектның хвалын сөйләшендә *чакчур* – кәвеш.

*Чара табақ//чара* – зур агач табак. *Бер чара табақ аш!* Урта диалектның тау ягы сөйләшләрендә *чара* яки *чара табак* сүзләре шулай ук зур аш табагы, зур агач табак мәгънәсендә кулланыла. Бараба диалектында: чара – зур аш табагы, көнчыгыш диалектта: *цара//чара табак* – зур агач табак; касыйм сөйләшендә: *чара* – тагарак. Татар әдәби телендә бу сүз күзәтелми. Ләкин ул башка төрки телләрдә киң таралган һәм эчемлек, шәраб савыты, касә, тустаган төшенчәсен белдерә. П.М. Мелиоранский рус телендәге *чара* сүзен, төрки телләрдән монгол эпохасына кадәрге чорда кергән сүз, дип саный.

*Әпә* – телсез: *Чыгам диб әйтмәгә белми, әпә булып китте қый. Безнең монда күрше әпә, ымлашып кына шүләшә.*

Бу сүз аваз ияртеменә нигезләнеп ясалган һәм татар теле сөйләшләрендә еш очрый: урта диалектның казан арты сөйләшендә – *әпә* (телсез, чукрак), тархан сөйләшендә – *әпә* (телсез), көнбатыш диалектның мәләкәс сөйләшендә – *әбә* (телсез), чистай – *әпәтә* (сакау) сүзләренең барлыгы билгеле.

Китерелгән материаллар Барда төбәге татарлары сөйләшенең татар теленең төп диалектлары, аеруча, урта диалект белән зур уртаклыгы булуын күрсәтәләр. Монда бигрәк тә тормыш-көнкүреш, хуҗалык кирәк-яраклары, йорт җиһазлары белән бәйле булган лексиканың уртак икәнлеген билгеләп үтәргә кирәк.

Шушында ук бары көнчыгыш диалект белән генә уртак булган диалекталь сүзләргә дә тукталып үтик. Тематик яктан алар күбрәк тормыш-көнкүреш, хайваннар дөньясы һәм кайбер этник моментларга карыйлар. Бу төр сүзләр белән Барда төбәге сөйләше, Көнбатыш Себер һәм Бараба татарлары сөйләше белән генә түгел, бәлки борынгылыкны үзләрендә ныграк саклаган чуваш, якут, алтай, бурят һәм монгол телләренә дә барып тоташа. Шуларның кайберләренә тукталыйк.

*Баштақ* – шаян, тәртипсез, тиктормас, шук; *баштақлану* – шаяру, тәртипсезләнү, башбаштаклану. *Баштақ, үләр хәл, ул зыйан салмый йөрмәс, уйнамый утырмас. Баштақлана башласа, уқытучы апасына әйтербез әле.* Шушы ук сүзнең саңгырау ирен-ирен *п* тартык авазы белән башланган варианты Көнбатыш Себер татарлары сөйләшләрендә, алтай телендә дә бар: *паштак* – шалун.

*Терке* – яшь нарат. *Теркелекләр тау мендең исә күренә. Терке үсә, қартайғас, сагызланғас, қарағайға әйләнә.* Себер татарларында *терге* – яшь нарат. Фин-угыр һәм пермь телләреннән: манси *терӱ* – кечкенә нарат, мари *тыркэ* (нарат), ханты *teger* (нарат), удмурт *тэрег* (каратал) һ.б.

*Тет: тет ағач* – карагай агачы, татар теленең, шулай ук, көнчыгыш диалектларында гына билгеле. Ләкин ул көнчыгыш төрки телләрендә киң таралган сүз: алтай, хакас, шор, туза, тофа телләрендәге *тыт* һәм якут телендәге *тīт* (Э.К. Пекарский буенча) – карагай.

*Озан* – көртлек, кыр тавыгы. Себер татарлары диалектларында *осан* – көртлек, чувашларда *ăсан* – көртлек һ.б.

*Йоша/йуша* боланның бер төре. *Йуша* сүзе көнчыгыш диалектларда да күрсәтелгән.

*Өке* – филин (мәче башлы ябалакның бер төре). Себер диалектларында ул – *өгө.* Башка төрки телләрдә дә бу сүзнең актив яшәештә булуы күзгә ташлана: кырг. *уку*; к.-калп. *үки*; алтай теле диалектларында *ӧ̆гӧ̆, угу, уку, ӱгӱ*; башк. *өке*; хак. *ӱгӱ*; шор *ӱге//ӱгӱ*; каз. *үкі;* чув. *ӱхĕ* һ.б. Бу сүзне фин-угыр телләрендә дә очратырга мөмкин: удм. *шуралu//ыгы*; мари *ӱңгы(тау ягы) – филин***.**

*Чорғу* – а) насос эчәгесенең су сиптерүе: *Болары* (насос эчәгеләре) *чорғый суны теләсә қайа.*

б) ату, ыргыту: *Кәрәкмәс кәмпит тәғаж, чорға* (кирәкмәс конфет кәгазе, ыргыт). – *Тәрәзәдән чорғадым...* Себер татарлары телендә *чоргу, цыргу* – ату, ыргыту.

*Җөлү* – чәч алу: *Ирләр башларын җөлиләр, сақалларын. Бабайның чәчен җөлибез, дип өрәбез ий дә, бер мәсе дә қалмый аның* (тузганак турында). Татарча-русча сүзлектә чәч алу мәгънәсендәге *йолу* сүзе искергән сүз дип күрсәтелгән. Көнчыгыш диалектта *йөлү*: 1) җирне үләннән тазарту, 2) йолку. Чагыштыру өчен, тагын әдәби телдәге *йолу* (бәладән), *йолку* сүзен дә китерергә мөмкин.

*Тәwлек* – ел әйләнәсе. *Дүртенче тәwлек мыса, синтәбердә дүртәw буладыр*. Димәк, көнчыгыш диалектлардагы кебек үк, әлеге төбәктә дә *тәwлек* сүзенең эчтәлеге әдәби тел белән чагыштырганда башкачарак.

*Курҗаw//қурйым//қурлық* – ачыткы. Мәсәлән: – *Курҗым ачытқы була инде икмәкнекеме, балнықымы. – Кичә ачытып қуйдым қый мин аны қурҗаwға дип, икмәк қурҗым. – Курлығы, диб әйтәләр башын* (икмәкнең), *қурлық йасыйбыз, диләр баш йасағанда*.

*Қурлық* сүзе әдәби телдәге мая мәгънәсендә дә кулланыла: – *Қурлығы да қалмад инде ақчаның. Қурлық қую* – мая кую.

Себер (Бараба, Тобол, Тара) татарлары телендә бу сүзнең семантик функциясе тагын да киңрәк: *кур* – камыр; *курлы бавырсак* – әчегән камырдан пешерелгән ашамлыкның бер төре; *кур чиләк* – күәс чиләге; *курыклык* – 1) азык юлы, 2) аш казаны.

*Нәгәр//кийәwнәгәр* – кияү егете. *Кийәwнәгәр була, җырға оста кеше. – Бал күнәккә қулҗаwлык җабалармы, тастымалмы, кийәwнәгәр ақча салып ала аны.*

*Чийу* – сызу. Йазуны чийды да қуйды (сызды да атты). *Чима* – шырпы. *Чима чийу* – шырпы сызу. *Чима қап* – шырпы кабы. *Ала да чакма таш белән чийа. – Чима бир әле, қараңгы*.

Бу сүз татар теленең шулай ук көнчыгыш диалектларында гына билгеләнгән. Шор, хакас, тува, алтай, караим һәм башка телләрдә бар.

Пермь татарлары сөйләше – территориаль яктан төп татар халкыннан читтә, башка төр халыклар белән чолганган хәлдә формалашкан сөйләшнең берсе. Мондый факторлар Барда төбәге сөйләшендә дә борынгы сүзләрнең сакланып калуына китерә.

Борынгы сүзләрнең кайберләре татар әдәби телендә парлы сүз тезмәләре составында өстәмә мәгънә төсмере бирә торган компонент буларак кына сакланып калганнар. Мәсәлән, шундыйлардан *сықтау* – елау. *У сықтый, мин сықтыйм ул киткән чақта. Хәзер уқып җиппәрәм, сықтап җиппәресез.* Сықтақ – әд. елак: *Йаратып тормийым әле, сықтақсын. Сықтау, сықтақ* сүзләре татар теленең көнчыгыш диалектында да күрсәтелгән. Борынгы *сығ* тамырыннан тагын пенза мишәрләрендә *сыкрану* – яшь чыгармыйча елау, хвалын мишәрләрендә *сыхрау* – ыңгырашу, әдәби телдә *сыкрау* – сызлау сүзләрен китерергә мөмкин.

Борынгы язмаларда *сықтау* сүзе, фигыль буларак, *елау* сүзе белән янәшә йөргән һәм үкереп елау, бик каты елау төшенчәсен белдергән булса кирәк. *Сықтау* сүзе, мөстәкыйль лексик берәмлек буларак, тагын алтай, шор, якут, кыргыз һ.б. телләрдә очрый. Хакас телендә *сықтау* һәм *елау* сүзләре параллель кулланыла.

*Қодоқ* – бәке. Бер яктан, бу сүз хәзерге татар әдәби телендәге кое сүзенең борынгы формасы. Борынгы язма истәлекләрдә *adaq, adyyr, adyy, qadyu, quduy* һ.б. шундый формаларда йөргән кайбер сүзләрдәге d авазы татар телендә *й* сонантына үзгәргән: *айақ, айу, айгыр, кайгы, койо* һ.б.

Тикшерелә торган сөйләштә *қодоқ* сүзе сузыкларның әйтелеше һәм соңгы иҗектәге тартык авазның сакланып килүе белән борынгы формадан аерыла. Димәк, тартыклары белән бу сүз көнчыгыш диалекттагы *қотық,* башкорт телендәне *қоҙоқ,* казакъ телендәге *құдық*, тува һәм хамий уйгырлары телендәге *кудук*, алтай телендәге *кутук* сүзләренә якын тора, ә сузыкларда инде башкорт һәм татар телләре өчен характерлы булган *у>о* күчеше күзәтелә.

Икенче яктан, сөйләштәге *қодоқ* сүзе үзенең семантик функциясе белән дә әдәби телдән аерыла. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, бу сүз үзенең төп мәгънә үзенчәлеген саклаган һәм кое төшенчәсен белдерә. Ә пермь сөйләшендә *қодоқ* сүзе бәкене белдерә һәм бу яктан башкорт теленең әй-йерүзән сөйләше белән уртаклык күрсәтә. Әдәби мәгънәдәге кое сүзе исә сөйләшкә казан татарлары белән соңгырак чорда килгән булырга мөмкин.

Сүзнең билгеле шартларда башкачарак үсеш алуына мисал итеп урығ тамырыннан булган сүзләрне күрсәтергә мөмкин.

*Орғау* – 1) өргәү – самоварның көйрәве: *Самуwарың өргәтә алмыйсың;* 2) чирнең азуы: *Бүлничкә барың сез орғамас боро;* 3) үрчү, арту, күбәю. *Быйыл берсенең дә өргәмәде қаз. Башлап ике генә кеше килеп утырған да орғаганнар да орғаганнар артаба.*

*Орғау* сүзенең сөйләштә бала табу төшенчәсен белдерүе шул ук үрчү мәгънәсенә кайтып кала. *Ылычтан* (авыл исеме) *аwырлы булып килдем, артаба монда килгәч орғадым. Малай орғаған* һ.б.

*Орғау* сүзе, үз чиратында, яңа сүзләр ясалуда да нигез булган. Мәсәлән, сөйләштә *өргәчел* – үрчемле: *шундый өргәчел ийе сарықлары, икешәрне-өчәрне бәрәнни торғаннар ийе.* Шуннан чыгтай *урғачи*, кыргыз *урғашы, урғачы* – хатын кыз яки ана хайван, үзбәк *урғочи* – ана хайван; башкорт *орғасы* – йорт хайваннарының

ана булганы; монгол *ургац* – уңыш, үсемлекнең үсү дәрәҗәсе сүзләре ясалган.

*Ору* сүзе хатын-кызның бала табарга сәләте мәгънәсендә тагын *оруwы беткән, оруwы йуқ, оруwы туқтау* кебек тәгъбирләрдә очрый: *Картайған, оруwы беткән қатын инде.*

*Иләсә* – бияләй: *Кулына кимәгә иләсәсе йуғ ыйы, айағына кимәгә кийестеге йуғ ыйы.*

*Иләсә* сүзе борынгы *äl* тамырыннан татар әдәби телендәге җиңсә, беләксә, күкрәкчә, муенса кебек сүзләр моделендә ясалган. Аның *илик* формасы хамий уйгырлары лобнор телендә кул, алтай телендә бияләй мәгънәләрендә сакланып калган. *Elik* – бармак, сары уйгырларда *елығ* – кул. Ләкин күпчелек төрки телләргә илик сүзенең редукцияләнгән формалары хас. Мәсәлән, якут телендә *к(г)* авазы йотылып озын сузык барлыкка килгән *илии* һәм *алии* (Э.К. Пекарский буенча). Билгеле булганча, мондый төр озын сузыклар кыскаручан булалар һәм чуваш телендәге *алă//ал* (кул) сүзендә шул этап чагылган булса кирәк. Хәзерге угыз телләрендә *эл* – кул. *Иләсә* сүзенең эл тамырыннан булуына тагын бер дәлил итеп чуваш телендәге ăлса – бияләй сүзен дә күрсәтергә мөмкин. Тикшерелә торган сөйләштәге *иләсә* сүзе билгеле бер чорда, ягъни борынгы *ä/i/lig* сүзе кайбер фонетик үзгәрешләр кичергәннән соң формалашкан булырга тиеш.

Әдәби тел белән чагыштырганда сөйләштә башкачарак мәгънә төсмерләре белдерә торган сүзләрдән тагын *сыр* (әдәби телдә – бизәк, резьба, ә сөйләштә – буяу); *ил* (әдәби телдә халык, дәүләт мәгънәсендә, ә сөйләштә ул тагын башка авыл мәгънәсендә дә. Чагыштыр: анатолий төрекләрендә *эl* – чит кешеләр), *қаwдан* (әдәби телгә узган елдан калган үлән мәгънәсендә кереп бара, ә сөйләштә моңардан кала тагын елан кабыгы төшенчәсен дә белдерә), *ару* (әдәби телдә чиста, әйбәт, яхшы, ә сөйләштә тагын арулау – мәетне юу) һәм башка шундыйларны санап китә алабыз.

Кайбер борынгы сүзләр сөйләштә үзләренең төп специфик үзенчәлекләрен саклап калганнар. Мәсәлән, *олау* – ялгау, кушу, өстәү, тоташтыру: *Җиңенә оларбыз, ише барыйы қый. Малайы чилсәwиттә олаттық.* Хәзерге вакытта татар, казакъ, каракалпак, тува, алтай, хакас, якут һ.б. телләрдә дә бу сүз, нигездә, кушып озынайту, өстәү, ялгау, тоташтыру мәгънәләрендә йөри.

*Күнәк* – каен тузыннан ясалган цилиндр формалы савыт, *тоз күнәк* – тоз савыты. *Күнәк* сүзе борынгы язмаларда *кöпäк, кöŋäк*

формаларында йөргән. *Тасқақ* сүзе Барда татарларында, күбесенчә, *тасқағ ас: – Тасқағ асқа йаwып куйған.*

Шушы рәвешле борынгы мәгънә төсмерләрен саклап килә торган һәм мөстәкыйль кулланылышта булган сүзләрне тагын да дәвам итәргә мөмкин: *кул* – чокырлы урын, *йийу* – ашау, *инү* – керү (мәсәлән, *мунча инү* сүз тезмәсендә), *абышка* – ир, *җаwрын* – иңбаш һ.б.

Татар әдәби телендә һәм аның җирле сөйләшләрендә әлегә табылмаган, ә тикшерә торган сөйләштә актив кулланылышта булган сүзләрдән тагын бер төркемен китерик.

*Арчалау* – 1) сугышкан кешеләрне аеру, аралау. – *Тегесе малайы минем бөтен думымны қырды, күршеләр арчалады;* 2) берәр хатын-кызның кеше ирен аерып алуы; 3) кайгы-хәсрәттән котылу. – *Әдәм башларына эшләр төшсә, Хақ Тәғәлә үзең арчала* (халык җыры).

Бу сүз тагын башкорт, казакъ, кыргыз, хакас һ.б. телләрдә бар.

*Чүрә* – тирә; *чүрәли* – тирәли. – *Ызба чүрәдә эш күп. Чүрәли күммә кәрәк ызбаны. – Утырдығ өстәл чүрәгә.*Чуваш, караим, уйгыр һ.б. телләрдә бар.

*Тоқон, топ-тоқон* – ябык, йомык, ачыгы-тишеге булмаган (әйбер). *Тоқон кулча* – божра. *Тоқон итеп бәйләү* – бауның ике башын кара-каршы бәйләү. Чымылдыкны тоқоннап бәйләү – чыбылдыкны түшәмнән идәнгә тоташтырып ачык урын калдырмыйча кору. *Тоқон* сүзе исем буларак та кулланыла: кечкенә җылы абзар. *Тоқон қарта* – сукыр эчәк һ.б.

*Арғыш* – кызны озата баручы парлы кунаклар: *Кыз кешенең туганы арғыш булып бара. Арғышлар, өндәwлеләр бергә баралар қыз озатқанда, ирмәғ итеп.* Хакас, шор, алтай телләрендә бу сүз иптәш мәгънәсендә; якутларда *аргыс* – юлдаш.

*Зумнау* – агачны кирәкле үлчәүдә һәм формада кисеп әзерләп кую.

*Қақлығу* – салулау. *Қақлығып төшеп киткән чанасы җег утыны белән*. Казакъ, башкорт телләрендә бар.

*Кипләнү* – әйбернең тар урынга кереп кысылып калуы: О*йа тишегенә барып кипләнеп керәлми үлеп яталар кумаклар дару сипкәч.* Чагышт.: *кара калпак кепле, кыргыз keptel* һ.б.

*Меңге* – акча, мөмкинлек, байлык: Меңгең бармы соң? Тува, алтай, якут, сары уйгыр, бурят, монгол телләрендә шушы ук сүз көмеш мәгънәсендә кулланыла.

*Тапчыҡ//таб алама* – йомычка. Чагышт.: как. *тап//тапчых*, алт. *табы, табылан, тап, тапкай, такпай*, башк. *тапсыҡ* – йомычка.

*Тырҡыш* – пычрак. *Тырҡу* – пычрату. *Тимә! Тырҡыйсың чүмичне. Мынчада бик тырҡыш, пычыраҡ, мәтерүшкәне мынчаға алып керү йазыҡ.*

*Уҡсын* – сарымсак. Алтай, башкорт телләрендә бар.

Сөйләш өчен специфик булган сүзләрдән тагын *әнтәк* – сукыр тычкан, *йарымтыҡ* – шүрәле, *шырамта* – юыну өчен туралган мунчала, *чыбыту* – сүтү, таҡылайу – тазару, сәламәтләнү, *аҡшағ ас* – тез асты, *ҡоно* – мәчесыман ерткыч һ.б. сүзләрне күрсәтергә мөмкин.

## Алынма сүзләр

Барда төбәгендә, пермь сөйләшендәге кебек, төрки тамырлардан һәм сүзләрдән кала, икенче зур төркемне алынма сүзләр тәшкил итә. Билгеле булганча, алынма сүзләрнең составы һәм күләме, беренчедән, тормыш-көнкүрешнең үзгәрүе нәтиҗәсендә туган яңа әйберләрне яки күренешләрне белдерә торган яңа төшенчәләргә мохтаҗлык туу, икенчедән, башка халыклар белән иҗтимагыйсәяси, икъдисади-мәдәни, сәүдә һәм башка шундый мөнәсәбәтләргә керү кебек факторлар белән билгеләнә.

**Рус теленнән кергән сүзләр.** Күләм ягыннан алар урта диалектның башка сөйләшләре белән бер чамада диярлек, ләкин бу уңайдан урта диалектта татар сүзләре белән йөртелә торган бер төркем төшенчәләрнең Барда төбәге телендә рус сүзләре белән белдерелүен күрсәтергә мөмкин.

Мәсәлән, *пытылук//пытлук* – түшәм. *Идән-пытлукларын сырлаған* (буяган).

*Заwал'нә* – нигез. *Бездә заwал'нәне күммиләр, эстина черемәсен дип* (бу сүз сирәк).

*Кезнеч* – тимерче; тимерче алачыгы. *Кезнечтә эшли бабайым, төшлеккә ҡайтаwы.*

*Мылток* – чүкеч; *Мылток беле тебедем дә мичкә ордом.*

*Дум* – өй, хуҗалык. *Электән утызлап ҡына дум булған монда.*

*Пумич* – өмә. *Пумич йасыйсың ызбаны күтәргәндә. Орчоҡ пумич тиб әйтәбез ий, ҡышҡыда була йы, тене беле утырабыз ий.* Рус телендәге помочь сүзеннән.

*Пачна сату* – сөйләшеп утыру, ләчтит сату. *Идийалы эшләми қайтқан, пачна сатып йаталар ийе үләрендә.* Рус телендәге басня сүзеннән.

*Миста* – урын. *Сыwық миста, бүлнистә йатам дип йазды малайым. Бол ызбаның мистасындамы?*

*Бырат* – туган. *Туғыз быратлар булғаннар. Үзе түгел, хатыны бырат мийе.*

*Пәтәкә, пуруда, пыртсуwа* – нәсел, кардәш-ыру. *Аның пәтәкәсе, Алла сақласын, усал, йаматай. Безне Солтан портсуwасы диб әйтәләр.*

*Гурбайу* – бөкрәю. *Менә урақ белән гурбайыб урасың ий.*

*Пәчкитләү* – пычрату. *Майығызны алып қуйың, чебен пәчкитләмәсен.*

*Ышкул* – мәктәп. *Ышкулға керер бала йы, суға ақты йазғыда. Ышкул эшлиләр йаңыны.*

*Ладум* – дөрес, яраклы итеп. *Күңгернеке бырачлар ладум бирмәгәннәр ыспыравканы.*

Санап кителгән сүзләр сөйләштә актив кулланылалар һәм, мисаллардан күргәнебезчә, алар грамматик күрсәткечләр алырга яки яңа сүзләр ясауда нигез булып хезмәт итәргә мөмкин.

Рус халкы белән аралашу берничә гасырлар буе дәвам итеп килгән һәм шуңа күрә рус теленнән кергән алынмалар, гадәттә, икегә бүлеп каралалар.

I. Октябрь революциясенә кадәр кергән сүзләр, нигездә, тормыш-көнкүреш һәм хуҗалык эшләренә карыйлар. Аларны тематик яктан берничә төркемгә бүләргә мөмкин.

1) Тормыш-көнкүреш, игенчелек һәм башка төрле хуҗалык эшләре белән бәйле булган сүзләр: *пирез* (җир үлчәү берәмлеге), *шажень* (сажень), *душ* (бер җанга тигән җир), *буразна*, *әбен* (әвен), *җичмин* (ячмень), *гәрәчүкә* (гречуха), тулчийә (тегермәннең ашлык кизәү өчен эшләнгән өлеше), *герән* (грань), *дулгуша* – арба төре; *күләсә, турбичә, палыч, тулка* (тәгәрмәч белән бәйле терминнар), *бутала* (ботало), *эрчәк//әрчәк* (рычаг), *пабуска* (өсте ябулы арба), *нажҗум* (назем), *пултинә* (плотина), *гурбуша* (чалгы төре), *Илә көн* (Ильин день), *былаwышинҗә* (благовещение – көн исеме), *мекриҗләнү* (хайванның аягына, буынына су җыелу) һ.б.;

2) йорт һәм каралтылар, аларны эшләү белән бәйле сүзләр: *ызба*, *пудбал'ник* (өй стенасының беренче бүрәнәсе), *лүҗәнкә* (мич-

нең төтене турыдан-туры чыкмасын өчен, морҗада эшләнә торган борылыш), *уграт* (ишек алды), *лаука* (мунча ләүкәсе), *гернәчә* (өйалдында күтәрмәдән менгәч ясалган урын, анда өстәл дә булырга мөмкин), *керәнте* (кран сүзенең диалекталь крант формасыннан), *гелбич* (подпол) һ.б.

3) йорт җиһазлары, савыт-саба һәм башкалар белән бәйле сүзләр: *бидрә, чегин, ыстукан* (стакан), *мичкә* (миски), *пичкә/печкә* (бочка), *гәрәчин* (керосин), *тас* (таза), *самуwар, ыштур* (тәрәзә кашагасы), *манжит* (шулай ук), *шамбир* (күгән) һ.б.;

4) кием салым: *wахилә* (вахилы – аяк киеменең бер төре, сөйләштә зур резинка галош дип аңлаталар), *кәлүшә* (галош), *пырзумит* (позумент), *запун, парочкы* (костюм; чалбар яки юбка белән), *түрик* (кәтүк) һ.б.;

5) азык-төлек: *кѝдрә читләwеге, кәртүк//картуп*; *мәрәкән кәртүк* (кызыл бәрәңгенең бер төре), *кәлигә* (шалкан), *пучиңкә* (мичтә пешерелгән гәрәнкә) һ.б.;

6) урман (флора, фауна) һәм урман эшләре: *мулем* (моль сүзеннән, агач агызу ысулы), *тубил, пумил* (яшь ылыслы агачлар), *дырман* (тилбәрән), *печтек/бечтек/мечтек* (пестик), *биләңке, гериҗ/герүҗ* (гөмбә исемнәре), *мелек*/маләк; әд. чукмарбаш) һ.б.

Хәрби хезмәт, сәнәгать, сәүдә, мәдәни һәм икътисади мөнәсәбәтләр, администрация, идарә эшләре белән бәйле сүзләрнең бер өлеше тормыш-көнкүрештәге иҗтимагый процессларга бәйле рәвештә искергәннәр яки пассив сүзләр рәтенә күчкәннәр. Мәсәлән: *өйәз, никерт* (рекрут), *зимнәмир, үрәтник, кантун, фитфибел* (фельдфебель) һ.б.

Октябрь революциясенә кадәрге рус алынмалары турыдан-туры сөйләм теле аша кергәннәр һәм, татар теленең специфик фонетик закончалыкларына буйсындырылып, шактый сизелерлек фонетик-морфологик үзгәрешләргә дучар булганнар. Аларның бер өлеше татар телендә бик күптәннән яшәп килә һәм әдәби телнең төп сүзлек составында да урын алган.

Рус алынмалары өчен характерлы булган икенче үзенчәлек – аларда җирле рус сөйләшләренә хас диалекталь күренешләрнең чагылуы. Билгеле булганча, төп аралашу коралы булып, беренче чиратта, сөйләм теле хезмәт итә һәм, шуңа күрә дә, теге яки бу сөйләшкә рус теленең шушы тирәдә үк таралган сөйләше йогынты ясый. Менә бу закончалык Урта Урал тирәсендә таралган

рус сөйләшләре өчен характерлы булган диалекталь сүзләр яки формаларның урнашып калуына китергән. Мәсәлән, татар әдәби телендәге самовар сүзе самуwар дип әйтелә. Монда, һичшиксез, җирле рус сөйләшләренә хас *о*-лаштыру күренеше чагыла. *Гәрәчүкә, чәйгун, көрәнтә, шукетерит итү* сүзләре дә шушы тирәдә таралган рус сөйләшләрендә күзәтелә торган диалекталь формалар: *гречуха, чайгон, крант, шукетерить.*

Җирле рус сөйләшләреннән бер төркем диалекталь сүзләр дә кергән.

*Бутала* (рус. ботало) – туры почмаклы формадагы зур металл кыңгырау. *Бабушка* (рус. бабушка) – кендек әбие. *Нажҹым* – тирес, *нажҹым сәнәк* – сәнәк (рус. назем). *Бида* – татар сөйләшләрендә дә, рус сөйләшләрендә дә көчәйткеч кисәкчә буларак кулланыла, әдәби телдәге бик, нык сүзләренә туры килә. *Бида* (бик) *ҟыйын ҟый. Шуны ки дә бида ҟызарсың* (бик нык җылынырсың). Шунысы характерлы, бу сүз шушы ук функциядә башкорт сөйләшләрендә һәм тагын коми теленең язьва диалектында да таралган. *Дырапач*// *тырапач* – өчпочмаклы җир тырмасы. Урта Урал тирәсендәге рус сөйләшләрендә *драпач* – тырма. *Дукил* – бик ерак, бик озак. *Арта шул көйгә ңукил ҟалтыратты, дукил ҟалтыратты. Кул буйы дукил бардыҟ, шоморот тапмадыҟ.*

II. Октябрь революциясеннән соңгы чорда да сөйләшкә рус сүзләренең сөйләм теле аша керүе дәвам итә: *калхоз, сапхуз, фирмә//бирмә, туртармийә* (трудовая армия сүзеннән кыскартылган: трудармия), *туритнә* (трудодень), *саwит, кулып//кылуп, әгитәтер* (агитатор), *параwыз, сәмәлүт* (самолет), *касманат, камунис, фартийанный, бергадир, ражҹийә, тилебизор, тырактыр, тырамбай, «доружба»* (моторлы пычкы), *салфиткә* һ.б. Совет чорында кергән рус сүзләре, эчтәлекләре генә түгел, форма ягыннан кичергән үзгәрешләре белән дә беренче чорда кергән сүзләрдән берникадәр аерылалар, чөнки алар язма тел (мәктәп, матбугат һ.б.ш.) аша да керәләр, аларны әдәби әйләнештә кабул итүгә омтылыш сизелә. Билгеле, бу үзенчәлек хәзерге көндә, күбрәк, яшь буын һәм интеллигенция теленә хас.

Кайбер төрки (татар) сүзләрнең башта рус телендә, рус теленнән яңадан төрки телләргә кайту очраклары билгеле. Сөйләштә шундыйлардан *чөгөн* (чуен), *такта түшәмә* (борондок), *чөлкә, пирук//бирук* сүзләрен санап китәргә мөмкин.

**Гарәп, фарсы телләреннән кергән сүзләр,** нигездә, фән, дин, сәясәт, мәдәният белән бәйле сүзләрне тәшкил итәләр.

а) Дин, төрле мифик җан ияләре белән бәйле сүзләр: *Алла, мәчит* (мәчет), *молла* (мулла), *ислам, зәқмәт* (зәхмәт), *иблис, мәзин, мөселман сawап, сиқыр* (сихер), *шайтан, шәригәт* һ.б. Фарсы: *Қодай* (Ходай) һ.б.

б) Фән, мәдәният һәм иҗтимагый тормыш белән бәйле сүзләр: *дәфтәр, т'әггаҗ* (кәгазь), *милләт, сәқнә* (сәхнә), *қалық* (халык), *қәреп* (хәреф), *хөкүмәт, китап* һ.б.

в) Гарәп-фарсы алынмаларының шактый зур өлеше абстракт мәгънәле төшенчәләрне тәшкил итәләр: *ақыл, awa* (һава), *дөнҗа, гәдәт, гәҗәп, газап, хыйал, гумер, эрәқәт* (рәхәт), *қәл* (хәл), *пайда* (файда), *рәwеш, уш* (һуш), енәр (һөнәр), *бәқыт* (бәхет), *дус, дошман, дәрес, өмет, қыйбат, әмәл* һ.б.

г) Төрле көнкүреш әйберләренең исемнәре: *шалбар, тастымал, сандық, пәрдә, шешә, тирәзә, гөл, сәгәт, ырзық* (ризык), *шәрбәт, һәйкәл* һ.б.

Гарәп фарсы алынмаларының күләме ягыннан Барда төбәге сөйләше башка сөйләшләрдән аерылмый, дияргә мөмкин. Тик шунысы характерлы, әдәби телдәге кайбер гарәп-фарсы сүзләре урынына сөйләштә төрки сүзләр яки рус алынмалары кулланыла.

| **Әдәби телдә:** | **Сөйләштә:** |
|---|---|
| очсыз//арзан | очоз |
| мәктәп | ышкул |
| пыяла | көмешкә//шешә |
| гариза | прошение яки зийәвлинҗе |
| ятим | үксез |
| танык (искерг.); шаһит | танык |
| зарар, зыян | пукач//зыян |
| идарә | пыраwлинҗә |
| инкарь итү | тану һ.б. |

Бер төркем гарәп-фарсы алынмалары әдәби телдән әйтелешләре белән генә аерылалар: *лайық* – әд. лаеклы; *дисбе* – әд. тәсбих һ.б.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең кайберләре телдәге шундый ук сүзләргә мәгънә төсмерләре буенча туры килеп бетмәскә мөмкин. Мәсәлән, *эшкәрә* сүзенең фарсы телендә (эшкяре) ике мәгънәсе бар: 1) ачык, ачыктан-ачык, яшермәстән, күз алдында;

2) кычкырып. Татар әдәби телендә бу сүз кулланылыштан төшеп калган. Барда төбәге сөйләшендә исә аның семантик функциясе шактый үзенчәлекле: ул берәр кеше бәхетсезлеккә, уңышсызлыкка очраганда икенче кешенең сөенеп, шатланып әйтә торган «шулай кирәк» дигән тәгъбиргә туры килә: *Ай эшкәрә булды қый йығылып, пийеп башлад ийе* – Ай кызык булды егылуы, биеп башлаган иде).

Тубыл-иртеш диалектында ***әшкәрә*** сүзе көчәйткеч кисәкчәсе функциясендә кулланыла һәм әдәби телдәге бик сүзенә туры килә. Шунысын да күрсәтеп үтәргә кирәк, казакъ теленең кайбер сөйләшләрендә дә бу сүзнең шундый ук мәгънәсе билгеләнеп үтелгән. Пенза мишәрләре телендә: *эшкәрә булу* – ачык мәгълүм булу, ягъни фарсы телендәге мәгънәсенә якын. Каракалпак телендә дә бу сүз шул ук мәгънәдә урнашкан: *эшкара* – ачыктан-ачык, күренеп тора торган; эшкара бол – фаш булу.

*Дәрмешлек* – фәкыйрьлек, ярлылык. *Королай себерсәң, барғайуққа сызғырынсаң дәрмешлек килә, ишектән башлап элгәре таба себеренсәң...* Татар әдәби телендә дәрвиш – 1) чүлдә ялгыз яшәүче, аскет; 2) кешеләр белән аралашмаучы кеше һ.б. Ә фарсы телендә дәрвиш сүзе берничә мәгънәдә кулланыла: 1) дәрвиш (ягъни, татар әдәби телендәгечә); 2) бернәрсәгә дә исе китми йөрүче, дөньядан кул селтәгән кеше; 3) фәкыйрь, ярлы кеше. Димәк, Пермь татарлары телендә әлеге сүз шушы өченче мәгънәсендә сакланган.

*Мысқалтабақ* сүзе шулай ук үзенчәлекле генә. Әдәби телдә ул, гарәп телендәге кебек үк, 4,25 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге. Ә тикшерелә торган сөйләштә бу сүз авырлык үлчәү приборын – кечкенә үлчәүне белдерә. Шулай ук бәрәңге сөйләшендә *мыскал* – кечкенә үлчәү.

*Заман*. Татар теленең нократ сөйләшендәге *заман*, көнбатыш диалекттагы *замат* сүзләре кебек, ул – тиз, хәзер, бик тиз генә, момент төшенчәсен белдерә: *Өйдә тороң, қайтыр заман. Заман киләдер, бүгенме-иртәме дип торалар.*

Гарәп-фарсы алынмаларының кайберләре сөйләшнең үзенчәлеген хасил итәләр:

*Әргиз* (< фарсы *нәргиз*) – беркайчан да, бер дә, һич тә: *Әргиз күргәнем йуқ.* – Бер дә күргәнем юк. *Әргиз аңнамыйм* (һич аңламыйм). Башка сөйләшләрдә билгеләнмәгән. *Нәқыс* – 1) тар; 2) житмәү. *Ишекләре нәқыс, керәлмәм* (хал. жыры). *Анда жир нәқыс өчен монда килә башлағаннар. Ақчаң булмағач, тормыш нәқыс инде.*

*Шулай ук минзәлә сөйләшендә дә Хәттин ашқан* – чиктән ашкан, ягъни бигрәк яхшы һ.б.: *Ат җиккәннәр хәттин ашқанны. Нықый шул хатынны алд ийе, хәттин ашқан. Байығып петтеләр, ызбалары хәттин ашқан.* Гарәпчә *хәддә* – чик (край, предел).

*Кәбен* – никах. *Элек моллалар кәбен уқымый қыйышалар ийе, унсигез тулмый тороп.* Фарсы *кябин* – 1) никях, туй; 2) калым, мәһәр. Урта диалектның бәрәңге сөйләшендә кәбен – никах; бигрәк тә керәшен татарларында актив: кәбен – туй; зәй керәшеннәрендә кәбен кыю – кияү белән бикәчне кавыштыру; малмыж *кәбен кою*// *кәбен уку* – никах уку; нократ *кәбен салу* (никах уку) һ.б.

*Бахырниса*//*бәхырниса* – бака (бары Барда төбәгендә генә күзәтелә): *Суwық тотса, бәхерниса күрсәтәләр қурықсын өчен. Бәхырниса*//*бахырниса < бәхер – ниса* – хатыннар, хатын-кыз.

*Бәхер, һәргиз* сүзләрен татар язма әдәби телендә унтугызынчы йөзгә кадәр очратабыз.

*Аның имен һич утачы белмәгәй,*
*Нәчә дару куйса, һәргиз уңмагай.*
*(Төхфәи мәрдан, 388 б.)*

*Бәхре гыйсъян эчрә булмаса кәми,*
*Мешкел ул чыккай сәламәт би кәми.*
*(Төхфәи мәрдан, 390 б.)*

*Мәвеҗ кылса бу күңелнең бәхре кайнап...*
*Мән гафильне дөнья таба арткан ирмеш,*
*Бу халәтне һәргиз белмәй калдым, дуслар.*
*(Мәүлә Колый).*

*Атарларди хаҗәр аның йөзигә,*
*Инанмазлар иде һәргиз сүзигә.*
*Чумып бәхре хәзамга дерләр алдым,*
*Гамәл кылмак өчен күксемгә салдым.*
*(Утыз Имәни).*

*Әя җаным, ике күзем, кызыл алмам,*
*Сәндин гайре кемсәне һәргиз алмам.*
*(Г. Кандалый).*

*Ниш(ш)ан* – бик (кечерәйткеч сүз). *Бездә нишан күб инде өмеҗе.* Кура җиләге бездә бик күп инде. *Нишан оло бабай йе ул* – Бик карт бабай иде ул һ.б.

**Фин-угыр телләреннән кергән сүзләр.** Барда төбәге сөйлә_шендә өченче, күләм ягыннан иң кечкенә төркемне тәшкил итә. Алар уртак географик тирәлек, күп еллар бергә гомер итү, тормыш тәҗрибәсе алышу барышында кергәннәр, тематик яктан, нигездә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына карыйлар.

*Өмеҗе//меҗе//әмеҗе* – кура җиләге. *Өмеҗелек* – кура җиләклек. *Өмеҗе пирук* – эченә кура җиләге салып пешергән пирог һ.б.ш. Чагыштыр: удмурт *эмезь*, коми *өмидз* – кура җиләге. Мисаллар: *Бер чақырым бардың исә – өмеҗелек. Бырач қыз мәйтәм қайчан ара килеп төшкән, әле өмеҗедә қалдийы.*

*Мал'.* Барда төбәге татарларында бу сүз нарат җиләген белдерә. *Мал' башта җәшел була, аннан қызара.* Коми *моль* (рус. бусинка, перл), ә җирле сөйләшләрдә аның күп төрле мәгънә төсмерләре бар: ‘төймә’, ‘түгәрәк металл’, ‘балыкның умырткасы’ һ.б.; кушма сүз составында килгәндә мүк җиләге төшенчәсен белдерә: *термул'и, тури мул'и, ’нурыол, кадмол, тури мол.* Удмурт *’нурму'лы* – шулай ук мүк җиләге, мари *миδǝ̂, моδǝ̂* (җиләк, кара җиләк), ханты *тәt',* манси телендәге *тәl'* сүзләрен *моль* сүзе белән тамырдаш дип саныйлар.

*Түни.* Бу сүз Барда татарларында кыска кунычлы һәм йомшак кына итеп басылган аяк киемен белдерә, ул хәтта оекбаш урынына чабата эченнән дә киелә торган булган.

*Үжин* – карабүрек (рус. снегирь). *Үжин қып-қызыл түшле қый ул, йазғыда килә қый ул.* Коми-зырян теле диалектларында: *җон', җөн'кай, җойна;* коми-язьва диалектында: *җун'//жун'он, жун'ис, удмурт җойна* – карабүрек.

Күреп киткәнебезчә, Пермь татарлары сөйләшенең лексик-семантик системасы әдәби телгә һәм башка сөйләшләргә мөнәсәбәтле рәвештә генә түгел, сүзләрнең чыганагы ягыннан да зур төрлелек күрсәтә.

## Диалекталь лексикага тематик характеристика

Югарыда Барда төбәге татарлары сөйләшенең лексик составын әдәби тел һәм татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштырып һәм генетик яктан карап чыктык. Ләкин моның белән генә сөйләшнең лексик-семантик системасын, бигрәк тә аның диалекталь үзенчәлекләрен, җирле колоритын бөтен тулылыгы белән ачып бетереп булмый. Минемчә, диалекталь лексиканың байлыгы, аның

барлыкка килү шартлары һәм формалашу үзенчәлекләре, ясалу юллары төрле тематик төркемнәргә аерым-аерым тукталып үткәндә тагын да ачыла төшәчәк.

**I. Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы белән бәйле лексика.** Бу өлкәгә карый торган лексика Урал алды территориясенең бай терек табигатен чагылдыра.

Йорт хайваннары исемнәре, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Аерымлыклардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: а) сарык һәм кәҗә бәрәннәренең, чебиләрнең ана булганы *инәч* (барда) дип атала: *инәч бәрән, инәчкә чебеч бала* һ.б. б) эт һәм песиләргә карата *әкәр* (ата песи яки эт), қанчық (ана песи яки эт) сүзләре кулланыла. *Әкәр* төрки телләрдә киң таралган *үгез* сүзенең шушы сөйләшкә хас җирле варианты. Борынгы *оғуз* (~ *öғӱз*) сүзенең *р*-варианты формасы; чуваш *вӑкӑр*, монгол *үхер* һ.б., ягъни сөйләштә бик борынгы сүзләр сакланып килә.

Кыргый хайваннар исемнәренең дә зур күпчелеге татар әдәби телендәгечә. Минем тарафтан бу өлкәдә язылып алынган диалекталь сүзләр түбәндәгеләр: *йуша* – болан, кийек – кыргый кәҗә, *қоно* – кыргый, мәчесыман ерткыч хайван, кайвакытта аны рысь дип аңлаталар; *әнтәк* – сукыр тычкан, *кумак//оло тычқан* – күсе (минзәлә, бөре, типтәр, сергач сөйләшләрендә дә шул мәгънәдә; нократ сөйләшендә бу сүз тычканны белдерә); *чичкан* – тычкан; *очар тийен* – белка-летяга (тиеннең бер төре) һ.б.

Кош-корт исемнәре: *Дүдүт* – ата кәккүк (алтай тудут – күке төсле кычкыра торган кош, хакас тудет – ата кәкүк). *Ужин* – карабүрек. *Өке, бабалаш* – мәче башлы ябалак төрләре. *Тумыртқа* – тукран. хвалын, кузнецк сөйләшләрендә: тумырка; *озан* – көртлек, кыр тавыгы. *тәлитүт* – ярга кереп оя ясый торган кечкенә кош (керәшә). *Суқа чыпчық//җәйелмә чыпчық* – тургай. *Парпилдақ//пархилдақ//барқылдақ* – сыерчык һ.б.

Балык исемнәрен белдерә торган сүзләрнең бер өлешен рус сүзләре алып тора: *пискәр* (пескарь), *лиш* (лещ) һ.б. Кайбер балыклар русча да, татарча да аталып йөртеләләр: *щукә//чуртан//шешле* (Барда), *шамбы//нәлим* һ.б. Татарча исемнәрдән тагын *бәрде* (хариус), *аҗау* (голавль), *алабоға* (у>о), қаты қанат (ерш) һ.б. күрсәтергә мөмкин. Маймычны төрлечә атыйлар: *чор//чорды//әнчүре//чор балық//салдат чыр* (бу сүз татар сөйләшләрендә билгеләнмәгән).

Елан исемнәренең бер өлеше охшату-чагыштыру аркылы семантик ысул белән ясалган: *қара жылан* – агулы, кара төстәге чага торган елан (әд. кара елан), усаҕ жылан – каралы-яшелле, *чуар елан* рус. полоз узорчатый. Сөйләштә бер төркем елан атамалары рус телендәге шундый ук терминнар белән сүзгә-сүз туры киләләр: *баҕыр жылан* – рус. медянка (әд. бакыр елан), *орчоҕ жылан* – рус. веретенница, *буwар жылан* – рус. удав.

*Кәлтә* сүзе татар теленә фарсы теленнән кергән. Сөйләштә исә бу төшенчә *қонжоҕор* сүзе белән белдерелә. Әлеге сүз татар сөйләшләрендә һәм башка төрки телләрдә билгеләнмәгән.

*Каwдан.* Барда ягы сөйләшендә исә *каwдан* сүзе еланның салып ташлаган кабыгы мәгънәсендә дә кулланыла. Чагыштыру башкорт *қау* – елан кабыгы. Күргәнебезчә, сөйләштә каwдан сүзенең семантикасы тагын да киңрәк икән.

*Зөңге* (татар *сөңге*); 1) очлы тимертаяк; 2) бал кортының угы; 3) елан угы; *Саҕызақ//саҕадақ//кондоҕа* – шөпшә**.** *Дөңгөж* (төп вариант)//*дөңгәж//диңгеж//дөңгериш* – төклетура; **д***ыраж* – шушы ук семьялыкка керә торган, тик төклетурадан зуррак, чага торган бөҗәк (әд. *усан*). *Сөгезлин* – селәүчән. *Ислекәй//сөйдергеч* – кандала. *Дым корт* – кыргаяк. Башка урынчылыкларда исә кыргаяк билгеле түгел. *Рышқы//эрешке* – муллы һәм барда сөйләшләрендә зур чебен.

Үсемлекләр дөньясы: *қараҕай* – нарат, тет аҕач (карагай), *терке* (яшь нарат), *кидрә* – эрбет (рус. кедр); *чаган* – өрәңге, *Этборон* (барда) – гөлҗимеш.

Җиләк-җимеш исемнәре. Фин-угыр сүзләре ярдәмендә икенче терминнар да ясалган: *йар өмежҫе* – кара бөрлегән; *күк мал'* – күк җиләк, қара мал' – кара җиләк, *шартлама* – әд. җир җиләге (жыйганда шартлап өзелүенә карап); *саз жимеш* – мүк җиләге; *жир жиләге* – әд. каен җиләге, *қараҕат* – карлыган. Бөре сөйләшләрендәге кебек үк, *қараҕат* сүзе белән йөртелә. Бу сүз шулай ук көнчыгыш төрки телләрдә киң таралган: башк. *караҕат,* кырг. *qaraqat,* шор *караньат,* хак. *харагат,* каз. *қарақат,* тув. *каракат.* тува *кат*, хакас *хат,* татарча *жиләк,* ягъни *карагат* < *кара кат* – кара җиләк, кызыл карлыган – *қызыл қараҕат* һ.б.

Яшелчәчелек һәм яшелчә төрләрен белдерә торган терминнар да, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Бу өлкәдә күзәтелә торган характерлы үзенчәлекләрнең берсе – кайбер атамаларның семантик

ысул белән ясалган булуы. Мәсәлән: қызыл торма (чөгендер), *сары торма* (кишер), *тегерик шалқан* (гәрәнкә), *сыйыр шалқан* (турнепс); *кәлигә//кәлигә шалқан* (калига), *картуп* (барда) – бәрәңге, *чиснок* (сарымсак), элегрәк *уқсын* дип йөртелә торган булган һәм өлкән буын бу сүзне әле дә хәтерли. Алтай *уқсын,* башкорт *оскын,* хакас *ухсум; муксун* – суган.

Яшелчә термины сөйләш өчен характерлы түгел, аның урынына, гадәттә, *җимеш//йемеш//бакча җимеш//бакча йемеш* сүзләре йөри.

Гөмбә (мәшкә) исемнәре: 1) рус теленнән кергән сүзләр *гөриҗ//гөриҗлә//гөрүҗ* – грузди (шуннан ук: ак гөриж һ.б.); *биләңке* – белянка; 2) гомумтатар сүзләре. Алар, күбесенчә, охшату-чагыштыру аркылы яки гөмбәләрнең кайсы агач астында үсүенә карап аталганнар: *чыбар эшләпәле мәшкә//чебен мәшкә* – чебен гөмбәсе, *нәзег айақ мәшкә, терке биләңкәсе//қарағай мәшкә, җүкә мәшкә, төтен мәшкә* һ.б. *Мәшкә* сүзе минзәлә сөйләшенә дә килеп керә; тагын башкорт (бәшмәк) һәм аның диалектларында *(мәшкәк, мәшкә),* хакас *(миске),* бараба диалектында *(таумашка), (мешкә)* һ.б.да да бар.

Үлән һәм чәчәк исемнәрендә дә җирле үзенчәлекләр байтак. Характерлы үзенчәлекләреннән берсе – әдәби үлән сүзе урынына даими рәвештә *печин* сүзен куллану, чәчәк мәгънәсендә аның *т'ит'и* варианты әйтелә. Бер төркем чәчәкләр, татар телендәге кебек үк, төсләре белән бәйле рәвештә аталганнар: *ақ т'ит'и//ақ печин, ақбаш печин, күк печин//күк т'ит'и* (күк чәчәк), *алай т'ит'и* (ал чәчәк) һ.б. Шулай да охшату-чагыштыру аркылы яңа атамалар ясау үлән, чәчәк исемнәрендә аеруча зур урын алып тора. Мәсәлән: *чиркәй печин* – мәтрүшкә; *шәңгә печин//шәңгә т'ит'и* – ромашка. Ак читле ромашканы *ак шәңгә печин,* сары читлесен *сары шәңгә печин* дип тә атыйлар (*шәңгә* – ватрушканың Урал тирәсендә киң таралган төре һәм формасы ягыннан ромашкага охшый). Шулай ук, *садап печин//(садап т'ит'и)* – песи борчагы (сәдәф төсле җимешләре өчен шулай аталган; Барда татарларында шушы ук мәгънәдә *песи түмә печин* тәгъбирен дә ишетергә мөмкин); *эрек печин//эрек т'ит'и*; бу үләннең очындагы күпсанлы чәчәкләре эремчеккә охшыйлар. Мондый юл белән ясалган терминнардан тагын *җирек печин* (зиреккә ошаган), *қуйан қолақ, айу табаны, кәкүк читеге* (чәчәкләре формалары белән итеккә охшаганнар), *қазайақ* – абага һ.б.ны күрсәтергә мөмкин.

Бер төркем үсемлекләр башка характерлы үзенчәлекләре белән аталганнар: *әбәк печин* – сукыр кычыткан (әбәк уйнаганда шуның белән сугалар); *қар чәчәге* – умырзая (кар бетәр-бетмәс үк үсеп чыга) һ.б.

Азык буларак кулланыла торган үләннәр: *қымызлық* – какы: *ачы қымызлық* – какы, *чече қымызлық* – какы шикеллерәк, ашый торган үлән), *сарана* (рус. саранка лесная), *пикан, зәрәтә* (сәрдә), *печтек* (пестик), *балтырган, кәҗә күшә//қырлы күшә* (кәҗә сакалы) һ.б.

Генетик яктан караганда, кайбер атамаларның этимологиясе ачык билгеле түгел: *шөқмит* – әрекмән (үсемлеге), *шөкмит җапрақ* – әрекмән яфрагы, *шөқмит түз* – тигәнәк, *шөқтил* – пион һ.б.

Рус теленнән кергән терминнардан бу төркемдә түбәндәгеләр күзәтелә: *мечтек//бечтек//әпечтек* (рус. пестик), *мимеч* (немец?) – фасоль борчагы, *усут* (рус. < осот) – билчән һ.б.

Кайбер исемнәр әдәби телдән әйтелешләре белән генә аерылалар: *қумалақ* (колмак), *печин* (печән), *чекерткин//кечеткин//чегерткин* (кычыткан), *зәрәтә* (сәрдә) һ.б.

Шушында ук игеннәр белән бәйле булган тематик төркем турында да берничә сүз әйтеп үтик: 1) иген ашлыклары исемнәренең күпчелеге әдәби телдәгечә; 2) татар әдәби теленнән һәм күпчелек сөйләшләрдән аермалы буларак, карабодай рус телендәгечә аталып йөртелә: *гәрәчукә* (рус. диал. гречуха); 3) әдәби телдәге киндер сүзе сөйләштә таррак мәгънәдә: ул бары җитеннән сугылган тукыманы гына белдерә. Ә киндер үсемлеге *тарма* дип йөртелә, *тарма рлоқ* – киндер орлыгы. Шул ук сүздән: *тарма бау* – сүстән ишелгән бау. Барда татарларында бу сүзнең яңгыраулашкан *дарма* варианты да очрый.

*Тарма* сүзе борынгы язма истәлекләрдә күзәтелә торган *тар* (возделывать землю, сеять), *дарїғ//тарїғ* (посев, жатва) сүзләре белән белән бер тамырдан. Бу тамыр татар әдәби телендә *тары, иген-тару,* тарлау сүзләрендә сакланып килә. *Тарма* формасы тагын минзәлә сөйләшендә бар: чәчмичә, кыргый рәвештә үскән киндер; Бараба татарларында *тарма башы*, башкорт телендә *тарма* – киндер үсемлеге һәм орлыгы.

Үлән, чәчәк исемнәре төркеменә тагын *айақ* – сабак мәгънәсендә, *түгелү* (чәчәкнең коелуы), *түз* – үсемлекнең чабып, кисеп алганнан соң җирдә утырып калган өлеше, *күшә//қурай* (сирәк) – көпшә һ.б. керә.

Шушы кыскача күзәтү дә сөйләштәге флора һәм фауна белән бәйле лексиканың никадәр бай һәм күпкырлы булуын күрсәтә.

**II. Терек булмаган табигатьне белдерә торган диалекталь лексика** сөйләштә шулай ук бай. Мәсәлән, җир йөзе төзелеше, рельефны белдерә торган атамалар. Билгеле, аларның зур күпчелеге гомумтатар характердагы сүзләр: *йаға* – елга яры; *қул* – чокыр, ике тау арасы; *тоба* – текә, биек ярлы чокыр, күл; *җыпқы* – ерганак; *җир кендек* – баткаклы сазлык, (трясина); *ирем* – су упкыны; *дүмсәк* – түмгәк; йепсәк – сазлыклы, сулы җир, *елға түзе* – елга тамагы һ.б.

*Түз:* 1. *Минең суғанны да бетерделәр чебечләр, түзлек кенә утыра* (суган башы); 2. *Борон түзгә шешеп чыға шунда, арпа чыккан дип әйтәләр* (ике каш арасы); 3. *Картлар сүзе – кәбестә түзе* (әйтем; кәбестә күчәне); 4. *Җилкә түз* – җилкә тамыры һ.б. Шушы ук тамырдан *түзлек* – агач төбе, кәүсәсенең төп буе, *түзлек умарта* – шул төп буеннан ясалган багана умарта һ.б. *Түзлек* сүзе башкорт телендә дә бар. *Түз* сүзенең вариантлары һәм шул тамырдан булган ясалмалар хакас һүм алтай телләрендә киң таралган.

Кайбер топонимик атамаларда да җир йөзе төзелешен белдерә торган борынгы сүзләр сакланып килә. Мәсәлән, Барда районындагы бер калкулык һәм аның түбәсе *Уба* дип йөртелә (чагышт: башк. *уба* – курган, калкулык; алт. *оба* – кыяташ; хак. *обаа:* 1) курган таwы; 2) тау иясен олылап салынган ташлар өеме).

**III. Табигать күренешләренә караган лексика,** безнең материаллар күрсәтүенчә, нигездә, әдәби. Шулай да кайбер аерымлыкларны күрсәтергә мөмкин: *көн туу* (әд. кояш чыгу) тәгъбирендә *көн сүзе*, күпчелек төрки телләрдәге кебек, кояш сүзенә туры килә, кешеләрнең турыдан-туры күзәтүләре нәтиҗәсендә үзләренчә фикер йөртүләре аркылы ясалган кайбер тәгъбирләр дә әдәби тел белән чагыштырганда башкачарак формалашканнар: *йәшен ату* – әд. яшен сугу; *чық су* – чык; *түкмә яңгыр* – чиләкләп койган яңгыр (түгелүгә ошату) һ.б.ш.

**IV. Кеше белән бәйле лексика**. Әгъза атамалары: *нәнәй* – күз карасы; *күз таш* – күз алмасы (ак җире); *кәзә күз* – зур, аксыл зәңгәрсу күз; *чағыр күз* – ачык зәңгәр, зәп-зәңгәр күз (татар телендә киң таралган); *иңәк* – теш урты (< *äӈäқ* – ияк); *җаwрын* – җилкә, *җаwрынбаш* – иңбаш, *җаwрын қалақ* – калак сөяге (сөйләшләрдә

киң таралган); *тобоқ* – тез; *тобоқ күмәче* – тез капкачы; *ақсағ ас*//*ақшағ ас* – тез асты (борынгы *ашуғ* сүзеннән булырга мөмкин); *җинчек*//*йенчек* – бу сүзне Барда татарларында начар беләләр һәм аяк йөзе дип аңлаталар, Көнгер татарларында исә ул шактый еш очрый һәм мәгънәсе белән әдәби телдәге сыйрак сүзенә туры килә. Түбән сөйләшендә *йенцек* – тубык, тубык сөяге; аның сыйрак мәгънәсендә тагын төрекмән (*инҗик*) һәм башкорт (*йенсек*) телләрендә барлыгы билгеле; *орчоқ баш сүwәк* – тубык сөяге; *йөзлег ест* – аяк йөзе; бармак исемнәре: *баш бармақ* (әд.), *балан бармақ* (әд.)//*балан тайақ, урта тирәк, уйын қубыз, бетеки тәпеч*//*чығылыйк бармақ* һ.б.

Билгеле булганча, кешенең тән төзелеше белән бәйле терминнарга тотрыклылык хас һәм алар үзләрендә иң борынгы лексик катламны чагылдыралар, бабаалтай чорына тоташалар. Шуңа күрә югарыда санап кителгән кайбер сүзләрнең (*ақсағаз, йенчек* һ.б.) башка сөйләшләрдә һәм башка төрки телләрдә аз очравы аеруча характерлы моментларның берсе булып тора.

Кешене характеры ягыннан билгели торган сүзләр: *ләҗбәк* – елак (ләҗбәю – сытылып елап тору); *мыжғыw*//*wақсу* – вакчыл (мыжгыну, wақсу – ваклану фигыльләреннән); *менчел* – берәзгә, талымлаучан (менәшү – талымлау); *сере* – сер яшерүчән, кире, эчендәген кеше белән бүлешмәүчән; *әпәч* – көяз (*әпәчләнү* – көязләнү); *алмаша, ырый, сантый, исәр* – тиле, юләр, акылсыз, аңгыра; *азман* – азгын; *азымтық* – ялкау; *бақмачы* – имгәк, багуга, тәрбиягә мохтаҗ кеше; бетек – мәнсез, булмаган, җебегән; *йоқлош* – йокы чүлмәге; *қатмыш* – аңгыра, тик катып тора торган; *кәтмәр* – уенчак, шаян; *мылҗы*//*ымылҗы* – төче, җаһил; онытчақ – онытучан; *ордыбай:* 1) тиз ачуланучан; 2) алдын-артын карамый эшләүчән; пыртық – тиз үпкәләүчән (*пыртаю* – үпкәләү); *тизген* – кызу кеше; шәпле – көчле; *ыспайы* – чибәр, матур, сөйкемле; *әҗәме*//*әшпә*//*әшбә* – җебегән, булдыксыз; *җегәрле* – булган, уңган.

Кешенең физик хәрәкәтен һәм сиземләвен, тоюын белдерә торган сүзләрнең кайберләренә тукталып үтик: *ләпәйеп* – чүгәләп (ләпәю – янчелү, яссыланып басылу һ.б.); *мыштырау* – сулыш кысылу; *тезенә қату* – турыга катып калу; *тәнтерәп җөрү* – алпан-тилпән килеп, чайкалып йөрү; *тақылайу* – авырудан тазару; *чәңкү* – күшегү; *йүнәү* – яраның төзәлүе; *йандыру* – пешерү; *қолақай* – чукрак; *җемерҗү* – тәннең оеганда, күшеккәндә, курыкканда чы-

мырдавы; *кечү* – кычыту; *сеңер түү* – кан төшү; *түкмелдериг ату* – мәтәлчек ату; *туйтақ-туйтақ йөрү* – тыйтаклау һ.б.

**V. Көндәлек тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары, йорт-җир төзелеше белән бәйле лексика:** *ызба төп* – нигез; *кәҗүнкә* – чолан; *мөгөш* – почмак; *айақ* – чынаяк чокыры, стакан; *сосқайақ* – касә; *йалғаш* – тагарак; *қашық* – чүмеч; *пелмин қашық* – пилмәнне сөзеп ала торган махсус чүмеч; *урә қашық* – аш чүмече; *чомоқ* – сапсыз чүмеч яки чүмеч урынына кулланыла торган савыт; *түгеч* – бәрәңге тукмагы; *қабызлық* – ут алдырырга ярый торган чыра, йомычка; *күз көзгесе* – күзлек; *тықыwыч* – гөбе агачы; *чырақ* – чыра; *әстә тимер//әстә* – чыра кыстыра торган тимер, *бау-чеү* – бау; *тырнаwыч* – тырма; *камыт-курамта* – ат сбруе. һ.б.

Китерелгән материал, тулы булмаса да, Барда татарлары сөйләшендәге йорт кирәк-яраклары һәм һәртөрле җиһазларны белдерә торган терминнар ясалышының әдәби телдән беркадәр аерылуын күрсәтә. Бу аерымлыклар, бер яктан, сөйләштә икенче төрле морфологик күрсәткечләрнең активрак булуында (мәсәлән: *сөзгәк, үлчәмеч, қабызлық, түгеч, тықыwыч, тырнаwыч* һ.б.), икенче яктан, семантик алым белән сүз ясау һәм халыкның үз тел мөмкинлекләреннән үзенчә файдалануында (мәсәлән: *пелмин қашық, таба тотқоч, чәй табақ, мыскал табақ, күз көзгесе* һ.б.) чагыла.

**VI. Көн исемнәре**. Татар телендәге көн исемнәренә ислам дине көчле йогынтысы ясаган. Шулай булуга карамастан, кайбер җирле сөйләшләрдә борынгы көн исемнәре тулысынча сакланып килә. Бу яктан караганда, мишәр сөйләшләре, подберезье керәшеннәре һәм пермь татарлары сөйләше үзенчәлекле урын тота.

| Пермь һәм Барда төбәге | Подберезье | Мишәр | Мордва-каратай |
|---|---|---|---|
| Дүш. туғаң көн | тунди көн | баш көн | баш көн |
| Сиш. атлаңгаң көн | утлари көн | буш көн | буш көн |
| Чәрш. қаң көн | кан көн | чәршәмбе | кан көн |
| Пәнж. кечәтнә | кеч әтнә көн | атна кич | кес атна |
| Җом. җомға | атна көн | атна көн | атна көн |
| Шим. қорокөн | шимбә | атнараскөн | ара көн |
| Якш. урсәтнә | урысатнаскөн | урыс атнасы | урыс атна көн |

Күргәнебезчә, сөйләштәге көн исемнәренең бары берсе генә әдәби: җомга. Кечәтнә атамасы, әдәби телдә кабул ителмәсә дә, урта диалект сөйләшләренең күпчелегендә сакланып килә.

Китерелгән таблицага күз салсак, Барда төбәге татарлары сөйләше *қаң кен, урсәтнә көн* атамалары буенча югарыда телгә алынган сөйләшләр белән зур уртаклык күрсәтсә дә, *туғаң көн, атлаңғаң көн, қоро көн* атамалары белән алардан аерылып торуын күрәбез.

Борынгы көн исемнәренең кайберләре башка төрки телләрдә дә бар. Мәсәлән: караим, карачай, чуваш һәм башкорт телләрендә.

Тагын шунысы характерлы, татар сөйләшләрендә сакланып килә торган көн исемнәренең күпчелеге Идел–Урал тирәсендә яши торган фин-угыр халыкларындагы көн исемнәре белән мәгънәдәш.

| **Пермь татарлары** | **Мари** | **Удмурт** |
|---|---|---|
| Дүш. туғаң көн | туган көн | туган көн |
| Сиш. атланган көн | атка атлану | утыру |
| Чәр. каң көн | кан көн | кан көн |
| Шим. қоро көн | буш көн | атна арты һ.б. |

**VII. Пермь татарларында төп туганлык атамалары** нигездә, әдәби телдәгечә. Шулай да аерымлыклар да табыла.

Гомуми кардәшлек-нәселдәшлек төшенчәсе берничә атама белән белдерелә: *туған, қәрдәш, нәсел, зат, зат-зерийәт, төп, тамыр, төбе-җире, кардәш-ыру, нәсел-ыру, иш-қуш, иш-ыру, тармақ, төп-тамыр, җәwер, нәсел-нәсәбе* һ.б.

*Туғаннардан туған//ике туған балалары* – әд. туганнан туган.

*Әни//инә(й)//әней* – әни. *Әней* – эндәшү формасы һәм, асылда, әни кешегә мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. Инә, әдәби телдә кулланыла торган әни сүзе кебек үк, борынгы төрки телдәге *ана* сүзенең хәзерге төрки телләрдә таралган күп төрле фонетик вариантларыннан берсе; ул татар теленең бигрәк тә Урал сөйләшләрендә таралган. Башкорт теленең көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш сөйләшләрендә табыла. *Әти* – формасы һәм семантикасы белән татар әдәби телендәгечә. *Ата-йнә* – ата-ана. *Әни//инә, әти* сүзләре нигезендә икенче төшенчәләрне белдерә торган атамалар ясала: *қартәни//қартинәй//қартнә//қартый//қәртәни//қәртнәй//қәртнә* – әд. әби; *қәрт'әт'и//қартәти//қартата//қортәти қәртти* – әд. бабай. Әтинең һәм әнинең олы бертуганнарын белдерү өчен *әби, бабай* терминнары

кулланыла. Сөйләштә алар ире, хатыны мәгънәсендә дә, ирле-хатынлы, әбиле-бабайлы кешеләрнең бер-берсенә эндәшү формасы да була алалар.

*Абзый//абызый//абый (сирәк)* – абый. *Тутай//тәтәй* – апа. *Эне// энекәй* – эне. *Сеңел//сеңелкәй* – сеңел. *Энекәй, сеңелкәй* – формалары эмоциональ-экспрессивлык төсмерләрен югалтканнар. *Энекәй* бигрәк тә Барда районының көньяк авылларында күзәтелә.

*Абзый, тутай, эне, сеңел* терминнары, турыдан-туры булган туганнарга гына түгел, әти, әни, әби, бабай аша булган, ягъни төрле дәрәҗәдәге туганнарга да карыйлар һәм аларны яшь ягыннан икегә бүләләр: сөйләүчедән олырак булган туганнар (әти һәм әнинең олы бертуган апалары яки абыйларыннан кала) һәм сөйләүчедән кечерәк яшьтә булган туганнар. Димәк, санап үтелгән терминнарга көчле гомумиләштерү хас.

Балаларга карата кулланыла торган терминнар: *қыз, малай, ул, улан.* Беренче өч термин эчтәлекләре белән татар әдәби телендәге шундый ук терминнардан аерылмыйлар. *Улан* сүзе, башкорт телендәге кебек үк, бары күплек санда гына кулланыла һәм семьядагы балаларның барын да җыеп әйтүне белдерә. Шунлыктан олы кешеләр үзләренең оныкларын да җыеп *уланнар* дип сөйлиләр.

*Қызлар алу* (әд. өйләнү) тәгъбирендә *кыз* сүзе даими рәвештә күплек формасында кулланыла.

Балаларның баласына карата бу сөйләштә рус теленнән кергән *уничек* сүзеннән башка махсус термин күзәтелмәде. Онык төшенчәсе *баланың баласы, улымның кызы (малае), қызымның малае (қызы)* кебек тәгъбирләр белән белдерелә.

Сөйләшкә хас туганлык терминнары составында алынма сүзләр дә бар. Аларның бер төркеме кардәшлек, нәселдәшлек төшенчәсен белдерә: *срудназ* (< рус. сродный), *патака//пәтәкә, портсуwа, поруда//пуруда* (рус. порода) һ.б. *Бырат* термины Барда татарларында теләсә нинди туганны белдерә: – *Ире түгел, хатыны бырат мийә. Нәҗми агайның быраты ул қыз.*

*Бырат* сүзенең туганлык термины буларак кулланылуы татар теленең күпчелек сөйләшләренә хас күренеш.

*Никахлашу* нәтиҗәсендә булган туганнарны *иш-қуш* яки *қода-иш* дигән гомумиләштерә торган термин белән атыйлар. Ә бер семья эчендәге мондый туганлык, башка төрки телләрдәгечә, *қайын* сүзе белән белдерелә.

Килен кешегә иренең эти-әниләре *қайын, қәйнә* тия, ә эндәшү, мөрәҗәгать итү өчен *әткәй, әнкәй* сүзләре кулланыла. Кияү кеше хатынының эти-әниләре, шулай ук, *қайын-қәйнә* тия, тик ул аларга *қәйнәни, қәйнәти* сүзләре белән мөрәҗәгать итә. Киленгә дә, кияүгә дә бер-берсенең олы ир туганнары *қайнаға,* ә олы кыз туганнары *қәйенбикә//қәйминқә//қәймикә* тия; мөрәҗәгать итү өчен дә шушы ук терминнар йөри.

*Килен, кияw* терминнарының функцияләре татар әдәби телендәгечә. Бары *кияw* сүзенең Барда татарларында берничә вариантта әйтелүен генә күрсәтеп үтәргә кирәк: *кийеw,* чөнки бу төбәктә әдәби телдәге *ау-әү* дифтонгы *ow–ew* дифтонглары яки $^{o}$w, $^{e}$w дифтонгоидлары белән алмашына һәм *көйеw* тамырдагы *ө* авазы белән әйтелә, бу вариант борынгы язма истәлекләрдәге *küdägü* формасына якынрак тора.

*Абышқа* – ир, *бичә* – хатын. *Бичәле-абышқалы* – ирле-хатынлы. Бу терминнар, бигрәк тә, билгеле бер ирнең хатыны яки билгеле бер хатынның ире турында сөйләгәндә кулланыла. *Малайы суғышта үлде, абышқасы суғышта үлде. Бичә* термины татар әдәби телендә искергән сүз булып санала; нигездә, Урал тирәсендә таралган сөйләшләрдә күзәтелә, семьядаш төрки телләрдән башкорт телендә бар. *Абышқа* термины себер татарлары диалектларында *бабай, карт* мәгънәсендә билгеләнеп үтелгән, борынгы телләрдә һәм хәзерге казакъ, кыргыз, башкорт, чуваш телләрендә бар.

*Йезнә//җизнә//йезнәй, җиңгә//йеңгә*. Бу терминнар үзеннән олырак кыз туганнарның (нинди дәрәҗәдәге туган булуына карамастан), шулай ук, ир кешегә хатыны, хатын кешегә ире ягыннан булган һәртөрле олы кыз туганнарының ирен яисә хатынын белдерәләр.

*Җизнә, җиңгә* терминнары *әби, бабай* терминнары белән атала торган туганнарның ире яки хатынына карата кулланылмый. Әйтик, сөйләүче этисе белән бертуган абыйсын «бабай» дип әйтә икән, хатыны «әби» дип йөртелә һәм киресенчә.

Бертуган кызларның ирләре *бажа* дип, ә бертуган ирләрнең хатыннары *абсыннар* дип йөртеләләр. *Бажай* формасы эндәшү өчен кулланыла. *Абсын* татар теленең тагын касыйм сөйләшендә һәм Себер татарлары диалектларында сакланып калган. Ул, шулай ук, күпчелек төрки телләрдә дә табыла. Тикшерелә торган сөйләштә *абсын* сүзе кече киленнең олы киленгә эндәшү формасы да булып кулланыла.

Кияүнең яки килённең кече туганнарына караган терминнар Пермь татарларында шактый үзенчәлекле. Мәсәлән, әдәби телдән аермалы буларак, *балдыз* термины хатынының ир туганына карата да кулланыла: *Силпа персидәтеле Ахмитов Сәит минеке балдыз була, сәлам әйтте йезнәң, дийерсең.* Аерып күрсәтергә кирәк булганда *ир балдыз, кыз балдыз* дип әйтелә. *Балдыз* терминының ир туганнарга карата да кулланылуы татар теленең тагын бөре сөйләшендә күзәтелә, төрки телләрдән казакъ, каракалпак телләрендә һәм башкорт теленең төньяк сөйләшләрендә бар.

Әдәби телдәге *қаенсеңле, қаенэне* терминнары урынына сөйләштә *ул бала, қыз бала* терминнары кулланыла.

Минем үземдә тупланган материаллар буенча, пермь татарлары сөйләшендәге туганлык терминнары турында кыскача менә шушыларны әйтергә мөмкин.

**VIII. Кием-салымнар** өлкәсендә Барда төбәге өчен беркадәр үзенчәлекле булганнарыннан берсе – *чоба//чыба*. Ул буй-буй итеп сугылган киндердән тегелә һәм Казан татарларындагы җиләнгә якын тора. Башлыча эш киеме булса да, кайбер урта хәлле һәм ярлы кешеләрнең бәйрәмнәрдә кия торган киеме булып та хезмәт итә. Аны Идел буе фин халыкларындагы тышкы киемнәрнең берсе белән бәйләп аңлаталар.

Пермь татарлары өчен характерлы аяк киемнәренең берсе итеп *қонжорыйқны* күрсәтергә кирәк. Ул хайван (ат яки сыер) аягының сыйрак тиресеннән тегелә. Формасы белән қонжорыйқ чабата төсле үк. Аның өстен, еш кына, тубык сөягенә кадәр киндер белән тышлап, бау тыгалар һәм мондый *бушымны қонжорыйқ*ның эченә кар керми. Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, чабатаны да шулай ук бушымный торган булганнар.

Қонжорыйқ, халыкның сөйләвенә караганда, хатын-кызның, аучыларның эш киеме булып хезмәт иткән. Хәзер исә аны балаларга тауда шуар өчен тегәләр. Әлеге лексема *кын – күн* < *йон* + *чарык* (аяк киеме) сүзләреннән тора. Кавказ ареалы телләрендә киң таралган. Аның борынгы болгар чоры белән бәйләнешле сүз икәнен удмурт телендәге *ген* (*ген сапог* – киез итек) сүзе дә раслый. *Қонжорыйқ* сүзенең таралыш ареалы пермь һәм златоуст сөйләшләре белән чикләнә.

С.И. Руденко (*қынйырақ*)ны аучыларның махсус аяк киеме дип билгеләп үтә һәм гәйнә, уран, ай, таныш башкортларына (ягъни

төньяк-көнчыгыш Башкортстан. – *Д.Р.*) хас дип күрсәтә. С.Н. Шитова, *қынйырақ* Башкортстанның бары төньяк-көнчыгышы өчен генә характерлы, дип яза.

*Беләзек*нең ике төре белән танышырга туры килде: 1) беләзек; 2) челтермәкле беләзек. Челтермәкле беләзеккә тәңкәләр дә тагылган була һәм ул башкортларда киң таралган сылтыраклы беләзеккә туры килә булса кирәк.

*Қалфақ*, Казан татарларындагы кебек үк, энҗе-мәрҗәннәр тезеп эшләнгән. Муенга тагалар, *муйынса* яки *йақатөп* һәм *чылбыр йаға* кияләр: *муйынса* (шул ук йақатөп) тукыманы тар гына итеп сырып, шуңа ике рәт тәңкәләр тезеп эшләнә һәм арттан эләктерелә; *чылбыр йаға* татарларда киң таралган яка чылбырына туры килә.

Күкрәккә сул як иңбашы аша кыйгачлап киелә һәм тәңкәләр, һәртөрле мәрҗәннәр, ахаклар тезеп тегелә торган бизәнү әйберсе – хәситә Барда төбәге татарларында *буйынча*/*буенса* дип аталып йөртелә.

Чәчнең толым очына *чулпы* яки *тәңкә* тагалар. Ә толым буйлап *арқалық* киелә торган булган. *Арқалық* (мишәрләрдә *артча*) кул киңлегендә итеп, чәч толымы озынлыгында сырыла һәм өч рәт тәңкә тезелгән була. Аны бау белән башка яки толым төбенә бәйләп куялар һәм ул чәч толымы белән бергә асылынып йөри. Казан арты төркеме, минзәлә һ.б. сөйләшләрдә *тезмә* дип атала.

Кием-салымнарны, бизәнү әйберләрен өйрәнгәндә шундый нәтиҗәгә киләсең: аларның күбесе белән Барда төбәге татарлары Казан татарларына, шулай ук мишәрләргә бик якын тора, тик алар кайбер очракларда икенче төрле аталалар гына.

**IX. Аш-су**ны, бүтән халыклардагы кебек үк, Барда төбәгендә дә үсемлекләрдән, һәм бөртекле культуралардан әзерләнгән ризыклар, сөт һәм ит продуктлары тәшкил итә.

Бу өлкәдә аерым күрсәтеп китәсе килгән моментлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Барда төбәгендә аш-су бирү тәртибе, Казан татарлары белән чагыштырганда, үзенчәлеклерәк. Мәсәлән, кунак җыйгач, башта чәй әзерлиләр, аннан соң гына аш чыгаралар;

2) үсемлек азыклар, яшелчә, җиләк-җимеш Барда төбәгендә хәзер дә актив кулланыла. Алар пешереп тә, табигый хәлендә дә күп файдаланылалар. Мәсәлән, пиканнан (рус: *дягил*) аш, шәңгә, пилмән, пирог һ.б. пешерәләр. Җиләк-җимешләрне киптерәләр, ка-

гын коялар, пирогын пешерәләр һ.б. Шомыртны киптереп тарталар һәм онын шикәр белән болгатып, чәй тәмләү әйбере итеп, өстәлгә куялар. Варенье кайнату киң таралган;

3) Казан татарларыннан аермалы буларак, Барда төбәгендә *гөмбәне* (мәшкә) дә бик яратып файдаланалар;

4) оннан яки онның башка әйбер белән булган кушылмасыннан пешерелә торган ашамлыклардан иң күп таралганнарын ике зур төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

а) Көндәлек ашлар. *Шәңгә* – ватрушканың Урал тирәсе өчен характеры төре. Ул ачыга да (*ачы шәңгә*), төчегә дә (*чөче шәңгә*), бәрәңге белән дә (*кәртүк шәңгә*), һәм, хәтта, гади онның сөт яки каймак белән тугылаган сыекчасын ягып та (*аг он шәңгә*) пешерелергә мөмкин. *Шәңгә* Пермь татарларының кунак өчен дә, болай ашар өчен дә пешерелә торган, иң яраткан һәм иң күп кулланыла торган ашамлыкларыннан берсе.

Көндәлек ашлардан тагын *катлама* (*ачы* һәм *чече қатлама*; камырга май кушып пешерелә), *пирук* (*эрек пирук*, ягъни эремчектән пешергән; *суган пирук, кәбестә пирук, кәртүк пирук, кишер пирук, өмеҗ* (кура җиләге) пирук, *шоморт пирук* һ.б.), *баwырсақ* (ак оннан, сөткә һәм йомыркага тугылап, бераз эрерәк итеп пешерелә) һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

б) Туй һәм кунак ашлары. *Баwырсак* (Казан татарларында – *төш*) югарыда әйтеп узган ашамлык, тик бу юлы аны сөтсез, бары йомыркага гына туглыйлар һәм, ваграк итеп ясап, майда пешерәләр.

*Йықамыш* – камыры бавырсакныкы кебек үк ясала, тик аны юка гына итеп җәеп, табада май эчендә пешереп алалар (күзикмәк).

*Чәлпәк* – шундый ук юка камырны төрле формада турап, шулай ук, майда пешерәләр.

*Чәкчәк* – әдәби мәгънәдә: бик вак итеп пешерелгән бавырсакны бал белән болгатып билгеле бер формага кертеп катыралар, өстен төрле-төрле төстәге конфетлар, монпансье белән бизиләр.

*Гөлбәдия* (Барда төбәгендә). Пермь төбәгенең башка районнарында *как бәлеш* (ирен, сылва, карьево төбәкләрендә), *җиләк бәлеше* (муллы һәм шауба төбәкләрендә) – бәлешнең бер төре. 3, 5 яки 7 (так булырга тиеш), хәтта 9 катлы булырга мөмкин. Һәр каты да җиләк-җимештән була, тик бер җимеш ике мәртәбә салынмый. Аны махсус осталар гына пешерә.

Мондый бәлешне туйга төп кодалар пешереп алып киләләр. Кыз ягында да шундый ук бәлеш пешерелә. Кодагый аны, кияү кыз куенына кергәч, икенче көнне үзенең туганнарына килен күчтәнәче итеп алып кайта. *Гөлбәдия* ничә катлы булса, туйга килгән кунаклар (төп кодалар, аргышлар һ.б.) шул хәтле кич кунак булып китәләр.

5) Казан татарларыннан аермалы буларак, Барда төбәгендә *кыстыбый* пешерү гадәткә кермәгән. Билгеле, алар кыстыбый белән таныш, ләкин ул беркайчан да пешерелми һәм халык аны Казан ягы яки кайбер очракларда башкорт ягы өчен үзенчәлекле булган ашамлык дип саный.

**X. Барда төбәгенең рухи мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән бәйле лексика.**

*Кыз алу, кыз бирү* тәртибе, Казан татарларындагы кебек үк, ике төрле: 1) ярәшеп бирү; 2) «қачырыб алу» – ябышып чыгу.

Борынгы туй – ягъни, кызны ярәшеп, туйлап бирү, шактый катлаулы булган һәм *кызны ярәшү, түр күрсәтү, кодага бару, кәбен уку, тун ябу яки яулык ябу, туй, кияүләп йөрү* һәм, ниһаять*, киленне төп җортка төшерү* кебек этаплардан тора.

Ярәшеп бирү тәртибе бөтен төбәкләрдә дә бертөсле. Шулай да аерым төбәкләрнең үз эчләрендә дә беркадәр үзгәлекләре булуын күрсәтеп үтәргә кирәк. Төбәкләрне бер-берсеннән аера торган үзенчәлекләр туйлап бирү белән бәйле булган йолаларны башкару ысулларындагы аерымлыкларга кайтып калалар.

Кыз сорап егетнең әтисе яки башка бер туганы бара. Барда районында кыз сорап килүче үзенең кем икәнен «мин мендәрле кунак» дип сиздертә, аны мендәргә утырталар. Ә Көнгер якларында яучы кеше «Без килдек сезгә сәбәп бели, сез тормагыз безгә сәнәк бели», дип сүз башлый. Кызны ярәшкәч, *түр күрсәтү, кәбен* (никах), *туй, тун йабу* (кыз куйнына керү) көннәре һәм *тарту*ның күләме билгеләнә.

Тарту кызның ата-анасы тарафыннан билгеләнә. Аның бер өлеше туй чыгымнарына, калганы кызга әйбер алырга тотыла. Ул берьюлы да түләнергә мөмкин, бүлеп-бүлеп тә, тик килен төшергәнче бирелеп беткән булырга тиеш.

*Тарту* термины Казан татарларында киң таралган, мәсәлән, аның Казан арты сөйләшләрендә, минзәлә, бөре сөйләшләрендә барлыгы билгеле. Тартудан тыш егет туйга бал, он, шикәр һ.б.ларны, кызга сандык һәм бер кат кием, бизәнү әйберләре бирергә тиеш,

ә кыз үзе *теркәү/теркөү/теркү, терлегәрбир* (чаршаулар, сөлгеләр һ.б.) әзерли.

*Түр күрсәтү*, кызны ярәшү белән, аның якын туганнарын гына чакырып, егет ягында мәҗлес оештыру.

*Кәбен уку* – шул ук никах уку. Никахта катнашучыларны *никах суы* (әчеткән бал яки башка эчемлек) белән сыйлыйлар.

*Туй* кыз ягында була. Егет ягыннан *күмәчләр* (ягъни күчтәнәч) алып, *төп кода, аргышлар* (3–4 пар) килә. Төп коданы карап йөртү өчен, күбесенчә кыз ягыннан, *өндәүле* билгеләнә. Ул бик сизгер һәм тапкыр кеше булырга тиеш, кодага юынса су салып, сөлге биреп, киемнәрен карап һ.б.ны эшләп йөри. Өндәүле йоклабрак утырса, аның мендәрен тегеп куялар һәм «өндәүленең арты да мендәрле» дип көләләр.

Туй алдыннан күчтәнәч ашау (*күмәч ашау*) була. «Монысы төп коданың», «монысы аргышның» дип бөтен казны бүләләр. Югарыда характерлап үткән 3–5 катлы бәлешләрне кисәләр, һәр «күмәч»не ашаганнан соң, акча салып баралар.

*Кыз аракысы чыгару* белән туй башланып китә. Төп кодага балны табактан кечерәк агач савыт (тустаған) белән бирәләр, кода үзе эчми, башкаларны шул тустағаныннан сыйлап утыра.

*Бирнә бирешү,* шулай ук, туй вакытында була: кода-кодагыйлар бер-берсенә бүләк итеп кием-салымнар бирәләр, бирнә кара-каршы (ягъни «*бир сийә дә бир мийә*») була.

Туй барганда кода белән бәйле булган кызыклы гына йолалар бар. Мәсәлән, ул мәҗлес вакытында өстәл артыннан торып китсә, урындыгына кулъяулык салып калдыра, юкса, анда таба белән су яки бал куеп, кода килгәч, аны ятып эчәргә мәҗбүр итәләр.

*Кода урлау* шулай ук бик үзенчәлекле. Кода берничә көн кунак булгач, тары боткасы пешерәләр, боткадан соң кодалар кайтып китәргә тиешле була, бу ботка шуңа күрә *эткеч ботка* дип атала да. Ләкин кода ботка пешә башлаганны күрүгә чыгып качарга тырыша. Өндәүле күрмәгәндә генә, аны берәр туганы яки танышы «урлап яшерә». Хуҗалар, коданы таба алмасалар, аны тагын 3 көн кунак итәләр. Кода *эткеч ботка* ашагач та китмәскә маташса, аны кабыкка утыртып ишегалдына чыгаралар. Бу гадәт Көнгер ягында соңгы елларда да күзәтелә.

Коданы мунчага да кабыкка утыртып алып бару гадәте бар, «*ирмәк булсын өчен*».

Туй мәҗлесе җырлар белән бара, кода-кодагыйлар кара-каршы җырлашалар.

*Қодағый имеш (икән) бу кеше,*
*Қәлwәт (затлы тукыма) имеш тун тышы.*
*Қодағый булып җөрөмәгә*
*Қәлләреннән килми күп кеше.*

Өстәлдәге ашамлыкларны, кода-кодагыйларны мактап, гел җырлап кына йөри торган *кияүнәгәр* була, аның муенына махсус чигелгән сөлге бәйлиләр.

*Кияүнәгәр* термины кияү егетен белдерә булса кирәк. Халык аны хәзер начар хәтерли һәм төрлечә аңлата. *Кияүнәгәр* кияүне кыз янына беренче килгәндә җырлар белән озата килә. Күпчелек очракта аның бик матур җырлый торган, шаян, җор кеше булуына басым ясыйлар.

Туйга килгән кунаклар кызның туганнарына туктыйлар. Кунакларны бөтен нәсел-нәсәп белән карауны галимнәр, ыруглык чорыннан килә торган традиция, дип карыйлар.

Туй вакытында «яшьләр шарт-шарт итеп, сау-сәламәт торсын дип», мылтыктан ату йолалары булган, хәзер ул онытылып бара.

Егетнең кыз куеынына керүе Барда районы татарларында түбәндәгечә сурәтләнә: 3 яки 5, хәтта 9 кат түшәк җәелеп, урынның өстенә кызны киендереп, меңгереп утырталар һәм ике якка ачылып китә торган чаршау коралар, чаршауның ике читендә ике хатын-кыз «Хан кызы» бәете әйтеп торалар, ә берничә кеше кияүне урын өстенә чөеп (*ороп*) җибәрәләр.

Шунысы характерлы кияү кызның ата-анасына күренми йөрергә тиешле, алар икенче өйдә яки берәр күршедә торып торалар, ә кайбер авылларда, сөйләүләренә караганда, кыз кияүнең битенә махсус чигелгән яулык ябарга тиеш һәм кияү қәйне-қайнәсе (ягъни, кызның әти-әнисе) алдында битенә яулык япкан килеш йөри.

Шуңа күрә булса кирәк, кияүнең кыз куйнына керүе «йаwлык йабу» дип йөртелә.

Кияүләп йөрү срогы ата-ананың килешүенә карап, төрлечә булырга мөмкин, тик кызны килен итеп төшергәнче *тарту акчасы* түләнеп беткән булырга тиеш. Киленне, гадәттә, көз көне төшерәләр. Сандык янына киләләр, килен төшкәч. Сандык өстендәге кыз *«ат та сурамыйм, сыер да сурамыйм, әйберне дә бирмим»* ди, аңа бүләк биреп, сандыкны алып кереп китәләр.

Барда төбәгендә киленнең урын-җир әйберсен барын бергә тоташтырып бәйлиләр, бер көчле кеше аларны аермый гына күтәреп кертә. Киленне бал-май каптырып мендәргә төшерәләр. Өйгә кергәч, ул каенанасына, каенатасына (*қәйне-қәйнәсенә*) сөлге белән намазлык бирә. Икенче көнне киленгә су юлы күрсәтәләр.

Туйлап бирү тәртибе, нигездә, менә шундый.

## Гореф-гадәтләр, ырымнар, ышанулар

Барда төбәге татарларында да тормышның төрле өлкәләрендә үзенчәлекле гореф-гадәтләр, ырымнар, һәртөрле ышанулар бар.

Әгәр берәр семьяда балаларның туганы берсе үлеп барса, чираттагы яңа туган баланы берәр карчыкка «саталар». Карчык бала өчен акча түли һәм бала инде һәрвакыт шул әбинеке булып исәпләнә. Гәрчә ул ата-анасы янында торса да, халык аны барыбер «фәлән әбинең малае» дип сөйләргә, үз эти-әнисенең исеме белән беркайчан да әйтмәскә тиеш.

Яңа туган баланың киеменә берәр әйбер тагып кую, сиртмә агачын каеннан түгел (югыйсә кайгылы була), ә башка агачтан эшләү кебек ырымнар киң таралган. Балалар бик күп булмасын өчен бишек сиртмәсенә шомырт яки миләш агачының укмашып түгел, ә берәм-берәм генә үсеп утырганын алып кайталар; бала тыныч һәм күп йоклый торган булсын өчен ата кеше шул агачның төбендә бераз йоклап кайтса тагын да яхшы.

Кош-кортлар һәм хайваннар белән бәйле юраулар бик үзенчәлекле.

Сөйләүләренә караганда, Зәйнәп һәм Кәккүк исемле ике бертуганның берсе, «кә-күк, кә-күк» дип үзенең икенче туганын чакыра. Бу әкият татарлар арасында киң таралган. Сак-сок бәетенә якын тора.

Халык хайван һәм кош-кортларның бер төрлесен уңыш, бәхет кертүче дип, ә кайберләрен, киресенчә, бәхетсезлек, ярлылык китерүче дип саный. Мәсәлән, авылга кәккүк килгәнне яратмыйлар, бәла-каза булыр дип юрыйлар. Ә бабалаш (мәче башлы ябалакның бер төре) авылга якын килеп кычкырса, икмәк яхшы уңар, дип сөенәләр.

Күкенең сакаулануын тамагына арпа кылчыгы утырганга дип, ә сандугачның сайраудан туктавын гөлҗимеш чәчәгенә карап, аның матурлыгыннан телсез калганга дип аңлаталар.

Кызыклы гадәтләрдән яңа ел яки благовещение кичендә эшләнә торган һәртөрле юрауларны күрсәтергә мөмкин. Шулардан берничәсенә тукталып үтик.

*Сарык аягы тоту* – кич булгач, сарыгы күп булган кешенең абзарына барып, караңгыда сарык аягы тоталар. Яшь сарык яки бәрән аягы эләксә, кияүгә яшь кешегә, олы сарык эләксә, карт кешегә барасың имеш.

Келәт тыңлау; ашлык кыштырдаган тавыш чыкса, байыйсың, яфрак кыштырдаган тавыш ишетсәң, ярлы буласың имеш.

Тавык тоту. Тавыкны тотып ашаталар һәм су эчереп карыйлар. Эчсә, «эчкеле» абышкага (эчкече кешегә) барасың, дип юрыйлар.

Тагын чабата ыргыту, чиләкне тоткасыннан бикләп ачкычны баш астына салып яту, читән кочаклау, кашык белән су кую һ.б йолалар бар.

Табигать көчләренә табыну өлкән кешеләр арасында әле дә яхшы сакланып килә. Мәсәлән, кайбер чишмәләрне, елгаларны «тота» дигән ышану яши, аларны карамый гына үтәргә, ә беренче мәртәбә күргәндә чәч бөртеге яки башка берәр әйбереңне ташларга кушалар.

Казан татарлары кебек үк Барда төбәге татарлары да авыруларны җан ияләре итеп күзаллаган булсалар кирәк. Аларның уенча, авырулар хурлана, кимсенә беләләр, курка торган булалар һәм кешегә ияреп йөриләр. Дәвалау ысуллары да шуннан чыгып билгеләнгән: арпаны кукиш белән хурландыру, бизгәкне елан, бака белән куркыту һ.б.

Сары һәм бизгәк авыруларын да җанлы булалар, кешегә ияреп йөриләр дип ышана торган булганнар. Шуңа күрә бу авыруларны дәвалауның бик кызыклы ысуллары булган. Аларны өлкән буын кешеләре әле дә яхшы хәтерлиләр. Мәсәлән, авырый торган кешене мичкә кертеп, мичнең авызына ут ягалар, ә чир уттан куркып качып китә имеш.

Бизгәк белән авырый торган кеше мунчага кереп китсә, чир аның чыкканын көтеп тора имеш. Сөйләүләренә караганда, бер әби бизгәк белән авырый башлагач, мунча ягып бик каты чабына һәм хәле киткәнгә күрә, бераз ятып тора. Ә бизгәк чире әбинең чыкканын көтеп тора: ишекне ача да карый, ачы да карый имеш. Бер ачып караганда әби янындагы каен себеркесен күрә һәм «қайчан ара үлеп киткән, қайчан ара өстенә чаwыл (каен) үсеп чыққан» дип

гаҗәпләнә икән. Әбигә чирнең киткәнен көтеп байтак ятарга туры килгән имеш.

Бизгәкне дәвалауның иң таралган ысулы – аны адаштырып калдыру. Мәсәлән, авыру кеше өйдән сиздерми генә чыгып китәргә һәм сөйләшми-нитми генә авылның икенче башындагы, күп вакытта елга аша да чыгып, берәр кешегә (бу кеше туганың булмаса тагын да яхшырак) кереп мич башына менеп ятырга тиеш. Бу вакытта бер дә сөйләшергә ярамый, юкса бизгәк аны хәзер килеп табачак, дип уйлыйлар.

Пермь татарларында, шул исәптән Барда төбәгендә дә, күп сөйләнә торган легендаларның берсе – *ярымтык* белән бәйләнгән. Сөйләүләренә караганда, ярымтык тузгыган чәчле хатын-кыз сурәтендә була һәм озын күкрәкләрен җилкә аркылы артка җибәреп йөри. Ул күбрәк агач башында яши, еш кына кешеләрне адаштыра, «ихахай» дип кычкырып, кешегә исеме белән эндәшә.

Ярымтык урманда йөрүче хайваннарны кытыклап ябыктыра, атларга атланып шабыр тиргә батканчы чаптыра имеш. Беркөнне Әрманша исемле кеше сыерына (икенче вариантларда: атына) сумала сылап җибәргән һәм ярымтык, шуңа ябышып калып, авылга кайткан. Ул, Әрманша карттан үзен азат итүне сорап ялвара башлый. Карт исә ялгыз булган һәм ярымтыкка үзенә хатын булуны шарт итеп куйган. Шуннан соң ярымтык авыл халкының булышчысына әверелгән: авылга яу киләсен алдан белеп, хәбәр итеп торган һ.б.

Ярымтык өйдә вакытта Әрманша карт капкадан ук, үзенең кайтканлыгын белдереп, тамак кырып керергә тиеш булган. Карт моңа гаҗәпләнеп йөргән-йөргән дә, көннәрдән бер көнне искәрмәстән генә өйгә килеп кергән. Керсә, ярымтык баш капкачын алып тез башына куеп, бетен чүпләп утыра икән. Ярымтык бик каты куркып киткән һәм егылып, башы бәрелеп үлгән. Барда районы, Усть-Тунтор авылының «ярымтык» дигән кушаматы, имеш, менә шуннан калган.

Кайбер авылларда халык үзләренең авылында ярымтык нәселеннән килгән кешеләр булуына ышандырырга тырыша, чөнки бу авылда ярымтык кияүгә чыгып, балалар да үстергән имеш.

Ярымтык Казан татарларының шүрәлесенә туры килә. Билгеле булганча, шүрәлене төрлечә сурәтлиләр: озын бармаклы, маңгаенда мөгезле, йонлы кеше яки күкрәкләрен җилкә аркылы артка ташлап йөри торган хатын-кыз, дип сөйлиләр.

С.И. Руденко башкортлар ышана торган төрле җан ияләреннән ярымтыкны да күрсәтеп үтә һәм аның төньяк-көнбатыш башкортларында, дөресрәге Гәйнә ягында гына булуын күрсәтә.

Бу язмада Барда төбәге татарларының этнографиясенә караган кайбер материал тасвирланды. Алардан аңлашылганча, төбәкнең матди һәм рухи мәдәнияте Казан татарлары белән бертөсле. Шуның белән бергә, аларның тормыш-көнкүрешендә беркадәр аерымлыклар, җирле үзенчәлекләр дә бар.

## Авыл тарихлары турында

Бу аwыл Сарашқа урнашкан. Сараш дигән елга бар. Самарада самовар эшләгәннәр. Күчтәнтигә килгән. Сараш Күчтәнти Сарашқа қарағанда элегрәк булган. Самарау алып қайтқан, үрәткән бы төшенә су салырға, қай төшенә ут салырға. Қатын әйбәтләп тыңнамаған, сыу урынына күмер салған. Тол йылғада Кучтәнти урнашқан. Йылғадан тапчығ алама *(йомычка)* ағып килгән. Шулай белгәннәр, Сараштан йуғарыда да аwыл бар имеш *(икән)*. Үткән ғомөр – атқан уқ.

*Сөйләүче: Зайляев Зарип*
*Минияхмәт улы (1928 елгы).*
*Сараш авылы*

Иң беренче безнең аwылға Ишимовлар килеб утырған, 1370 нче йыллар дип йазылған ийе, бар тәғәҗ *(кәгазь)* бар ийе. Йуғаттым мин аны. 1783 нче йылда, у *(ул)* чақта аwыл зур булған. Ишим аwылы Күңгер йақта да бар. Безнең аwыл боронғырақ. Татарлар килеб утырған. Безнең аwылның тирә-йағы урман булған, балықчылық, урманчылық булған монда, ауға йөрөгәннәр.

Тол йылғасы озур булған, алабуға, чуртан, бәрде, қызылқанат тотқаннар. Безнең прадидушканықы қапқа бағанасын башын кисеп кенә эшләгәннәр. Чыршының башын кисеп кенә төшөргәннәр. Аның урынында торам мин.

*Сөйләүче: Зимасова Ләбибә*
*Шамил кызы (1942 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Чүрәле тау баш тибез, үрелеп *(әйләнеп)* менгәнгә Чүрәле диләр.

Тауға китәбез ий печингә *(үләнгә)*, Туғызақ тау, әлә ненди *(бик, искиткеч)* бийек, ағачлы *(урманлы)*.

Тол су да тирән, бөтөн чишмәләр төшөп тора.

*Сөйләүче: Зимасова Ләбибә*
*Шамил кызы (1942 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Чикләwек таwы бар, әлегә чақлы була чикләwек. Барабыз ий аймақ булып.

Чишмәләр дә күп бездә. Ақбүләк чишмәсе бар, җиләккә йөрибез ий. Хәзер андыйны сатыб алабыз. Йырақтарақ Тамирлы чишмә бар ийе. Рақы *(кыскартылган исем)* қулы чишмә бар, Рақы қул тибез, шунда чишмә бар.

*Сөйләүче: Кучуқбаев Нәҗибулла*
*Нәҗмугата улы (1937 елгы).*
*Байавыл (Куземьярово)*

Күгем би чишмәсе бар Күземйарда *(авыл исеме)*. Монда Ирменшаһ килгән беренче башлап, Бухарадан булган ул.

Җите ғәзизләр килгән. Аларныкы берсенеке қабере бар. Бу Әрҗәңгә *(авыл исеме)* 460 йыл.

Үрләр, таулар менәсең, анда Ақ балчық чишмә бар. Аурадың исә әни шуннан сыу менеб алмаға қуша йы. Бер җиләк булса да қап, ату мич җимерелә ди торған ийе.

*Сөйләүче: Балтаева Роза*
*Хөрмәт кызы (1947 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I)*

Тау буйға барабыз, Барда су *(елга исеме)* буйда Тән чишмәсе бу, шул мөсламанның, ди, Барда суwы – чыққан чишмәсе. Анда Қаршы тау, Наратлық тау, Ғарифулла тау *(Молла Ғариф)* аны үтергәннәр, шунда күмеп қуйғаннар.

Йәш печин, суларға, басқан туфрақларға айәт уқып киткәм мин, абыйлар, энекәйләр йата бит анда, Барданы искә алып уқыйм. Ул аwылныкы матурлықларын күрсәң ий, шундый матур, барысы да қойашқа қарый. Минем кендек әнийем шундан. Узур түгел ул, анда

кулып бар, җирдән кереп җөри торган (*урамнан кергәндә баскычы, күтәрмәсе юк дигән сүз*).

*Сөйләүче: Салихова (Узакаева) Нурисә*
*Гаптелхай кызы (1927 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I)*

Тәнә *(әнә)* шушы урында урман булған, түмгәкләр күп булған. Шуннан аwыл қалған. Төн кебек қараңғы булған, урман булған. Урманнарны *(агачларны)* кисеб утырғаннар. Шәж (?) қатлаулы.

Қәртәтийемнең өч бичәсе була.

Башта монда килеб урнашқан Әләкси қарт. Шуннан аwыл булған. Элеке налук түләмәс өчөн урысқа чыққаннар бит: Шуннан Әликсий булғандырмы. Безең фамилийә Алексеев.

Аны Көлөк қарт тийеп йөрткәннәр татарча. Анысы нимә булғандыр. Аның малайы Ғаптелғәй Мәжит, Йусуп мулла анан сын. Аликсийнең правнугы булған, Йусупқа әйткән, бигрәк урыснықына ошаған фамилийәң, тип.

Масиевқа күчергән бабай, мәк чәчәге дигән сүзгә ошатып алған.

Әти сүли инде, Аликсий қартның дүрт улы булған: Кузяй, Усяй, Мукай, Мәкчи. Төнгүк дүрт фамилийәдән таралған дип. Исемнәре дә қызығ аларнықы. Хәзер дә шушы фамилийәләр таралган: Кузайыв, Усайыв, Мукайыв, Максийев. Бу фамилийәләр башқа аwылда йуқ. Болар мондағы төп фамилийәләр. Йусуп мулла үзе мулла булған, балалары күп булған, жиде-сигез малай. Шуннан таралған Макайывлар. Алар күп, ну безгә туған түгел, ике төрле йазылған: Максийевлар, Максейевлар. Йусуп мулланың бичәсе үзенең малайға калымға бирдерткән муллалықны. Өлкән малай Шамғун староста булған, өч қатыны булған. Икесе бер йортта торған. Өлкән бичә – Махи, икенчесе – Сайран, ансы безнең қәртәтинең әнийе. Миңке бабайнықы... Өченче қатын аwылда торған, Нәҗмегөлөм булған. Шушы Шәмғун қартәти, сиңә генә бирәм, тип, күк минчақ (*мәрҗән бөртеге*) биргән. Мәҗлестә жырлый икән: Күк минчағым кемнәрдә, көңөлләрем шунарда. Бичәләре аулашалар (*сөенәләр*) икән.

Қазый шул Шәмгунның малайы – көчле кеше булған. Қазый йодрық қына күрсәтә икән. Үзенеке абийын тыңнаталмаған, жиңгәне қыйнап күрсәткән абийы, менә шулай тыңнаталар, дип. Эшчән дә, көрәшчән дә булған.

Әти шулай сули йе. Йунусовлар, чуқындырудан қачып, Қазан йақтан килгән, дип. Башқа аwылда Йунусовлар йуқ. Қасим молла Ижевск йаққа қачып киткәннәр. Новая Казанкаға *(авыл исеме)* җирне Шамғун қарт биргән.

Старый Башап – татар аwылы. Уч *(Усть)* Ашапқа башлап арлар *(удмуртларның элекке исеме)* килеб урнашқаннар диләр. Ыстарый Ашапны мийән *(миннән)* сурап җийалар. Миңке *(минем)* әти-әни күп белә йе. Фазилә апа Қучуқпаева күперне чыққач та, Тулвинскайа тийән урамда.

*Сөйләүче: Максиева Гүзәл*
*Зәки кызы (1953 елгы).*
*Төнгүк (Тюндюк)*

**Тормыш-көнкүреш турында**

Палас суққаннар. Киндер суғып, аны ағартып қар өстендә. Бөтөн кийемнәре киндердән дә тиредән булған бабайларныкы.

Йабу тун дибез ий. Тирене илиләр, қушып-кушып тегәләр. Шуны җәйеп идәндә бары да җәйелеп йаталар. Шул туннымы, паласмы җабыналар.

Урманнар бетте бездә қәзер. Қайын утын қыйммәтрәк, йүкә, усағ очызрақ була.

Элгәрдән арпа, солы, борчақ, арыш, гәрәчүкә *(карабодай)* чәчкәннәр. Түләмнәрне Осаға барып түләгәннәр.

Бездә шәңгә йнде тәмне аш. Шәңгәне ике төрлө, өч төрлө итеп пешерәләр.

*Сөйләүче: Рангулова Зәйнәбә*
*Мулламөхәммәт кызы (1929 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Кийәүгә чыққанчы дайарка булыб эшләдем. Суға төшәләр, элег атлар җөздөргәннәр, Әмзә суwы бу. Суға төшмәгә *(коеныргa)* төшәләр. Басмалар күләнгән ана шунда. Элегерәк моллалар уқып, бергә аш пешереп ашыйлар. Элек шулый итәбез ий дә, кийем белә суға төшәләр. Йылға буйда бер-беребезне дә кийем беле ороп, сыу мазар сипмәдек, йылғаға оралар ий кийеме беле. Хәзер бу җийында

*(тирәдә, авылның бу төбәгендә)* әбиләр йуқ. Элек шулый итеп йаwын теләгәннәр.

*Сөйләүче: Кучукбаева Тәслимә*
*Мөхлис кызы (1944 елгы).*
*Байавыл (Куземьярово)*

Затыбыз бик олоға *(озын гомер)* йәши торған булды.

Утырың *(утырыгыз),* бер доға қылыйық. У дәверләр, у хәлләр Қорән китабында йазылған. Университет бөткән әтийебез. Минең йәшкә йитәрсең. Икене қыз бала китердем. Сеңлем бар. Намаз қала.

Китаплар да җийасыз ийме. Миңке әтийем үзеннән-үзе уқып утыра иде. Ундан ике қыз бала қалды. Мин шушы аwылда туғаным. Тугандан өч йәштә Қызыл Йардан *(авыл исеме)* күчергәннәр. Сырқайышны, Үтәйне, Үтәйбашны *(авыл исемнәре)* алдылар, Йаwыш қырны *(авыл исеме).*

Мәйетләргә айат уқы, тиделәр. Минең зыйарәт озор анда, мәйетләр, бабайлар, кендек әниләр қалды анда. Киләләр мийә йәшләр. Мин әйтәм, синең йегетләрең *(малайларың)* бар ике, динне, искене дә кертеп тәрбийәләгез. Мине гел әйттеләр, синең қартлығыңа дин ачыла, дип. Часаwайга иске тимер қайнатмаға алып киттеләр, асқа сыйығы ағып төшә, самал'ут қанаты йасыйлар. Ағач эшенә кердем. Мийә аwыр була башлады. Андары пирәнникләр пешерүгә кердем. Мине ололый башладылар, қәртәни әйтәләр мийән *(миннән)* йәшерәкләр.

*Сөйләүче: Салихова (Узакаева)*
*Нурисә Гаптелхәй кызы (1927 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I)*

Қызыл келивернеке башы нирмыларға әйбәт. Этпорон *(гөлҗимеш)* бар, балан да бар. Җитене беткәс (7 сыйныфны тәмамлагач), суғыш чықты. Шу җылны кийәүгә чықтым. Аны әрмийәгә әпкиттеләр. Мин эти-әнигә қайттым, аларны қаручы *(караучы)* йуқ. Ирем қайтқас, аныға *(аңа)* бармадым, эти-әнине қарыйм, дидем. Кийәүгә чықтым барыбер, анысы да аwыл кеше йе. Қырық йәштә малай таптым. Йаңқыз кешегә аwыр инде, тоттым да бардым. Бер кеше белән дә җаматай *(начар)* сүз сүләшкәнем жуқ. Қунақтан да

куймыйлар, Аллаға шөкөр, апа дип кенә торалар. Әтийе-әнийе бар ишле, биш уланнарлы, аймак *(ишле, зур)* симйәле ийе.

*Сөйләүче: Сабитова Наилә*
*Габдрахман кызы (1923 елгы).*
*Султанай авылы*

## Өйләр турында

Аңан *(аннан соң),* синеңдә, диде, ачқычны. Икәү малайлары *(ике малае)* бар. Кеше көнгә *(кеше көненә)* қалғач рәт жуқ. Суwыш чығып китте. Тормаға ызба тузды, тее *(теге)* таба төнтәйде. Ызбаң тәбәнәк, тиләр. Қышқыда ызба җәт *(тиз)* суwый. Идәннең ырудасы *(өрлек)* ғына күрсәткәнчи сыу төште – Уланнарлы кешегә кийүгә киттем..

Йазғыда йортқа кереттем үземән *(үземнән)* йәшерәкне, йалғыз йәшәргә дә көч икә *(кыен икән).* Читән *(чардуган)* токон төбәгә *(чормага)* қуйдым әзерләп. Таза булғаным, эшләдем дә эшләдем. Күрдек күрәмәтне. Җәң *(ягез),* исән-сау эшләң.

*Сөйләүче: Чуракова Нәҗмия*
*Миңнулла кызы (1921 елгы).*
*Сараш авылы*

Нықый *(әнә бит)* әле шыл ызбаны эшләп чықтық. Пумыч *(өмә)* итәләр күтәргәндә. Тормаға *(торырға)* чыққач азан әйттерәләр. Көмөш тәңкәләр мөйөшкә қуйып қалдыралар, бай булсыннар, тыныч йәшәсеннәр, дип, зәхмәт-пәлән килмәсен, тип.

Үкәртәбез *(ишегалды)* озур, тоқон *(бар яктан да койма тотылган, мал керерлек түгел)* үзе. Утын тасқақ *(сарай)* бар анда, утын сақлый торған урын, арба, көрәк тора.

Кәрим көзнөч *(тимерче Кәрим)* қәртәни белән рәттән тора йы.

*Сөйләүче: Рангулова Зәйнәбә*
*Мулламөхәммәт кызы (1929 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Җирдән кергән генә өй, күтәрмәсе *(баскычы)* бер генә. Қәзер күтәрмәсендән менәлмим. Идәндә чиптә *(чыпта)* мынчаладан. Элекке заманада җирдә йоқлағаннар, *(урын-җирне)* өйнең мөгөшенә *(почмагына)* өwөп қуйалар.

Ағач саwытлар, миңке wы *(ул)* саwыт қайда икә ни. Чара табаққа ашны созалар да, шунынан ашыйбыз барыбыз да, өстәл жабу *(ашъяулык)* өстә. Қалақны (агач аш кашыгы), қашықны *(аш чүмечен)* йүкә ағачыннан йасыйлар да сырлыйлар *(буйыйлар)*.

Киндерне үзем дә суқтым, сике была, шунда суға торған ысначлар да бар: қылычы, көрөсе, ыстаны да бар, ыстинада ничә бүрәнә жөгөртәсең *(киләп сарасың),* басып суға торған айақчалар, айақны алмаштырып басасың, сосланы жөрөтәсең. Қәзер санулы *(санаулы)* ғына аны белүчеләр, аwыр эш ул суғу. Жөннө дә суғам ий, чөлкәне туладан тегәм ий. Туланы жөндән суғабыз ий, ирлибез дә суғабыз, қышқыда каwир жәйәм. Туланы басасың, сулыйсың да басасың, жөндән ирлисең дә басасың, сулыйсың да ышқыйсың. Ойоқ боты белән *(бөтенесе дә)* ололар булды. Чабата мынан қунычлы итеп тула чулкәне кийәбез. Жүкә ағачны барыб алабыз, чабата йасыйбыз. Бишәр кийем чабата үрәбез, қатлыйбыз.

Миң үзе чыға күз тимәсен, дип. Миңсез бала тумый.

Бал һаwа алмасын, банкыға сыразы сал да жап. Һаwалады исә тәнгә файдасы жуқ аныған *(аннан)*. Балчықта утырсын ул банкы, келивер печиндән *(үләненнән)* йақшы бал алалар.

*Сөйләүче: Салихова (Узакаева)*
*Нурисә Гаптелхай кызы (1927 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I).*

## Кием-салым турында

Элек балайтәкле күлмәкләр кигәннәр, алжапқыч жапқаннар. Элгәредә (өйнең түр ягы) жөрөсә дә гел алйапқыч кийеп йөрөгәннәр. Мағылайдан өстә түбәтәй кебекне кигәннәр, йаулықны тамағастан бәйләп, жәйеп йабына торған булғаннар йаулықны. Бүкләп тә йабына торған булғаннар.

Узыр *(зур),* қызыл чуқлы чана шәл жабынып жөргәннәр, қышқыда *(кышын)* анда-монда барсалар. Қышқыда кийестек *(киез итек),* кийез қата булған айақларында.

Тула чөлкә *(тула оек)* кийәләр ийе. Аңқы эше күп. Йөннө ирли *(эрли),* буйлық кәрәк була, арқырысы *(аркавы)* шул йоннан. Суққачтан пүмич *(өмә)* итәләр ийе: бер-икене ирләр ала. Сикедә басқаннар туланы, мөгөштә *(почмакта)* йөзлөг өскә *(сәке өсте күздә тотыла)* қуйып, читән үреп, аны қуйғаннар да.

Әwәле читек булған айақта. Кичкедә (кичен) салып қуйалар, тышқа чықсалар сеңер *(рус. резина)* галуш. Узыр сеңер галушлар була, чисунқаға кийәргә. Күндән дә галуш кийгәннәр, унты. Көлөкий *(колын)* тиредән унты миңке *(минеке),* туңғалақта *(каткакта)* көзгөдә кимәгә әйбәт.

Чабаталар да төрлө булған: суқма чабата *(юкә башмак),* баулы чабата, урыс чабата. Суwыш wахытта қатнап-қатнап (катлау – табан астына тагын бер кат юкә үреп чыгу) кийәм ий озон қунычлы чөлкә *(оек)* белин, чөлкәбаш *(оекбаш)* белин.

Тиредән тун, тулуп тегәләр ий қышқыда қийәргә. Җабу тун була торған ийе әллә ничә тиредән журған җасыйығ ый. Қулларыбызда иләсә (бияләй) иләгән тиредән.

Қатын-қыз балайтәкле күлмәг ийе, җақаларға тәңкә тезеп шунда. Ирләрнеңке җә туры йақалы, йаурын *(җилкә)* йақтан элдерә, ар та *(аннан соң)* чықты әйләндермә йақалы. Күлмәкнеңке үңере *(изү, изү уемы)* кем ничек эшли, эчтән күкрәкчә қый мөсөлман қатын-қызларның, сомнық *(бөтен тәңкә)* тағалар ый ишү *(толым)* очқа, беләзек беләккә, бармақта йөзөк кийәм ийе, қашлы. Чулпы да қашлы йы.

Қолақ сырғаның дуғанақлысын кидем ий. Хәзер җимин төрле *(күп төрле)* сырғалар. Айлы була фурмысы, дуғанақ тиләр шундый сырғаны. Туйда кигәнен йөзекне балдақ тиләр, йөзек қашлы була.

Буйынса кийәләр ийе байырақ қортқалар, тәңкә тезеп, бер тасмаға тегәләр дә арттан элдерә торған итеп көйлиләр. Тағын озур буйынса була, хәситә инде ул, сул җақ җилкәдән җибәрәләр дә, тәңкәдер, матур қашлардыр тезеп йасыйлар. Қәзер бетте инде буйынса да йуқ, қәситә дә йуқ.

Элгәре бала-чағаларның күкрәк турысына қадап қуйарға көчкә-көчкә табалар да ыспайы ғына туқымаға теккән, күз тимәскә инде ул балаға. Безнеке қодаларнықы таң атқанчый сықтап *(елап)* чықты. Мич қаштан қором алып сөртөп қуйды йы, йоқлады. Ақ уланнарға күз күп тейә. Аны күз теленнән әбиләр беләләр.

*Сөйләүче: Чуракова Нәҗмия*
*Миңнулла кызы (1921 елгы).*
*Сараш авылы*

Түшелдерекне эчтән кийәләр. Ағысы *(анысы)* пуйынса *(хәситә),* әнинеке дә бар ыйы қый, тәңкә тезеп җыйған *(күп итеп*

*тәңкәләр тезгән),* қыйыққа болый итеп кийәләр сул йаққа иң башына.

Буйын тәңкәсе үзенә айырыла қый *(бит),* бауға тәңкә тезгән бер эрәт, буйынға элеп, арттан бәйләп қуйасың.

Қыз туғаннары күп булған, чулпысы да, тәңкәсе дә бар, озур ий чулпысы, чөприккә таққан, ишүенеңке *(толымының)* очонда тора.

*Сөйләүче: Рангулова Зәйнәбә*
*Муллалыхәммәт кызы (1929 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Балайтәкле күлмәкләр дә кидек. Изеwендә дә балайтәк булыр ийе әле. Басқан *(чиккән)* күлмәкләр дә кидек, канва белә басасын. Йаққаны ачық итмиләр, бишмәт жақа *(утыртма яка)* тиләр ийе, бабай йақа *(ирләр күлмәгендә кырыйгарак төймәләнә торган утыртма яка)* қырыйда була. Мийә күлмәк кенә бирең, диләр, малайлар да ыспайы *(матур)* күлмәктән йериләр ий.

Чулпыныңқы урта төшөндә сумнық, тиләр, эре тәңкә. Җимән төрле (мең төрле, төрле-төрле) кийеп җийалар буйынға кийәләр ике қатлы тәңкәдән генә, әбиләр эчтән түшендерек *(күкрәкчә)* кийәләр.

*Сөйләүче: Уразтимирова Фәймә*
*Фитих кызы (1930 елгы).*
*Танып авылы*

Буйынтәңкә қаш белән имәнеч *(гаҗәп, искиткеч)* матур ийе әнинеке, буйынға таққаннар. Чулпылар ишү *(толым)* очона, чәч астында тағын бетеү *(әд.бөти, догалык).*

Өскә җиңсез жилит, камзул җиңне була, басқан алҗапқычлар кидек.

Шуннан чықты қый *(бит)* қысқа күлмәк.

Көмеш дуғанақлы сырғалар *(алкалар)* таққаннар, бырушкилар қадап кигәннәр күлмәкләрне ыспайы *(матур)* итеп. Тутайныңы орган *(гармун итәкле)* күлмәге, бөкләмне (складлы), атлап җөрмәгә рәхәт.

*Сөйләүче: Сабитова Найлә*
*Габдрахман кызы (1923 елгы).*
*Султанай авылы*

## Аш-су турында

Қыстыбыйны дары *(тары)* җармадан да була, чөчөлий (төчегә) қамырны җәйәсең дә табада бешереп аласың. Дары җармадан ботка пешереп йағасын. Икегә бykләп табаға үwәсен майлап-майлап.

Икмәк күwәсен икмәк чапчақ тибез без, тақтадан йасап бирәләр кисеп. Бер икмәк чапчақ қамыр була, икмәк әwәләп қуйасын ачы қамырдан.

Чәкчәк қыз йақтан әпкиләләр, уртара *(урталай)* кисеп берсен өстәлгә қуйалар. Тағын қаз әпкиләләр.

*Сөйләүче: Масагутова Тәнзимә*
*Мөхәмәтсафа кызы (1938 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

Кәкүк пичинйә – төгөрик қамыр була wы, өстөгә татлы начинка саласын. Ике йақны бер урыннан ғына чеметтереп қуйып, табада пешерәсен.

Төплөкәйне әни пешерәйде. Сийыр бозаулаған, уwыз эрегеннән *(эремчегеннән)* пешерә торган эризық. Эреккә йомырқа, қаймақ салайы, чынайақ тәлинкәсе қәдәр, өстөгә эрекне саласың йоқа ғына була, майлап өйәсең, аннан кисәсең.

Мичаш *(камыр ашлары)* пешереп җийам (күп-күп итеп) күб итеп.

*Сөйләүче: Максиева Гүзәл*
*Зәки кызы (1953 елгы).*
*Төнгүк (Тюндюк)*

## Йолалар

Қымызны (какы), пиканны (дягил) иңгелек имгә булсын дип эзләп қабып җөрибез ий. Шушының озорлоқ итеп киләсегә дә ашамаға Ходай қушсын дип ашыйбыз. Көнө буйы җөрибез ий. Бүре қузғалақ иренгә тисә иренне җара. Пиканның шәнгәсен (пәрәмәч) пайда булсын, дип, мийә дә әпкилеп бирделәр.

Шәңгә, дибез ий, пикан пеште исә шуны турыйлар ийе, картуп җәйгән кебек җәйәләр ийе. Майны эретеп қанат белә майлыйбыз ийе. Пешергәне тәмне була кый.

*Сөйләүче: Якшиева Мөкәрәмә*
*Хуҗа кызы (1920 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

Әни-этей белә үстем. Кийәүгә чықтым. Бер бала белән қалдым ийе аңан *(аннан),* иремән *(иремнән).* Уланнарны сақлап қына үстерәсен. Сәлигә *(бишеккә)* бетеүләр *(догалык)* қуйасын шайтан алыштырмасын, зәхмәт тимәсен, тип.

Чирләсә, өшкөрәсен, йә күреше әбидән өшкөртәсен. Көмөш тәңкәләр эләбез сәлигә, уланнарға чир, зәхмәт килмәсен, дип.

Туй йасағанда қызны сурап башқода килгән. Сүз булса (*килешсәләр*), қызға сурағаннар тарту, ақча йнде ул. Сүз була да кийем өскә-башқа, күлмәк, җаулық, ақча бирәләр ийдер. Кәбен *(никах)* уқыталар муллалар алып. Бирнә була, азрақ кийем-салым.

Қайынана қаршы ала, балда-майда йәшәң, тип. Әңкә қарчыққа бүләк саласың, балаларға шишара сибәсен.

Туйда, қунақ wақытта тутырма бирәләр, ит беле эчәкләр эченә тутырған, кискеләп бирәләр ашамаға. Эчликмәк *(пирог)* җимеш салып эченә. Җәйгеч *(көлчә),* ағысы теләсә қайчан да пешерәсен, әпәй қамырдан. Мич алда қузда *(утлы күмер өстендә),* ачы қамырдан мич алда пешереб алалар.

Туйда тағын чәкчәк, гөлбәдийәсе қатлы-қатлы. Торт йасыйлар өстөндә чәчәкләр йасап җийалар. Қөрән уқыталар. Қорбаннық аш пешерәләр, сарық чалалар, йасин уқыйлар.

Йыланны үтермәгә қушмыйлар, мал-туwарның хуҗасы ул дип.

Йаwыны аңқы аның булмый, урак урғанда йолт-йолт итә, күк чатлый диләр *(аҗаган турында).*

*Сөйләүче: Рангулова Зәйнәбә*
*Мулламөхәммәт кызы (1929 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Элек әти-әни бирә иде қый *(бит).* Ақлар суғышты, әти суғышта булған. Атын биреп қалдырған да үзе қызыллар йаққа чыққан. Оло йәшендә генә қызлар алған, 29 йәштә булған. Мехәммәтшакир үксез малай булған. Уқый алмаған, уналты йәшьлек қызымны бирәм, дигән. Әрҗән *(авыл исеме)* аwылнықы қәртәтийем, әтийем Ақлыш аwылнықы, ике қарт сүләшкәннәр дә баларын қушқаннар. Йортлар бөтөргәннәр. Мине әти үзе йәрәшеп бирде. Әти бирә. Сеңелемне дә әти бирде. Йегетне күрәләр дә ризалашалар. 38 йәшемдә кендек тамырымны бордороп қына бер малай таптым. Ыстукан *(рюмка күздә тотыла)* тотмадым. У чақта көчлө әбиләр

күб ийе, кендек әбиләр. Быwыннар чыкса, утыта йы, теләгәненчә. Тушы аwылда дөнйаға килгәнем. Озон йалан *(авыл исеме)* мәктәптә, жите чакрым, белем алдым.

Үзебез теләк белән түгел. Мин күргән жуғ ийе ул җегетне. Әти күргән. Аңкы *(аның)* этийен дә күргән. Икесе сүләшкәннәр. Суңыдан тормышка чыкмадым. Туй йасадылар, түшәк җәйделәр өч қат. Өч қат җәйәләр дә син менеп жатасын. Қунақ җийалар да синеңке туйыңны үткәрәләр. Шаршау була, әнә шушылый җабылып қуйылған була. Суңыдан *(соңыннан)* чыкты чымылтық җиңгәләр. Шаршау қырда мин үзем дә жырлап тордым. Бик матур жырлар жырлыйсың аны икесе турында. Туйларда бик жырчы идем. Йәшлегеңән жырладын да жырладың, ат белән жырлап үтәсен ий.

Ақча, бер қат кийем биргән җегет қызга. Ақча сала җегет, тән хақы, қызныңқы тәненең хақы, тарту шунысы була.

Әти әнине сөwә йе, илле мөңнөк қый бу дип әйтә йе. Тән тартуwы дип силәшкәннәр туйға җегетнеңке ақчасын. Мал биргәннәр, сыйыр, сарықлар. Чебеч *(тавык),* қазлар бирмәгәннәр, аралар бозолмасын, тип. Алып бирәләр аны.

Мәһәр эне *(әнә)* бер қат кейем, туй, шул мәһәр бит инде, биргәннәр. У чақта балдақ кийелмәгән. Кәбен *(никах)* туйында молла уқый. Сума күпме тора, туйында, кәбендә сүлейләр. Кәбен әти жақта була. Қыз шаршау эчтә утыра. Кешеләр қызны күрмиләр анда.

Йегет шаршуны ачып қарый. Күршедә бер бабай бар ийе, көлдөрәдер ийе. У чақта қыз итеп бер матур қызны утытқаннар. Ачып қарадым, суқыр икәнен күрмәдем, астағысы бар ийе, өстәгесе йуғ ийе, ти икә.

Кәбенгә оло йәштәге туғаннарын җийалар, йәшләр керми. Туйларына кем керсә дә йарый, ақча салып керәләр. Түшәкне ничә қат җәйгәннәр, шул хәтле кич, җоқлыйсың. Иртән кийәү мунчасы. Аны зурлап силиләр. Ақ мунча була, қыйбат ул, ақча түлиләр.

Туй йасаучылар аз ийе қый, аны эзләп алалар. Әкийәтчийе бит этийебез. Қызым туды, қарадым да, бидрә алдым да, бодай тутырдым да, киттем базарға йаулық алырға. Фырансуз йаулық алып қайттым қызыма, тип сүли ийе әти.

Қызны тегенәнтын қәйнә қарчық алып чыға. Ат қый *(бит)* ошу *(ул)* чақта. Арба ите, көймә дәwерләр элек булған. Көймә *(килен төшерә торган, өсте ябулы арба)* белән җөргәндә қызның төсен күрмәгәннәр. Анда ишыгалда җыйылған халық, қәйнә қарчық май

қаптыра. Анантын, йөзең йақты булсын, миңә йақын был тиб әйтте, битен сыйпый. Уқымасаң урам буйдағы аламага *(чүпкә)* әйләнәсең. Киленне күтәреп қәдерләп кенә алып кереп китәләр.

Атқа чиккән сөртүләр *(сөлге)* эләләр. У (сөлге) ат кемнеке, кем йөрөткән, шуныңа була у чиккән сөртү. Нықый *(әнә бит)* киленне аттан төшөргәндә, «килен төш, сарық бирәм», ти, хәленә күрә, чебеч (тавык) тиб әйткән кешеләр дә була.

Бусағадан кергәндә, тиң ғөмөр, матур таза балалар булсын тип, тату балалар дөнжаға китерең, хезмәт балалары тусын, тип телиләр. Киленне ишектән кергәч мич алға әпкилеп қашын қаралтасың қором белен. «Тиң тороң, мәхәпәтле булың» тип әйтәсең киленгә. Йитенче-сигезенче көнөндә он иләтәсең дә, шул онға ике қулын шул онға тықтырасың, уңышлы булып йәшәсеннәр, дип. Қурықыч *(хәтәр)* туғаннар өйләнешеү.

Үземнеке малайымныңқы қызы үлде. Үсем генә қыз.

Бала тудырам, кентеген кисәмен, мунчада тәрбийәлим. Унсигез йәшь қый у чақта мин. Эле шу балалар үсеп җийдылар *(барысы да үстеләр)*. Нәнәйләре *(әниләре)* йалғыз, этиләре үлеп җийдылар.

Буwыннар утытам, күзләреннән тел белә аламалар алам, гырижалар алам, кендектән өрөп урынына утыртам гырижаны. Бырач апиратсы йасый, эзләп алды гырижаны. Әле бысы атасы, диде, гырижаныкы, бер ай ашатма, диде, әз генә сөт бир бик сораса, диде. Нәнәйләре сықтамас *(еламас)* булғас бүсер дип аталаwы татарча.

Үзе күзем белән күрдем. Арпа ул күзеккәннән чыға, бусы беренче. Икенче, ул җилдән була. Урамға апчығарға кәрәкмәй, укыйсың қолһуалла, күзенә өрәсең өч мәртәбә, чипаны *(чуан; биредә арпа авыруының үзәгендәге үлекле шеше)* тишелеп аға да бетә ул. Аңғай *(тиз, шунда ук)* ғына бабай килде дә суға салды. Өч көннән йарға чығып утырғаным. Ипи пешеп чыққанда мине дә пичкә орғаннар. Алып кийендергәннәр дә кийемне йаққаннар. Мине су аста оҗмахны күргәнсен, диделәр. Нинди ризыклар ашыйлар, барын күргәнсен, диделәр.

Суwық чир *(бизгәк)* белән мин үзем йатқаным, ашулар *(ашау)* начарлықтан була. Мунчадан чығалар да җилгә басалар, суwық чир була. Үзеңнең әргәнизмыңны сақламаға кирәк, теләсә-нимә ашыйсыз, чирлисез.

Киленне сыныйлар, суwы бидрәсендә чайпалмаса йақшы дип саныйлар. Аш-суға қулланасың ул суны. Киленне қәйнәсе сынап

қына тора. Суның ағышына түбәнрәк, өскә таба алмаға кәрәк. Шайтан алды, дип әйтәләр қый. Килен алдан уң айағын атлап керә. Һөнәр булмас, башта сун айағын алды диләр.

Әлхәмне тулы уқың, жаwынны теләң, дидем. Шунда арқыры урам, балчықлары жүwешле булмаса, кәртүпләре ыwақ була.

Узырлап *(зурлап)* қарый киленем. Қөрәнне ачып жыр кебек уқыйсың. Қурқудан қайын ағачны бөгәләр дә, әлхәм уқып жөзөнә өрәсең қурықсаң, әлхәм белән отқарасың *(куасың)* аны.

Йәше житкәнме, ағачныңқы төбөнә басасың да ботағын санйысың. Қарыйсың, өскә қарағанмы, асқа қарағанмы. Өскә қараса озақ чирей *(чери)*. Идән асқа Йаңаwыл йақта кистек ағачны без. Қарағай житкән булса 78 *(ботак буыны)* булырға, қарағай ағач чирле була. Қарагайның аның кешесе үлә. Қарағай ағач кешенең ғумерен қысқарта, диб әйтә. Усағ ағач озақ чыдый, ну таза булмый. Жүкәдән мунча салалар, ызба салғанны белмим.

Қорбаннық итеп мал суйалар ийе басуда, сарық, жә жылға буйда. Итне ашыйсын да аққан суға оралар кешене, бала-чағамы, оло кешеме кейеме белә, айыпламыйбыз да. Урамлардан азан әйтеп жөриләр ийе, бер 3 бабай урамнар сайын әйтеп жөриләр ийе. Аwыллар да тынычланып китәләр ийе, чаташып *(тәртипсезләнеп)* жөрүчеләр дә бар. Чаташып китте исә, жиде әлхәм укыб өрмәгә кәрәк.

*Сөйләүче: Салихова (Узакаева)*
*Нурисә Гаптелхай кызы (1927 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I)*

Балаға күз тисә ничә тәрәзәнеке тирен сөртәләр дә битләренә маңғайларына тийерәләр. Арта *(аннан соң)* қором буйап қуйалар күз тимәсен дип.

Энә ағысын *(әнә анысын)* ишеткәнем бар. Ике йәбешеп пешкән ипине баланың башы өстөндә икегә айырып жибәргәннәр теле озақ чықмаса.

Қорбан чалу бар. Балалар йармадыр, йомырқасын, майын жыйалар да Тол буйда ботқа пешерәләр әбиләр. Моллалар йаңғыр сурап намаз уқыйлар. Артан сыу сибешергә тотыналар. Моллаларны, әбиләрне, кем бар, барысын суға ташлыйлар. Бөтөн кешене суламаға тийешле. Бездә қорбанға үгез суйалар. Тәлинкә қалағыңны чығарасың, ашын ашап қайтасың.

Йаңғыр йаумаса, анан, йалғыз қәбер булса, шуның қәберенә су алып барып салалар йаңғыр теләп. Ул туры килә дә. Йәшен йәшнәп, күк күкрәп йаwа башлый.

*Сөйләүче: Максиева Гүзәл*
*Зәки кызы (1953 елгы).*
*Төнгүк (Тюндюк)*

Элке дә, хәзер дә шулый, қыз йақтан чәкчәк булған, қаз, теге қодағыйлар әзер гөлбәдийә пешереб аппарғаннар, өч қатлы булған, күпчелек, өч кич қунып йата кийәү. Өмөҗө *(кура җиләк)* пирук, баллы чәкчәкләр алып бара. Күпле *(ишле)* қунақ булса қазны икене дә пешерәләр, туй ашлары шулар, аннары чәй.

*Сөйләүче: Гозаерова Фәния*
*Нәҗмехәмәт кызы (1928 елгы).*
*Күчтәнти (Константиново)*

## Қарга ботқасы

Ололар уқый. Тол *(елга исеме)* буйларға төшөп уқыйлар. Ар та *(аннан соң)* суға орошоп *(ыргытышып)* бересе бересен. Қарға ботқасы дип әйтеп.

Қорбан чалу қатыланып *(ешаеп),* күбәйеп китте. Үлгәннәргә җиңеллек килә, тиләр. Элек сирәг ийе, хәзер күбәйде, дөнйалар байыққач *(баегач).* Қорбан чалғач туған-тумачаларын җыйып ашаталар, тараталар. Суwәген этләргә бирмәгә қушмыйлар. Суға ағызып қына җибәрәләр ийе. Атап суйдырған кешесенә атап бағышлыйлар. Қолағы да қатты қый инәйнеке дә. Сызавай *(торак пункт)* дип сүләшәбез, шул буйда барысы да. Җите ғәзизләргә бағышлап қуйалар. Шушы Тол буйларны, җирләрне сақлый, диләр. Баш сүwәген ормаға йарамый, чалған кеше ашамаға тийеш, тиләр ий. Хәзер кумәләр дә қуйалар эчәге белән башын.

*Сөйләүче: Гаязова Гамбәрә*
*Рәхимҗан кызы (1929 елгы).*
*Сараш авылы*

У йылны җийылыштық та қорбан чалырға булдық. Қорбанның бәйрәмнәрендә туғаннар, ишләр *(қода-қодағыйлар)* барың бергә утырасың. Ашый башлама борон салаwат әйтәбез ишсез *(парсыз, так)* итеп. Малларның хуҗасы, хайваннарнықы Зәңки бабай,

Даwыт пиғамбәр тихникаға хужа диб әйтәбез. Болында бийек тау бар, шунда.

*Сөйләүче: Чуракова Нәҗмия*
*Миңнулла кызы (1921 елгы).*
*Сараш авылы*

## Риваятьләр

Ағач башқа икү *(икәү)* йарымтыққа *(ярымтык булып)* менеб утырғаннар да ике қарчықныңы исеме белә қычқырғаннар. Икү әби печин җиймаға барған булғаннар, қайтып киткәннәр. Йарымтық булмағандыр ул, берсе шайартқан ғына.

Қәртәнийем Камилә исемне. «Аһа-һай, Камилә, қайа барасың, Камилә» дип қычқырғаннар. Әме қый, аһа-һай тип исеме белә қычқыра имеш *(икән)* җарымтық *(шүрәле)*. Җарымтықныңы тешләре аwызындан сәлдерәп тора, күзләре чығып тора. Озон тырнақлары да җаматай *(ямьсез)* булған. 4 айақ белән қуллары булған, бармақлар болый озонның булған. Күргәннәр сүлиләр қый. Қачқылар ағач башына менеп қачып җатқаннар. Күкрәкләре сәленеп торған, қойроғо сирәлеп җөргән.

Ақалан бабай, йәмсезрәк бабай, балаларны Ақалан бабай дип қурқыта торғаннар ыйы. Без кечкенә чақта, Хәким килә диләр ийе, йәмсез дә түгел ийе.

Уникедән суң шайтан дип сүләмәгә дә йарамый. Шайтан мунчада улан да таптырған. Бер әбине алып киткәннәр. Ашар имә *(нәрсә)* апкилеп күрсәтәләр әбинеке. Шайтан бала таwыб утырған. Баланы тудырған да, қайтарып җибәргәннәр. Әбинеке ыризықны алып килгәннәр дә, җалап қына алалар. Менә қый *(бит)* өстәлдә ыризық қалса шайтан йалый, дип сүлиләр.

*Сөйләүче: Мавлютова Мәмдуха*
*Нурулла кызы (1920 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

## Хатирә

(*Рәшит Җәгъфәр турында*)

Мийән йәшсен икә. Үскән чақта имәнеч *(бик)* күрдем күрәмәтне *(күрмешне)*. Уланнар күбий, апам бар ий, уртанчысы да бар ийе, қалдығыбыз уланнар ғынай әле. Инәйем биш уланнар қараб

үскерде. Уланнар узырайтисә *(зурая, үсә төшкәч тә)* көтүгә чабу хәттийүг *(еш кына)* ийе. Бетеки генә чабабыз да печинен, имәнеч тә аwыр у.

Рәшитне сағынабыз инде рәдем *(рәттән, янәшә)* торғас. Хәзер ул үне кийәүнеке абзийы алды, қырына ызба төп *(фундамент)* қуйдылар. Рәшит гел шушында *(бездә)* булды. Имәнеч тә сағынам. Мин йақын күршесе булам. Қарман *(авыл исеме)* мәктәбендә уқыдық. Имәнеч әйбәт ийе, игелекле, намуслы, эшкә тырыш ийе. Сабантуйларында баш булып, уйын-көлкеләр қуйып йөри ийе. Миндә дә бар аның шиғырь китабы. Әнисе суқыр аның хәзер, Әминә әбийебез.

Кичләрен «Күбәләгем» тип тә жырлыйбыз ий, үрелеб *(әйләнеп)* уйныйбыз ий житәкләшәбез дә икешәр кеше, жырлыйбыз.

*Жырлыйғ әле, жырлыйғ әле,*
*Жырламый тормыйғ әле.*
*Чәчкә кебек йәш ғөмөрне*
*Бушқа уздырмыйғ әле.*

*Жырлыйғ әле, жырлыйғ әле,*
*Жырлаб ачыла күңел.*
*Жырлаб ачылмаса күңел,*
*Мәңге ачылачақ түгел.*

*Сөйләүче: Хасанова Камилә*
*Корбан кызы (1937 елгы).*
*Күчтәнти (Константиново)*

### Рәшит Фәйзрахман улы Ягъфәровка багышлыйм

«Тәңрем сиңа үзгәрүчән холык биргән, бер “чәчәктә” озак утыра алмый торган “күбәләк” жаны биргән»

*Бисмилла диеп башлыйым*
*Рәшит дусқа бәйетем,*
*Аның рухына доға қылам*
*Қабул қылғыл ил'аһым.*

*Сиңа, дусқай, бала чақтан*
*Әдәбийат жене қағылган,*
*Шуның өчен дә әле син*
*Бөйек ғалим булып танылган.*

*Туған аwылың Күчтәнти Баш*
*Урал тау итәгендә.*
*Кечкенәдән хезмәт сөйдең,*
*Ирештең теләгеңә.*

*Синең ижқат җимешләрең*
*Сөйендерде күпләрне.*
*Бигрәк матур ижқат иттең*
*Хәтерләтеп күкләрне.*

*Қайда ғына йөресәң дә,*
*Йуғалып қалмадың син.*
*Туған иттең һәр кешене*
*Қаршы алып, озаттың син.*

*Әле күпме ижқат итәр идең,*
*Йәрдәм итәр идең халқыңа,*
*Ышанасы килми китүеңә,*
*Йәшисеңдер кебек арада.*

*Чәчләреңнән йуллар салып,*
*Көтә бит ғәзиз анаң.*
*Көйли ул йәшләрен сөртеп,*
*«Озақ йөрисең, балам».*

*Көтәләр сине улларың,*
*Көтә сине, Әкълимәң,*
*Ашын суытмыйча көтә:*
*«Қайчан қайтасың иркәм».*

*«Қайтыр йулыңа ақ томан*
*Төшәр дә төшәр инде,*
*Ақ томанның ақлықлары*
*Чәчләргә күчәр инде».*

*Йақыннар сағына сине,*
*Сағына-сарғайа инде.*
*И Ходайым, айырылулар*
*Дөнйада булмаса иде.*

*И, Ходайым, айырылғанға*
*Бирче күркәм сабырлық,*
*Була инде аwыр чақлар,*
*Сабырлық безгә сабақ.*

*Шундый кеше дөнйа куйар дийеп*
*Башыбызға бер дә килмәде.*
*Қәбер әһле булған бу бәндәңә*
*Саwап булып барсын һәр доға.*

*Автор: Расулева Язилә*
*Искәндәр кызы (1945 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

## Яңа ел кичендә

Миңке йат хәбәрләр бар. Берәү апа килде Қазаннан. Анда қунақлап *(кунак булып)* қайтқаныбыз бар.

Жаңа йыл кичләрдә кичкедә кереп бәйрәмгә җөриләр. Без көтөп торабыз сөрән суққанда шикелле. Балалар килә, дип, қәнфитләр алып, пичинйә пешерәбез ий. Қамырны җәйәсен дә, самаwыр камфаркасын басып, писуклар сибеп пешерәм ий. Алар сүwенеп, сикергәләшеп, уйнап чығып китәләр.

*Сөйләүче: Гаязова Гамбәрә*
*Рәхимҗан кызы (1929 елгы).*
*Сараш авылы*

## Аулағый

Қойолып-түгелеп утыра торған бер ызба бар сул йақлап. Пескеттин ут *(сукыр лампа)* белин утырабыз. Ағысын (анысын) эшләп, буғысын *(моносын)* эшләп утырабыз. Аулағыйларда бүтәнчә *(искиткеч)* ыспай *(матур)* итеп җырлап җийабыз ий *(җийлу – фигыльдән аңлашылган эшнең күп башкарылуын белдерә).* Малайлар утны тизрәк сүндерәләр ий, йаратқан қызларын қочасылары килдисә.

У чақта йаза *(җәза)* қый *(бит),* җитен җиткезеп, ирләп *(эрләп)* киндер күлмәкләр дә кидек.

*Сөйләүче: Гаязова Гамбәрә*
*Рәхимҗан кызы (1929 елгы).*
*Сараш авылы*

Аулағыйда йөзөк салыб уйныйбыз ий. Йөзөкне әйтәлмәсә, йаза бирәләр. Қайсығысы тышқа чығып китәләр ий сүләшмәгә. Чоланға *(өйалдына)* чығып суләшәсең. Абзыйыңны чығарғаннар. Бергә

чыққан қыз күршесе булған, аңан күрсәтәбез, дип. Қыз абзыйыңны танымаған да ике қатлы йортны әйткән безнеке өй, дип. Бере берсенә сынашқаннардырмы. Абзый үзенеке күрше булған. Тутайны қуwып *(ияреп)* җөрдөм дә кечкенәсе булғач җөртмәгәннәр. Бик ғайәр *(усал)* булған ул. Җегетләр йаматай сүз әйтсәләр суғышам ий мин алар белә.

Җөзөкне җөрөтәләр дә, йөзек кемдә, сикереп чық, диләр, әтәч булып қычқыра йә шунда.

Шүрәле уйынын уйныйбыз, тунны әйләндереп кийәбез дә, аwызға чыра қаптырабыз да сүләшәбез, мине танымыйлар ийе.

Әтиләре, әниләре киттисә аулағыйлар йасыйлар ийе.

*Сөйләүче: Мавлютова Мәмдуха*
*Нурулла кызы (1920 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

**Уеннар, җырлар**

«Наза» уены: Қул белән тотонышып тезелеп басалар да җырлыйлар:

*Қашың қара күзең күк,*
*Сиңа сүләр сүзем күп.*
*Сүләр идем сүзләремне,*
*Сине күргән кичем йук.*

*Наза-Наза,*
*Наза матур қыз бала,*
*Наза матур ударница,*
*Уқыуда алдан бара.*

*Җырлап күрсәтүче: Айтачова Фәния*
*Сәхрәт кызы (1939 елгы),*
*Сараш авылы*

Кичтән утырабыз ий, җырлыйбыз ий:

*Қара дуға, пар қыңғырау*
*Бармы сезнең илләрдә?*
*Таwышығыз илләрдә?*
*Кичке салқын җилләрдә.*

*Җилфер-җилфер җил исә,*
*Чәч толомын җил кисә,*
*Мин дә сәләм әйтер идем,*
*Сезгә китереп җиткерсә.*

Кичтән җөрөгән чақта ыспай җырлар күп була торған ий:

*Туғаннарым мин үлгәчтән*
*Қәбрем тирән қазығыз.*
*Баш очома таш утыртып,*
*Исемемне йазығыз.*

*Исәм җилләр искәндә,*
*Үсәм гөлләр үскәндә.*
*Сағынамын туған илне*
*Әллә бергә үскәнгә.*

*Йоқоң килсә, йатып җоқла,*
*Ләкин йабынып түгел.*
*Син йар сөйсәң, мин дә сөйәм,*
*Ләкин йалынып түгел.*

*Йоқоң килсә, йатып җоқла,*
*Қараwатның буйына.*
*Уйанып китсәң, қурқып китмә,*
*Мин булырмын қуйыныңда.*

*Ишегалдым гөрнәчә,*
*Күгәрченнәр гөрләшә.*
*Үзе йарларың булмаса,*
*Йатлар қаты эндәшә.*

*Йәшлегемдә бер йар сөйдем*
*Аныңа гөлләр чәчәк атсын, дидем.*
*Шул чәчәкләргә қарап,*
*Күңелемне җуwаттым.*

*Җегет булса шундый булсын,*
*Сағнам сезне ул йақта.*
*Төрлө қошлар төрлө җақтан*
*Моңно сайраған чақта.*

Йомычқа уйын. Утынныңтағы тақтаның берсе башына йомочқаларны қуйасың. Йомочқаны кем күбрәк җийа шул чыға. Тағын қабатлап уйныйлар.

Тақмақлар нишшан *(искитәрлек)* күп монда.

*Сөйләүче: Расулева Язилә*
*Искәндәр кызы (1945 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

Аwылныкы жыллыкларын да үткәргәннәре йуқ. Сабан туйлары бар ийе. Кичке уйыннар беткән инде.

Шоморыт тоқыны, дип шүләшәбез, ике йаклап ағач. Бу йағыннан керәләр дә китәләр. Җанғарап тора торған музыкалар жуғ ый. Һәр замана үз wақыты белә.

Алдаш уйныйлар, қулалышып уйныйлар. Аймақ уланнар үстек. Эшләмә йуқ қәзер, төнө буйы бииләр. Эш қалмады, чабуларға ағач үсе беткән.

*Сөйләүче: Кучубаев Нәҗибулла*
*Нәҗмугата улы (1937 елгы).*
*Байавыл (Күземьярово)*

Кичкуйын, тиб әйтәбез ий. Жырларын онтоп бөттөм қый. Мәгә *(нигә)* онотам исә ни *(микән)*. Тағаннар атынабыз ий, миңке *(минем)* Сылутай *(кеше исеме: Сылу тутай – апа)* бар ийе.

Миңке бабай *(минем ирем)* үлде у *(ул)* жыл, жите йыл инде. Үзем дә берсе айағым жирдә, берсе айағым гүрдә. Мәчеткә йөрөб алғалы кәрәк. Анда намаз уқыйбыз. Ақрин-әзләп *(әкрен-әкрен)* йәшләрне дә үрәтәм.

*Сөйләүче: Хәсәнова Камилә*
*Корбан кызы (1937 елгы).*
*Күчтәнти (Константиново)*

*Бийек тауға менгән чақта*
*Борылып қарамадым.*
*Әйтер сүзем әйтәлмәдем,*
*Өзөлә йөрәк майларым.*

*Ағыйделдән ағып килә*
*Санийа дигән сабын.*
*Берәү булса үләр иде,*
*Әле дә үзем сабыр.*

*Ағыйделдән ағып килә*
*Санийа дигән тарақ.*
*Мине исегезгә алырсыз*
*Шушы урынға қарап.*

*Алый қарағән була,*
*Болый қарағән була.*
*Ат-дуғарып җигә белми,*
*Қызлар сайлағән була.*

Кичке уйынны очта Тирәк бар, озур ағач ул, шу тирәккә барабыз, таған атынабыз ийе. Үрелеп тә уйныйбыз ийе җырлап-җырлап.

*Сөйләүче: Мәсәгутова Гөлҗиһан*
*Газихан кызы (1943 елгы).*
*Султанай авылы*

**Үсемлекләр дөньясы**

Монда қайын, имин, шыршы, чаған *(өрәңге)* үсә. Ызба *(өй)* асларға имин ағачны утырта йек. Җирек, тал үсә, қарағай (нарат) да бар. Акчаға была *(өчен)* үзебез дә утыртқаныбыз бар, уҗым *(үсенте)* үстерәләр дә анан утыталар. Чыршы да утыталар шикелле *(ахрысы)*. Шартлама *(җир җиләге)* үсә, бер дә харап. Қайыннан йапрақлар бәйлиләр, қатыққанчыға хәдәр *(яфрак ката башлаганчы)*.

*Сөйләүче: Гаязов Галиәскәр*
*Гаяз улы (1946 елгы).*
*Сараш авылы*

У җылларда ашар имә бармы? Икене җоморқа пешереп самаwырда, пикан көпшә *(дягил)* турап ашадық. Чабуда үсә ул. Қымызлар, балтырған ашыйбыз ий. Арыш икмәкләр исәпле булды, бодай икмәкне әйткән дә йуқ. Чемеркә *(рус. бутень клубненосный)* тамыр, дибез ий, арта қычыртқанны күб ашадык, әле дә ашыйм әле, аңқы ашы сөт белә ыспайы була, имәнеч тә әйбәт. Көзгөдә *(көзен)* кәтүк *(бәрәңге)* сатам.

Ишегалдында өмөҗө *(кура җиләге)* үсә, иргә *(ирга),* қарағат *(кара карлыган),* мелиш *(миләш),* шоморот, этборон *(гөлҗимеш)* үсә.

Бездә черекей *(мәтрүшкә)* күб үсә, сары черекей *(зверобой),* күк черекей *(мәтрүшкә).* Чәйе тәмне була, сатыб алған нимә түwел қартлықта.

*Сөйләүче: Чуракова Нәҗмия*
*Миңнулла кызы (1921 елгы).*
*Сараш авылы*

Мәтерүшкә парлыйбыз сыwық тидисә, ағәрем дә пайдалы. Кечерткинне күб ашадық. Қарағач *(кара чыршы),* элмә, усақ, ақ чыршы ағачны беләсезме? Череки печин, бөтнөк, қумалақ күп була бездә, қолмақмы сезнекенчә. Даруланабыз җимән төрле қый печин.

Баңкы да утыталар, қоро баңка да утыталар ыйы. Қанны да чығарталар банкы утытып. Қан банкы тиб әйтәләр ағысы *(анысын).* Мин үзем сүлег утытам *(сөлек салу).*

Башның мийе төште *(баш аву),* шушы әби утытты қағып. Баш аwыртса төбәгә *(баш түбәсенә*), җомоққа *(лепкәгә)* шоқмит *(әрекмән)* җапрақны қуйам. Бупча (рус. *вовсе)* электә әбиләр ағ эремнәр эчкән. Суқыр кечеткән уғата (бик) пайдалы қый. Миңке *(минем)* узыр *(зур)* қызым суқыр кечеткән эчеп кенә айағына басты. Бер җәйгедә мин үзем дә шуның белән дәwаландым.

Себеркәй күкәй (рус. *бутень клубненосный)* күб ашадық. Аны қый қазыб алалар, җуwалар да ашыйлар. Тирмәндә тартыб ашыйбыз тамырын, күкәйен.

*Сөйләүче: Мәсәгутова Тәнзимә*
*Мөхәммәтсафа кызы (1938 елгы).*
*Үдик (Елпачиха)*

Киндер күлмәк тә кейдек кичкенә чақта. Ирләп җийасың *(күп итеп эрлисең).* Ағачтан нийе була суға торған. Әни кеше суғыб утыра, ары қаға. Аңғай качан суғып бетәләр, йәш уланнар бар ый.

Кәбестә бақчада эшләдем җәйли, көзгөдә ташыдылар ат беле.

Пиканны күрсәк, җийыб алып пичтә шәңгәләр пешереб ашыйбыз. Мешик *(капчык)* белә тутырыб алып қайтабыз ий. Қымыз *(какының бер төре),* қузғалақ, ат қузғалағы, себерткәй, кәзә сақал, этборон *(гөлҗимеш).* Төрлө печин *(үлән)* ашап, кечеткин пешереп,

нимә қындырып *(нәрсә эшләп)* ашағаннар. Тауға китәбез ий эшхәрә *(һаман).*

*Сөйләүче: Рангулова Зәйнәбә*
*Мулламөхәммәт кызы (1929 елгы).*
*Түбәнавыл (Ишимово)*

Җир өстөндә үскән печиннәр *(үләннәр)* эчәсен парлап барысы да чирдән дару. Өчмәсе *(өеме)* белән ийе қом, қомда йату кәрәк айына өч көн.

Кечеткәнне қайнар суда парлап аласын да, суға утырасын, чиста суwын эчмәгә дә кәрәк. Бырач миңән сурый, син нийә ғыжламыйсың титән. Пичен суларны парландырып эчәсен. Үпкәгә җите төрле пичен кәрәк: чирекей печин *(мәтрүшкә),* қайын йаwрақ, кечеткин, барысы да печин. Кечеткинне чичтартып, эчәй итеп эчсәң да йақшы.

*Сөйләүче: Салихова (Узакаева) Нурисә*
*Гаптелхай кызы (1927 елгы).*
*Беренче Әрҗән (Краснояр I)*

Шундый симез булыб үскән чемеркәй *(бәрәңге күшәсе*), қаҗаб *(кабыгын арчып)* ашыйсың, кикәйе була. Суwырыб алабыз да кикәйен әричебз дә қаждаб, ашыйбыз.

Қуйан қолақ *(балтырган)* сусыл, тәмне була, каҗаб алабыз да ашыйбыз. Қапчығы белән җийыб ашадық. Печтик *(нарат үләне)* ашадық, русча хәтле. Черкин *(мәтрүшкә)* сарысы (зверовой) да бар, күк чичкәлесе дә бар, қымыз *(какы),* үләннәр күб алар.

*Сөйләүче: Гозаерова Фәния*
*Нәҗмехәмәт кызы (1928 елгы).*
*Күчтәнти (Константиново)*

# АШЛЫ-СУЛЫ КИЛЕН БУЛСЫН

## Барда төбәгендә халык традицияләре

*Флера Баязитова*

Билгеле булганча, халык йолаларының күбесе бүгенге көндә югалган яки югалып бетү алдында тора. Ләкин әле өлкән буын вәкилләренең хәтерендә, телендә борынгы йолалар һәм йола сүзләре саклана, алар буыннан-буынга тапшырылып, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән. Менә шул рухи байлыкны халыкның үзеннән сөйләтеп, мөмкин кадәр тулырак итеп җыйнап алу бик зур бурыч булып кала килә. Бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребезне төрле яклап өйрәнергә, элемтәләрне ныгытуга зур игътибар бирергә кирәк.

Пермь краенда яшәүче татарлар – татар халкының үзенчәлекле бер төркеме. Биредәге татарларның традицион йолалары, йола сүзләре, фәндә кабул ителгәнчә, ике зур төркемгә бүлеп өйрәнелде:

1. Гаилә йолалары һәм аларның терминнары;
2. Ел фасыллары, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре белән бәйле йолалар, борынгы ышанулар һәм аларга караган сүзләр, терминнар.

Барда районында яшәүче татарларның традицион йолалары, этнолингвистикада кабул ителгәнчә, җирле сөйләш яссылыгында, ягъни телне үзгәртмичә, ничек сөйлиләр шулай итеп язып алынды. Йола терминологиясен, йола сүзләрен контекстта, текстлар эчендә, ягъни иллюстратив материал белән ачыклап, ныгытып баруга игътибар ителде.

## Гаилә йолалары һәм йола сүзләре, өйләнешү, туй ясау

***Яучы килү, кыз димләү, йәрәшмәгә килү:***

– Йаучы йөретәләр ике арада. Йегет йағыннан килә қыз димләмәгә. Кызның ата-анасы бирмәгә булса, қыз бара. Безнеке абызыйға қыз алдылар йәрәшеп *(Сараш)*.

***Йәрәшмәгә килү, кызның ризалыгын белү.***

– Йегетнеке эти-әниләре қызнықы эти-әниләренә йәрәшмәгә киләләр. Атасы-анасы ыриза, кыздан сурамага қыйышмыйлар этиәнисе. Қызға бүрек белән орып қарағаннар йәрәшмәгә килгән йаучылар. Ыриза булса, қыз аwып китә имеш, ыриза булмаса, тик тора имеш, арқыры *(Солтанай)*.

***Сүз бетерү.***

– Сүз бетерүгә бара қызға. Қызның ата-анасы әзерләнә, каршы ала.

***Бүләк бирү, билге бирү.***

– Йәрәшеп қайталар, сөлге бирәләр билгегә дип. Киң озын тастымал, қазан тастымалы бирделәр. Ышандықлы була. Бүләккә күлмәклек тә, шәлйаулық та бирделәр *(Күчтәнти)*.

***Кәбен қойу, кәбен уқыту*** – ниқах уқыту дигән сүз. *(Кәбен – фарсы теленнән кергән сүз. Ул татар теленең күп кенә башка сөйләшләрендә дә бар. Мәсәлән, бәрәңге сөйләшендә (Мари Эл), керәшен сөйләшләрендә, мишәр диалектының темников сөйләшендә һ.б).*

– Қызның атасы-әнисенә барып кәбен уқыталар. Кәбен уқытқач, туй йасыйлар. Кәбеннән сун, мунча кергән қыз белән кийәү.

– Иң беренче қыз йаққа чақыралар туйға. Кәбенне дә қыз йақта уқыталар *(Сараш)*.

***Божал*** (< монгол теленнән кергән сүз: *болзол* – вакыт, срок). Божалға бару, *хәбәргә бару – егет белән кыз үзләре генә килешеп өйләнешкәннән соң, егет ягыннан кыз ягына туй һ.б. турында киңәшергә бару. «Божал» сүзе вакыт мәгънәсендә минзәлә сөйләшендә, мишәр диалектының кузнецк сөйләшендә (Пенза өлк.) дә бар.*

– Кызларны урлап алып китәләр. Иртәгесен эти-әнисе китә қызнықы эти-әнисенә. Чәй, кампитлар алып бара божалға барғанда.

Қачан туйларны җасыйбыз, ти, wақытларны белмәгә килә. Божалға барабыз, тип баралар ий қызны алғач.

***Божал сорау** – туй вакытын билгеләү:*

– Қызны алучы җегет әти-әнисе килә божал сорамаға. «Қызығыз бездә, әрләшмәң инде, шул wақытта туй йасыйбыз, қода-қодағый» – тийеп йегетнеке әтисе-әнисе килә хәбәргә.

– Божалға килгәндә, хәбәргә килгәндә тастымал биреп кайтара. Икәү килсә, икене биреп қайтара. Хәбәргә барғач, әйбәтләп сүләшеп қуйалар *(Танып).*

***Түр күрсәтү** – туйга кадәр егет ягында кызның ата-анасын чакырып үткәрелә торган мәҗлес.*

– Түр күрсәтәләр. Чақырып аласың қызнықы ата-анасын. Хәзер дә туйға қадәр түр күрсәтәләр. Аны егет җақ күрсәтә.

– Сүз бетермәгә килгәннәр. Сүз бетереп қайтқач, егетнеке әтисе-әнисе қызнықы әти-әнисен қунаққа чақыралар, түр күрсәтергә. Никах уқығанчыға хәтле чақырмаға тейеш, ти, ул. Шунда инде бүләкләр, сөлгеме, җаулықмы бирә *(Сараш).*

## Бирнә, туйда үзара бүләкләшү

***Бирнә** – туйда, кыз тарафыннан кияүгә, аның ата-анасына һәм туганнарына, кияү тарафыннан кызның ата-анасы һәм туганнарына кара-каршы бирелә торган бүләкләр һәм кызның өйгә элү өчен алып бара торган әйберләре.*

– Пар тәңкә, пәрхәт *(бәрхет)* камзул сорыйлар кийәүдән бирнәгә. Ыриза булса, тиз була туйлары. Кийәү бирнәсен бирә алмыйча торса, озақ торған қыз төшмичә. Минең қәрт әтинеке *(бабайның)* қызы үсеп торған кийәү үwенә төшкәнче. Қызы тәрәзәнең буwын *(парын)* сөртмәгә йабышқан, ти.

– Қызға читекләрен, шәлләрен бирә кийәү җағы. Малайның бирнәләрен белгерә җаучы: «Шундый-шундый бирнәләре бар, ти, – мал-туwар, өс кийемнәре». Кийәү йағыннан бирәләр.

– Бирнә ике йақтан да була, йегет йақтан да, қыз йақтан да. Қыз йақтан чыныйақ сөртүләре *(чынаяк тастымалы)*, қул сөртүләре *(кул тастымалы),* айақ чолғау, күлмәклекләр була.

– Мендәр, йастық, җабу туны *(сарык тиресеннән тегелгән юрган)* була бирнәгә. Сарық тиресеннән теккән җабу тун, диләр. Берсе җағы җон була, берсе җағына басма *(ситсы)* тегә қайсы кеше.

Қайсы бер дә текми, тун күwе жөри ул. Жабу тунын қышқыда суықта аймақ *(күп, ишле)* уланнарға *(балаларга)* жабасың. Қунаққа барғанда чанада шуңа чормалып утыралар.

– Бирнә әзерләгәндә киндер урны қорабыз, ақ киндер чымылдықлар суғып жыйабыз. Тасқақта *(лапаста)* тастымаллар суғайық, тақта күтәреп суқтық тастымалны, жуғарғы чоланда суқтық. Ағысына *(ансына)* кирәк, боғысына *(монсына)* кирәк, түшәге, кийезе, мендәре килә. Тастымалны күп суғып жыйа.

– Чаршау, чымылдық қызнықы киндердән була. Өстәл жабу *(ашъяулык)* қызылға суққан, кижеле. Күтәреп суққан тастымалларым сандықта күп. Қулдан, күбәләк төшереп суққан.

– Өстәлгә илтеп жәйәрен, ишеккә илтеп эләрен – барын да биреп жибәрәләр қызға. Айаққа чормарға чолғаулар суғып жыйа киндердән.

– Паласлар анықлаған дүрт бүрәнә. жиде бүрәнә *(Сараш)*.

***Бирнә тарату, бүләк тарату.***

– Қодағый кеше тарата бирнә, қода-қодағыйға. Қызның қайынына (қаен атасына) кижеле ыштан, кижеле күлмәк булайы элек. Қайынына кижеле күлмәк китергән, тип әйтәләр ийе.

– Бүләк тарата. Қыз жақтан атасы-инәсе кийәүнеке заты-зөрийәтенә *(нәсел-нәсәбенә)* бүләк тарата. Кийәүнеке тағын қызнықы заты-зөрийәтенә бүләк таратып жыйа. Қара-қаршы була бүләк.

– Туй wақытында бүләк салышалар. Әти-әниләренә күлмәк, жиңгәләренә йаулық, түбәтий *(түбәтәй)* қара-қаршы биргән *(Танып)*.

***Инче** – кыз кияүгә киткәндә кызның атасы ягыннан бирелә торган тере хайван.*

– Сыйырын бирә, сарығын бирә, ат бирә қызның атасы.

– Қыз кийәүгә киткәндә инәчкә сарық бирәләр, орғасын *(үрчесен)* тип. Тана бирәләр ике жәшлек, қачқан тана бирәләр *(Күчтәнти)*.

## Килен әйберләре белән өй бизәү

– Өйне бизи қыз әйберләре белән: чуқлы қашағалар, чымылдық, йастық, мендәрләр.

– Тастымал, чымылдық, чуқлы қашаға элә килен қыжжиңгә белән. Мич қырына чаршау элеп жыйалар. Тастымалларны тәрәзәнең ике йағына сәлендереп эләләр ий.

– Беренче башлап чүгә тастымалын элә, қул сөртүwен илтеп элә, өстәл жабуын жаба. Килен кешене кем чақыра, шуңа тастымалын элә.

– Туйлашқан чақта қызның әйберен элеп җыйалар. Шаршау, чымылдық, тастымал эләләр. Тәрәзә араға сөртүләр, күбәләкле тастымаллар эләләр.

– Қыз үзе элеп җыйа төшкән җиренә. Қыз баласы *(кияүнең сеңлесе)* да булыша. Ызбаға чүрәли *(әйләндереп)* бау сузып, озынозын тастымаллар сәлендереп җыйалар, әрбирләрен күрсәтеп.

– Өстәл җабулары, тастымаллар алып килә килен. Тәрәзә өсләренә сәлендереп эләләр күбәләкле тастымалларны.

«Себертке *(себерке)* генә качып қала», – ди, қыз кийәүгә киткәндә.

– Бәйрәмнәр булса, ү беренә *(өй саен)* сәлендереп қуйалар тастымаллар, өстәл җабулары. Бәйрәм күрсен әйберләр, тип.

Қыз әйберләрен элеп күрсәтә, тастымалын, сөлгесен элеп җыйа, күрсеннәр өчен, йәмлиләр ызбаны. Матчаларға элдерәбезей қашаға. Гайетләрдә дә эләләр, ғаетне зурлап *(Солтанай)*.

### Килен сандыгы

– Сандық булайы қызның, пар мендәре, басқан кийез, йоннан басқан.

– Кийеү җегет белән қыжҗиңгә сандықны күтәреп кертәләр.

– Тиң торған, бергә торып қартайған кеше генә сандықны күтәреп алып чыға. Айырым торған, йалғыз кешегә күтәрмәгә қушмыйлар сандықны.

– Сандық урынға ақча салып қуйалар, урыны буш қалмасын тип, сандықны күтәреп алып чыққач.

– Қызның төшкән җирендә заты-зөрийәте кертергә тийешле сандықны.

– Килен сандығын, аныңқы әйберләрен керткәндә арасына кеше кертмиләр. Мендәрләре белән бергә кертәләр киленне. Шуңға күрә ике мендәрне дә мөгөшләреннән *(почмакларыннан)* тегеп қуйалар ый.

– Сандықны җақын туганнары алып керәләр дә җәймә җәйгән җиргә генә утырталар. Сандықта бирнәләре инде: қайнатаға күлмәк, үзе суққан тастымал, қәйнәгә *(кайнанага)* – күлмәк, қайнағаға – җаулық, қәймиңкәгә *(кияүнең апасына)* күлмәк биргән *(Солтанай)*.

## Кием-салымнар

***Камзул, букаптан.***

– Камзул кийәләр. Камзулның тәңкәләре була. «Букаптан» тиләр камзулны. Бәрхәт камзул, пырзумитлы камзул киделәр ару кешеләр.

*Запун – алъяпкыч.*

– Киленнең билләренә запун бәйләтәләр: «Киленең эшчән булсын», – тип.

***Бала итәкле күлмәк.***

– Монда итәк олыйлар ыйы *(ялгыйлар иде),* киндер күлмәк булайы.

***Алача күлмәк*** *– үзләре сугып теккән күлмәк.*

– Алача күлмәк кидем, алачаны үзебез суқтық элек.

***Әмәйлек*** – әд. *хәситә.* – Әмәйлек була. Әмәйлекне қыйықча итеп кийеп, тәңкә түшәп җыйасың аны.

***Читек-калуш, чәкәнне читек*** кийәләр, кийез қата бастырып бирәләр қыш көн.

***Чыба*** *– өске кием.*

– Чыбаны киндердән тегәләр.

***Уқа қалпақ, энҗе қалпақ, тәңкә қалпақлар*** булды башқа кимәгә. Қалпақ кимәгән кеше қарт күренә. Сағалдырыйқлап қалпақ кийәләр. Қачып йөрийе килен, бөркәнеп.

***Тәңкәле камзул.***

– Әниләребез тәңкәле камзуллар киделәр. Қалпақларында да тәңкә ийе.

Чулпы, айақлы тәңкә тағалар чәчкә.

Чылбыр йаға, түшлек кийәләр.

***Кийәү киеме.***

– Кийәү түбитийләре без тектек. Кийәү ыштаны әзерләп қуйған, киҗедән күлмәк салалар кийәүгә. Түбитий, чөлкәбаш, киҗеле ыштан, киҗеле күлмәк бирәләр кийәү кешегә.

***Қонҗырыйқ*** *– атның алгы аягы тиреләреннән тегелгән аяк киеме.*

– Почқақ беләң тау җылабыз ый *(шуа идек),* айаг очтан җылабыз ый. Ул җылы була. Ат суйдылармы, почқағын алабыз ый. Ул бер

җылда ғына тузмый әле. Қонҗырыйқ, диләр аны. Атның алғы айақларыннан йасыйлар. Урманга китәбез, җылы ул. Тау менгәндә таймый, тау түбәдән җылып төшәбез *(Күчтәнти).*

**Туйда катнашучылар**

***Оло қода, төп қода.***

– Қызнықы, җегетнеке атасы була оло қода, төп қода. Төп қода түргә утыра.

***Арғыш қода.***

– Арғыш – кийәүнеке әтисенең туғаннары була, арғыш қода була.

– Арғыш қода туйны аппаручы, кийәү җактан қуйалар. Өстәл чүрәли утырталар, қунақ итәләр.

«Арғышқа төшмәсен қарғыш», – тип җырлағаннар *(Танып).*

***Затқыч*** (озатучы), ***затқыч қода.***

– Заткыч булып киленнеке туғаннары килә. Чанадан, арбадан уң җакка төшерәләр.

– Затқычлар килделәр сандықлар белән. Күршеләре, туғаннары инде ул затқычлар. Шул затқычлар әйберләрнең барын да элеп қуйдылар. Паласларны җәйделәр, тәрәзләргә тастымаллар, мөгөшләргә тастымаллар элделәр, чаршаулар элделәр, чымылдыкқашағалар элделәр. Ызба матурлар өчен бөтен җиргә элделәр шул затқычлар *(Төнгүк).*

***Өндәүле, өндәүле қода.***

– Төп қодағый кемне җарата, шуны – өндәүле төп қоданы қарап йөретә, ризықлар сала қодаға.

Өндәүленең тақмағы да бар?

«Өндәүленең арты мендәрле», – ти *(Сараш).*

***Қыжҗиңгә*** – *қыз җиңгәсе.*

– Қыжҗиңгәнең эше: ул кийәүгә аш утырта, мунча йагып кертә, ул қунаққа җөрөми.

– Қыжҗиңгә мунча йаққан иртә торып. Қыжҗиңгәгә акча салып қуйғаннар: «Тийен – қуйан» тип.

– Қыжҗиңгә пар мендәрне күтәреп йөри, пар мендәрне үгә алып керә. Қызның арқасына ап-ақ чиккән мендәр тышларын сүкәп утырта.

– Суға барғанда қыжжиңгә белән барғаннар *(Түбәнавыл)*.

***Кийәү җегет, кийәүнәгәр*** – *кияү егете*.

– Кийәү җегет атларны бағып җөри. Ул қунаққа җөри кийәү белән. Кийәү җегет җырлап-бийеп кенә тора, җырға оста була.

– Кийәү дигән кешенең буйынында тастымал була, ул бийеп йөри, йырлап. Җырчы кеше йөри кийәүнәгәр булып.

*Сөлге тотқан кийәүнәгәр*
*Тыпыр да тыпыр бийи.*
*Аңарға бүген күңелле*
*Моңсулықны һич белми.*

*Кийәүнәгәрнең қулында*
*Сөлге җилфердәп китә.*
*Қарап торған йәш қызларның*
*Йөрәге җилкенеп китә (Сараш).*

***Иш-ыру.***

– Кийәүнеке, қызнықы иш-ыруйын чақыралар туйга *(Әрҗән)*.

## Туй атлары, туй көймәсе

***Ат***.

– Атларға линтечкеләр, тастымаллар тағалар. Атны арғыш утырса, арғыш баға инде, затқыч утырса, затқыч баға. Дуғаға кийәү тастымалы бәйлиләр, күберелеп торған тастымалларны атның дуғасына бәйлиләр, қаңғыраулар тағалар.

***Кучер.***

– Кучер үзенең атын сақламаға тийешле. Туйда атнықы ызбыруйларын жуғалтқаннар, тәртәләрен алдын артқа қуйғаннар.

***Кимә.***

– Туйда арбалар, кашаwай-чаналар кимәле була. Арбаның өстендә кимә йасалган була зур иттереп. Кимәдә қызны алып килгән туған-тумачасы, абзыйлары, тутайлары була *(Солтанай)*.

## Кияү килү, кияүләп йөрү

***Кийәү килү.***

– Кийәүне барыб алалар қаңғыраулы атлар белән. нағышлы мендәрләр тийәп. Кийәү килә қыз алырға. Кийәү төшкәч, ақча чәчеп җибәрә. Балалар тийен ақчаларны чүпләп алалар.

***Кийәү күренеше.***

– Әтисенә-әнисенә күренеш бүләге сала кийәү. Күлмәкме, читекме сала, бәхилли.

– Кийәү, иңгелек, күренми килә, бүләкләшкәч кенә күренә. «Күренеш белән килә», – диләр. Қәйнә булған кешегә дә, қайната булған кешегә дә бүләк бирә кийәү.

***Қыз қуйынына керү, кийәүне түшәккә сикертү.***

– Қыз шаршау эчендә утыра түшәк өстә. Зур итеп, бийек итеп өч қат, йә биш қат түшәк җәйелгән була. Йә җиде қат та була әле. Кийәүне түшәккә сикертәләр күтәреп кергән кийәү җегетләр, кийәүнең ике қулыннан тоталар да түшәккә сикертәләр.

«Биш қат түшәккә сикереп килгән кийәү мин», – дип сөйлиләр.

– Мин әнине қуwып туйға бардым ый. Кийәү белән қызға чымылдық короп, ничә қатлы түшәк салдылар.

Ничә қатлы түшәк, шул хәтле кич кийәү қуна.

*Чымылдықларың чып-чыбар,*
*Чебен генә қунмас, дисеңме.*
*Безнең кийәү бигрәк зирәк,*
*Сикереп үк кермәс, дисеңме (Сараш).*

***Билбау чишү.***

– Кийәүне қыз қаршы ала, чишендерә. Билбауны чорнап очын йуғалталар. Иңгелек шушы билбауны чишәргә тийешле. Тапмаға кәрәк бит әле.

– Җегеткә қып-қызыл бута бәйләп җыйалар. Қыз шуны сықтап-сықтап (елап-сыкрап) эзли очын. Аны тапмаса, уңған қыз булмый.

***Ак келәткә кертү.***

– Кийәү кеше белән килен кешене ақ келәткә чаршау эченә йатқырғаннар, өчәр кич йатқарғаннар, өч қат түшәк салғаннар. Келәттә, җә җаңғыз ызбада кийәүләп йата *(Солтанай).*

***Кызның намуслылығын тикшерү.***

– Җиңгә кеше карый қый кийәү белән қызны. Җиңгә кийәүдән үрин генә *(шыпырт, яшерен генә)* сорый: «Бүрегең үзеңнекеме?» – ти. Қыз намуслы булдисә, «үземнеке», ти, булмадисә «бүрек кешенеке», – ти.

***Кийәүләп йөрү.***

– Әтнә кич сайын килә ул кийәү кунаққа, қәйен-қәйнәсе кийәүне сыйлый.

– Кийәүләтеп җөрткәннәр кийәүне, бер кич җоқлаған сайын берсе түшәген алып баралар.

***Кийәү мунчасы.***

– Кийәүләшмәгә килгәч, кийәүгә мунча җаға қыжҗиңгә. Көн сайын җаға, кийәү ақча салып қуйа мунчаға тәрәзә төбенә. Мунча йағучыны хөрмәтләп.

– Мунчаға кертәләр иртән торуға. Мунчадан чығуға самуwарың қайнасын, қоймағың пешсен. Қодалар да керә кийәү мунчаға. Мунчадан барыб аласың қодаларны ат белән барып алған кебек, күwәнтәгә тастымаллар бәйләп барып алып киләсең *(Сараш)*.

## Килен төшү

– Килен әйбәт қаңғыраулы атлар олау белән төшә. Теге чуқта торған қыз, бу чуққа төште (суқ – *авыл яки урамның бер өлеше*).

– Килен кимәдән орғап төшә *(сикереп төшә),* ат чүрәли, кимә чүрәли әйләнәләр.

– Килгән ыңғайға ат башыннан әйләндереп, уңнан кермәгә қушалар:

*«Уң айағыңны атла,*
*артқа қарама», –*

тиләр *(Күчтәнти)*.

– Килен төшми утыра. Қайсы әйтә: «Қыз бирәм, сарық бирәм», – ти, кер килен», – ти, шуны бирәм тип кертәләр ишек ачқач. Шулай күтәрмә төптә *(баскыч төбендә)* кийәүне мендәргә төшерәбез ий. Мендәргә төшергәч кенә, кереп китәләр ий.

***Киленгә бал-май қаптыру.***

– Арбаданмы, чанаданмы төшкәч үк, қәйнә *(кайнана)* булган кеше күтәрмә төптә *(баскыч төбендә)* торып, бал қаптыра ишектән кермәс борын. Мендәргә басқан чағында қаптыра, чоқыр белән бал, қалағын қуйған.

*Атаң-инәң йоласы,*
*Пәйғабәрләр доғасы,*
*Май кебек йылғыр булың,*
*Бал кебек татлы булың,*
*Тату торың,*

*Таң мәхәббәт белән,*
*Тиң ғомер белән йәшәң,*
*Озын ғомерле булың,*
*Бездән дә рәхәт торың, – ти.*

Бал-май қаптыра да, апкереп китә үгә. Шулай теләкләр теләп кертәләр киленне.

*Тату тормаға булсын,*
*Озын ғомер,*
*Мул тормыш булсын, –*

тип, теләп кертәләр ызбаға кергәндә *(Сараш)*.

*Йаулық йабу, килен күренеше.*

– Өйгә кергәч тә йаулық йаба қайнана.

*«Килен, сиңә бүләк,*
*бәқытле, тәүфикле*
*киленем булың», –*

тип, җаулық җаба киленгә қәйнәсе.

– Килен килгәч, иртән иртүк торғач йаулық йабындыра қәйнәсе «Килен күренеше шул булсын», – тип *(Солтанай)*.

## Килен хезмәте, киленне сынау

– Тоқмач кисмәгә белсә, эшне белә, тигәннәр, тоқмач кистергәннәр.

– Қайсы кеше су китертә киленгә. Иптәш қыз булып бара бер қыз.

– Киленгә он иләргә бирмиләр.

«Ул тормышны пылтырауға илтә, тарата», – тиләр, Қамырны әwәли торған эш қушалар, тоқмач қамыры басамы анда.

*«Қамыр кебек йәбешеп торсон,*
*ашлы-сулы килен булсын».*

– Иртән торғач шәңгә *(бәрәңге пәрәмәче)* пешерәбез ий. Сөт салып күкәй сытабыз, қамырны җәйеп, картупны зур чөгөн белән мич алдында пешерәбез қый. Шул чөгөнне укуwат белән тартып алабыз да, шуны түwәбез аннары. Укуwат ул чөгөнне қыстырып ала торған. Шулай картук шәңгә, эрек шәңгәләр (эремчек пәрәмәче) пешердек килен булып килгәч *(Таныып)*.

## Туй мәҗлесләре, туй ашлары

*Қунақ өй сорау* – кыз өенә кияү килгәндә, аны озата килүче кияү егетләре капка төбенә җиткәч, *«кунак өй»* сорыйлар, *ягъни җыр яки билгеле бер калыпка салынган шигъри сүзләр әйтәләр:*

*...Қода белән кодагый,*
*Қунаг өй сорый без килдек…*

*Күтәрмәң (баскычын) бийек менәргә,*
*Ишекләрең нәқыс (тәбәнәк) керергә.*
*Җегетләр, қызлар, җул бирегез,*
*Қунаг өйне сорап чығарға.*

– Қода, без килдек сезләргә алтын басқычларыгызны басып, көмеш тупсағызны атлап. Йақты сарайларға индек, ай-қояш тик йөзләрегезне күрдек. Сездә зинәк *(ерәк)* баулы қошлар булса, без-дә қайыш баулы қошлар бар. Шуларның икесен бергә қаwыштырырбыз микән тип, өмит итеп без килдек. Үтенеч шулдыр кий: безнең киләчәк кийәwебезгә биш көн, биш төн қунақ итүwегезне теләп без килдек. Дәхи дә безнең киләчәк қода берлән қодағыйға қунағ өй шушында булырмы, йәйсә ғайре йердәме, шуны тәғайеннәп әйтәсез. Хушмы, қодағыйлар. Хуш, хуш. Қунағөй сорағач, тастымал эләләр, сөлге бәйлиләр инде, кийәү җегеткә *(Сараш)*.

***Уйын ызба*** *– кияү килгәнче, китәсе қызның өендә яшьләр-кызлар бергәләп җыелып уйныйлар, бийиләр.*

– Уйын ызбада бийи қызлар, туй дийеп бийиләр. Уйын ызба йасыйлар қыз ызбасында, кийәү килгәнче, йәшләр жыйылып уйныйлар, кийәүне көтәләр, чығып қаршы алалар. Кийәү төшә, чығып ақча сибә. Кийәүнең муйынында кийәү тастымалы элгән, чиккән матур тастымал. Қыз, кийәү килгәндә, уйын ызбада эчтә утыра. Кийәү тастымалын элеп, кийәү бийи. Кийәү тастымалын әни үзе әзерләп қуйған, күбәләкләп, нағыш *(бизәк)* итеп суғалар. Қаңғыраулы *(кыңгыраулы)* атлар килеп туктый уйын ызбаға. Үкәртәгә *(ишек алдына)* ақчалар, җимешләр сибеп қуйалар ыйы кийәү килгән уйын ызбаға. Кийәү тастымалын буйынына *(муенына)* салып, кийәү җегет тә, кийәү дә бийиләр.

– Уйын ызба киленнең туган-үскән җортында була. Шунда уйныйлар, гармуннар белән бийешәләр. Анда кеше күп була уйын ызбада. Җәшләр дә. олылар да була.

Wак күбәләкле тастымал була. Кийәү җегет бийи иң башта күбәләкле тастымалны муйынына салып. Аннан соң кем бийи, шуларның муйынына салып бийетеп җөри инде *(Солтанай)*.

***Туй көне.***

– Қоро көн *(шимбә)* йасыйлар хәзер туйны.

***Қодалашу, қодаға чығу, қода үткәрү*** *– туй үткәрү.*

– Қодаға чығу ул туйлашу инде.

– Қода үткәрделәр, сыйладылар. Қодаға чыққанда, туйлашқанда атқа бәйлиләр тастымалны.

– Қодалашу қыз йағында була, үзеңнеке туғаннар була. Қодалашып бер өч-дүрт көн йөриләр, қундырырға үзләренә қода алалар.

*Қода йөретү – коданы кунактан-кунакка йөртү.*

– Урам тулы халык җыйыла, қода сақлыйбыз тип. Қоданы аны қаңғыраулы ат белән йөретәләр. Бөтен аwыл чақырып йөретә қоданы. Хәзер дә иш-қушны чақырам *(Әрҗән)*.

## Туйның соңгы көннәрендә үтәлә торган шаян йолалар

***Төрткеч боткасы, эткеч ботка, ыступай ботка пешерү.***

– Қайтканда ботқа пешергәннәр. Төрткеч боткасы, диләр анысын, тары боткасы. Пешерүчегә йаулық бирәләр. Қайтучы қодаларға пешерәләр. Ботка пешергәч беләләр инде, қайтмаға кирәк инде, дип әйтәләр. Тәрилкәләргә сосалар ботқаны, шуннан ашыйлар.

– Ыступай ботқа пешергәннәр қодаларға, дары йарма, бодай йармадан.

– Эткеч ботқа пешкән, қайтмаға инде, диләр.

***Қодаларға қарата шаян йолалар.***

– Қодалар түрдән тороп китсә, урынына кеше утыртып қуйарға тийеш, ди. Әйтми тороп киттеләр исә, урыннарына таба белән эчемлек салып куйа, бал сала.

– Қодалар қайтқанда артларына тубал бәйләгәннәр. Тубал бәйләгәч, үзе чақырмаға тиеш.

«Қодағый, тубал бәйләдем, син чақырмаға тийеш», – ди.

– Қодаларның чаналарын, атларын қайтыр йаққа борып қуйған. Қайтасы килмәгән қода чананы кирегә борып қуйған *(Сараш)*.

## Туй ашлары

***Қода күчтәнәче.***

– Қодалар күчтәнәч белән киләләр. Төп қодағыйнықын, арғышнықын, өндәүленекен чығаралар. Аларның бәлешләре, қазлары, баллы баwырсақлары була.

***Қода күчтәнәче чығару.***

– Күчтәнәчләр қодаларнықы мынысы, тип әйтәләр, аwыз итең, тип әйтәләр. Йартысына хәдерле кисеп чығаралар. Күчтәнәчкә җыйалар, килгән қодаларны қунаққа йөртәләр.

***Гөлбәдийә – күп катлы бәлеш; гөбәдийә.***

– Қодалар күчтәнәч белән килә. «Парлы гөлбәдийә белән килгән, күчтәнәч белән килгән», – диләр.

– Гөлбәдийә – безнең зур сыйыбыз. Аны зур табаларда пешерәләр. Иң беренче қамырны ачытабыз. Ачытқанда йомырқа, май салып, күптерергә қуйабыз. Қамыр күпкәч, табаға җәйәң. Биш, җиде қатлы гөлбәдийәләр була. Аның қамырларын айырым-айырым пешереп, табаға салып барабыз. Бер қат эчлек салдың, пешкән қамыр салаң. Икенче қатына өмөже *(кура җиләге)*, йә қарағат *(карлыган)* салаң, тағын пешкән қамыр салаң. Ничә қатлы итәсең килә. Мичкә қуйасың да пешерәсең. Мин үзем газ пелитәсендә пешергәнем йуқ.

– Гөлбәдийәдән башқа туй булмый. Гөлбәдийә ул бик қадерле туй ашы. Аны күчтәнәч итеп тә биреп җибәрәләр. Қода белән қодағыйлар күрешкәндә иң беренче гөлбәдийә йөри алдан.

– Гөлбәдийәгә уртаға сала торған қамырларны мич ут алда пешереп аласың, пешкән қамырны уртаға қуйасың, аның өстенә тағын җимеш җәйәсең. Өч төрле җимешкә ике қат пешкән қамыр кирәк була. Қарағат, өмөже *(кура җиләге),* шартлама *(җир җиләге).* Бийек гөлбәдия була.

– Гөлбәдийәне қыз йаққа килгәндә җегет җағы пешереп апкилә. Ике гөлбәдийә: берсе өч қатлы, берсе ике қатлы.

– Җегет җаққа да ике гөлбәдийә пешереп баралар: берсе өч қатлы, берсе ике қатлы.

Менә мин өчне қызга бирдем, өчне гөлбәдийә озаттым. Қарақаршы була ул гөлбәдийә.

– Туйға пешерәләр икене гөлбәдийә. Берсен кечкенә, берсен зур итеп пешерәләр.

Бетеки гөлбәдийәне кийәүнең өйенә алып қайталар ийы *(Күчтәнти).*

***Гөлбәдийә пешерүче.***

– Гөлбәдийәне аны оста кеше пешерә қый. Гөлбәдийә пешерүче ул атаулы, саwыт-сабасы да, табасы да атаулы. Табада мичтә пешерәләр.

– Миңке әни пешерәйе гөлбәдийәне. Күптерәйе туқыған қамырны. Зур таба булайы гөлбәдийә пешерә торған.

– Гөлбәдийә пешерүче җимешне күп қоротты элек. Қороған җимештән җебетеп салдылар қый гөлбәдийәгә.

***Гөлбәдийә кисүче.***

– Гөлбәдийә кисүче оста булайы. Аңқы зур пычағы булайы. Бийек булы қый. Кеше сайын гөлбәдийәне кисеп сала таштабаққа үзенең зур пычағы белән.

– Гөлбәдийәне кискәнгә ақча салалар аңға. Бушлай түгел.

***Гөлбәдийәне күчтәнәч итеп бирү.***

– Туйға килгән кешеләргә гөлбәдийәне өлеш итеп кисеп бирәләр. Ашамаса, өйенә күчтәнәч итеп алып қайта. Без әниләрнең гөлбәдийә алып қайтқаннарын көтеп утырабыз ый. Ул безгә бик зур күчтәнәч булайы.

– Туй күчтәнәче була ул гөлбәдийә. Ул алдан китә, үзең барғанчы бара ул.

– Гөлбәдийәнең чиреген кире биреп җибәрәләр. Йартысын монда қалған әдәмнәргә ашамаға қалдыралар. Хәзер генә қадере бик йуғ аның

– Гөлбәдийәнең йартысын, йә икәү булса берсе кире биреп җибәрәләр. Теге йақлар: «Күчтәнәчкә, гөлбәдийәгә килегез, чәйгә», – дип чақыралар күршеләрен. Шуныңа ақча салалар күчтәнәчкә *(Күчтәнти).*

***Гөлбәдийә ничә қатлы – шул кич кодалар кунак булалар.***

– «Гөлбәдийә ничә қатлы!», – дип қарыйлар. Ике қатлы булса, қода белән кодаға ике кичтән қайтып китәргә була. Өч қатлы гөлбәдийә булса, өч кич қуналар булар.

– Туйға зур итеп гөлбәдийә йасыйлар, йә дүрт қат, йә өч қат. Гөлбәдийә парлы була. Элек мичтә қамырын пешерәм. Қамырына күкәй сытасың, май саласың йомошақ булсын өчен. Җимешләрен

пешкән қамырға җәйәсең. Йөзем, өмөҗе, қарағат була, қат-қат өстен чичкәләп қуйасың. Күрсәтәләр, менә өч қатлы гөлбәдийә, өч кич қунарға килгән, диләр. Биш қатлы булса. бишне қуна қода. Қарағат қағы, мәк тә салалар әле гөлбәдийәгә. Гөлбәдия ашағанда чәй дә бирәләр. Туйдан гөлбәдийә алып қайталар. Ағысы килен күчтәнәче була инде.

– Биш қатлы гөлбәдийә белән килдек, биш кич қундық (Күчтәнти).

***Чәкчәк.***

– «Туйның атасы белән анасы», – тип әйтәләр инде гөлбәдийә белән чәкчәкне.

– Чәкчәк йасыйлар балға қатырып. Аныңа ыспай нимәләр йәбештерәләр, чәкчәкне қырык күкәйдән пешерәбез туйға.

– Чәкчәк – кыз йақтан була. Бер күкәйгә бер қалак су қушып, шуныңа басасың да әwәләп пешерәсең.

– Мичкә йаққан сайын чәкчәк пешерәбез ий. Күкәй сытам, қамыр басам, кисәм wақ-wақ итеп. Өстенә май салам да пичкә тығам. Бодай ононнан шулай чәкчәк пешереп җыйабыз ый *(Танып).*

***Қоймақ.***

– Қодаларға иртән торуға қоймақ қойалар ый. Қодағый кеше қойа гәрәчүкә (< *рус.* гречиха) ондан, арпа ондан, солы ондан. Ү *(өй)* башлығы үзе қойа.

***Җәймә баwырсақ.***

– Күмәч итеп (күчтәнәч итеп) алып килә баwырсақ, җәймә баwырсақ алып килә. Чәкчәк қамырын кискеләп майда пешерә.

– Ару он белән пешерәләр ий, җиз иләктән бодай онын иләп.

***Бәлеш.***

– Бәлешләрне пуднусқа қуйып киләләр. «Менә монсо шул қодағыйның», – дип әйтеп чығаралар, wаклап. Кажни кеше берне алырға тийеш.

***Қаз турау.***

– Қазны қайнаға бүлгән. Қазның алғы өлеше – килен затларына булған. Қазның қанатларын – арғыш қодаға биргәннәр.

*«Арғыш қода булып килгән кеше*
*очып килгән, очып китсен», – дип.*

– Қазны белеп турарға кирәк, Иң элек уң җақтан қанатын кисәләр, уң җақ ботын кисәләр дә wақлап бирәләр. Бүләк җаба, шәлме, җаулықмы, Сөртүме *(сөлге)* җаба қаз турачыға *(Сараш)*.

***Эрек** – эремчек.*

***Кызыл эрек** – эремчекне кызарганчы кайнатып ясалган ашамлык, корт.*

– Қызыл эрек эретәбез ий. Аны пичкә қуйып алабыз ый, анарға қызыл чөгендер дә қушабыз ый әле. Қып-қызыл эрек була.

***Май белән эрек** – май белән эремчек.*

– Эрекне эретә дә шуны қазанда сүрән утта қайнаталар. Шикәр, сары май салып табаққа үwеп қуйалар. Өстенә қоры өмөҗе *(кура җиләге)* қуйалар. Қаты майны мәсерубкадан чығарып өстенә қуйа. Матур булып тора. Май белән эрек була.

***Эрек шәңгә** – эремчек пәрәмәче.*

– Ун күкәй сытабыз эрек шәңгәгә. Эрек күбенеп китә. Эрек шәңгәнең өстенә күкәйнең сарысын йағабыз өч бөртек. Қып-қызыл булып китә ул мичтә. Туйға әнийем шулай пешерәйе, оста қарчығ ый.

– Талқан шәңгә, кәртүк шәңгә, пикан шәңгәләр пешерәбез ий, талашып ашыйлар ый. Талқанны қатық белән туқылап йағабыз қамыр өстенә. Талқан шәңгә булып пешә.

– Кәртүк шәңгәне көн сайын, мич йаққан сайын да пешерәбез ий аны. Пикан шәңгәне җәй көне пикан өлгергәч пешерәбез ий. Пикан – *шома көпшә* (рус. дягиль).

## Савыт-сабалар

***Аш қалақ** – аш кашыгы.*

***Чәй қалақ** – чәй кашыгы.*

***Қашық** – чүмеч (аш бүлеп сала торган).*

***Ағач күбәтә** – агач җамаяк.*

– Қәрт әнинең *(әбинең)* қәрт әнийе *(әбисе)* базға қатық алмаға төшкән, ағач күбәтә белән. Күбәтәне башына кигән булған, сала алмаған. Йарып алғаннар күбәтәне *(Солтанай)*.

***Чапчақ** – кисмәк.*

***Икмәк чапчақ** – ипи камыры әзерләх өчен эшләнгән агач кисмәк, күәс чиләге.*

***Май чапчақ*** *– май яза торган савыт, гөбе.*

***Қоймақ чапчақ*** *– қоймақ камыры әзерли торган савыт.*

***Җалғаш*** *– агач тагарак. Җалғашта пилмин ите чабалар.*

***Күнәк, туз күнәк*** *– каен тузыннан ясалган савыт, туз чиләге, тырыч.*

***Таштабақ*** *– фарфордан эшләнгән табак.*

## Кунаклашу һәм туй җырлары

### Бал эчү җырлары

*Йуқа чөлкә кийә-кийә*
*Айаққа салқын итйә.*
*Йә, дусларым, җырлыйқ әле*
*Қодаларға бал тийә.*

*Безнең аwыл бақчасында*
*Сусыз кәбестә үсми.*
*Күптән бирле қарап торам,*
*Хуҗалары бал эчми.*

*Бийек икән таwығыз,*
*Қаршы йаwа қарығыз.*
*Без килдек тә қунақ булдық,*
*Инде үзегез барығыз.*

*Бик өзелеп чақырсағыз,*
*Иртәгә үк барырбыз (Сараш).*

### Туғаннар җыйылғанда җырлау

*И туғаннар, туғаннар,*
*Ай туғанда туганнар.*
*Ай туғаннарда туганнар,*
*Шуңа матур булғаннар.*

*И, туғаннар, сезнең belән*
*Шат минем күңелләрем.*
*Ыңғай шулай шатлық белән*
*Узса йы ғомерләрем.*

*Алый да бергә-бергә,*
*Болый да бергә-бергә.*

*Бергә чақлар ай бер генә,*
*Қадерен белмибез генә.*

*Алмалар өзәр идем,*
*Бауларга тезәр идем.*
*Йанмаса бу йөрәккәйем,*
*Сагынуға түзәр идем (Сараш).*

**Кич утырганда җырлау**

*Бийек тауға менгән чақта,*
*Өзелә қамыт баулары.*
*Өзелми қамыт баулары,*
*Өзелә йөрәк майлары.*

*Ағыйделдән ағып килә*
*«Ағыйдел» дигән караб.*
*Мине искә алырсыз бер*
*Шушы урынға қарап.*

*Ағыйделдән ағып килә*
*«Фагыйлә» дигән сабын.*
*Берәү булса, үләр иде,*
*Әле дә мин үзем сабыр.*

*Атларым, йөгәннәрем,*
*Атланып йөргәннәрем.*
*Йаныйым дигән сүзләреңә*
*Алданып йөргәннәрем (Солтанай).*

**«Чабата киертү»**

Бу скетч 1920 нче елларда Төнгүк авылында булган хәлгә нигезләнеп язылды (2012 ел). Авторы Максиев Фаиз Хәлит улы.

*Гади генә авыл йорты. Хатыны Җәмкарь бау, аркан ишә. Қызы көзгегә қарап матурлана, чигенә. Ире Хәйретдин кереп килә.*

**Җәмкарь.** Қайа чығып йуғалдың син?
**Хайретдин.** Атларға гәҗит биреп қуйдым әле.
**Кыз.** Әти, атлар гәҗитне ничек уқыйлар алар, үзең шикеллеме? *(көлә).*
**Хайретдин**. Ну, қызым, смотря нинди гәҗит бирәсең инде, мин татарчасын биреп қуйдым: татарча өйрәнеп, татар ризықларына

ийәләшсеннәр, дидем. Қарале, Җәмкарь, карта бәлешең пештеме әле, қорсақ ачты, ашаштырып алырға иде.

**Җәмкарь.** Йуқ, пешмәде әле.

**Хәйретдин.** Бәлеш қайчан пешә, нәрсә әйләндергәләп утырасың анда?

**Җәмкарь**. Арқан ишәм, сине тошаулап қуйарға дип, чығасың да китеп йуғаласың. Өйгә қайтсаң, телеңә салынып утырасың. Бар әнә, берәрне тотып эшли торган эш қара бәлеш пешкәнче.

**Хәйретдин**. Хәзер табабыз аны, тотоп эшли торган эшне. Әһә!!, табылды, хәзер... *(Гармун алып такмак җырлый).*

*Атлар килә чарасыз,*
*Арттағысы чанасыз.*
*Кеше хәлен кеше белми,*
*Қорсақ ачты чамасыз.*

*Қулымдағы балдағымның*
*Исемнәре Фәрхетдин.*
*Иреннән қалған хатыннар*
*Бары да безнең бәхеттән.*

**Җәмкарь.** Әй қарт алаша, нәрсә җырлап утырған була, буйға җиткән қызыбыз үсте бит, кийәwең дә үзеңә охшаса, бик тә уңарсың, балда-майда ғына йөзәрсең инде.

**Кыз.** Начар булмас, начар булмас кийәwегез этигә охшаса, ачтан үлмәбез, азық күктән йаwар ичмаса.

*(Урамда тавышлар ишетелә. Җәмкарь тәрәзәгә карый, кычкырып җибәрә).*

**Җәмкарь.** Үлдек, Сәет, қалды қолақ, безгә киләләр.

*(Хәйретдин дә тәрәзәгә карап ала, намазлыкларын, киемнәрен алып, кечкенә бүлмәгә керә, дога укырга керешә. Иң элек тыны бетеп староста Гаптелхак килеп керә).*

**Җәмкарь**. Гаптелхак, нәрсә булды, налог салалармы әллә?

**Кыз.** Староста абзый, әллә миңа йаwчылар алып килдеңме, қайсы йаққнықылар алар?

**Гаптелхак.** Нинди йаwчылар ди, обыскы йасарга килгәннәр, аwылдағы дисциплинаны тикшерәләр буғай. Қарале, Җәмкарь, на всякий случай ачы-мочыңны әзерләп қуй әле. Туп-туры сезнең йортқа алып килергә тырыштым. Синең майлап-җайлап җибәрергә рәтең була бит.

*(Кинәт оперуполномоченный килеп керә, сугышчан киемдә, сумка-папка таккан)*

**Опер.уполн.** Староста! Кто в этой избе живёт!?

*(Җәмкарь скамейкага утыра, кызы аңа сыена).*

**Гаптелхак.** Хайретдин, Җамкар, дочь живут.

**Опер.уполн.** Здесь я вижу одних женщин. А где хозяин?

**Гаптелхак.** Туварищ начальнек, он молитва читает, тривожить нильзя, Алла сугар.

**Опер.уполн.** Тогда, женщина, иди сюда!

**Җәмкарь.** Әстәгафирулла, нигә чаķыра икән?

**Опре.уполн.** Как звать? Староста, переводи!

**Гаптелхак.** Исемең ничек, ди.

**Җәмкарь.** Җәмкәр инде, Җәмкәр.

**Гаптелхак.** Имя – Жамкар, Жамкар *(оперуполномоченный кәгазьләрен ала, старостаның аркасында яза башлый).*

**Опер.уполн.** Вчера в деревне ты не видела подозрительных людей?

**Гаптелхак.** Кичә аwылда чит-йат кешеләр күрмәдеңме? ди.

**Җәмкарь.** Йуķ, күрмәдем, нәрсә булган тағын?

**Гаптелхак.** Нет, не увидела говорит.

**Опер.уполн.** Не могу писать стоя. У вас есть диван?

**Җәмкарь.** Дивана ди мәллә мине?

**Гаптелхак.** Утырырға урын кирәк, ди.

**Опер.уполн.** Кума, давай рассказивай, сколько голов у вас скота?

**Җәмкарь**. Кумушка эчәргә сорый мәллә? Бар, ķызым, баздан тиз генә көмешкәне төшеп ал.

**Гаптелхак.** Ничә баш малларығыз бар, ди.

**Җәмкарь.** Күп түгел инде, сарыķлар ғына бар, чебечләр бар. Күкәйгә – җөнгә ķарыйбыз.

**Опер.уполн.** Староста, что она говорит.

**Гаптелхак.** Овца, кура только. На яица и шерсть.

**Опер.уполн.** Хватить болтать. А лошадь, лошадь есть?

**Гаптелхак.** Атығыз бармы, ди.

**Җәмкарь.** Ат ķарамыйбыз без, атыбыз йуķ. *(Кыз кумушка кертә, әнисенә бирә, Җәмкарь старостага бирә, староста яшерен генә оперуполномга бир, Хәйретдин кычкырып укый башлый).*

**Хәйретдин**. Әгүзү билләһи миннәшшайтаниражим. Бисмилләһир рахманир рахим *(сузып укый)*.

Хатын, хәзер үк қыз белән абзарға чық, атның йақларына чабата кийертегез, чабаталы атны таwыш-тынсыз бақча йағыннан алып чығып китегез. Өйгә килүчеләр күрмәсеннәр. Ашығыгыз! Тиз булығыз!

**Опер.уполн.** Скоро он закончит свою молитву? Иди узнай!

**Гаптелхак.** Нәрсә сөйләнәсең син, Хәйретдин, нинди ат алдығыз, сезнең атығыз йуқ бит.

**Хәйретдин.** Сөбхәәнәкә әллааһәмнә wә бихәмдикә wә тәбәрақас мүкә wә тәгалә җәддүка wә ләә тләәһә гайрүк.

Ғаптулхақ, булмале син ахмақ.
Атның ботлары булыр уртақ.

*(Гаптелхак аңлап ала, йөгерә).*

**Гаптелхак.** Туварищ уполномоченный, он скоро намаз закончит.

**Хәйретдин.** Аллаһеакбәр, аллаһеакбәр, аллаһеакбәр.

**Опер.уполн.** Вчера ты в деревне конокрадов не видел, может слышал?

**Хәйретдин.** Товарищ уполномоченный, я вчера дома сидел, никуда не ходил, намаз читал, богу молился.

**Опер.уполн.** Тогда я забираю с собой...

**Гаптелхак** *(куркып кына)*. Кого?

**Опер.уполн.** Ни кого, а чего. Староста, провожать не нужно *(«Кумушканы» алып чыгып китә)*.

**Гаптелхак.** Қотым очты бит, Хәйретдин. Син нәрсә элегрәк атны уртақлашу турында қолақ йарып қуймадың. Опер уполномоченныйга чабата кийертең бит ә. Мин дә ахмақ, чыннап торып намаз уқыйсың имеш дип торам.

**Хәйретдин.** Гаптелхақ, тормале аптырап,
Җаwабын бирербез бергәләп.

**Бергә әйтәләр.** Чабата кийерту булған тақ,
Ат урлаулар булған – хақ!

## МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

**Әрәмә авылы:**
Акбашева Мөхтәрәмә Хәким кызы
Акбашева Разиха Хәким кызы
Аптрахманова Нуридә Гариф кызы

**Әрҗән:**
Балтабаева Роза Нурмәт кызы
Балтаева Ләбибә Гәйни кызы
Иманаева Хәбибә Сәлахетдин кызы
Кучумова Һаҗирә Бәдертдин кызы
Салихова Нурисә

**Байавыл**:
Конякова Гөлфәридә Миннехан кызы
Раимова Хәдичә
Сариянова Разифә Гафур кызы

**Барда:**
Кучукбаева Зильфира Зөфәр кызы
Мушакова (Батыршина) Якутелзинан Әхмәтҗан кызы
Шакирҗанова Равия Гадел кызы
Яхина Зөлфия Закирҗан кызы

**Каенавыл:**
Сакаева Әнүзә

**Күчтәнти:**
Гозәирова Фәния
Закирова Мөнирә
Рангулова Фагыйлә
Сакаева Наилә Суфи кызы
Тякина Гәнҗийан Әләм кызы
Ягъфарова Әминә Мөхәммәтхуҗа кызы

**Сараш:**
Гәрәева Мәрзия
Мәсәгутова Гөлнур Гәптрәхим кызы
Мәсәгутова Мөнирә Сәетҗан кызы
Тимганова Кадрия
Туйгилдина (Мостаева) Сария Сафи кызы
Хәлилова Сания Заһид кызы
Хәлилова Сафыйка Юныс кызы
Хәлимова (Мортазина) Хәнүзә Вәли кызы

Шәрәфетдинова Тәнзилә Фазыл кызы
Шәрипова Зәбирә

**Солтанай:**
Атнабаев Минҗан
Гаптукаев Гаптулла
Дускаева Тәскирә Гәрәй кызы
Йосыпов Әүхәт
Кариев Шәрипҗан
Кариева Миңсылу
Мәсәгутова Гөлҗиһан Газихан кызы
Ягъфәрова Нәгыймә Нәҗметдин кызы

**Танып:**
Азмагулова Шәкифә
Батыркаева Гөлсем
Тапаева Мәҗмүнә
Хәлимова Сәрия
Чугалаева Хәсия
Юлышева Рәхилә
Якупова Фәүзийән Таһир кызы
Якупова Гәүһәрия Мәлик кызы

**Төнгүк:**
Адутова Рәшидә Сәлахетдин кызы
Максиева Вафирә
Максиева Гөлзәмийә
Нурсыбина Нәҗмехәнә

**Түбәнавыл:**
Аслашова Назимә Бари кызы
Кучукбаева Әлфинә
Маматова Тәрҗемә Гафи кызы
Сәетова Вәлимә Хәмит кызы

**Үдик (Елпачиха):**
Ибраһимова Радифә
Сәйдәшева Галия Зарифхан кызы

# БАРДАЛАРГА БАРДЫК ӘЛЕ...

*Рәмил Исламов*

Пермь краеның Барда районына комплекслы экспедиция Институт һәм төбәк җитәкчеләренең әлеге мөһим мәсьәләне алдан сөйләшеп-аңлашып килешүе нәтиҗәсендә үткәрелде.

Безгә кадәр анда 1963 елның җәендә Казан дәүләт университетыннан доцент (соңыннан филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы) Нил Юзиев (1931–1996) җитәкчелегендәге экспедиция эшләгән. Алар, мәсәлән, Үтәйбаш авылыннан инде җырга әверелгән «Бүз атым» шигырен, Вафаиның «Рәүнәкъел-Ислам» («Ислам чырагы») әсәренең 1780 елда күчерелгән бер нөсхәсен, Каенавылда (Березнякида) Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») поэмасының 1600 елда күчерелгән бер кульъязмасын табып кайталар.

Танылган археограф, тарихчы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Миркасыйм Госманов (1934–2010) җитәкчелегендәге экспедиция бу якларда 1974 елда була. Түбәнавылда (Ишимовода) гармунчы Әхнәф абзый аларны әле дә хәтерли булып чыкты. Экспедиция әгъзасы Рөстәм Мәһдиев (ул хәзерге вакытта Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте каршында оештырылган «Хузур» нәшриятында эшли) шул ук Каенавылда Мөхәммәдъярның «Нуры содур» («Күңелләр нуры») дигән икенче поэмасының күчермәсенә дә юлыга.

Безне Барда районы татарлары һәм башкортлары мәдәният үзәге җәмәгать оешмасы рәисе Сәлим әфәнде Назин каршы алды. Ул унике еллап район хастаханәсенең баш табибы, аннан соң хакимият

башлыгының социаль мәсьәләр буенча урынбасары булып эшләгән. Халкыбызның рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен саклауга һәм үстерүгә, милләтара дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытуга зур өлеш керткәне өчен аңа Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты бирелгән.

Эшебезнең беренче көнендә безне Барда муниципаль хакимияте башлыгы Сергей Миңнехан улы Ибраев кабул итте. Ул кыскача гына районның хәзерге вакыттагы эшчәнлеге белән таныштырды һәм экспедициянең максат-бурычлары белән кызыксынды. Очрашу эшлекле һәм нәтиҗәле үтте.

Аннан соң район музеенда (ул 1974 елның 15 августында ачылган) булып, андагы экспонатлар белән таныштык. Аның директоры Альберт Мәхмүтов һәм фәнни хезмәткәре Ләйлә Әмирова безне кызыксындырган һәрбер сорауга тәфсилле аңлатмалар бирделәр.

Барда белән якыннан танышуны андагы мәчетләрдә дәвам иттердек. Аның агач биналысы әүвәлдә Иске Чат авылында 1903 елда төзелгән булган. 1990 елда бирегә күчереп корганнар. Имамы – Нәзир хаҗи Кучуков, ярдәмчесе Илдар Иманаев икән. Җәйге каникул вакытларында мөселман балалар лагере дә эшли.

Кирпечтән корылган яңа мәчеткә нигез ташын 1999 елның 8 октябрендә салганнар һәм 2009 елның 30 декабрендә манара куйганнар. Аның имамы Марат хәзрәт Мозаффаров, бер үк вакытта, төбәкнең мөхтәсибе дә икән. 2005 елдан башлап аена ике тапкыр мөхтәсибәтнең басма органы булган «Нурлы Барда» газетасы нәшер ителә. Гомумән, районда булган утыз өч мәчет Пермь Диния нәзарәтенә карый икән.

Әлеге мәчеттә без янә бер могтәбәр шәхес – бу изге йортны төзеттерүдә башлап йөргән, Диния нәзарәте һәм мөхтәсибәт әгъзасы – Рафикъ хаҗи Акманаев белән очрашып таныштык. Аны бирелә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның (1886–1913) бабасы Зиннәтулла хәзрәткә (1830–?) алтынчы буын туганы дип беләләр. Каҗмакты һәм Барда елгаларының Толга кушылган урынындагы Каҗмакты авылы (хәзер Барданың бер өлеше) урнашкан. Аның мулласы Әмирхан Әмиров (1769–1817) белән җәмәгате Бәзиха абыстайның (1776–1834) икенче уллары Зәйнелбәшәр (1803–1853) була. Зәйнелбәшәр белән аның хәләл җефете Габидә (1804–?) гаиләсендә Зиннәтулла туган. Ул әүвәл Солтанай авылы мәдрәсәсендә тәгълим-белем ала. Аннан соң Уфа губернасына ка-

раган Аргаяш кантонындагы Гашир авылында балалар укыта. Кышкар мәдрәсәсендә белемен камилләштергәч, Өчиле авылына мулла итеп тәгаенләнә.

Рафикъ ага Акманаев Тукайның Барда тамырлары турында «Туган илем Кожмакты карьяседер...» (2011) дигән китап та язып бастырган. Шагыйребезгә район үзәгендә шушы елның 28 июнендә ачылган бюстны куюда да аның тарафыннан төзелгән шәҗәрә шулай ук дәлилле нигезләмәләрнең берсе булган.

Өйләдән соң хакимият бинасында башлыкның социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, рус милләтеннән булуына карамастан, татар телендә бик яхшы сөйләшүче Татьяна ханым Балтаева катнашлыгында район ветераннары белән очрашу булды. Аны С. Назин ачты һәм алып барды. Андагы сөйләшүләрдә экспедиция җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, халык авыз иҗаты бүлеге мөдире Ильмир Ямалтдинов безнең алда башкарыласы эш планнары белән таныштырды; филология фәннәре докторлары Дария Рамазанова, Флера Баязитова телне фәнни нигездә өйрәнү зарурияте турында сөйләделәр, Марсел Әхмәтҗанов этногенез мәсьәләләренә берникадәр ачыклык кертте.

Икенче көнне Сараш авылында эшләдек. Элек анда атна саен үткәрелә торган базар булган, 1912 елгы янгын казасына кадәр өч мәчет эшләнгән. Билгеле булганча, шул авылда 1908–1915 елларда бертуган Шәриф һәм Сәгыйть (1889–1937) Сүнчәләйләр рус-татар земство мәктәбендә укытканнар. Булачак драматург, прозаик һәм публицист Риза Ишморат (1903–1995) белән аның агасы Зыя 1911 елның сентябреннән 1915 елның май урталарына кадәр Сараштта укыганнар. Мәктәп Гариф исемле хәлле кешенең ике катлы өендә, югары катындагы зур ике бүлмәдә урнашкан була. Ул бина хәзерге вакытта сакланмаган.

Агалы-энеле Сүнчәләйләр әниләре Һаҗәр апа белән Галәветдин исемле байның зур өендә икенче катта фатирда торганнар. Шунда ук Риза һәм Зыя Ишморатларны да сыендырганнар. Әйтергә кирәк, Сәгыйтьнең күп кенә әсәрләре нәкъ менә Сараштта яшәгән һәм эшләгән вакытында иҗат ителгәннәр. Җәй вакытларында ул Казанга килеп, Тукай белән очрашкан, соңыннан хатлар язышканнар. Бөек шагыйрьнең вафаты турындагы хәбәрне дә шунда алган...

Р. Ишморат, истәлегеннән мәгълүм булганча, 1967 елда Сараштта булганда янә шул өйдә (дөрес, аның икенче каты инде сүтелгән

була) Галәветдин абзыйның улы Габдерәхим белән очрашалар. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, безне авылда озатып йөргән Рәмилә апа Мостаевада әнә шул Габдерәхим Галәветдин улының гаиләсе белән әнә шул өй каршында төшкән оригинал фотосын да күрергә насыйп булды.

Ул өй хәзерге вакытта да бар икән. Анда Уса шәһәреннән күченеп кайткан, янгын сүндерүче Таһир һәм почтальон булып эшләүче хатыны Резедә Курмакашовлар гаиләсе яши. Аларның үзләрен күреп сөйләшү насыйп булмады, хуҗалар囲 эштә булып чыктылар. Шунысы кызганыч, бу авылга Казаннан күп кенә татар язучылары килгәләгән булсалар да, бертуган Сүнчәләйләр, Р. Ишморат истәлекләренә әнә шул өйнең диварына хатирә элмә тактасы куйдыру хәстәре турында уйланмаганнар булса кирәк. Ә йорт инде хосусыйлаштырылган...

Сараштa Советлар Союзы Каһарманы Шәрифҗан Казанбаев (1916–1944) туып-үскән. Ул, 1944 елның 1 апрелендә Молдавиядәге Чеколтень авылы янында камалышка эләккәч, 14 нче гвардия полкының байрагын коткарып кала. Авылда аңа бюст куелган һәм гомуми белем бирү мәктәбе аның исемен йөртә.

Зур гына калкулыкта элекке мәчет (соңыннан ул бина 1922, 1943 елларда ачылган балалар йортына бирелә) урынына 1994 елда бөтен авыл белән матур итеп яңа мәчет төзеп куйганнар. Дөрес, үзенең хосусый эшләре белән йөрүе сәбәпле, имам Рәсил хәзрәт Сабитовны очрата алмадык. Шулай да ветераннар советы рәисе Гөлнур Мәсәгутова ярдәмендә, кәрәзле телефон аша аның рөхсәтен алып, изге йортта саклана торган берничә кулъязмага ия булдык. Алар арасында татар һәм гарәп телләрендә дини өйрәтмәләр язылганы да бар. Аның бер битендә шундый сүзләрне укыйбыз: «Ошбу китабны язгучы Насыйбулла бине Гаядулла Җилиев әс-Сараши».

Ветеран укытучы, халык мәгарифе отличнигы Һәнүзә апа Хәлилова (ул 1953–1958 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укыган) тематикалары төрле булган шигырьләр язылган кулъязмалар бирде. Шунысы кызыклы, 1954 елның 23 августы белән билгеләнгән икенче дәфтәргә кемдер аларны янә гарәп хәрефләре белән күчереп язган. Аларның шәкертләрне тәгълим-белем алырга өндәп язылганнарыннан бер мисал:

*Бу нурлы мәктәп,*
*Укыйк күмәкләп.*
*Булаек без шәп,*
*Укыйк, шәкертләр.*

Монысында исә милләт язмышы турында уйланулар теркәлгән:


*Милләтем, син бик кызганыч,*
*Фикер итсәм, янадыр эч.*
*Кулыңда һич калмады көч,*
*Нидән бу хәлләргә төштең тәкрар.*

Һәнүзә апа бик кечкенә форматлы басма Коръән дә бүләк итте.

Үдик (Елпачиха) авылы мәдәният йорты директоры Салават Садретдинов (әтисе Башкортстанның Илеш районыннан булган) үзенең җиңел машинасында безне турыдан-туры Әрәмәавылга (Конюковога) алып китте. Анда без сиксән дүрт яшьлек Нуридә әби Абдраковада 1926 елда язылган тәсбихкә һәм җиде газиз (гази) исемлегенә юлыктык. Фасиха апа Габдушева йөз яшьтән узып вафат булган әнисе Шәрифә Акбашевадан (1910–2012) калган Коръәнне чыдамлы ситсадан тегелгән букчасы белән тапшырды.

Халык арасында киң таралган риваятькә күрә, җиде газиз (гази) электә биек тау башларында яшәгәннәр һәм дошманнар килү куркынычын учак ягып (көндез төтен, төнлә ут яктысы ярдәмендә) белдерә торган булганнар. Алар: Солтанай авылында Солтан гази, Әрҗән авылында Хәсән шәех, Оек тавында Солтангали, Толбашында Солтан Әхмәт, Буза тавында Солтан Сәет Сәлим, Җирмиябашында Морат хаҗи, Урал тавында Миян Мәгъсүм.

Әрәмәавылда күргән исемлектә шулай язылган: «Ошбу әүлияләрнең рухларына Коръән укып багышлап үтенәмезләр». Без аралашкан кешеләр



*Җиде әүлия исемлеге*

сөйләгәнчә, әйтелгән шәхесләр әүлияләргә тиңләштерелгәннәр һәм дини мәҗлесләрдә алар исеменә дә аерым дога кылалар, ди.

Искир авылында, 1998 елдан башлап, Габделхан абзый Мокъсинов имамлык итә икән. Ул безгә тапшырган материаллар арасында типография ысулы белән нәшер ителгән Коръән нөсхәләре, тәфсир һәм төрле кулъязма китаплар бар.

Түбәнавылда мәчет 2000 елда ачылган, имам вазифасын Мәүлиҗан абзый Зимасов башкара. Ул анда тупланган ташбасма «Шәрхел-викая», «Китабел-Кодури», «Татар тарихы», Коръән һәм дини эчтәлекле биш кулъязма китап бирде.

Байавылда (Куземьяровода) унбиш еллап Габдуллаҗан ага Аптукаев (1935–2012) имам булып торган. Кызганыч ки, без барганда аның вафатына нәкъ бер ел тулган иде. Хәзрәтнең хәләле Язилә абыстай Сәет кызы безне ачык йөз белән каршы алды. Экспедициядә сәнгать юнәлеше буенча эшләүче Эльмира Галимова магнитофон тасмасына аңардан байтак кына мөнәҗәтләр дә яздырып алды.

Габдуллаҗан имам авыл, мәчет турында байтак тарихи мәгълүмат туплап, аларны аерым бер дәфтәр итеп төзегән булган. Аны күчереп язарга вакыт җитмәү сәбәпле, хуҗабикәнең рөхсәте белән, яшь галим – филология фәннәре кандидаты Радик Хөснетдинов аларны фотоаппарат белән сурәткә алдырды.

Язилә абыстай ярдәме белән бу авыл мәчетеннән басма «Гайнел-гыйлем», «Рисаләи Газизә», «Тәһлилел-усул», «Кыйссасел-әнбия», «Әл-әхәдия әш-шәриф», Коръән, тәфсир кебек китаплар һәм төрле язмалар теркәлгән ике кулъязма дәфтәр алдык.

Район үзәге Барданың үзендә яшәүче Равия апа Шакирҗанова безгә басма «Мәҗмугел-әхбар», «Кыйссасел-әнбия», «Мохтасар тарих мөкаддәс», «Рисаләи Газизә», шигырьләр җыентыгы, Коръән нөсхәләре, Г. Тукайның 1914 елда нәшер ителгән шигырьләр җыентыгының бер өлешен тапшырды.

Икенче Әрҗән (Икенче Краснояр) авылында эшебез шактый нәтиҗәле булып чыкты. Авылда элекке мәчет урынына 1994 елда яңасын төзеп куйганнар. Хәзерге вакытта анда имам булып Илсур хәзрәт Рангулов эшли. Ул дини гыйлемне 1998–2000 елларда Башкортстан Республикасының Агыйдел шәһәрендә үзләштереп кайткан. Илсур хәзрәт безгә басма «Фазаилеш-шөһүр», «Бакырган китабы»ның бер нөсхәсен, «Шәрхел-фәраиз әс-сиражия», «Китабел-Кодури», «Мөхәммәдия», «Китабер-Рикак», «Мохтасарел-

викая» һәм башка китаплар тапшырды. Соңгысының барлык битләрендә дә диярлек кемдер аңлатма-шәрехләр язган. Гомумән, бу электә киң таралган күренеш.

Бу авылда без янә бер кызыклы шәхеснең гаиләсе белән очраштык. Алар – хажи Сөләйман хәзрәт Кучумов һәм аның җәмәгате Гөлзадә абыстай (тумышы белән Татарстан Республикасының Балтач районы, Арбор авылыннан). Хуҗа кеше бик дини белемле икән, шактый сирәк очрый торган китаплар туплаган. Безгә тапшырганнары арасында, мәсәлән, «Төхфәтел-мөлек тәрҗемәсе», «Китабелмугсамәләт», «Тәгълимел-салават», «Тәварих», «Тарихел-әнбия», «Китабе кыйссаи хәзрәт Йосыфән-нәби галәйһиссәлам», «Әхкәмү шәргыя», «Хауса әсама Аллаһ» һәм башкалар, төрле эчтәлекле унтугыз кулъязма дәфтәрләр бар.

Төнгүк авылы турында сүз башлау белән хәтергә, барыннан да элек, шунда туып-үскән, Әлмәт татар драма театры аристкасы, ТАССРның халык артисткасы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Дамира Кузаева (1948–1993) исеме килә.

Авылда 2009 елдан башлап үзе дә мулла нәселеннән булган Гадил абзый Усаев имамлык итә икән. Кызганыч, без аны өендә очрата алмадык. Авыл көтүенең чираты аларда булган көнгә туры килдек. Шулай да җәмәгате Гөләзимә абыстай Гарифҗан кызы, кәрәзле телефон аша аның рөхсәтен алып, безгә басма «Рисаләи Газизә» һәм дүрт кулъязма китап бирде.

Күчтәнти авылын без, барыннан да элек, фольклорчы-галим, танылган җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәров (1946–2008), җырчы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Сәнифә Рангулова исемнәре белән ишетеп белгән булсак, инде үз күзләребез белән күрергә, анда яшәүче халык белән аралашырга насыйп булды. Рәшит абыйның әнисе – туксан алты яшьлек Әминә әби белән очрашып-күрешү, хосусан, минем үзем өчен зур вакыйгаларның берсе булды.

Авылның мәчетен төзүдә башлап йөрүчеләрнең берсе булу сәбәпле, бу изге йортка Рангулов Шәмсемөнир хаҗи исеме бирелгән. Имам вазыйфасын үзбәк милләтеннән булган Ташбулат Низаметдинов башкара икән. Шушы авылда туып үскән җәмәгате белән Ташкент шәһәрендә утыз ел яшәгәннән соң, аларның бергә күченеп кайтуларына да ун елдан артып киткән. Татарча бик яхшы сөйләшә, үзбәкчәдән гайре таҗик телен дә белә. Минем фарсыча

«Агаи Ташбулат, мәрдум-е Кучтанти хуб аст?» («Ташбулат әфәнде, Күчтәнти халкы яхшымы?») дигән соравыма самими елмаю белән «Хейли хуб аст!» («Бик яхшы!») дип җаваплады.

Бу авыл мәчетеннән тулы булмаган ташбасма «Шәрхе Ниязи», «Әхтәри кәбир», «Сәләтыйн исламнан беренче җөзә», тулы басма Коръән, «Тәгълимел-әдәб әла әл-вәләд» дигән китаплар алдык.

Танылган татар шагыйре Гали Чокрый (1826–1889) белем алган Хәйреззаман бине Габди (?–1879) һәм аның мәдрәсәсе белән киң билгеле булган Танып авылын күптәннән бирле күрәсем килә иде. Унбиш-уналты яшьлек Гали анда «Тәһзибе мантыйкый» («Логика укыту») исемле калын китапны күчереп язган, хәлфәсенең вафатына мәрсия иҗат иткән. Элекке гыйлем йорты һәм аның башка каралты-куралары урынында хәзер кибетләр, хосусый өйләр икән. Ни аяныч, 2008 елның июль аенда ут казасы чыгып, тугызъеллык мәктәп тә янган.

Кайчандыр китапханә, фатир ихтыяҗлары өчен файдаланылган өйне мәчет итеп корганнар. Моны вакытлыча дип уйларга кирәк, чөнки изге йортның яңа бинасын да төзи башлаганнар. 2004 елдан башлап авылда имам вазыйфасын Миңлесәгыйть абзый Нурмөхәммәтов башкара. Ул үз вакытында Башкортстан Республикасындагы Яңавыл районы газетасы редакциясендә, соңра Барда мөхтәсибәтенең басма органы «Нурлы Барда»ны чыгаруда эшләгән икән. Мәчеттән берничә борынгы китап алдык.

Солтанай – үзенең данлыклы дин эшлеклесе Әрмәншаһ бине Әхмәд (1798–1874), аның улы – мәгърифәтче, сәүдәгәр, иганәче Мөхәммәтгата Мансуров (1834–1924), Бохарадан тәсаувыфка иҗазәт алып кайткан Нәүширван бине Мөхәммәдрәхим (1809–1891) исемнәре белән билгеле авыл. Бу могтәбәр затларның өченчесе Пермьгә сөргенгә җибәрелгән күренекле шәех Мәхмүд Дагыстанига (1814–1877), Россия империясендә иркенләп йөрү өчен, хакимияттән хокук алуда зур тырышлык куйган.

Нәүширван хәзрәт шулай ук мәдрәсә тоткан. Археограф Марсел Әхмәтҗанов әле күптән түгел генә нәшер иткән «Татар археографиясе. Соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары (1972–2012 еллар). Өченче кисәк» дигән хезмәттә бу уңайдан кызыклы мәгълүматка юлыктым. Хосусан, анда сүз бу мәдрәсәдә Могътәсим бине Могавия, Җәгъфәр бине Могаттар исемле кешеләр тарафыннан күчереп

язылган гарәп телендәге китаплар турында бара. Аларны 1963 елда Н. Юзиев җитәкчелегендәге археографик экспедиция Куян авылында табып алган.

Гәрчә безгә билгеле чыганакларда искә алынмаса да, үз вакытында әлеге мәдрәсәдә булачак татар шагыйре һәм драматургы Кәрим Әмири (1893–1962) укыган. Ул соңыннан Мөхәммәтгата хәзрәтнең оныгы, кызыл комиссар (язмыш шаяруымы?) Әмин Касыйм улы Мансуров турында «Урал баласы» дигән китап та язган.

1939 елда Пермь Татар педагогия училищесен тәмамлаганнан соң, булачак шагыйрь һәм прозаик Әдип Маликов (1921–2009) юллама буенча шушы авылдагы җидееллык мәктәпкә укытырга килә. Дөрес, аңа анда озак эшләргә насыйп булмый, ул хакыйкый хәрби хезмәткә чакырыла. Әмма аның шул авылга карата булган тирән ихтирамы инде җырга әверелгән шигъри юлларында чагылыш тапкан. Безне анда каршы алган, гомере буе мәктәптә тарих фәне укыткан, туган төбәкне өйрәнүче Гөлҗиһан апа Мәсәгутова үзе гармунда уйнап, шул юлларны җырлап та күрсәтте:

*Тол елгасы – агым су, йөзе тулган ай,*
*Яшьлек хатирәсе калган синдә, Солтанай.*
*Аерды безне юллар, ярсулы еллар,*
*Очрашу көтеп талды сузылган куллар.*

Солтанай авылында үземнең юнәлешем буенча табышларым әллә ни булмаса да, шактый гына гыйбрәтле тарихи вакыйгалар турында ишеттем. Мөхәммәтгата Мансуров, аның әнисе Мәгъфүрә абыстай Габделгани кызы, хәзрәтнең улы Касыйм (?–1907) һәм Мөхәммәтмәгъсүм хаҗи (?–1909) каберләрен зиярәт кылдык, язулы ташларының фотосурәтләрен алдырдык.

Кеше вафатыннан соң җанның кош сурәтендә очып китүе турында күзаллаулар борынгы заманнарга барып тоташа. Ул фарси, төрки әдәбиятларда да бик күптәннән чагылыш тапкан. Аның үрнәген без әйтелгән кабер ташларының берсендә очраттык. Ул шулай:

*Тормас, бу форсат тиз күчәр,*
*Бу җан кошы бер көн кафәсдән очар.*

Электә авылда яки гаиләдә булган төрле мөһим вакыйгаларны китап читләренә язып кую гадәте булган. Без аны Түбәнавылда Айсылу Аптукаева тапшырган тәфсирдә дә очраттык. Хосусан, анда туучылар һәм вафат булучылар турында мәгълүмат теркәлгән.

Шулай итеп, Барда районыннан барлыгы 149 берәмлек материаллар һәм документлар туплап алып кайттык. Алар Үзәкнең кече фәнни хезмәткәре Салават Галимов белән берлектә тәртипкә китерелеп, сакланмага куелдылар.

Гомумән, ул яклар миндә соклану һәм тирән ихтирам хисләре барлыкка китерде. Анда яшәүче милләттәшләребез бернинди дә чит тел сүзләре кулланмыйлар икән, руслар да саф татарча сөйләшәләр. Менә кайда ул чын мәгънәсендә икетеллелек!

Экспедиция эшчәнлеген тәэмин итүдә уңай шартлар тудырган район хакимияте башлыгы Сергей Ибраевка, чын мәгънәсендә кураторыбыз булган Сәлим Назинга, авылларда безне озатып йөргән һәм даими рәвештә ярдәм күрсәткән җирле үзидарә башлыкларына, укытучыларга, китапханә, мәдәният хезмәткәрләренә, дин эшлеклеләренә, башка һөнәр кешеләренә һәм без эшләгән барлык авылларның халкына, экспедиция әгъзаларын юлда хәвеф-хәтәрсез йөртеп алып кайткан шоферыбыз Рөстәм Гыйльфановка олуг рәхмәтемне белдерәм.

# МУЗЫКАЛЬНЫЙ ФОЛЬКЛОР ТУЛВИНСКИХ ТАТАР ПЕРМСКОГО КРАЯ: ТРАДИЦИИ И СОВРЕМЕННОСТЬ

*Эльмира Галимова*

Традиционный музыкальный фольклор тулвинских татар, безусловно, является олицетворением некоторых устоявшихся точек зрения в области этногенеза пермских татар, подтверждая многокомпонентность их этнического состава, и вызывает огромный научный интерес. Материалом для данного исследования послужили музыкальные образцы, записанные в Бардымском районе Пермского края в ходе комплексной экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова в июле 2013 г. Всего было обследовано 12 деревень: д. Сараши, с. Елпачиха, д. Арама, д. Ишимово, д. Куземьярово, д. Краснояр, д. Тюндюк, с. Константиновка, с. Танып, д. Султанай, д. Искир, д. Сюзань.


В первую очередь, рассмотрим жанровую систему обрядового фольклора в историческом и современном аспекте. Систему обрядов тулвинских татар подразделим по установившейся в этномузыкологии систематизации на две группы:

1) обряды внесемейного функционирования: календарные, сезонные.

2) обряды семейного функционирования: родинные, свадебные, рекрутские, похоронные.

В описании обрядов исследователи реконструируют структуру народного календаря конца XIX и начала XX в. Поэтому в данном разделе попытаемся проанализировать традиционные обряды с точки зрения данных нашей экспедиции, а также выявить с «высоты XXI в.», какие атрибуты ритуала сохранились, а какие исчезли или трансформировались.

Особенностью календарно-обрядового фольклора пермских татар являются *сөрән җырлары.* На сегодняшний день мы можем отметить полное редуцирование данного напева у тулвинских татар. Обряд *бүләк җыю* с исполнением *сөрән җырлары* проводился за день до праздника Сабантуй. Участники обряда сбора подарков заходили во двор и исполняли песню с пожеланием благополучия. На сегодняшний день у тулвинских татар в комплекс обрядов сабантуя также входит и праздник *Җыен* (сбор, сходка), который проводится в рамках определенного округа, например: *Барда җыены, Сараш җыены.* По сведениям этнофоров, раньше перед сабантуем проводили обряд *Карга боткасы* (воронья или грачиная каша). Любопытно, что существовали разные значения данного ритуала: «вороньей кашей» называли сваренные в ведре яйца, собранные для сабантуя, а «грачиную кашу» (аналогично татарам-кряшенам) готовили в большом котле из собранных продуктов. Сопровождая криками «кар-кар», приготовленную кашу разбрасывали вокруг. В настоящее время у тулвинских татар из данного ритуала сохранился только фрагмент приготовления каши с исполнением игровых песен, например *«Иделләре, иделләре...»*[1]*:*




[1] Напев исполнила Галиева Сатира Шаймухаметовна, 1951 г.р. (д. Сюзянь, Бардымского района).

Основой некоторых игровых песен служат популярные напевы такмаков казанских татар, например *«Алсу алма ...»* исполняется на мелодию песни «Әннәгидер генәем».




Все эти перечисленные весенние обряды предвосхищали главный праздник – *Сабантуй,* который вплоть до конца XIX века проводили до сева. В дальнейшем сложилась традиция отмечать его и после сева. Р. Уразманова отмечает, что это явилось особенностью пермских татар. В последующем развитии *сабантуй*, по сведениям этнофоров, отмечался уже дважды: «Как сойдет снег, и после сева». В настоящее время пермские татары проводят его после завершения посевных работ до начала сенокоса (май–июнь). Во время праздника Сабантуй тулвинские татары исполняют песни в жанре *авыл көе («Барсам карыйм, кайтсам карыйм…»), салмак көй, такмак.*

Летом во время засухи пермские татары совершали обряд вызывания дождя *корбанлык, корбеннэк, корбан чалу*[1]*. В* одних регионах это обряд сопровождался поливанием друг друга водой с

[1] *Корбан* – жертва.


обязательным купанием в водоемах, в других – приносили в жертву животных, варили детям кашу – *яңгыр боткасы* (дождевая каша). В деревне Сараши Бардымского района[1] нами зафиксирован обряд *«Яңгыр теләү»* (вызывание дождя), который продолжает свою жизнь и в настоящее время. По сведениям этнофоров во время засухи жители деревни ходят на кладбище и, выбрав «свежую могилу», поливают её водой (ровно 40 ложек).

Активные контакты с русским населением послужили причиной проведения календарных праздников по примеру православных народов. Так, 12-го июля тулвинские татары отмечали праздник Петров день *(Питрау)*. Этот день сопровождался определёнными ритуалами: ранним утром собирали травы, а вечером проводили различные игрища. В ходе экспедиции нам удалось записать игровые напевы от этнофора Галиевой Сатиры Шаймухаметовны, 1951 г.р. (д. Сюзянь, Бардымский район), которые исполнялись во время празднования *Питрау: «Иделләре-күлләре...», «Биек тауның башларында ...»;*

*«Безнең авыл уртасында ... »:*




[1] Сведения от этнофора Масагутовой Мунибы Саетзяновны, 1941 г.р. (д. Сараши, Бардымский район).




Корпус обрядов семейного функционирования тулвинских татар является примером интересного сочетания языческих и мусульманских традиций, что отражается в культуре их бытования. Как уже отмечалось, именно языческий аспект, ярко представленный в обрядовой системе Пермского края, и порождает вопросы, связанные с историей этногенеза пермских татар. Отдельные этапы проведения семейно-бытовых ритуальных действий позволяют провести некоторые аналогии с культурой финно-угорских народов, в частности, в обрядах, связанных *со строительством дома*, *встречей и проводами гостей*, *рождением ребёнка*, *проводами рекрута*. Мусульманский компонент в обрядовой системе пермских татар отражается преимущественно в традиции проведения свадебного и похоронно-поминального комплекса. Подробнее всего рассмотрим *проводы солдата, свадебный и похоронно-поминальный комплекс,* так как именно в этих ритуалах музыка приобретает свою особую функциональную роль сопровождения.

Как уже отмечалось, к обрядам семейного функционирования относятся **проводы солдата** на военную службу (*рекорт, некорт, лекорт озату)*. В экспедиции нам удалось выявить от этнофоров как традиционные формы проведения данного обряда, так и особенности его современного бытования.

С целью обеспечения безопасности новобранца на службе и его возвращения тулвинские татары выполняли ряд ритуалов магического характера. Такую функцию оберега выполнял, например, обряд надкусывания рекрутом хлебного каравая перед отъездом на службу. Этот каравай мать хранила до его возвращения, приговаривая: «*Икмәгең өйдә көтә – кайт улым тизрәк өйгә»* (Твой хлеб дожидается дома – скорее возвращайся сынок)[1]. Любопытно, что аналогичный обряд был зафиксирован у нагайбаков ещё в XIX веке[2].

[1] Записано со слов Тубиловой Таслимы Галимзяновны, 1939 г.р. (д. Краснояр, Бардымский район).

[2] Бектеева Е.А. Нагайбаки: крещеные татары Оренбургской губернии // Живая старина. СПб., 1902. Вып. 2. С. 173.

Во время проводов рекрута у тулвинских татар было принято готовить блюдо из курицы в связи с символическим представлением об этой птице: «Тавык артка җилкенсә – солдат өенә кайтачак» (если курица тянется назад – солдат вернётся домой). Интересный обычай зафиксирован нами в д. Танып Бардымского района. В данной деревне на вершине горы растет дерево, на которое призывник перед уходом на службу обязательно должен был завязать платок, вышитый матерью. Существовали и другие оберегающие ритуалы, например перешагивание порога дома рекрутом только с правой ноги, определение результата службы по первому шагу лошади, махание при проводах платками не от себя, а к себе и т.д.

Однако, выполняя ритуалы, аналогичные ритуалам православных татар (кряшен), пермские татары не забывали, что они мусульмане. Так, у тулвинских татар существовал обычай перед отъездом рекрута читать суры Корана. Не меньший интерес представлял обряд разделения бумажного листочка с записью мусульманской молитвы на две части: одну отдавали рекруту, а вторую оставляли дома. Считалось, что это способствует возвращению солдата, так как текст молитвы в будущем непременно должен соединиться со своим смысловым продолжением[1].

В каждой этнотерриториальной группе пермских татар наблюдаются свои нюансы проведения и музыкального сопровождения данного обряда. Например, у тулвинских татар нами зафиксированы несколько образцов наигрышей на губной гармони или тальянке *«Барда көе»*[2], исполняемые во время застолья.





[1] Черных А.В. Народы Пермского края. История и этнография. Пермь: Пушка, 2007. С. 261.

[2] Записано от этнофора Зимасова Маулизяна Мухаматзяновича, 1940 г.р. (д. Ишимово Бардымский район).




Содержание песен проводов солдата охватывает широкий круг тем: тревожное ожидание службы, прощание с домом, описание дороги, по которой должен будет пройти солдат, воспоминания о родном крае. Поскольку поощрялись импровизации текста в испол-

нении самого призывника, то в них господствовали образы сугубо личного характера с содержанием обращений, вопросов к родным. В ходе полевых исследований в Бардымском районе, нам удалось зафиксировать рекрутские песни в жанре *авыл көе: «Без барасы юлларының ...»*[1], *«Барда җыены көе»; такмак: «Солдат озату җыры»* и т.д.




**Свадебный обряд** пермских татар интересовал многих исследователей в области этнографии, диалектологии (*Р.К. Уразманова, 1983, 1990, 2001; Д.Б. Рамазанова, 1997*), местных историков-краеведов (*Г.Н. Чагин, А.В. Черных, 2002, 2007; Бардымский..., 2009*). Материалы наших экспедиций раскрывают не только произошедшие за эти годы изменения этнографического характера, но и впервые обогащены аудиозваписями музыкального сопровождения.

По сведению этнофоров **свадебный обряд** тулвинских татар растягивался на продолжительный срок и состоял из нескольких этапов: *никах, зур туй* (проводился в доме невесты), *кода туй,* который проводился в доме жениха. Распространенной формой считался брак по сватовству – *киңәшеп итү, ярәшеп йөрү.* В этом случае молодой человек засылал сватов в дом невесты. В течение недели родственики и родители жениха приходили с различными подарками в дом невесты (*кызны җуату*). Затем родителей невесты приглашали в гости к жениху (*өй күрсәтү йоласы*). В этот же день определяли дату проведения религиозного обряда, который аналогично

[1] В исполнении этнофора Акбашевой Разифы Имамутдиновны, 1938 г.р. (д. Арама, Бардымский район).

чепецким татарам и кряшенам назывался *кәбен,* который в послевоенный период был заменен мусульманским термином *никах*. Родители молодых определяли размеры выкупа невесты – *мәхер* и обговаривали приданое невесты – *бирнә.* Наши экспедиционные материалы подтверждают сохранение данных традиций как важных элементов свадебной церемонии, которые являются обязательными, но уже перед регистрацией брака.

*Зур туй* включал в себя несколько интересных особенностей. Жених со своими друзьми запрягал лошадей, украшал их бубенчиками, разноцветными ленточками и ехал к невесте[1]. На следующем кортеже ехали родители, затем близкие родственники и друзья. Отца жениха называли уважительно *төп кода* (главный сват), а близких родственников жениха, которых представляла молодая пара, называли *аргыш кода* (второстепенный сват). В день проведения обряда *зур туй* жених оставался ночевать с невестой[2]. Для них сестра невесты или жена её брата (*кыз җинги*) готовила постель, на которую укладывали столько перин, сколько ночей проведет жених у невесты. Этот ритуал назывался *түшәккә сикертү, чемылдыкка сикереп керү.* Существовал обряд *чаршауга кертү* (пропуск за занавес к невесте). Вход в комнату невесты, перед которой вешали занавеску (*чаршау)*, охраняли две родственницы. Жених со своими друзьми *кияү егетләре*, чтобы встретиться со своей невестой, должен был сделать выкуп. После этого друзья жениха раскачивали его и бросали на занавеску *чаршау*[3].

Свадебный пир начинался после выхода молодых из-за занавеса. Раньше во время свадебного застолья существовал свой порядок подачи блюд. Аналогичная традиция существовала у чепецких татар и кряшен: суп и мясные блюда подавались только после чаепития с пирогами *(бәлеш)*. По данным нашей эксепедиции подача блюд сводится к более стандартному, принятому, в частности, у казанских татар: сначала гостям предлагают суп с лапшой, затем

---

[1] Необходимо отметить, что в настоящее время свадебный кортеж, запряженный лошадьми, вновь актуализируется в Пермском крае, вытесняя автомобильные средства.

[2] В настоящее время это возможно только после регистрации в ЗАГСе.

[3] Сейчас обряды *чемылдыкка сикереп керү* и *чаршауга кертү* потеряли свою актуальность и значимость.

мясные блюда, а особо торжественным моментом является угощение слоёным пирогом *гөлбәдия* (гөбәдия) и подача гуся. Во время застолья исполнялись песни в форме диалога между родителями жениха и невесты на напев «*Барда көе», «Авыл көе»* и любого такмака:

*Алай да бергә-бергә,*
*Болай да бергә-бергә.*
*Бергә булгач, бергә булыйк,*
*Аерылмаек бер дә*[1].

Необходимо отметить, что в современной трактовке три этапа многодневного свадебного обряда тулвинские татары проводят всего за два дня. Заметные изменения коснулись и песенного сопровождения свадебного обряда. Отметим, что в Бардымском районе многие песни, особенно старинный свадебный напев *Чемылдык җыры,* звучавшие в определённый момент свадебной драматургии, начисто исчезли. В настоящее время песни звучат только во время застолья и репертуар их ограничен наиболее популярными образцами песенного фольклора казанских татар. Довольно редко можно зафиксировать от этнофоров *свадебные песни* или *такмаки.* В ходе экспедиции всё же удалось записать несколько музыкальных образцов, сопровождающих свадебное торжество: «*Кодалар җыры... », «Кода-кодагыйлар җыры...»*[2]:




Наиболее заметно влияние мусульманской религии на **похоронно-поминальную обрядность** тулвинских татар. Некоторые

[1] Сведения Маматовой Мухимы Шакирзяновны, 1939 г.р. (д. Тюндюк, Бардымский район).

[2] Сведения Акбашевой Гульазимы Хатмиевны, 1942 г.р. (д. Танып, Бардымский район).

элементы данного обряда фактически повторяют традиции *казанских татар*. Похороны принято было проводить чаще всего на следующий день после смерти человека, но обязательно до обеденного намаза (*өйлә)* в его родном доме. Аналогично казанским татарам выполнялся обряд *мәет саклау төне* (ночной караул покойника). В настоящее время у татар Казани и Заказанья этот ритуал сопровождается только чтением сур из Корана. Исполнение специальных мунаджатов *(үлем мөнәҗәте* или *мәет мөнәҗәте)* начисто исчезло.

Основные этапы погребения покойного проходили также аналогично религиозно-обрядовым действиям казанских татар со всеми проведениями поминальных дней, на которых проводили *искә алу ашы,* т.е. поминальный обед с приглашением муллы. Сохранилась традиция поминовения предков, выполняемая каждую пятницу, когда принято было одаривать муллу, а также чтения молитв за упокоение душ всех усопших *(корбан ашы)* во время праздника жертвоприношения *Корбан бәйрәм.*

По результатам нашей экспедиции можно сделать определенные выводы о том, что некоторые обряды семейно-бытового характера (гостевой, свадебный, рождение ребенка, проводы рекрута, похоронно-поминальный комплекс) у тулвинских татар не теряют своей актуальности даже в начале XXI века, в то время как проведение ритуалов аграрного календаря почти исчезли и бытуют преимущественно в воспоминаниях этнофоров старшего поколения.

Наряду с жанрами обрядовых и необрядовых песен, характерных для угро-финского населения, у тулвинских татар мусульманского вероисповедания активно представлена традиция книжного интонирования в современном бытовании таких жанров, как *бәетләр* (баиты) и *мөнәҗәтләр* (мунаджаты).


Наиболее полное обоснование формированию и развитию мунаджатов даёт М. Бакиров[1]. Возникновение этого жанра он связывает с профессиональной поэзией различного содержания, особенно с суфийской. Мунаджаты, прославляющие Аллаха и Пророка Мухаммеда, по его мнению, возникли на основе суфийской поэзии и фольклорных традиций. Позднее вместе с суфизмом

[1] Бакиров М.Х. Мөнәҗәтләр // Мирас. 2003. № 11. С. 59–77.

этот жанр получил широкое распространение и у мусульман Волго-Камья.

Этномузыколог М. Нигмедзянов рассматривает мунаджаты как жанр музыкального эпоса, хотя и не исключает тяготение их к лирике[2]. Фольклорист М. Бакиров без сомнения относит мунаджаты к лирическому жанру, вобравшему в себя особенности как фольклора, так и профессиональной поэзии. Ради справедливости стоит сказать, что мунаджаты (особенно бытовые) по содержанию близки лирическим песням, ибо (в отличие от баитов) отражают не конкретную историческую или личную трагедию, а горестные чувства человека (тоска, обида, раскаяние, страдание и т.д.), его внутренний мир. Нельзя не учитывать и того факта, что напевы мунаджатов (равно как баитов и книжного интонирования) представляют собой законченные 4-строчные музыкальные построения, постоянно повторяющиеся. Это сближает их с песенной формой. Кроме того, именно мунаджаты как образцы ранней песенной лирики мусульман послужили основой формирования такого уникального музыкального жанра казанских татар, как *озын көй*[2].

В нашей работе, исходя из классификации З.Н. Сайдашевой[3], представлены религиозные мунаджаты только трёх видов, выполняющих функции: ***славления***, т.е. воспевающие Аллаха, мусульманскую религию, пророка Мухаммеда, святых; Например мунаджат *«И, мөселманы ...»[4]:*





---

[1] Нигмедзянов М.Н. Татарские народные песни. Казань: Татар. кн. изд-во., 1984. С. 12.


[2] Сайдашева З.Н. Песенная культура татар Волго-Камья: Эволюция жанрово-стилевых норм в контексте национальной истории. Казань: Матбугат йорты, 2002. С. 40.

[3] Сайдашева З.Н. Татарская музыкальная этнография. Казань: Татар. кн. изд-во., 2007. С.78.

[4] Напев исполнила Галиева Сатира Шаймухаметовна, 1951 г.р. (д. Сюзянь, Бардымский район).




***обращения к Аллаху*** с просьбой о помощи, милосердии, например, *«Раппем Аллам, диде Муса ...»*[1]:





***ритуальные,*** исполняемые во время религиозных обрядов и праздников, в частности «Маулид»а – праздника в честь рождения Пророка Мухаммеда, например: *«Мәүлид көненә җыйлыгыз...»*[2].




---

[1] Напев исполнила Галиева Сатира Шаймухаметовна, 1951 г.р. (д. Сюзянь, Бардымский район).

[4] Напев исполнила Галиева Сатира Шаймухаметовна, 1951 г.р. (д. Сюзянь, Бардымский район).




Главная находка наших экспедиций – это запись *мунаджатов*, интонируемых во время похоронного ритуала, ставшего уже редким явлением в быту мусульман. К данной группе мунаджатов можно отнести и произведения, размышляющие «о смерти и бесссмертии», в которых переплетаются религиозно-суфийское и мирское начало. Смерть здесь рассматривается как неизбежность и показывается в разных планах: в одних случаях – как долгожданное, радостное свидание с Богом; в других – как явление, приводящее к горькой утрате, огромной потере. Расставание с жизнью воспринимается как трагедия. Мунаджаты исполняются, как правило, родственниками или близкими усопшего (усопшей) во время ночного бдения в его доме. Во время экспедиции нам удалось зафиксировать несколько образцов, называемых этнофорами *«Үлем мөнәҗәте»,* и некоторые образцы *«Салават әйтү».* Поэтому их нотные образцы, представленные в работе впервые, являются по-существу, находкой.

Что касается мунаджата *«Салават әйтү»*, то существует определённая специфика исполнения в Бардымском районе Пермского края. Как правило, родственники, провожая покойного в последний путь, выстраиваются в два ряда около двери дома или ворот и исполняют данный религиозный напев три раза[1]:

---

[1] Сведения предоставила и исполнила мунаджат Кучукбаева Зельфира Зуфаровна, 1951 г.р. (с. Барда, Бардымский район).




Значительно уменьшился удельный вес в быту жанра *бәет (*баит*),* который являлся в свое время самобытным и национальным достоянием музыкально-поэтического творчества татар-мусульман. Этот жанр еще с середины XIX в. неоднократно привлекал внимание многих учёных. Татарская фольклористика насчитывает большое количество работ в области собирания, публикации и изучения этого жанра.

Термин *бәет* арабского происхождения и обозначает двухстрочную строфу. По мнению фольклориста Ф.И. Урманчеева, этот термин вошел в тюркскую поэзию не позднее X–XI вв. Со временем значение его расширилось, так как он стал обозначать уже законченное стихотворное произведение и жанр татарского народного творчества[1]. Если ранее исследователь рассматривал *бәет* как жанр героического эпоса[2], то позднее он стал считать баиты как эпические, лиро-эпические, иногда лирические стихотворно-поэтические произведения, рассказывающие о крупных исторических событиях, социально-бытовых фактах прошлого, которые исполнялись на определенные мелодии и занимают важное место в жанровом составе национального фольклора[3]. Исследователь предлагает следующую жанрово-тематическую классификацию баитов:

1) исторические, в состав которых входят:

а) военно-исторические и б) социально-исторические;

---

[1] Урманчеев Ф.И. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. Казань: Татар. кн. изд., 2002. С. 4.


[2] Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд., 1984. С. 9.

[3] Урманчеев Ф.И. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. С. 21.

2) бытовые, также включающие две группы:

а) социально-бытовые и б) семейно-бытовые.

В настоящее время в Пермском крае в целом традиция интонирования произведений в этом жанре, к сожалению, угасла. Однако современное бытование этого жанра продолжается в письменной традиции. В экспедиции нам удалось зафиксировать баиты преимущественно на социально-бытовые и семейно-бытовые темы: *«Диләрә бәете», «Тәзкирә бәете»*[1]. Отметим, что интонирование баитов этнофором представлена очень однообразно, в виде варьирования одного напева. В ходе полевых исследований нам удалось зафиксировать баит *«Рәшит бәете...»*, посвящённый фольклористу Р. Ягъфарову, родом из д. Константиновка Бардымского района:




Композиционная структура текста состоит из зачина, основного повествования и концовки. Как правило, зачин представляет собой начальную фразу из мусульманской молитвы: *Бисмилләһи рахмани рахим...* . После зачина следует повествование от первого лица, т.е. от лица погибшего или безвременно умершего. Функция заключительной части композиции жанра баита более разнообразна: в одних – герой прощается с родными, в других – от имени автора говорится об истории создания баита или излагаются пожелания спокойного сна погибшему.


***Песенная лирика*** тулвинских татар представлена преимущественно жанрами *авыл көе* (*урам көе)* и *салмак көй.* В народном

---

[1] Все баиты нам исполнила Расулева Язиля Искандеровна, 1945 г.р. (д. Елпачиха, Бардымский район).

понимании *авыл көе* – это не столько определённый стилистический тип, сколько маркировка места бытования напева. Это термин, по мнению этномузыколога Э.Р. Каюмовой, который очерчивает основной ареал распространения мелодии[1]. Например, в Бардымском районе Пермского края самый популярный напев в жанре *авыл көе* – это разные варианты «*Барда көе»* в исполнении этнофоров как в вокальной, так и инструментальной форме. В ходе экспедиции нам также удалось зафиксировать несколько жанров лирического склада *салмак көй: «Синдер ул, дип уйладым»*[2]*, «Яшьлек җыры», «Хушлашу җыры»*[3].

Синдер ул дип, уйладым




Что касается жанра *салмак көй,* то по сравнению с жанром *авыл көе* он не получил у тулвинских татар столь активного распространения, как у казанских татар. Причина этого явления, по всей вероятности, кроется в преобладании в быту обрядовой культуры. Нам удалось зафиксировать лишь отдельные переинтонированные популярные песни казанских татар *(«Гөлмәрфуга», «Рамай», «Шахта көе», «Сарман көе»).* Отметим, что в отличие от аналогичного

---

[1] Каюмова Э.Р. Татарская народно-песенная культура Нового времени: проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции. Казань, 2005. С. 20.

[2] Напев исполнила Мансурова Зөлхәбирә Лотфурахмановна, 1956 г.р. (д. Куземьярово, Бардымский район).

[3] Напевы исполнила Тубилова Таслима Галимзяновна, 1939 г.р. (д. Краснояр, Бардымский район).

музыкалмузыкального жанра казанских татар, бытующего с закрепленными текстами, этнофоры репрезентируют только напевы этих песен, используя их с текстами самого разного содержания, но с сохранением названий. Основная тематика песен лирического жанра связана с содержанием, в котором выражены философские размышления человека о прожитых молодых годах, быстротечности жизни, предначертания будущего.

Сюда же можно отнести песни самодеятельных авторов – *«Бер кош туган якка кайтып...», «Өй артында үсә пар юкә...», «Сызылып зәңгәр таң атты...»*[1].

Бер кош туган якка кайтып...




В музыкальной культуре тулвинских татар наряду с песенным фольклором представлена также инструментальная музыка, но в довольно скромном бытовании. Во время полевых исследований нам удалось зафиксировать наигрыши на следующих инструментах: *гармонь, скрипка, кубыз*, *курай, мандолина,* которые по существу определили характерные особенности сложившихся традиций как исполнительского стиля, так и жанрового контекста.

Из всех инструментов наибольшей популярностью в быту населения данного края пользуется *гармонь (гармоника)* – пневмати-

---

[1] Этнофоры не могут дать координаты об авторах песен. Данные образцы бытуют как народные песни, являясь примерами фольклоризма.

ческий двухклавиатурный инструмент ручного типа, источником звучания в котором является проскакивающий язычок[1]. По мнению этноорганолога И.В. Мациевского, именно этот инструмент стал «символом европейских интеграционных процессов в культуре, знамением своего времени»[2].

В сельской местности тулвинских татар из многочисленных разновидностей гармоник наибольшее распространение получили *саратовская, вятская гармонь, тальянка* и *хромка.*

У исследуемой подгруппы татар Пермского края перечисленные разновидности гармоник использовались как в качестве сольного инструмента, так и аккомпанемента вокальной мелодии. Однако фактура в этих видах исполнения почти ничем не отличается. Гармонист обычно не дублирует вокальную мелодию при сопровождении, а стремится насыщать её вариациями.

Но полное воплощение своей бурной фантазии в ритмическом и интонационном плане гармонист демонстрирует преимущественно в плясовых инструментальных наигрышах *(бию көе).* Поэтому в партии левой руки чередование по принципу «бас-аккорд» является весьма важным для возбуждения многообразных двигательных импульсов, сферы моторики в целом, играющей значительную роль в передаче настроений и образов народной музыки. Жанровый состав наигрышей на гармонике не большой, так как данный инструмент использовался для аккомпанемента деревенских напевов *(авыл көе)*, такмаков *(такмак)*, скорых напевов *(кыска көй)* и плясок *(бию көе)*[3]. Во время полевых исследований в Бардымском районе нами были записаны наигрыши на *вятской и саратовской гармони, хромке, тальянке* вышеперечисленных жанров*: «Бию көе*», *«Үлмәс җыр*», *«Барда көе*», *«Ишим көе»*, *«Ишимово бию көе»*, *«Әртил көе», «Авыл көе».*

---


[1] Гайсин Г.А. Гармоника в русской народной музыкальной культуре XIX века // Ярославский педагогический вестник. 2012. № 3, том I (Гуманитарные науки). С. 219.

[2] Мациевский И.В. Гармоника в системе традиционной музыкальной культуры // Гармоника: история, теория, практика. Майкоп, 2000. С. 15.

[3] Нигмедзянов М.Н. Татарская народная музыка. Казань: Магариф, 2003. С. 94. М.Н. Нигмедзянов объясняет это использованием лишь одного звкукоряда («кряшенского», по Сайдашевой) и ограниченной аккордикой левой руки.

В исполнении на гармонике местными музыкантами можно выделить две стилистические сферы. Одна из них представлена наигрышами в указанных жанрах, которые по музыкально-стилевым особенностям, благодаря использованию в финалисе нисходящей типовой ангемитонной попевке и троекратному закреплению тоникального звука, близки народной исполнительской традиции казанских татар. В этом плане представляет интерес наигрыш на тальянке гостевого напева «*Әртил көе*», в основе которой мелодия народной песни казанских татар «*Уйнат әле, дустым, гармуныңны...*»[2].

Әртил көе




Данный пример интересен своей гармонизацией, выраженной необычным способом: на сильную долю берётся аккорд, а на слабую – бас. В функциональном отношении возникает гармоническая синкопа. Данная манера игры на гармонике и необычный ритмический способ аккордового сопровождения являются особенностью инструментальной традиции пермских татар, так как в практи-

---

[1] Наигрыш исполнил Булатов Ахнаф Мидхатович, 1949 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).

ке игры на гармонике у казанских тата) принято наоборот: бас – играть на сильную долю, а аккорд – на слабую:

М. Нигмедзянов. Сб. «Тат. нар. песни». 1970. № 219



Следующую группу составляют плясовые наигрыши «*Бию көе*»[1], в которых ярко проявляются стилистические особенности музыкальной традиции удмуртов, прежде всего, это выражается в ладовой (диатоника в объеме квинты) и ритмической организации (переменная акцентность сильной и слабой доли):

Бию көе



а также в использовании ритмической асинхронности мелодической линии и аккордового аккомпанемента, например[2]:

---

[1] Наигрыш исполнил Булатов Ахнаф Мидхатович, 1949 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).

[2] Записано от Булатова Ахнафа Мидхатовича, 1949 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).

Барда көе



Для инструментальной культуры пермских татар характерен определенный тип исполнительства, основанный на вариантном изменении устойчивой мелодической попевки. Примером может служить плясовой наигрыш «*Бию көе*»[1]:

Бию көе




В следующем варианте наигрыша исполнитель переходит на трехдольный размер с изложением мелодии на фоне протяженного звука с неожиданным выделением акцента на последней восьмой доле:




В третьем проведении этнофор использует в мелодической линии ритмическое клише ямбического типа:

---

[1] Записано от Булатова Ахнафа Мидхатовича, 1949 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).




В последнем проведении *бию көе* происходит смещение сильной доли за счет объединения двух восьмых.




Для народной традиции игры на гармонике у пермских татар характерно использование форшлагов в объеме октавы, квинты, кварты, терции с акцентированием слабых долей (особенно последней доли), что создает ощущение ритмической асинхронности, например[1]:




[1] Наигрыш исполнил Зимасов Маулизян Мухаметзянович, 1940 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).

Материалы полевых исследований музыкальной культуры данного края позволили выделить любопытную особенность исполнительства, относящуюся к технике игры на гармонике, когда при помощи всего лишь тремолирования одного аккорда (за счёт сжима и разжима меха) с акцентированием сильной или слабой доли возникает короткая попевка, являющаяся основной темой плясового наигыша. Далее музыкальное развитие этой попевки, зависимая от индивидуальной фантазии гармониста, образует как бы бесконечную вариационную форму, например «*Бию көе*»[1] (одна из вариаций).




Стоит отметить, что вариантное мышление пермских гармонистов при исполнительской реализации напевов традиционных жанров музыкального фольклора отличается удивительной самобытностью, и методы его претворения требуют специального исследования со стороны профессиональных инструменталистов.

Во многих письменных памятниках отмечается широкое бытование у татар струнных инструментов, как щипковых (*думбыра*), так и смычковых (*кыл кубыз*). На рубеже XVIII и XIX вв. *кыл кубыз* был вытеснен европейской скрипкой. С названием *әскрипкә* этот инструмент впервые упоминается в сочинениях писателя Тазетдина Ялчыгола аль-Булгари (1768–1838). Он пишет, что «у него имеются четыре жильные или шелковые струны. Они издают певучий звук,

---

[1] Наигрыш исполнил Зимасов Маулизян Мухаметзянович, 1940 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).


когда по ним водят древком, на которое натянут пучок конского волоса»[1]. Если у казанских татар этот инструмент закрепился с русским названием *(әскрипкә),* то у православных татар (преимущественно у нагайбаков) за новым инструментом сохранилось древнее название *кубыз*[2].

В настоящее время в быту казанских татар начисто исчезли народные исполнители на этом инструменте. Поэтому встреча с единственным исполнителем на скрипке – Идеалом Закировым (1931 г.р., д. Константиновка Бардымского района) – явилась для нас полной неожиданностью. Репертуар этнофора состоял в основном из плясовых наигрышей (*бию көе),* который он исполнил в разных вариантах, например:

Бию көе




Второй вариант «Бию көе»




[1] Монасыпов Ш.Х. Истоки формирования татарской смычковой культуры // Музыкальная культура народов Поволжья: сб. науч. трудов. Казань, 1978. С. 47.


[2] Там же. С. 94.




Примечательно, что в народной манере игры на скрипке, безусловно, ощущается родство с исполнительской фабулой игры на гармонике. Прежде всего, это выражено в использование бурдона на открытой струне скрипки в виде ритмической пульсации, способствующей сдерживанию быстрого темпа плясового наигрыша. Кроме того, в манере исполнения этнофоров очень чётко выявляется ритмическая синкопа за счёт акцента на первую и последнюю долю. Тем самым одна и та же короткая попевка обретает разный ритмический рисунок в мелодии и на слух наигрыш звучит довольно необычно. Данную манеру народной игры можно определить как этническую особенность инструментальной традиции пермских татар.


В процессе полевых исследований в Бардымском районе нам удалось познакомиться с несколькими образцами *кубыза* (ручной работы) в строе «ре», «фа», «ля». В основном мы зафиксировали плясовые наигрыши (*«Ирләр бию көе», «Кызлар бию көе»*) и деревенские напевы (*авыл көе*)[1]. В процессе игры на *кубызе* этнофоры стремятся выделить основную тему наигрыша, а потом обогатить её вариантными изложениями с помощью акцентирования ритмического рисунка.

Авыл көе




---

[1] Наигрыш на кубызе исполнил Мустаев Мусабих Галиевич, 1945 г.р. (д. Ишимово, Бардымский район).



Репертуар исполнения на *курае*, записанный в экспедиции, к сожалению, представлен довольно бедно и ограничен несколькими популярными народными песнями и наигрышами казанских татар. Один из таких примеров – популярная народная песня казанских татар *«Уракчы кыз»*:




Любопытно, что этнофор (Максеев Фаиз Хамитович, 1960 г.р., д. Тюндюк, Бардымский район) данную лирическую песню *(салмак көй)* переосмыслил в жанр *«кыска көй»* с использованием синкоп и порой маркированием некоторых звуков.

Наряду с этим нам удалось зафиксировать довольно интересный с точки зрения мелодико-стилевых особенностей напев в исполнении на курае *«Тол буйлары»*. Ни на одном из других перечисленных инструментов, не говоря о вокальном исполнении, не проявляется такая возможность передачи богатства мелодического орнамента, разных видов мелизматики, как на *курае*. К традиционным методам исполнения можно отнести густоорнаментированный подход к протяжным устоям, которые завершают мелодические построения.

«Тол буйлары»




Этнофор данный напев представляет в агогической манере изложения с использованием большого количества фермат, трактуя широкое дыхание и ритмическую свободу мотива. Начальные два такта исполнитель повторяет два раза, как бы выделяя основное тематическое зерно.

В ходе полевых исследований мы также познакомились с разными видами *мандолины,* бережно хранящиеся в коллекции некоторых этнофоров. К сожалению попытки исполнения на этом инструменте ограничивались лишь едва узнаваемыми фразами напевов известных народных песен казанских татар. Однако радует сам факт сохранения и почитания данного инструмента как образца антиквариата, некогда (особенно в начале XX века) довольно популярного инструмента городских (казанских) татар.

Такова общая картина современного бытования инструментальной музыки исследуемой подгруппы татар Пермского края, в которой (аналогично песенной культуре) проявляются музыкально-стилистические особенности как *тюркской*, так и *финно-угорской* народной традиции. Однако специфические этнотерриториальные

черты традиционного музыкального фольклора тулвинских татар в инструментальной культуре представлены ярче.

Научные работы по изучению пермских татар в целом и тулвинских татар Бардымского района в частности выполнены на уровне историков, лингвистов, этнографов без участия этномузыкологов. Отметим, что в исследовании культуры каждого народа немалую роль играет и музыкальный фольклор, благодаря наличию «фонда музыкальных формул и исполнительских клише»[1]. Поэтому мы надеемся, что полевые и научно-теоретические исследования традиционной музыкальной культуры тулвинских татар, впервые представленные в данной работе, также послужат подтверждением устоявшихся точек зрений в области истории, этногенеза и этнокультуры данной территориальной подгруппы.

---

[1] Земцовский И.И. Музыка и этногенез: исследовательские предпосылки, задачи, пути // Советская этнография. М.: Наука, 1988. № 2. С. 16.

## Авторлар турында кыскача белешмә

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Галимова Эльмира Мөнир кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Фирдәвес Гариф кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге мөдире.

*Исламов Рәмил Фәнәви улы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

# ЭЧТӘЛЕК

СҮЗ БАШЫ
5

ТАШЛАРНЫҢ ДА ТАМЫРЫ БАР
*Марсель Әхмәтҗанов*
9

ДРЕВНИЕ КОРНИ БАРДЫМЦЕВ
*Мирфатых Закиев*
49

БАРДА ЯГЫ – БАРЛЫ ЯК
*Фирдәвес Гарипова*
59

ТОЛ БУЕНДАГЫ ТЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ
Барда төбәге татарлары сөйләше
*Дария Рамазанова*
67

АШЛЫ-СУЛЫ КИЛЕН БУЛСЫН
Барда төбәгендә халык традицияләре
*Флера Баязитова*
231

БАРДАЛАРГА БАРДЫК ӘЛЕ...
*Рәмил Исламов*
255

МУЗЫКАЛЬНЫЙ ФОЛЬКЛОР
ТУЛВИНСКИХ ТАТАР ПЕРМСКОГО КРАЯ:
традиции и современность
*Эльмира Галимова*
297

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Десятая книга

**Национально-культурное наследие**
**ТАТАРЫ ПЕРМСКОГО КРАЯ. БАРДА**

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Унынчы китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**ПЕРМЬ ТАТАРЛАРЫ. БАРДА**

Редакторлар *Я.М. Абдулкадыйрова, Л.Ш. Давлетшина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

Басарга кул куелды 09.01.2017
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 13,3. Шартлы басма табагы 19.
Тиражы 500 д. Заказ